# казан утлары

8

АВГУСТ-1971

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**8**

АВГУСТ
1971

## Бу санда:

ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ, ПЬЕСА, ШИГЫРЬЛӘР

**Б. КАМАЛОВ.** Ялыкмаслар. Повесть . . . . . 3
**ЗӨЛФӘТ.** Хәрәкәттә йөрәк. Авыр... Кичер. Күпердә. Фатыйма. Юралмаган төш. Тынлык. Көлү-елау. Кайтмый калган. Сүз. Шигырьләр 34
**М. НОГМАН.** Умырзая. Киек казлар китә. Төн патшасы. Шигырьләр . . . . . . . . . 41
**В. НУРУЛЛИН.** Ул яшәргә тиеш иде. Хикәя . . 43
**Ф. ШӘФИГУЛЛИН.** Яшьлек. Таныш түгел этнә. Кою цехында. Оныттым сине. Каеннар. Исеңдәме... Шигырьләр . . . . . . . . . . . 56
**Р. МИНГАЛИМОВ.** Көзге төндә. Сәбәп. Ул шулайдыр әле.... Төзәтеп тә булмый... Карчык. Күптән болай... Юл бирегез. Көз. Ташлар. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 58
**Х. ВАХИТ.** Күк капусы ачылса. Комедия . . . 62
**К. МОСТАФИН.** Алиһәләр. Бала чактан бирле... Йөз дә беренче хикмәт. Поши. Җыр турында баллада. Тормыш — лоторея, дигән... Шәфәкъ... Син оныткан ап-ак яулык... Шигырьләр 87

ИБРАҺИМ САЛАХОВКА 60 ЯШЬ

**С. РАФИКОВ.** Үрләргә кыю атлый . . . . . 90
**И. САЛАХОВ.** Карлыгач. Чын хикәя . . . . . 91

ӘДИП МАЛИКОВКА 50 ЯШЬ

**Р. ТӨХФӘТУЛЛИН.** Кояшны юлларда каршылап... 106
**Ә. МАЛИКОВ.** Куриль чәчәкләре . . . . . . . 113

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

**А. МАЛОВ.** Тәвәккәллек. Очерк . . . . . . . 126
**В. ГУДКОВА.** Эзләнү азимуты. Очерк . . . . 135

БИШЬЕЛЛЫК СӘХИФӘЛӘРЕ

**К. ЗАРИПОВ.** Юллар чатында . . . . . . . . 141

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

А. ХӘСӘНОВА. «Азат хатын» журналы чыга башлауга 45 ел . . . . . . . . . . . . . 146

ТӨРЛЕСЕННӘН

М. ЮСУПОВ. Сүриядә очрашулар . . . . . . 153

ӘДӘБИЯТ ФӘНЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Э. НИГЪМӘТУЛЛИН. Тәҗрибә һәм белем алмашып . . . . . . . . . . . . . . . 162

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ш. ӘХМӘДУЛЛИН. Уйланырга кирәк . . . . . 170

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Ф. МОСТАФИН. Муса Җәлил — татарча балалар журналларын оештыручы . . . . . . . . 174

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

Г. МӨХӘММӘТШИН. Ике әби бәрәңге ала... Хикәя 177
Полякча кинаяләр . . . . . . . . . . . . . 184

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . 187

Редакциягә килгән
кульязмалар
кире кайтарылмый

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казан, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: Зәки Нури.
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.

---

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сулейманова, К. Корбангалиева.*

---

Производствога бирелде 4/IV-1971 ел. Басарга кул куелды 1/VII-1971 ел. ПФ 09058. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 79346 экз. Заказ И-299. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1971 ел.

Барлас Камалов

# ЯЛЫКМАСЛАР[1]

ПОВЕСТЬ

## 1



Әнисе Азатны тудыргач ук ташлап киткән. Яшүсмер егетнең бүгенгә кадәр булган тормышындагы бөтен бормалар шул хәлнең дәвамы. Башта ул нәни үксезләр йортында тәрбияләнде, аннары мәктәпкәчә яшьтәге балалар интернатында торды. Соңгы ун елы Чиләбедәге мәктәп-интернатта үтте.

Ике канатсыз ятим кеше сабый чакта ата-ана назына күпме генә сусамасын, гомерендә бер тапкыр да ашамаган ризыкның тәмен белмәгән шикелле, газиз әткә-әнкәнең җан җылысын тәгаен чамалый алмый иде. Ата-ана һәм баланың үзара якынлыгын аңлау ягыннан сукыр килеш туган ул җан иясе көн яктысын күз алдына китерә алмаган кебегрәк хәлдә үсә. Тумыштан сукырга салават күперенең гүзәл төсләре дә, чәчәкләр яме дә, урман-суларның матурлыгы да юк ич. Әмма еллар үтү белән баладагы хисләр үзгәрә; тойгылар бүтән төсмер ала, тирәнәя, җитдиләнә бара. Ул үзенә гомер биргән ата-ана хакында торган саен ныграк уйлана. Билгесезлек томанын таратасы килә аның. Нәсел-ыруын ачыкларга омтылуы тыелгысыз бер көчкә әйләнә.

Азат Ишбулдин да, бик озак уйланудан, күңелендә кат-кат үлчәп караудан соң, аттестат алуга багышлап үткәреләчәк чыгарылыш кичәсе алдыннан мәктәп-интернат директорыннан әти-әнисен яки туганнарын эзләшүдә булышуын үтенде. «Ком чүлендә адашкан кош кебек япаялгызым гына түгелдер мин. Ярдәм итегез, киңәш бирегез»,— диде ул.

Аның куанычынамы, әллә хәсрәтенә каршымы, директор бу эшне җиңел һәм тиз ачыклады. Мәктәп-интернатта тәрбияләнүчеләрнең дирекция сейфындагы делоларында шактый тулы мәгълүмат бар иде.

— Инде мөстәкыйль кеше син, Ишбулдин. Паспортың да, аттестатың да кулыңда. Урта белем алдың. Зур тормышка аяк басасың. Синең белән олыларча сөйләшергә мөмкин,— диде директор.— Әтиең хакында бездә бер мәгълүмат та юк. Әниеңнең адресы бар. Ул Татарстанда, Аккүл дигән район үзәгендә. Роза Люксембург урамы, йорт номеры...

— Алайса, мин аны барып күрә алам?

---

[1] Әсәр кыскартып басыла.

Ишбулдин. Анын семьясы, балалары бардыр. Хәер, син уйламыйча эшләүче егет түгел...

Чыгарылыш кичәсе булган көннең иртәгесен үк Азат төзелеш бригадасына эшкә урнашты. Таза гәүдәле, нык беләкле, шыншый белми торган бу егетне төзүчеләр бик тиз үз иттеләр. Ай ярым дигәндә, ул хәйран гына акча эшли алды. Һәм менә инде Азат Аккүлдә. Килеп төшүгә энисен эзләп барырга ашыкмады ул. Беренчедән, карангыланды инде, өйләрдә ут алдылар. Икенчедән, орды-бәрде генә барып керүнең азагы ни белән очланасын кем белә? Шунлыктан Азат гостиницага урнашуны иң кулай дип санады. Ләкин анда борын төртү мөмкин түгел иде.

— Бер генә урын да юк, егеткәем,— диде кунак йортында дежурлык итүче хатын.— Берәрсенә фатирга гына кермәсәң... Иртәгә булып куймасмы, сугылып карарсың...

Болай юатудан гына егетнең хәле яхшырмады, әлбәттә. Ул гостиницаның парадный ишеге буена чыкты да, чемодан өстенә утырып, тирәюньне күзәтә башлады. Шул чакта аңа олы яшьтәге бер агай эндәште. Русча сөйләшсә дә, аның татар икәнлеге сизелеп, әллә каян кычкырып тора иде. Азатның үзенең дә татарчасы барлы-юклы булганга, сүз ничек башланган булса, шулай дәвам итте.

— Урын юк диләрме, улым, ә? — Бу кешене Азат администратор тәрәзәсе буенда торганда искәргән иде.— Урак өсте, улым, урак өсте! Шәһәрдән булышырга килүчеләр күп. Тирә-як районнардан да халык өзелеп тормый. Тимер юл тарта үзләрен... Товары кайта, төзү материалы, ашламасы...

— Шулайрак икән шул...— Турысын гына әйткәндә, юлаучы егетнең кунак өендә халык күплеге турында җәелеп сөйләшер нияте юк иде. Бары тик абзый кеше:

— Булмаса, әйдә үзебезгә! Без карчык белән икәү генә. Сыярбыз,— дигәч кенә, Азатның йөзе ачылып китте.

— Чыннан да, абзый! Бер генә кичкә, ярыймы? Мин сезне бер дә кысрыкламам,— диде ул һәм житез генә сикереп торды да чемоданын кулына алды.— Иртәгә урын булыр дигән төслерәк әйттеләр...

— Анда күз күрер. Җае чыкмаса, икене дә кунарсың, өчне дә. Кешедән тарсынмыйбыз без. Бу дөньяда төрлесен татыдык инде. Әйдүк!

Алар үзәк урамнарның берсе буйлап киттеләр. Китап кибетен уздылар, аның каршында утларын балкытып ресторан калды. Халык суды бинасы янышнан үттеләр. Аннары Азат шәһәр паркы каршындагы икмәк заводына игътибар итте. Арырак, уң кулда, ул Дәүләт банкы һәм район элемтә конторасын күрде.

— Кай яклардан килешең, улым? — Мостафа абзый шулай сорап куйды.

— Уралдан, абзый.

— Озаккамы? Төзелешкә киләмсең әллә?

Азат жиңел сулады. «Әйе!» дип кенә җавап бирәчәк. Һәммәсен ничек итеп сөйлисең?! Шуңа күрә абзыйдан «төзелеш» сүзе чыгуга, ул:

— Әйе шул, төзелештә эшләп карыйсы иде,— дип җавап кайтарды.

— Синдәй егетләрне дүрт куллап алалар анда.— Абзый бара-барышка Азатны башыннан аягына кадәр тагын бер кат күздән кичерде.— Күп төзиләр бит. Көшчылык фабрикасы бик зур булачак. Шундый дәү фабрика Мәскәү янында гына бар ди бугай. Тугрыбай урманында колхозлар уртактан санаторий салдыра. Аккүлдә культура үзәге кора башладылар. Кино залы, сәхнәле зал, спорт залы, шахмат клубын бергә итеп төзиселәр икән... Сорамый да торам, ни атлы син, улым?

— Азат.

— Бәрәкәт! Татар малаемыни син?

— Әйе шул. Татарча белүем генә чамалырак...

— Аның каравы, русчаны шәп беләсеңдер, русча укыгансың. Мин, улым, Мостафа абзаң булам. Мәктәптә хуҗалык командиры. Завхоз дигәнем... Мәктәп безнең Муса Җәлил исемендә. Аны ишеткәнең бардыр бит? Геройны?..

— Аны белмәгән кеше бармы икән соң, Мостафа абзый? Моабитта язган шигырьләрен яттан сөйли алам мин аның...

— Молодец икәнсең, кем, Алмаз, әй генә лә... Азат!

Мостафа абзый Азатны өенә алып кайтты.

— Кунак белән бергә кайттык, карчык. Гаиб кунак, көтмәгәндә килеп очраган кунак. Урал егете. Төзелешкә килгән. Самоварыңны җырлат, сыеңны куй...

Абзыйның хатыны Әкълимә түти, онытын сагынып көткән әбисе шикелле, Азатны ачык йөз, тәмле тел белән каршылады. Үзе, тыз-быз йөреп, чәй хәзерләде, үзе, гадәтенә кереп киткән утә бер төпченү һәм кызыксыну белән, кунакның хәлен сораштыра торды: бик арымаганмы, юлда артык өшәнмәгәнме, кайдан, нинди гаиләдән, әти-әниләре бармы, исән-саулармы?

Азат та җавапка саранланмады, тик, әлеге дә баягы, ата-анасы хакында сүз чыккач, бер сүз белән генә: «Исәннәр. Эшлиләр»,— дип, котылу ягын карады.

Ул, әйтсәң-әйтмәсәң дә, шактый йончыган һәм алҗыган иде. Ашап-эчкәч, тәмам авыраеп китте, йокы басты. Үзе кыюлыгы җитеп урын җәюне сорый алмас иде, Мостафа абзый аның кәефен бик тиз чамалап алды һәм:

— Әйбәтләп урын сал, карчык, кунак ятсын, ял итсен,— диде.

Әкълимә түти түр яктан юка такта белән бүлеп куйган бүлмәгә урын җәйде.

— Ят җирдә күргән төш рас килә, диләр, гөлем. Тәмле төшләр күреп йокла әле бер,— дип, кунакны бүлмәгә кертеп җибәрде.

Азат, башы мендәргә тиюгә, изрәп йоклап китәр төсле иде. Һич алай булмады. Әнисен барып табуын, аның белән күрешеп сөйләшүне уена китерүгә, йокысы өреп очыргандай юкка чыкты. Күзләрен зур ачкан килеш, түшәмгә карап ятты ул.

Олы якта карт белән карчык һаман кыштыр-кыштыр йөрделәр, чышын-пышын сөйләштеләр. Шулай да Азатка аларның барлык сүзе ишетелеп торды. Мостафа абзый яңа уку елына кадәр ремонтлап бетерәсе парталар, мәктәпнең тулай торагына чыгарасы мич, атка кышлык печән һәм тәҗрибә участогы өчен кайтарасы минераль ашлама турында сөйләде. Карчыгы исә, аның сүз арасына кыстырып, шушы араларда гына кемнәрнеңдер өйләнешүләрен, бик зур туй итүләрен, мәҗлестә кыз һәм егет ягыннан нинди бүләкләр салынуын, тагын әллә ничә төрле имеш-мимешен тезәргә өлгерде.

Шул чакта ишек шакыдылар.

— Керергә ярыйдыр бит? — Моны тонығрак тавышлы бер хатын-кыз сорады. Үзе исә, рөхсәт тә көтеп тормастан, бик тиз бусаганың бу ягына үткән шикелле булды.

— Әйдә, әйдә! Ишек уйган, тәрәзә куйган. Төнгә авышканда килдең, чәй суынган. Яманлап йөрисең дип әйтимме? — Мостафа абзый аны үз итеп шулай сөйләнде. Әкълимә түти:

— Әйдә, гөлем, әйдә, уз! Самоварны тагын яңартабыз аны! Яманлавы, мактавы шунда булыр, әйеме? — дип сүзгә кушылып китте.

— Яманларга вакытны шайтан ялмаган әле монда, Мостафа абзыкай гынам! — диде тонык тавышлы хатын-кыз.— Җиләк-җимеш өлгергәч, безнең комбинатта мәхшәр көне башлана бит! Тәүлегенә егерме дүрт сәгать эшләсәң дә артмас... Әле эштән кайтышым. Әхтәм Казанда. Базасына дару-чиру кайтартырга йөри. Тукта әле дим, кереп чыгыйм.

имин яталармы икән, мәйтәм. Шәт ун көн генә дә түгелдер сезне күрмәгәнгә...

— Әйтмә дә инде, Мәгъсүмә, гөлем! — Әкълимә түти аның сүзләрен хуплап куйды.

Аларның шуннан ары гәпләшүләрен Азат ишетмәде. Ишетсә дә, теге якта сөйләнгән сүзләрнең мәгънәсе аның аңына барып җитмәде. Мәгъсүмә дигән исем генә егетне кинәт тетрәндереп куйды. Әнисенең исеме шундый ич!.. Хәер, дөньяда Мәгъсүмәләр азмыни?!

Алай да Азат түзмәде. Җаны чыдамады. Песи шикелле тын гына урыныннан торды, бүлмә ишегенә эленгән хәтфә пәрдәнең читен сызык кына ачып, хәл белешергә килгән апаны карыйсы итте. Йомры гына гәүдәле, чибәр генә хатын икән... Бит урталарына алма алсулыгы йөгергән. Кашлары дугаланып күтәрелгән дә кинәт аска кыйгачланып төшкән. Зур соры күзләрен куе керфекләр тирәләгән. Килешле генә тулы иреннәре менә-менә елмаерга торалар төсле. Шулай да аның йөзендә ниндидер моңсулык бар сыман.

Азат таң атканны, яктырганны көтеп зарыкты. Бәхетенә, абзыйлар иртә торалар икән. Сәгать алты тулганда бер генә чынаяк чәй эчте дә шәһәргә чыгасы итте.

— Зрә дә иртә бит әле, конторда берәү дә юк. Сигез тулгач кына килә башлыйлар алар,— диделәр өлкәннәр.

— Аккүлне карап йөрермен. Яңа җирдә барсы да кызык,— дигән булды Азат. Тик аңарда район үзәген карап йөрү кайгысы юк иде әле. Шәһәр үзәгенә төшү белән, Роза Люксембург урамын белеште. Сорап торасы да булмаган, кичә шуннан үтеп киткән икән ич. Халык суды бинасы шул урам чатында булып чыкты.

Менә аның әнисе яши торган йорт. Зур-зур тәрәзәләр. Яшел калай белән ябылган түбә. Сырлап-сырлап бастырган урыс капка. Биек коймалар. Шундый йорт-җир хакында: «Кош та очып кермәслек», ди торганнардыр инде. Капка баганасындагы калайга йорт номеры һәм Билаловлар дигән фамилия язылган. Әнисе Билалова икән инде хәзер. Билалова. Мәгъсүмә Билалова...

Азат башта бу йортны узып китте, артына караштыргалый-караштыргалый урам башындагы колхоз базарына кадәр барды һәм кире борылды. Билаловларга житәрәк, ул каршы якка чыкты. Асты таш, өсте бүрәнәдән салынган өй турындагы газета витринасы янына барып басты. Анда район газетасының кичәге саны ябыштырылган иде. Шуны укыган булып, бизәкле мәһабәт капкадан кемнең дә булса чыгуын көтә Азат. Шул арада базар мәйданындагы багана башына куелган громкоговорительдән иртәнге сәгать җидене белдергән сигнал ишетелде.

Беравыктан капкада өстенә кара болоньий плащ, аягына тәбәнәк үкчәле туфли кигән, башына кыекча зәңгәр яулык бәйләгән хатын-кыз күренде. Матур кул сумкасы тоткан, вак-вак атлап кына килә. Менә ул кыйгачлап урам аша чыкты һәм витрина янына җитте. Шул! Кичәге апа! Очраклык юк дип Азатны кем ышандыра алыр моннан соң?

Егетнең йөрәге күкрәгеннән атылып чыгардай булып типте, гүя ул, телгә килгән һәм кысылып куйган саен: «Әйт, әни дип әйтеп кара, әйт!» дип кычкыра иде. Әмма Азат авыз ачарлык хәлдә түгел, иреннәре баллап ябыштырган кебек иде. Ә теле әйтерсең кипшенеп игәүгә әверелде һәм аңкавын ышкып торды. Чигә тамырлары күз алдын әлҗе-мөлҗе китерерлек булып сулкылдады. Мәгъсүмә ун-унбиш адым китүгә, Азат, күзгә күренмәс магнит белән тарттырган төсле, аның артыннан иярде. Ханымның автобус тукталышына барып басканын төшенгәч кенә, бер читтәрәк калды.

Автобуска кереп баскач та, Азат аңардан күзен алмады. Шунда ул үзе өчен ачыш ясады: икесенең дә күзләре бер төсле, чәчләре дә бер, кашларының дугаланып торуында да уртаклык бар.

урман ягына кереп киткән юл белән унга борылды. Аның артыннан төшкән Азат, шоссedан еpаклаша төшкәч, ханымны куып житте һәм янәшәсенә килеп:

— Исәнмесез! Сез Мәгъсүмә Ишбулдинамы? — дип сорады.

Мәгъсүмә имәнеп китте. Аннары:

— Әйе,— диде. Ул бу сүзне әйттеме, әллә иреннәре генә кыймылдадымы?

— Мин синең улың, әни!

— Азат!

Икесе дә тетрәнеп калдылар.

## 2

Хафиз Кадергулов район үзәгенә кайтып житәргә ашыга иде. Шуңа күрә ул «Гөлстан» колхозы идарәсендә озак тормады. Басуда, ындыр табагында, җәйләүдә күргәннәрен уртага салып сөйләшкәч, председатель Мингали Гаделҗанов белән партком секретаре Рауза Гашыйгуллина аны озата чыктылар.

— Кузгалабызмы? — диде шофер егет.

— Кузгалабыз гына түгел, очабыз, энем! Өйгә дә сугылып, чыгып булмасмы? Ләйсән аш өлгертеп көтәдер. Икедән дә калмый кайтырмын дигән идем. Чакырткан кешеләр бар. Аларны көттерү шәп булмас...

Машина Суык алан авылының ике-өч чакрымга сузылган урамнарын узып олы юлга чыккач, тизләгеч бермә-бер арттырды. Таш юл зарланырлык түгел иде. Кояш күзне чагылдырганга, Хафиз каршындагы карасу пыяланы аскарак төшереп куйды. Аннары папирос кабызды, җибәрде һәм тирән итеп сулыш алды.

Ул бүген ике колхозда булды. Икесендә ике төрле хәл. Яртугайда тәмам кәефе кырылган иде, Суык аланда җанына рәхәт тапты, ичмасам...

Егет халык та соң бу «Гөлстан» колхозы кешеләре! Бигрәк булганнар! Күрсәтмә дә көтеп ятмыйлар, сыныкка сылтау да эзләмиләр, һәр эшне җиренә житкерик дип җан атып торалар. Кара син аларның житезлеген! Августның егерме беренә дәүләткә ашлык сату планын үтәделәр. Быел бит бу, быелгы ел шартларында, уракка өч атна соңгарып чыккан елны! Колхоз буенча һәр гектардан быел егерме тугыз центнер ашлык алу — батырлык лабаса! «Ике план тутырабыз!» — дип торалар. Әйтteләрме — эшлиләр. Хафиз аларны яхшылап белә башлаганнан бирле буш сүз сөйләгәннәре юк әле. Ә планнары, ай-һай, зур!

Хафиз игенче хезмәтенең нәрсә икәнен яхшы белә. Авылда үскән кеше. Сабан сөргәне дә бар, урак урганы да. Быел бит игенче нихәтле уйланды, ни чама борчылды, үрсәләнде. Йокысыз үткән төннәрнең исәбе-хисабы юк. Кайгырмаслык та түгел иде шул. Үткән кыш үзенең ак юрганын үтә юка сырды. Зәмһәрир суык үзенең җан өшеткеч сулышы белән өй бүрәнәләрен шарт та шорт китереп торды. Ужымнар түгел, игенченең йөрәк җепселләре тунар төсле тоелды. Шулай да жир кешесе мич башына сыенмады. Басуда кар тотты, техникасын әйбәтләп көйләде.

Борынгылар сынамышы буенча, кышына карап җәй кызу килергә тиеш кебек иде. Кая ул! Явымнан баш чыкмады. Салкын яңгырлар җиргә иркенләп суларга бирмәде. Елдагыча дәртләнеп, вакытында чәчүгә чыгу насыйп булмады. Әшкә башлыйбыз дип кыймылдаган һәр кишәрлектә тракторлар жир өстендә батып интектерде. Чәчү сузылыпмы сузылды. Язгы эшләр айга якын кичекте. Аннары игеннәр өлгерә алмый тилмерде. Мондый хәлне чаларган картлар да сирәк күргән булып чыкты. Инде шикәр, көннәр утырып китте дигәндә генә, август кергәч үк, табигать салкынын өрде дә куйды. Соңгы культуралар дип йөрткәннәре-

без зыян күрде. Яшел чуклы кукуруз, бал исе чәчеп утырган карабодай сәлперәйде дә калды. Авыр ел дисәң дә, көфер сүз буласы түгел иде...

Хафиз моторлар гөрелтесе ишетелгән якка күз салды. Дүртәр чәчкечле агрегатлар арыш чәчә иде. Әле кайчан гына ул мәйданнарда тук кузакларын каешландырып борчак җитлекте, инде менә шул туфракка киләсе ел туклыгының нигезе булган бөртекләр салына. Эшнең уңышлы баруын әйтү белән бергә, председатель Мингали Гаделҗанов әчке бер горурлану белән өстәп тә куйды бит: «Бөтен мәйданда уҗымны бары тик аркылыга-буйга гына чәчәбез. Тәҗрибә раслап тора: шулай иткәндә, орлык бик тигез төшә, тамыр нык була, игеннәр куе үсеп китә...»

Соңгы елларда гадәткә кереп, законга әйләнде инде: басуда көзге эш агым булып бара. Өзелеп-сүрелеп торырга һич җай калмый. Сары алтын тасмалар булып калын теземнәр сузылгач күп тә үтми, комбайннар аларны суга башлый. Бөртек ындыр табагына, саламы басу читләрендәге эскертләргә озатыла. Аннары кыр өстендә трактор сабаннары бураэна яра башлый. Бераздан чәчкечләр килә...

Суык алан авылына, андагы «Гөлстан» колхозына килгәндә, бу хуҗалыкта эшләр районда бер дип әйтерлек. Чын иген осталары ул колхозда, кендекләре җиргә береккән кешеләр. Алар янында булу, алар белән күрешеп сөйләшү җанга рәхәт. Кара син ул механизаторларга! Гади комбинезон кигән, башына батырып ябыштырган фуражкасы тузанга чумган, йөзләре кояшта һәм җилдә янып, бронза төсенә кергән авыл арысланнары ризык муллыгы булдырыйк дип ни тырышалар!

«Гөлстан»ның житәкчеләре дә бик булдыклы.

Газик Аккүлгә килеп керде. Камышинкә күперен чыккач, Хафиз, уйларыннан бүленеп, сәгатенә карады. Биш-алты минуттан өч туласы иде.

— Туп-туры райкомга кайтабыз,— диде ул шоферына.— Ләйсәнгә шалтыратырмын гына инде. Чыдар корсак чыдар, соңрак берәр җай чыгар диләрме? Кешеләр көтә торгандыр.

Хафизның кабинеты партия райкомы бинасының икенче катында. Балконы үзәк урамга чыга. Коридордан кабинетка узган җирдә техник секретарь бүлмәсе.

Ишек төбендә үк Хафиз Кадергуловны берничә кеше сәламләп каршылады.

— Исәнмесез!

— Саумы, Хафиз туган!

— Хәерле көн!

Хафиз, аларга сәлам биреп, кабинетына узды, секретарен чакырып, үзе колхозларда вакытта кайлардан кемнәр шалтыратуын сорашты, почта ниләр китергәнен белеште. Аннары Ләйсән белән сөйләшеп алды.

— Тагын кайта алмадың инде, әткәй.— Телефон трубкасында кызының чынлап торган тавышы ишетелде.— Чәйне өч яңарттым...

— Шулай туры килде, кызым. Зур зыян юк дип исәплик. Аның каравы, кичен шәп итеп чәйләрбез, яме? Рафис кайтып җитмәдеме әле?

— Зөя буеннан, әбием яныннан кайтыр ул, көт! Суктырып кына алып кайтмасаң...

— Дүшәмбедә үзем шул яктагы колхозларга барам. Калдырмаска тырышырмын, утырып кайтыр. Укырга вакыт якынлаша. Кирәк-ярагын карыйсы бар ич әле аның. Я, ярый, мин алтыдан да соңга калмый кайтырмын.

Татарстан Верховный Советы депутаты янына дип үтенеч-йомыш, гозер һәм жалу белән килүчеләр биш-алты гына кеше булып чыкты. Уттай кызу эш өсте бит.

Башлап Күксу авылы карты Шәйхеразый абзый керде. Мәһабәт гәүдәле, симез табак битле карт. Җитендәй ак түгәрәк сакал, аңа килеп тоташкан мыек җил кискән йөзен яктыртып тора сыман. Тавышы бик көр, бөердән гөлдерәп чыга. Җитмешнең аръягына авышкан булса да,

абзый артыгын пич бирешмәгән, бер дә алай бетәшеп калмаган. Тәптән нык чыккан, яшьлегендә чамасыз биртелмәгән кеше булгандыр, күрәсең. Өстендә менә дигән затлы костюм, әйбәт күлмәк, башына кара хәтфә кәләпүш, аягына кара читек кигән. Ул, ишекне шакып керүгә, эре-эре атлап, түрдә утырган Хафиз янына узды һәм ике куллап күреште. Кадергуловның кулы Шәйхеразый абзыйның куш учында югалып калгандай булды. Хафиз аңа урын бирде. Карт барып утырды һәм, кесәсеннән ап-ак зур кульяулыгын чыгарып, битен, муенын сөрткәләде, кәләпүшен күтәреп, такыр башын ышкып алды. Битен сыйпаштыргалап куйганда аның күз читләрендәге җыерчыклары языла төште һәм аларның төбе аксыл җепселләр кебек күренеп китте. Аннары абзый, зәңгәрсу-шәмәхә тамырлары бүртеп торган кулларын тез башына куеп, райком секретарена текәлде.

— Урак мәшәкатьләре бер төрле җиңеләйгәч, кордашлар, менәтерә, синең янга җибәрделәр, Хафиз энем,— дип, ул йомышын сөйли башлады.

— Зират бик хәерче хәлдә безнең Күксуның, зират! — диде ул, тирән сулап куйгач.— Урыс әйтмешли, никудышный... Өченче ел әйттек председательгә, былтыр әйттек, быел да сүз кушып карадык. «Рәшәтка-коймалык материал юк!» — ди дә бетте-китте. Баштарак яңа ферма корабыз дип авызны томалады, дөрес әйтә дидек. Аннары яңа клуб салабыз дип ике дә сөйләтмәде, сүзе хак дидек, чыдадык. Хәзер колхоз мәктәп сала... Әйтерең бармы, күп төзибез, Хафиз энем, һәр җирдә бит, бихисап күп. Шул зиратны менә дигән итеп рәшәткәләп аласы иде. Бер дигән капкалар бастырасы иде. Ата-бабаларыбызның каберстаны лабаса...

— Дөрес, Шәйхеразый абзый, сүзең хак...

Хафиз шулай диде дә тынып калды.

Сүзен юпьләп торганны күргәч, Шәйхеразый абзый тагын да канатлана төште.

— Дөрес булмыйни, Хафиз энем. Рәхәтен күп күрмәсәк тә, сугыш елларында дөньяны күп күрдек. Уйлап кара син, Балтик буенда, Германиядә, Чехословакиядә зиратлар нинди!

— Урак беткәч, берәр җаен табарбыз, Шәйхеразый абзый. Мин район Советы башкарма комитетындагы иптәшләргә әйтермен. Җавабым шул. Менә монда язып куйдым.— Кадергулов күн тышлы калын блокнотын күрсәтте.— Кордашларыңа да шулай диген. Председателегез белән бу хакта аерым сүз булыр. Килештекме?

Карт, инде саубуллашырга дип ике кулын сузгач, теленең очында гына эленеп торган бер сүзен әйтәсе итте.

— Тульке, Хафиз энем, син мине председатель өстеннән җалу биреп йөрүче дип юрый күрмә берүк. Мин гомеремдә әләк сүз сөйләмәдем. Үз сүземне кешенең күзенә карап сөйләргә яратам. Кирәк икән, аркасыннан сөеп әйтәм, җирендә икән инде — баш түбәсенә төеп тә әйтәм...

— Алай уйламабыз, Шәйхеразый абзый,— диде Хафиз һәм аны ишек төбенә кадәр озата килде.

Күксу картыннан соң бер агай пенсиясен җайга салуда ярдәм сорап керде. Ул дистә елдан артык шахтада күмер чапкан, Ватан сугышына катнашкан, аннары янә колхозга кайтып төпләнгән. Колхоз аңа пенсия түли, абзый моңа гына канәгать түгел, шахтерлык еллары өчен дә түләүне дәгъвалап йөри икән. Хафиз шундук тәэминат бүлегенә шалтыратты, агайның пенсиясе мәсьәләсен бик тиз арада азаккача ачыклауларын үтенде.

Аннары Кадергулов янына балаларын бакчага урнаштыра алмый әллә ни гомер интегеп йөрүче ике яшь хатын керде. Үтенечләре икесенең дә бер. «Җиң сызганып эшлисе иде, балаларны калдырыр урын юк.

Район мәгариф бүлеге бусагасын елдан артык шомарттык, файдасы тимәде. Инде ни хәл итик? Булыша күрегез!» — диләр.

Балалар бакчасы һәм ясле дигәнең квартира мәсьәләсеннән бер дә кайтыш түгел. Бакчага чират көтүчеләр шушы ике хатын гына булса икән! Йөзләп бит алар...

Шуларны фикереннән уздырып, беравык тын торганда, яшь хатыннарның берсе, чандыр гәүдәле, ак йөзлесе, күңелендә айлар буе тулышканны берәм-берәм бушата башлады.

— Замана яхшыра, тормыш әйбәтләнә бара, ә карчыклар кыйтылана төшә, иптәш депутат,— дип тезеп китте ул. Аның белән бергә кергәне, ләм-мим эндәшмичә, бер читтә баш кагып кына утырды. Ә телдәр хатын сөйли бирде.

— Кайнана хәзер килен баласын кирегә тибәреп кенә тора. Минем кайнанам әйтә: хөкүмәтем бик әйбәт пенсия бирә, синең баланны тезем-дә түтелдәтеп утырудан коткарды, ди. Үзеңә арыслан кебек ир үстереп биргәнемә шөкер ит тә рәхмәт әйт, ди. Вәт чукынчык!

Тозлырак сүз ычкынгач, хатыннарның икенчесе уңайсызланып китте. Тонык кына тавыш белән: «Ипләбрәк сөйлә, Рәхилә! Ипләбрәк!» — дип куйды. Рәхиләсе, аның саен кыза биреп:

— Әй, тыймасана, Һаҗәр җаным, тыймасана! — дип, яңа җилкену белән элеп алды.— Кадергулов абый үз кешебез, гаепләмәс. Инде күпме җыенып, аңа кергәнбез икән, әйтәсе әче сүзем дигәндәй, эчемдә җыелганны әйтми китмим. Чишелеп бер сөйләмәсәм, эчемә кату чыга, ант әгәре менә... Кайнанам кызының бәбиен карарга Сарапулга барып торды. Сарапулга! «Кызымныкы сөйдерә, киленнеке көйдерә!» — менә шулдыр инде, Кадергулов абый... Үземә эшләмичә һич ярамый. Тормышта очын очка ялгыйсы да бар, гомере булган кешегә стажы да кирәгер...

Хафиз район үзәгендәге балалар бакчасының икесен киңәйтүләрен, шунда яңа корпуслар өлгергәч, аларның балаларына да урын бирү мөмкин булырын әйтте.

— Күбен түзгәнне анысына чыдыйбыз инде, Кадергулов абый,— диештеләр хатыннар. Саубуллашып чыкканда, Рәхилә дигәненең дә эче бушаган, күңелендә өмет чаткысы кабынган иде бугай, Һаҗәр дигәнен ай-кояштай балкып, култыклап алды...

Кемдер кабинет ишеген сак кына ачты, аннары эчкә бер баш сузылды.

— Керергә рөхсәтме? — дип сорады урта яшьләрдәге бер хатын.— Мөмкинме?

— Керегез, кер. Узыгыз, утырыгыз.— Хафиз әле генә булып узган сөйләшүләр тәэсиреннән тизрәк арынырга тырышып, ишек төбендә торган хатынны кул ишарәсе белән якынрак килеп утырырга чакырды.

— Исәнмесез! Танышып җибәриктер инде. Мин сезне белмим. Күргәнем бар барын. Аккүлнекеме сез, әллә авылданмы?

Йомры гәүдәле, кара тутлы, озын чәч толымы белән маңгай естен кыршаулап куйган бу хатын сызлану катыш елмаеп сөйләргә тырыша иде. Аның балланып пешкән чия төсле иреннәре менә-менә елап җибәрер төсле мимылдашты. Күз керфекләрен еш-еш какты ул. Сүз башлавы кыен иде аңа.

— Аккүлнеке мин, Хафиз абый. Унсигез ел монда торам инде. Азык комбинатында лаборантка булып эшлим. Мәгъсүмә Билалова. Зооветснабтагы Билаловны беләсездер. Шуның хатыны.

— Билаловны беләм, беләм,— диде Хафиз.— Ничек белмисен ди! Я, тыңлыйм сезне. Ни йомыш белән килүегез иде?

Мәгъсүмә күзләрен күтәреп карамас булды. Ахырда, үзен нык тотарга тырышып, ул:

— Йомыш дисәң дә читен инде, Хафиз абый,— дип сүзгә керешә —
Киңәш сорап та, ярдәм өметләнеп тә килүем. Тагын да дөресрәге, сезнең хөкемгә килүем, Хафиз абый.

Шулай диде дә Мәгъсүмә тыела алмыйча елап җибәрде. Баядан бирле тамагында укмашып торган кайнар төер, күзеннән яшь сытылып чыгуга, эреп юк булды, тик тавышы һаман калтырый бирде.

— Бу дөньяның зур гөнаһлы бәндәсе мин, Хафиз абый...— Мәгъсүмә, яшенә буылып, сүзен әйтә алмый газапланды.— Инде шуның җәзасын күрер көн җитте...

— Тынычланыгыз, сеңелем, тынычланыгыз...— Хафиз графиннан су агызды һәм стаканны Мәгъсүмәгә сузды.— Мәгез, су йотып җибәрегез... Тынычланыгыз да рәте белән сөйләгез. Тик, зинһар, башта тынычланыгыз...

Хафизның үз гомерендә бик күп гамьсез, ваемсыз чырайлар, кайгылы, сагышлы йөзләр, соңгы сулышта үлем белән тартышып яткан, өмет өзеп, шашынган кешеләр күргәне бар. Никадәр авыр булмасын, боларга ул чыдый иде. Тик хатын-кыз күз яшен күтәрә алмый Хафиз. Юк, күтәрә алмый. Ике елдан бирле бигрәк тә. Бөтенләй чит кешенең һәр тамчы күз яше дә аңа хатыны Гөлмәрьямнең үлем алдыннан тилмереп елаганын искә төшерә. Шуңа күрә ул ничәнче мәртәбәдер:

— Тынычланыгыз, тынычланыгыз! — дип кабатлады.

Мәгъсүмә бар көчен туплап сөйли башлады.

— Моннан өч-дүрт көн элек кенә Чиләбедән улым Азат килеп төште. Минем улым — Әхтәмгә үги бала. Мин аны тудыргач та балалар йортына тапшырып калдырган идем. Ул хәзер урта мәктәп бетергән, паспорт алган. Унсигезенче яше. Балигъ булгач, аңа минем хакта әйткәннәр, адресны биргәннәр. Ул да армиягә киткәнче мине күрергә теләгән... Яшьлегемдәге хатам — улым үзе килеп күземә күренгәнче дә туктаусыз сызлый торган бер ярага әйләнгән иде инде. Килеп төшүе — шул җәрәхәтне актарып тоз сипкән кебек булды.

— Ничек? Газиз балагызны ташлап киткән идегезме? — Хафиз, ялгыш ишетмимме дигән төсле, ышаныр-ышанмас хәлдә шулай сорап куйды.

— Шулай туры килгән иде шул...— Мәгъсүмә калтыранган кулын йөзенә күтәрде һәм учы белән авызын каплады. Йөрәк эчкәресеннән ихтыярсыз бәреп чыгачак кыргый авазның, үкенечле әрнү авазының юлын бүләргә теләде бугай.

— Әхтәм белә идеме соң бу хакта?

— Кияүгә чыкканда әйтмәгән идем. Елдан артык гомер иткәч, барысын сөйләдем. Дөньядагы әшәке сүз белән битәрләде, алай да куып чыгармады. Аңа телсез-тешсез хезмәтче кирәк иде. Шуңа чыдагандыр дип уйлыйм. Йорт-җире зур, бакчасы колхозныкыдай, терлек-туары күп, әнисе үлгән, сырхау әткәсе өченче ел урын өстендә ята иде... Шулай булгач, мине аерып җибәрмәде, тик рәхимсез янап куйды: «Балаң барлыгын ялгышып кына телеңнән чыгарсаң да, шәфкать көтмә. Бу мәсьәләдә миннән чебен иманы да ала алмассың!» — диде. Мин ничә ел буена телемне йотып яшәдем. Инде Азат үзе килеп тапкач, ни хәлләр итим?..

— Әтисе кем иде соң аның? Ул кеше кайда хәзер?

— Әтисе, Хафиз абый, Азатның дөньяда барлыгын-юклыгын да белми. Мин аны үзем дә ике-өч кенә күреп калдым. Чиләбенеке иде. Минем балага узуымны белүгә, җиргә сеңгән төсле юкка чыкты...

Хафиз әле һаман ни дип әйтергә дә белми иде. Шуңадыр «ала-а-ай!» дип кенә сузып куйды. Аннан соң Мәгъсүмәгә текәлеп карады.

— Тугач ук ташлап китүегез өчен улыгыз нәрсә ди соң? Рәнҗиме? Шулай да ни өчен алай иттегез? Ничек шулай эшли алдыгыз? Илле беренче елны булган бит инде бу хәл. Ач чак түгел, ялангач вакыт түгел... Өскә бомба, снаряд та явып тормый...

Мәгъсүмә, карашын бер почмакка төбәгән килеш, Хафизга җавап бирүдән битәр, үз алдына сөйләнгән төсле:

— Азат гафу итте шикелле. Итте. Итте,— диде.— Үксез баланың теле ачы булыр дисәләр дә, улым мина рәнҗеп, бер тәмсез сүз дә әйтмәде. «Балалар әти-әниләрен сайлап алмыйлар бит!» дип кенә үзәкне өзде. Мин аңа барысын да аңлаттым, бер нәрсәне дә яшермәдем... Бәхетсезлеккә тарганда, миңа уналты-унҗиделәр генә иде бит әле, Хафиз абый. Әти сугыштан инвалид булып кайткач, озак чирләп үлде. Без семьяда биш кыз бала калдык. Иң олысы мин идем. Әни тимер юл вокзалында җыештыручы иде. Күпме генә ала иде инде ул! Йөкле булып, алты ай йөргәч, әни минем хәлне сизеп алды. Шуннан соң инвалид ир белән ни гомер чиләнгән, өй тулы балалар белән иза чигеп, дөньясыннан күңеле кайткан әни шашына калды. Безнең өйдә күк гөмбәзе ишелде, җир убылды, кыямәт купты... Әни ярсуның аръягына атлаган иде.

— Җилдән туган бала күтәреп кайтсаң, үзеңне дә, баланны да бусагадан керүгә үк бәреп үтерәм! — дип, икмәк белән ант итте. Мин аның әйткәнен эшләми калмаганын яхшы белә идем. Баланы калдырдым да Чиләбедән бөтенләйгә киттем. Туган җан икән, яшәсен дидем. Үземнең дә күп газап күрәсемне белмәдем түгел... Күршебездә шушы Аккүлдән кияүгә чыгып килгән Мөслимә исемле бер хатын бар иде. Шул миңа апасы белән җизнәсенең адресын бирде, юллык акча юнәтеште. Мине вакытлыча үзләрендә тотуларын үтенеп, җизнәләренә хат язды. Әкълимә апа белән Мостафа абзыйга мең рәхмәт, ярдәмнәреннән ташламадылар. Кияүгә чыкканчы аларда тордым. Сез аларны яхшы беләсез, икесе дә мәктәптә эшли... Шуннан бирле Аккүл кешесе инде мин.

— Хәзер нишләргә җыенасыз?

— Шуны уйлап башым каткач, Мостафа абзыйларга барган идем, ирле-хатынлы бер авыздан сезгә килергә киңәш бирделәр. Килдем инде менә. Аптыраган башын тырнар, ди. Әхтәм Азатны өйгә аяк та атлатмаячак. Исемен дә ишетәсе килми. Ул Аккүлгә килеп төшкәнне белгәч, ишек бикләренә кадәр ныгытты. Шикләнә бугай. Азат үзе дә безгә керергә дә теләми. Аңлап алды барысын. Егет булган бит инде, егет!

Мәгъсүмә улы белән беренче тапкыр очрашкан минутларын исенә төшерде. Ул баласын танымыйча бик аз гына торды. Танышкач, Азат та әнисенә карамаска тырышкан, үзен үтә җайсыз сизгән иде.

— Буй-сыны чибәр,— дип сүзен дәвам итте Мәгъсүмә. Шушы мизгелдә гүя аның каршысында Азаты басып тора иде.— Сабыр холыклы. Уйлап-үлчәп кенә сөйләшә. Мин аңа әйттем, синә иязәшүе дә читен булыр инде, синнән оялам да, шундый зур булгансың, дидем. Эшкә урнашасы иде ди ул, Хафиз абый. Машина йөртергә урта мәктәптә өйрәттеләр, ташчы эшен дә беләм, ди. Урнаштырышмассызмы икән? Яшь димәсләрме? Тик аңа эшнең торыр җир белән булганы кирәк инде. Тагын әллә кайларга китеп бармасын иде дим. Күз алдымдарак булсын иде...

Конкрет сөйләшә башлагач, Кадергулов аңа бик тиз киңәш бирде.

— Аккүлдән бер километр гына кошчылык фабрикасы салына ич. Керсен шунда. Машинага утырта алмаслар, шоферларга кытлык юк. Ташчылар кирәк. Иртәгә иртүк комсомол райкомына килсен. Мин райкомолдагы егетләргә дә, механикалаштырылган күчмә колонна начальнигы Илларион Захарычка, Зотовка да әйтеп куярмын. Аларның тулай торaклары бар. Улыгызга урын булыр.

— Рәхмәт, Хафиз абый.

— Башка балаларыгыз бармы соң сезнең?

— Юк,— диде Мәгъсүмә. Аның сүзеннән: «Ярый әле, юк, алар да булса, өч ут уртасында көяр идем», дигәне аңлашылды.— Әхтәм бала турында авыз да ачтырмый...

Өйгә кайткач, Хафиз ваннада юынып чыгарга булды. Җинел ябык машинада булса да, йөз чакрымнан артык юл йөрелде: арыш чәчә торган басуларда булды ул, механикалаштырылган ындыр табакларына тукталды. Тузанга батудан гына да түгел, юынып-коенып алса, тәне җиңеләеп китә, фикерләре ачыла төшә, гомумән, кәефе яхшыра аның.

— Кызым, миңа чиста киемнәр карап бирсәнә,— диде ул, пианино янында ниндидер ноталар актарып утырган Ләйсәнгә эндәшеп.— Юл тузанын сыпырып чыгыйм әле бер. Талчыгу дигәне дә кимеп куяр. Иртәгә кинәшмә. Шунда сөйләргә хәзерләнәсем бар...

Чын-чынлап юыныйм дисә, мунча яктыра ул. Шунда бөтен шартын китереп керә. Мунча ташларын ажгыртып пар салырга ярата. Чабына башласа, аның белән юынучы кешеләр берәм-берәм мунча чоланына чыгып бетә. Хафиз аннары өр-яңа бер талпыну белән чабына башлый. Үзенең дә түзәр хәле калмый булса кирәк, мөлдерәмә салкын су тулы тасны башына каплый, ах-ух итеп идәндә тапталып ала һәм... янә ләүкәгә үрмәли.

Бик яшьтән, бот буе малай чактан ук, шуңа күнегеп үсте ул. Бабасы мәрхүм Кадергол да мунча ләззәте кагылган татар иде, эткәсе мәрхүм Галиулла агай да анардан кимен куймады. Хафизны да сабый чагыннан ук ай-ваена карамый чаптылар. Малай кулына себерке тотарлык булгач, үзләрен дә анардан кат-кат чаптыралар иде.

Көннәрнең берендә, мунчаның тәмуг кайнарлыгына чыдый алмыйча, Хафиз бабасының тәнне пешереп ялый торган себеркесе астыннан шуып чыкты да, ләүкәдән егылып ук диярлек төшкәч, тышка атылды. Тик мунча чоланы ишегенең бигенә буе җитмәгәнлектән, хәлне бик тиз абайлап өлгергән бабасы моны шундук эләктереп алды һәм җилтерәтеп мунчага сөйрәп керде. Малайның йомшак җирен карт ярыйсы ук җилле чәбәкләде. Ә үзе сөйләнә торды:

— Мунча чабына белмәгән ир — ярты ир ул. Анда ни гайрәт, ни куәт булмый. Саулыкка да туймый андый адәм. Гомер итим, көн күрим дисәң, кешегә барсы да кирәк. Ә син качып чыкмакчы, малай актыгы. Булмады, ә? Тормышта да шулай ул. Уттан котылып, сулу алдым гына дигәндә янә ялкынга тап буласың. Һәммәсенә чыдам булып үсәргә кирәк...

Сүзләре бабасының үзенә карата рас килде. Сиксән җидегә житеп кенә дөнья куйды. Сырхап түшәктә ятмады, кеше кулына калып, бәрәүгә дә йөк булмады. Тилмермәде дә, тилмертмәде дә. Җир селкетеп йөрер иде. «Басуга чыксам, яшәреп китәм», дип елгырлануыннан соңгы атна гомеренә кадәр туктамады. Эткәсенең язмышы исә бөтәнчәрәк булды. Аны әүвәле сугыш рәхимсез ботарлады, аннары пычрак куллы бәндәләр...

Ваннада коенуны Хафиз Зөянең бер аулак почмагында анадан тума калып, суга чумып алуга охшатып куя. Тәтештә, Идел ярындагы калада, укыганда да Зөя суын сагынып кайта иде. Монда да Зөя суы килеп тора. Ул суның йомшаклыгы, тәмлелеге әйтеп аңлата торган гына түгел. Аны куш учлап битенә бер генә сипсәң дә, керен алып кына калмый, йөзгә нур кертә. Чәченне юсаң — ефәк ясый. Гөлгә сипсәң — гөлең чәчәккә күмелеп утыра. Зөя өстендә яңа сауган сөт кебек куерып күтәрелгән ак томаннар дымы кагылганга, шуннан искән талгын җилләр сыйпап-назлап үстергәнгә күрә атаклыдыр ул Зөя буеның бодайлары! Җиләк-җимеше дә шунлыктан үтә татлыдыр. Зөя буе тугайларының печәне белән туенганга, безнең мал-туарның итe-сөте дә ашап туйгысыздыр. Шулайдыр! Хафиз Кадергулов моны бик күптән күнеленә шулай беркетеп куйган инде. Пәрәгенең ашкынлыгында, беләкләренең куәтендә, дөрләп яшәр кеше булып дөньяга килүендә дә ул туган туфрак

да гына булмады, сугыштан соң илебезнең кайсы почмакларын гына күрмәде, җәйге яллары вакытында чит илләргә барып кайту да насыйп булды. Тик ул барыбер күңеленә Зөя буедай якын җирне тапмады шикелле.

Үз районында, туып-үскән төбәгендә яшәгәндә, арыса бик тиз хәл җыя, сырхап китәр төсле булса да, колхозларга чыгып китүгә савыгып кайта кебек. Тик өйдә эшсез-шөгыльсез утырырга гына калмасын. Табигать аңа көчне кызганмаган, мул итеп биргән. Шул көч аны өзлексез хәрәкәттә тота, дөнья мәшәкатьләренең эченә чумарга этәрә, аларны берәм-берәм ерып чыгарга рухландыра...

Эчке киемнәр өстеннән аксыл-көрән җирлеккә куе яшел буйлар сузылган пижамасын кигәч, аягына киез туфлиен эләктереп, райком секретаре йокы бүлмәсендәге зур трюмо каршына килде. Кызарган йөзенә бәреп чыккан тирне сөртте, уң күзе читенә кунган бердәнбер шадра ясмыгындагы су тамчысын кулъяулыгы белән басып куйды. Шуннан соң заманасында шактый куе булып, хәзер инде сирәгәеп калган кылдай каты кара чәчен артка тарады. Хрусталь люстрадан көзгегә төшкән электр яктысы аның зур кара күз алмаларында җөй энәсе очыдай лампачыклар тәлгәше булып җемелдәшә иде. Ул көзгедәге шәүләсенә — озын буйлы, какчарак, ләкин чуендай нык гәүдәле, кара туткыллы ир уртасына — елмаеп куйгандай итте. Кәефе әйбәт, бөтен тәне иркенләп сулый, үзенә бик рәхәт. Аш-су ягына чыкканда авыз эченнән генә ниндидер кыска көй көйләп килде һәм:

— Ләйсән, кызым, чәең әзерме? Әйдүк, парлашып аулак чәе эчик әле,— диде.— Ничәнче катка кайнарлаттың инде, дүрт булдымы?

Хафиз кызының чәченнән сыйпап, аркасыннан какты. Ләйсәннең әткәсенеке шикелле үк төн карасыдай күзләрендә наз аралаш үпкә чаткысы елтырап китте. Ул чигәләре буйлап кара ефәк төсле аска сузылган чәчен рәтләштергәләде дә:

— Көләсе түгел, әткәй. Чыннан да, дүрт,— диде.— Син бит чәйне бик тәмләп эчәргә яратасың. Тик мин моны үземә эш артудан гына әйтәммени?! Вакытында ашап-эчмисең. Ашказаның интектерә башласа әле менә... Әнкәй исән чакта син әйткән сәгатькә төгәл кайта торган идең...

— Ул вакытта да төрлечә була иде, кызым.

Ләйсән соңгы айларда «Әнкәй исән чакта...» дигән сүзләрне ничектер ешрак әйтә башлады түгелме соң? Үсте шул, буй җитеп килә. Быел унынчы класста укыячак. Әнисе үлгәч, бик уйчанланды, җитдиләнде. Бәлки аның күңелендә берәр сагаю, шикләнү бардыр? Хафиз шулай уйлады, әмма кызына бөтенләй башка сүзләр әйтте.

— Урак өсте, Ләйсән. Ашлык сату чоры. Туңга сөрү бара. Көзге чәчү... Үзең беләсең эшнең тыгызлыгын. Быел бигрәк тә! Кышын төгәл булырмын, кышын, Ләйсән. Утыр, кызым.

— Әткәй, чәйләдем инде мин. Киногә барырга сөйләшкән идек. Сигез дә утызга. «Журналист»ны кабат күрсәтәләр.

Хафизның да бу фильмны тагын бер карарга нияте юк түгел. Ләкин ул бүген бара алмый. Вакыты тар.

Иртәгә район укытучыларының зур мәҗлесе. Менә шунда, шагыйрь әйтмешли, «сөйләр сүзләр бик күп алар». Алда торган бурычлар бик җитди, башкарасы эшләр тау чаклы...

Хафиз чәйләп алгач, икенче өстәл янына килде һәм бераз вакыт вазадагы ак, шәмәхә, тагын әллә нинди төсмерләре булган кашкарый чәчәкләре бәйләменә карап торды. Чәчәкләрне Ләйсән бүген иртән өзгән иде. Ул һаман шулай итә: анисеннән калган гадәт буенча, яздан башлап кара көзгә кадәр әтисенең эш бүлмәсендәге өстәлгә чәчәк куя. Сулганшиңгәннәрен чүпләп, суын алыштырып тора. Ә чәчәкләрнең төрле-төрлесен: пионнарны, розалар, гладиолуслар һәм кашкарыйларны үзләренең

[ч]аралты яны бакчасында үстерә. Суга утырткач, [...] чакланасыннар өчен, чәчәкләрне иртәнге сәгатьләрдә өзәргә тырыша. Кояш күтәрелер-күтәрелмәс чакта аларның таҗ яфракчыкларына, кәсәләренә чык суы тулган була. Шул шифа чәчәкне озаграк вакытка күркәм саклый.

— Кашкарыйлар! Кашкарыйлар! — Хафиз, чәчәкләргә эндәшкән кебек, аларның исемнәрен жиңел бер көйгә шыңшып алды һәм, вазаны өстәл уртасынарак күчереп, утыртмалы электр лампасын тагын бер кат жайлап куйды. Аннары ул тышына «Педагогик темаларга» дип язылган катыргы папкасын чиште. Сөйлисе сүзләренең тезислары, кул астында торсын дип туплап куйган газета-журнал мәкаләләре, белешмәләр, саннар тупланган иде анда.

Бераздан инде ул, бөтен күңеле белән укытучылар киңәшмәсе атмосферасына чумып, эшләп утыра иде. Алдындагы ак кәгазь битләрендә юллар ишәйгәннән-ишәя барды. Әмма, күпме генә ишәйсәләр дә, уйлануларын, истәлекләрен, күргән һәм кичергәннәрен ул юллар гына сөйләп бетермәс иде. Ул юлларны гына укыган кеше дә зур тәм һәм канәгатьләнү тапмас иде, бәлки. Кәгазь битендәге юллар Хафизга сөйләр сүзләренең жеп очын жуймас өчен, фикерләрен кирәгенчә тезеп барыр өчен зарур иде. Аның чыгышын гадәттә тын да алмый тыңлыйлар.

4

Хафизның фикерләрен ишек кыңгыравы чыңлаган тавыш бүлде. Ләйсән кинодан кайтты. Әтисе, аңа ишек ачарга барганда, көйли-көйли атлады:

Ләйсән дилэр, Ләйсән дилэр,
Ләйсән язның яңгыры...

— Кайтып та життеңме, кызым?

— Кайттым, әткәй. Эх, шәп соң фильмы! Шул чаклы дөрес, билләһи, ышандыра, әйбәт... Чистарып, сафланып киткән шикелле буласың.

Хафиз, эш бүлмәсенә узышлый, артына борылып, тагын Ләйсәнгә эндәште.

— Иртәгә чәйне иртәрәк өлгертербез, яме. Укытучыларның район киңәшмәсе ачыла. Аңа кадәр әллә нихәтле эшем бар.

Әтисенең сүзен Ләйсән дәвам иттерде:

— Кичен без укытучылар өчен концерт куябыз.

— «Без» дигәнең кемнәр була инде?

— Музыка мәктәбенекеләр.

— Аңлашылды.

Хафиз урынына барып утырган гына иде, Ләйсән кабинет ишеген ачты.

— Бая да әйтергә онытканмын, әткәй. Гөләндәм апа килгән иде. Сине сорады. Гөл-Төркемгә барган булган. Әбиемне күргән. Бик озак сөйләшеп утырдык, ди. Рафисны өйдә туры китерә алмаган. Балыкка йөридер, ди. Бөтен хәбәре менә шул...

Ләйсән ишекне ничек ачкан булса, шулай тиз генә ябып та куйды. Хафиз кызының тавышыннан, аерым сүзләреннән генә түгел, керфек кагышыннан, чигә бөдрәсенең тибрәнүеннән үк абайлап алды: соңгы араларда Гөләндәмнең өйгә ешрак килүен Ләйсән өнәп бетерми шикелле. Болай дип әйтүдә хата да бар. Ләйсән, бер карасаң, Гөләндәм өчен үлеп тора, «Алма апа!» дип муенына сарылырга риза. Ни әйтсәң дә, әнисенең бертуган сеңелесе иң. Икенче караганда, аңа карата кырыслана да башлады. Гөләндәм Хафизны еш сораса, Ләйсән аны өнәми башлый. Көнләшүме бу, әнисенең истәлегенә алма апасын да кагылдырырга теләмәүме? Бала дөньясы — иң нечкә камертон дип белми әйтмәгәннәрдер. Хәер, Ләйсән инде житеп килә торган кыз. Аңарда сиземләүнең бүтән төрлесе, акыл өстенлек алганы, уяна торган чак.

җиләк-җимеш питомнигында баш агроном. Авыл хуҗалыгы институтын тәмамлыйсы елны Вятские Поляны егетенә кияүгә чыккан булган, тик тормышлары мантып китә алмаган. Ире аны ташлаган һәм, семья ызгышсыннан башын аралап, Мәскәүгә, Тимирязев академиясенә аспирантурага барып кергән. Хәзер инде танылып бара торган галим диләр.

Гөләндәм, ялгыз калгач, Киров өлкәсендә яшисе итмәгән, туган төбәккә кайтырга карар кылган. Хафиз райком секретаре булып сайланганда, ул җиләк-җимеш питомнигында эшли иде инде. Моннан өч ел элек аны баш агроном итеп күтәрделәр.

Гөлмәрьям исән чакта да ул Кадергуловлар өенә еш килә иде. Апалы-сеңелле озак сөйләшеп утыралар иде. Гөләндәм Ләйсәнне дә, Рафисны да карашты. Балаларны бик ярата, алар белән көннәр буе мәш килергә риза. Киендерер, юындырыр, яшьтәшләре төсле булып, балалар белән качышлы уйнар, курчак күлмәкләре тегәр, волейбол уйнарга чыгып китәр, көлә-көлә телевизордан сабыйлар өчен тапшырыла торган мультфильмнарны кинәнеп карап утырыр. Апасы аңа: «Сиңа, үскәнем, балалар бакчасында эшләргә кирәк. Агрономлыкны ялгыш сайлагансың», дигәли. Гөләндәмнең үзенең исә баласы юк. Ул моңа эченнән сызланып, үкенечле уфтану кичерә иде.

Хафиз Гөлмәрьямгә өйләнүенең беренче көннәреннән үк балдызына бик ягымлы мөнәсәбәттә булды. Җизнәсенә Гөләндәмнең боега белмәве, эшне өздереп эшләве, кешеләргә теләктәшлеге, эчкерсезлеге ошый иде. Чибәр, бәлки артыграк та чибәр булган яшь хатынның гомере заяга узуы өчен борчыла да иде ул. Шул хакта үзе ни уйлаганын Гөлмәрьямгә дә әйткәне булды. Табигате артык тыйнак, басынкы холыклы Гөлмәрьям, бер вакытта да рияланa белми торган хатын, Хафизга шактый кырыс һәм әрнүле җавап биргән иде.

— Чәчәктәй яшь чагын пар канатлы итәсе килсә, басынкырак булсын, горурлыгын җуймасын, һәр елмайган балаклы кеше алдында балавыздай эрергә ашыкмасын,— дигән иде.— Ирсез хатынга каш сикертүче табыла ул. Җете кызыл тиз уңа. Гөләндәм дә шулай булды. Тормышта кешене михнәт һәм авырлыклар гына сынамый шул. Дан-дәрәҗә дигәнең дә сынап карый. Хәтта кешенең үз чибәрлеге дә бик каты сыный. Сеңел әнә шул сынауны үтә алмыйча сынган кеше. Иренең аңардан качып китүенә ни сәбәп булгандыр, дисең? Сүз чыккан, гайбәткә юл куйган. Менә нәтиҗә.

Мондый сүзне тыңларга мәҗбүрлектән үк җайсызланган Хафиз хатынына шелтәле караш ташлый һәм якын кешеләрчә орыша башлый иде:

— Иллә дә аяусыз син, Гөлем, ә?! Ичмасам, туган сеңелеңә мәрхәмәт кылыр идең. Бигрәк әче телле булып китәсең.

— Туган сеңелем генә түгел, җилбәзәк икән, туган анама да, кызыма да шулай әйтәчәкмен. Җуймасыннар хатын-кыз горурлыгын!..

Гомумән әйткәндә, Гөлмәрьям Гөләндәмгә карата шактый кырыс иде. Ә сеңелесе, бу катылыкның асылын аңлап, күрәсең, апасыннан читләшергә теләми иде. Хискә бирелеп, азаккача ачылып киткәне һәм туптуры: «Сокланам мин сезнең тормышыгызга, апа! Күз генә тимәсен лә бер үк»,— дигәне дә булды.

Апасының саулыгы киткәч, Гөләндәм һәр тумыш көнне Хафизларда булды. Аш-су хәзерләште (аңа бик оста ул!), юышты-җыешты, балаларны карашты. Ләйсән аны бигрәк якын итте. Ә Рафис күбрәк әтисе тирәсендә бөтерелде.

Гөлмәрьям дөнья куйгач, балалар бер мәлгә гел Гөләндәм куенында калды. Дөрес, тора-бара Хафизның әнисе Мәликә түти дә авылдан күбып килми булдыра алмады, ләкин ул, муенына таш бәйләп суга салам дисәләр дә, нигез үчереп, тәрәзә кадаклап, бөтенләйгә Аккүлгә килергә риза

түгел иде. «Гомер кичкән нигеземне, атаң каберен ташлап китә алмыйм, рәнҗемә, Хафиз улым. Илдә бер синең башыңа гына килгән хәсрәт түгел. Киленем килен генә идеме, дөнья бәясе кеше иде. Бигрәк үкенечкә булган икән. Әмма да ләкин вакытын белән тагын башлы-күзле булырсың инде, ни хәл итмәк кирәк»,— диде.

Гөлмәрьямнең елы үткәнче, Ләйсән Гөләндәм белән бик дус, бик сердәш булды. Шуннан соң араларыннан ниндидер салкынча сулыш үтте бугай. Ләйсән, әйткәнебезчә, алма апасына тәрпәләнеп куйгалый башлады. Аның белән бәхәскә кергәләргә дә батырчылык итте, хәтта вакытывакыты белән Гөләндәмгә дорфа булып китте. Хафиз берничә тапкыр аны кисәтте дә. «Олылар белән шулай сөйләшәләрме, кызым?!» — диде. Ана җавабында кызы: «Олы-лар!» дип, үпкә катыш ризасызлык белдерү белән чикләнде.

Ничек кенә булмасын, Ләйсән күңеленә борчу төшкәнлеге, хафа кергәнлеге сизелә иде. Әнә ич әле бүген дә: «Гөләндәм апа килгән иде. Сине сорады»,— дип кенә җибәрде. «Алма апа» сүзен торган саен сирәгрәк әйтергә тырыша түгелме соң? «Бар хәбәре менә шул»,— ди бит.

Хафиз бу хәлнең чын сәбәбен аңлый алмыйча аптырый. Нигә бу тикле үзгәрде Ләйсән? Һай, бу тормыш дигәнең! Һай, бу дөнья!

5

Якшәмбе көнне төштән соң, Рафис Гөл-Төркемнән кайткач, семья җыелып бетте. Хафиз да көннең икенче яртысын өйдә, балалары янында уздырырга булды. Иртәгә Ләйсән белән Рафис укый башлаячаклар. Ләйсәннең мәктәптә соңгы елы, ә Рафис сигезенче класска бара. Шуңа күрә балалар китап-дәфтәрләрен барлап, бүтән кирәк-яракны хәзерләп куйдылар.

Зөя буенда көне-төне балыкта йөреп, тәне чуендай каралган Рафис апасы каршына килеп честь биргән булды да тәтелди башлады.

— Иптәш гвардия старшинасы! Сигезенче класс укучысы Рафис Хафиз улы Кадергулов яңа уку елын башлап җибәрергә тулысынча әзер. Укытучыларның катыдан-каты кулларына барып ирешкәнче, сезнең соңгы боерыгыгызны көтәм...

Үзе тыкылдый, үзе шырык-шырык көлә. Кояшта янган, җилдә каралган йөзендә күзләре ялтырый да ак тешләре генә җемелдәшә.

Хафиз, аларга бер читтән карап, куанычлы елмая. Кара син малай Рафисны! Җәй буена ничек буй тартты. Күзгә күренеп үсә. Җилкәләре киңәеп киткән шикелле.

Ләйсән тырышып-тырышып житди булмакчы итә. Белә ул: әгәр Рафисның шаяруына бер юл куйсаң, малай азгыны кара төнгә кадәр сагыз булып сыланачак. Цирктагы шамакайдан бер дә ким түгел. Әллә ниләр уйлап таба, телдәрләнә. Ләйсән үпкәләсә яки катырак кагылса, көт тә тор, отыры үчегә башлый һәм тагын да тәрткерәк тәтелдәргә керешә.

— Таһир абыйны бүтән күрмәдеңмени соң, апа? Кәефеңнең рәте юк,— дип каныга. Ләйсәннең, билгеле инде, әткәсе алдында Таһирның исемен әйттерәсе килми. Ничектер оят ич әти алдында егет турында сөйләп тору! Хафиз исә район газетасы редакциясендә җаваплы секретарь булып эшләүче Дәмин Сөләймановның улы Таһирны әйбәт белә. Шуларны алдан ук исәпләп булса кирәк, Ләйсән бүген дә житди кыяфәткә керергә һәм сүзне уен-көлкегә, үчекләшүгә, әрепләшүгә жәй калдырмаслык якка борырга тырышты.

— Менә нәрсә, Аккүл негры,— диде ул, тавышын булдыра алганча кырыс итәргә теләп.— Җәйлеккә бирелгәннәрнең барсын да укыдыңмы икән соң? Исемлегеңне бир әле!

— Укыдым.

— Китер әле китаплар исемлегеннән, китер!

Рафис, кәгазьләр актара торгач, бер битне алып бирде.

— Кара.

— Ә «Слово о полку Игореве» турысында хәзер генә плюс куйдың, әйеме? Әйт дөресен, хәзер генәме?

Малай күлүеннән туктады һәм ялт итеп әтисенә караш ташлады. Әтисе, боларның сүзен ишетмәгән төсле, урам як тәрәзәдән карап тора иде.

— Укый башлаган идем мин аны, әллә нигә аңлашылып җитмәгән төсле булды,— дип акланырга ниятләде Рафис.— Авыр язылган.

Шунда әтиләре сүзгә кушылды:

— Бездә ул борынгы әдәби истәлекне яхшылап аңлатып биргән китап бар, улым. Анда барысын да бәйнә-бәйнә төшендергән. Сул яктагы шкафның өченче киштәсеннән кара әле. Әйе, әйе, шуннан. Таптыңмы? Иң әүвәле текстның үзен игътибар белән укып чык, аннары менә шул китапчык белән танышырсың... Инде сөйлә, авылда ничек? Әбиең исән калдымы? Син ниләр майтардың?

Рафис сөйләргә иренми. Очын-очка ялгап оста гына сөйли дә белә. Хафиз моны Гөлмәрьямнең тырышлыгыннан күрә, чөнки әнкәләре исән чакта балаларның фикерне бәян итә белүенә тоташ игътибар бирүчән иде. Ләйсәнне дә, Рафисны да бәләкәй чакларыннан ук янәшәсенә утыртыр иде дә теге яки бу көнне күргәннәрен, олылардан ишетеп белгәннәрен, балалар бакчасында китап укыганда отып калганнарын тезептезеп сөйләтер иде. Сабый тотлыгып калырдай булса, иплэп кенә сорау бирер, фикерен калыплый алмыйча интексә, үзе җөмлә төзешеп, шуны балалардан кабатлаттырыр иде.

— Авылда бик яхшы, әткәй,— дип тезеп китте Рафис.— Ләйсән апа юк, син дә әллә нигә бер генә килеп чыгасың. Әбием белән килешеп була. Басуга дисәм, басуга бардым, балыкка дисәм, балыкка йөрдем. Беләсеңме, әткәй, Зиннәтулла абый комбайнында мин утыз гектар бодай урдырдым.

— Кайсы Зиннәтулла икән ул, Рафис? Анда комбайнчы ике Зиннәтулла бар. Атаклысы, бик шәп эшли торганымы?

— Зыятдин бабай малае. «Дан ордены»ның өчесен дә алган Зыятдин бабайны беләсеңдер ич?

— Әйе, әйе,— диде әтисе.— Беләм. Шул. Бикморзин. Я, ярый. Ә син ничек урдырдың?

— Штурвалда мин йөрдем. Шул Зиннәтулла абый карап барды. Аның үз малае да җәй буе комбайнда... Зәбир... Ялга туктагач, Зиннәтулла абый әйтә, менә, Рафис, үзең салган тезэмнәр бодаен чәйнәп кара да мин урдырган тезэмнекен кап. Аермасы бармы икән, ди. Ашап карадым каравын, тик тәмен аера алмадым. Зиннәтулла абый әйтә, шәһәр малае шул син, энем, авызың тәм тоймый әле, ди. Үзең салган тезэмнәрнеке эре дә, тәмле дә булырга тиеш, ди.

Хафиз көлеп куйды.

— Дөрес әйтә, бик дөрес!

Рафис, «тукта, көлмә әле, әткәй» дигән кебек, әтисенә карады да тагын сөйли башлады.

— Бераздан үзем дә белеп алдым инде. Эшләп ашагач, тәмле була дигән сүзе икән...

Әтисе хуплап куйгач, малай тагын да дәртләнебрәк сөйли башлады. Хафизның да колак салып тыңлар исәбе барлыгы сизелеп тора иде. Ләйсән генә, «синең сүзенне тавык та чүпләп бетерәсе түгел» дигәндәй, кул селтәде дә аш өлгертергә кухняга чыгып китте.

— Әкәмәт кеше ул Зиннәтулла абый. Икмәк ул, энем, эчке эшләр министры да, тышкы эшләр министры да, политический деятель да ул, ди. «Ничек инде ул алай?» дигәч, «Шула-а-ай!» дип кенә сузды. Икмәк

мул булса, тамак тук, күңел көр, авылда да, калада да эшләр гөрләп бара, ди. Икмәк ул политик дигәнен дә аңлатты. Мең тугыз йөз алтмыш өченче елны, ди, илнең кайбер урыннарында уңыш начар булгач, корылык бәла салгач, чит илдән байтак бодай сатып алдык. Һәй, капиталистлар куанды шунда, һәй, керештеләр безнең гайбәтне чәйнәргә, ди. Сатып алырлык хәлебез булгач, бер баксаң, без мескенмени, я әйт, ди. Шулай да шаулап карадылар! Янәсе, социалистик строй промышленностьта гына алдыра, авыл хуҗалыгына социализмның хәле мөшкел... Әнә кая бөгәләр бит алар тал чыбыкны! Шул кабахәтләр кулыннан уен картасын сугып төшерер өчен генә дә уңышны бермә-бер артык аласы иде, ди.

Хафиз улының җилкәсенә кагылып куйды.

— Руслар борын-борыннан: «Хлеб — всему голова»,— дигәннәр. Икмәк ул — дөньяның тоткасы, улым.

Бу мизгелдә Хафиз, улының өлкәннәрчә сөйләшеп утыруына сөенү белән бергә, комбайнчы Зиннәтулланың гади, ләкин шундый оста итеп аңлата белүен чын күңелдән хуплый иде.

— Әбиең авырмыймы?

— Соң әле үзең барганга да ничә көн генә ич. Һаман шулай йөри инде ул. Иртән тап-таза, кичкә түшәккә ауган чагы да була. Мин аның сөйләгәннәрен магнитофонга язып кайттым, әткәй.

Рафис җәлт сикереп торды һәм кечкенә өстәлдәге «Комета» магнитофоны шнурын токка тоташтырды, тавыш язылган тасманы әйләндерә башлады. Иң әүвәле малайның үз тавышы ишетелде. Ул тамак төбе белән генә сөйләмәкче, нияте — Левитаннан ким булмаска, ләкин барып чыкмаган. Тавышы сынып-сынып китә кебек. Бер урында егетләрчә яңгырап ала, икенче сулышта — бөтенләй бала-чаганыкы.

— Тыңлагыз, әбием сөйли. Микрофон алдында Аккүл районы, Гөлтөркем авылы гражданкасы Мәликә Кадергулова...

Шул сүзләрдән соң магнитлы тасмада нәрсәдер шытырдап алды, кош чыркылдаган тавыш ишетелде, сузып әтәч кычкырды. «Бакча якның да тәрәзәсе, ишегалды ягыныкы да ачык булган икән,— дип уйлады Хафиз.— Ә-әй, тавыш операторы!»

Аннары Мәликәттәй тавышы килеп чыкты: «Нәрсә дип әйтим соң, Рафис балам?»

Тагын пауза. Рафис магнитофонны туктатып торган булырга тиеш. Әбисенә консультация ясаганга охшый. Менә, ниһаять, Мәликә әби сөйли:

«Оныгым Рафисның җәйге каникулда яныма кайтуына бик сөендем. Алланың рәхмәте төшсен. Рафис бик зур үскән. Бик акыллы, итагатьле. Эшкә дә булган. Ничә көн комбайнга йөрде. Шулай кирәк, улым. Игеннең ничек үскәнен белү кирәк.

Үзем, әлхәмделиллаһи, әлегә исән-сау. Барлык балаларыма да исәнлек-саулык, җан тынычлыгы, тәүфыйк-бәхет телим. Дөньялар тыныч булып, матур гомер итсеннәр. Ата-ана үз баласының рәхәтен күрсен, балалар ата-ана назыннан аерылмасын. Хафиз улыма сәлам әйтәм. Ләйсән кызыма да күптин-күп сәлам. Минем яныма ешрак килегез. Карт кешенең хәлен белеп булмый».

Шуннан соң Мәликә әби, дөньясын онытып, кычкырып-кычкырып нииндидер дога укый башлый. Ә тасма бер чорнавычтан икенчесенә савыла да савыла...

Әнисенең догалары язылган тасма әйләнгәндә, Хафиз уйлап утырды: нигә бу тикле диндар безнең әнкәй? Ике сүзнең берендә хода. Чыкылдап торган атеист әткәй дә йогынты ясый алмаган, күрәсең. Әллә, киресенчә, әткәй үлгәч, аллага сыенуы арта төштеме? Картая-картая кеше гайре табигый көчкә таянырга омтылучан буламы? Дөнья җиңел булмады әнисенә, ай-һай ла, җиңел булмады. Ирен, колхоз тәзүдә башлап йөргәне өчен, утызынчы елларда ук кулаклар каты яралаган. Сугыш башлан-

һәлак булуы хәбәре өстенә ире гарип булып кайтып төшкән. Инвалид көенә генә дә яшәсә икән... Кырык өчнең азагында өченче улын — Хафизны ут эченә озатып калды. Бер тилмергән йөрәккә килә тора бит ул, кырык бишенче елның апрелендә, сугыш менә бетә, менә тына дигәндә, Хафизның үлеме турында хат алды. Ике айдан соң госпитальдән улының хаты килгәч, ана акылдан шашар дәрәҗәгә җитте. Телеграмма биреп, Хафизның исәнлеген раслаган җавап алгач та, ике атна буе урын өстеннән тора алмый ятты... Бөтенесе дә бер йөрәккә җыелган. Әле дә түзә адәм баласы. Хәзер инде ул карчык бүгенге рәхәтемне, бүгенге бәхетемне хода күпсенмәсен дип ялвара торгандыр. Шулайдыр, күңеле курыккан кеше ниләр генә уйламас!

Магнитофон тынып калды. Хафиз, уйларыннан арынып:

— Бу язманы әйбәтләп җыеп куй, улым. Бозылырлык булмасын. Язып бик яхшы иткәнсен,— диде.

Ана — һәркем өчен иң изге зат. Мәликә карчык та Хафиз өчен шулай. Улы үзе олыгаеп баруга һәм оныклары балигъ булып килүгә карамастан, чал әнисе баласы хакында бүген дә моннан егерме ел, утыз, кырык ел элек булганча кайгырта, көенә, хафалана.

Мәликәттәйне бүгеннәрдә Хафизның сынар канатлы кош булуы бик борчый. Үткән дүшәмбедә «Коммуна» колхозына баруынча, юл уңаенда янына кергәч тә, чәй янында тел төбендә һаман шул мәсьәлә булды. Хафиз аның сүзен җөпләп утырудан узмаганны чамалагач, карчык туптуры сөйләүдән дә тартынмады.

— Ләйсән быел унынчыга бара, Хафиз балам,— диде ул, фикерен мөмкин кадәр нигезле итәргә теләп.— Сабагы бигрәк авыр буласы. Сине дә, Рафисны да тәрбия кылырга да кирәк. Аш-суы, чәе, табак-савыты, һай, бетәмени ул өй эше! Җыештыручыгыз кем әле, исемен оныттым рәхмәт төшкеренең, уа-юа да соң, барысына да ул гына да булышып бетә алмый инде. Аннан ары гомер дустысыз, киңәшчесез, таянычсыз яшәү — кысыр чәчәк гомере, Хафиз балам. Тол тормадың түгел, тордың. Сабыр иттең, рәхмәт. Гөлмәрьям киленнең рухы рәнҗемәс, боерган булса. Әй мәрхүмә...— Мәликәттәй туздырып бәйләгән башъяулыгының читен күзләренә китерде, яшь бөртекләрен сөртте. Фәрештәгә тиң иде мәрхүмәкәй. Булыр, булыр да, андый хатын сирәк булыр...

— Ярый, әнкәй, мин юлда булыйм әле,— дип, Хафиз чәй яныннан тора башлаган иде, Мәликәттәй кул ишарәсе белән аның кузгалмый торуын үтенде. Хафиз утырды.

— Күптән үземчә уйлап, хәерлегә багышлап йөри торган бер уем бар, балам:— Мәликәттәйнең яшьләре кипкән, йөзе үтә җитдиләнгән, кашлары арасыннан югарыга сузылган җыерчыгы тирәнәеп киткән иде.— Әгәр дә мәгәр, мин әйтәм, бер ходаның үзенә тапшырып, Гөләндәмгә өйләнсәң, ә? Белеме бар, гөрләтеп эшли торган урыны бар, ут кебек үткен, уңган. Балаларны да читкә тибәрәсе юк, туган апасының бәгырь җимешләре, ә? Акылы-фигыле, аллага шөкер. Төсен-битен, буенсынын әйткән дә юк инде, сөбханалла, күз тимәсен... Башыңа шундый уй кереп чыкканы бер дә булмадымы?

— Юк шул, әнкәй.

— Булмаса, уйла, менәтерә. Мин сиңа начарлык теләп әйтмәгәнне беләсең, балам.

— Беләм, әнкәй, рәхмәт.

Әнисе сүзен очламаган иде әле.

— Бер көннәрен безнең «Ватан» колхозына ни йомыш белән килгән булгандыр, минем яныма да кереп чыкты. Чәчәк тә бер, ул да бер, елмаеп, балкып тора, ходаның хикмәте. Сүзне, мин сиңа әйтим, шул тикле җиген җиккә китереп сөйли, авызына гына карап утырырсың.

— Анысына шикләнмим, әнкәй... Я, мин кузгалыйм. Эшләрем байтак. Сиңа бик рәхмәт. Авырма, әнкәй, таза-сау яшә. Тагын килеп чыгармын әле.

Хафиз хушлашып чыкканда, Мәликәттәй янә аның хәтеренә киртләп куйды:

— Мин биргән кинәшне ныгытып уйла әле, балам. Үз үтерми, ят ярлыкамый, дигәннәр. Балалар бар бит...

Әбисенең магнитофон тасмасына язган тавышын тыңларга дип түр якка чыккан Ләйсән, магнитофон шып туктагач, Рәфис кассетаны китап шкафының ян бүлмәсенә куеп маташканда, әтисенә тагын бер яңалык әйтте:

— Рафис чормадагы кәгазьләр арасыннан бабайның көндәлеген тапкан бит, әткәй. Әбием белән укыганнар да, акка күчерәм, язу машинкасында бастырам дип алып кайткан.

Хафиз кинәт әсәрләнеп китте һәм:

— Шулаймыни, улым? Нигә әйтми торасың? Кая әле, кая? Теге елларны ничек минем күзгә чалынмады икән соң ул? — диде. Улы аңа саргаеп беткән бер юка дәфтәр китереп бирде. Аның кайчандыр зәңгәр булган, хәзер инде төссезләнеп калган тышына «Кадергулов Галиулла. 1944 ел» дип язылган иде.

Хафиз беренче битне ачты. Анда укырга-язарга үзлегеннән өйрәнгән олы кешенең кулы белән язылган борчак-борчак хәрефләрдән торган сүзләр тезелгән иде. Юллар тигезлеге дә сакланмаган, хәреф хаталары да аз түгел. Аның каравы, сүзләре күңелгә бик, бик якын.

«Тәвәккәлләдем январь аеның 15 нче числосында, искечә яңа елның икенче көнендә. Госпитальдә әрнегән минутларда әйтә идем: гомерем булып, туган туфракка кайтып ирешсәм, күргәннәремне балаларыма вә аларның балаларына язып калдырырмын, дип. Теләгем чынга туры килде. Туган нигезгә кайтып егылдым. Только язасы зря дә кыен икән. Башымда фикер дә бар, сүзен таба алмыйм. Булмады әле бу. Нәзерем җилгә очмасын дип кенә язып куйдым.

Январьның 20 нче көнендә янә дә кулга карандаш тоттым. Язам дип тотынмаган да булыр идем. Мәликә утырып елагач, йөрәгем урыныннан купты. Ул, мескен, минем өскә карап, мине җәлләп елый бит инде. Малайларның үлгән хәбәре килү аның егәрен алган. «Балакайларым Тәбриз белән Нәфис чәчәк күк чакларыннан кара гүр иясе булдылар. Кай җирләрдә генә тилмереп җан бирделәр икән инде бәгырькәйләрем? Хафизыбыздан да хат килми. Әй, ходаем, анысының да гомере киселдеме соң әллә инде?!» — ди.

Мин юатырга дип аның янына барам. Янәшәсенә килеп туктагач, үземә дә бихисап кыен булып китә. Аның да йөрәк мае сыза. Ярты адәм бит мин хатыным янында. Сыңар аяклы ир. Минага эләгеп шул хәлгә төштем. Алга барган чакта, һөҗүмнең хәл кылгыч минутында шулай булды. Әллә кисмәскәме дип тә духтырлар тырышып караганнар иде, гангрин китте, чери башлады. Ничарадан бичара, өченче операциядә кистеләр.

Ну шулай булса да, хәсрәт шәлен бөркәнеп утырыр заман түгел. Башны югары тотарга кирәк. Кеше йөзенә, халык күзенә туры карап сөйләшергә полный правобыз бар. Совет власте өчен ике улым башын салды, үзем канымны да, тәнемне дә җәлләмәдем. Өченче улым бүгенгесе көнне ут эчендә. Мин кайтып төшкәндә аның китүенә өченче ай иде инде. Бу газаплар, бу әрнүләр, дәрья булып аккан кан вә күз яше каргыш булып Гитлерның үз башына капланыр көннәр якынлаша. Җиңүебезгә әлек тә мин бер бөртек тә шикләнмәдем. Хәзер фашистны сытасыбыз кояшлы иртә кебек ачык.

Февраль аеның 12 се житте. Правлениега бардым. Председатель һәнүзә белән сөйләштем. Соңра партсекретарь — мәктәп директоры

Хатимә дә килеп керде. Бер эш бирегез, болай тик ятa алмыйм, дидем. Каравылга куюларын сорадым. Аучы Хәйрулладан мылтык, патроннар сатып алдылар. Шуларны миңа тапшырдылар. Чәчүлек орлык келәтләре янына, авыл башына, төнге каравылга чыгам.

Шуны кайтып әйткәч, Мәликә тагын елады. Бу көнгә калырбыз дип кем генә уйлаган иде соң, ходаем, ди. Председательлектән киткән идең ләбаса, ди. Ничево! Үзебез төзегән колхоз, анда кем булсаң да хурлыгы юк. Кан коюлы яу вакытында читтә басып тору хурлык...

Мартның 16 сы. Өйгә Бикморза Зыятдинның хатыны килеп китте. Иреннән кичә генә алган хатны тота килгән. Ник дигәннән, Зыятдин авыл халкларен бәйнә-бәйнә сорашкан да, минем хәлгә особый туктап язган. Авылга кайтып ирештеме, үз аягы белән йөри аламы, кеше ярдәменә мохтаҗ түгелме? дигән. Бу хатны алу белән, Галиулланы барып күр, чтобы да полный җавап язарлык булсын, дигән. Стройдан ватылып чыктым, бер читкә сибелеп калдым дип уфтанмасын, арыслан төсле сугышты, без бер дә истән чыгармыйбыз аны, дигән. Үзен «Дан ордены» белән бүләкләгәннәр икән, шуны да язган.

Без Зыятдин белән авылдан бер таңда чыгып киткән кешеләр. Минн ранный булып ауганчы сугышта да бергә булдык. Арыслан дигәндә, менә кем арыслан, Зыятдин арыслан. Разведчик ул. Мин барында гына да ничә тере немец тотып кайтты ул иптәшләре белән... Авылда чакта, сугыш чыкканчы мин аны йомыкый бер бәндә дип йөри идем. Кемнең кемлеге илгә-көнгә кыен килгәч ачыла шул.

Шунысын гомере онытасым юк, кырык өчнең яңа ел таңын каршылагач, Зыятдин миңа шул төнне күргән төшен сөйләгән иде. Галиулла, ди, имеш, без синең белән Зөя аръягында урак урабыз икән, ди. Мин көлтәләрне кысып бәйли торам, син зуратка тезәсең, ди. Мин көлтәне саксызрак бирдем дә, җиргә шыбырдап бөртек коелды. Син мине бик орыштың, мин шуңа бик кәефсезләндем. Уянып китсәм, фашист козгыны бомбалар ташлый, землянка түбәсеннән биткә шыбыр-шыбыр туфрак коела икән, ди... Тавык төшенә тары керә, дигәннәр. Рас инде ул. Без, крестьян халкы, сугышта да я чәчү вакытын, я урак өстен төштә күреп юана идек. Зыятдин инде бигрәк тә. Авылда аннан уңган игенчене табуы читен...

Апрель аеның 18 ендә яздым моны. Бүген сабанга чыктылар. Елның килеше матур күренә. Игеннәр уңса, халыкның да тамагы туяр, фронтка һәм рабочи класска да ризык җитәрлек булыр...»

Искереп беткән дәфтәрнең җиде-сигез битенә бары шул сүзләр генә язылган. Апрельнең егермесендә колхозның чәчүлек бодаен урларга килүчеләр каравылчы коммунист Галиулла Кадергуловны кабахәтләрчә үтергәннәр...

Хафиз урыныннан авырлык белән генә торды һәм дәфтәрне семья альбомы эченә салды.

Хыялын күпме көчләп караса да, ул этисен һич ничек шыгырдавык протез кигән килеш күз алдына китерә алмады. Ул аны авылның иң таза гәүдәле кешеләреннән берсе итеп хәтерләп калган. Зур күзләр, кылыч борын, зур ихтыяр көчен әйтеп торгандай, алгарак чыккан очлы ияк, уң ягында бәләкәй чагында тай тибүдән калган эз. Ул эз яңа туган ай шикелле кыйгачланып ялтырый иде. Аны төк томалаганы булмады, гел ялтырап йөрде. Галиулла агай сакал-мыек үстермәде. Кырык эше кырык җирдә кырылып ятса да, чабуына ут капкандай тыгыз чагы булса да, көн аралаш кырынып иде.

Дөньядагы барлык малайлар кебек, Хафиз да этисе белән чиксез горурлана иде. Анардан батыр, анардан акыллы кеше юктыр дип чын күңелдән ышанып яшәде ул. Язгы мәлне, ни арба, ни чана чагында, Галиулла агай басуларны карарга атка атланып чыга иде. Хафиз аның кайтканын бик озак сагалап тора. Әтисенең авыл башыннан күренүе —

малай өчен шатлыкның шатлыгы. Карагыз сез председательне — Хафизның этисен! Кинодагы Чапай лабаса! Папаха белән мыек җитми дә кылычы юк. Ә кожаны бер дә Чапай плащыннан ким түгел.

Мондый көннәрнең Хафиз өчен тагын бер сөенече була. Басудан кайткач, этисе Җирән кашканы конюшнига илтергә Хафизга куша, чөнки ул төпчек малай, олыларның вакыты юк. Тәбриз һәм Нәфис абыйлары көне-төне ат җигеп эшлиләр, аларның кашкага исләре китми. Ә Хафизга тансык та, кызык та.

Галиулла агай шактый кырыс холыклы кеше иде. Аның кемнең кем булуына карамыйча, күңелендәген ярып салу гадәтен Хафиз әйбәт хәтерли. Районнан килгән вәкилләр белән дә, киреәксә, өстәл сугып тартыша белә иде. Колхозны яклап җан атканадыр, авылдашлары аны олылыйлар, ул әйткәнгә һәр чакта колак салалар иде.

Шундый кырыс, тарамаган-язмаган холыклы ир Мәликәсенә карата балавыз белән бер иде. Хатынының күңелен ничек күрергә белми аптырап чыгар иде. Бик яраткандыр, күрәсең, бүтәнчә ни димәк кирәк?

Менә шул кешенең язмалары. «Башны югары тотарга кирәк» «...бу сугыш гел сыкрану, гел сагыш кына түгел, безнең халык Октябрь строена иманы камил икәнен күрсәтте бу сугышта. Значит, бу сугыш — каты сынау һәм безнең чакматаш булуны күрсәтә», «үзебез төзегән колхоз, анда кем булсан да хурлык юк»... Моны бит аяксыз калган игенче, тормышта рәхәттән бигрәк михнәтне күбрәк татыган кеше язган. Картның йөзбласы ачык булган шул!

## 6

Кичке чәйгә әзерләнгәндә, ишек кыңгыравы чылтырады. Рафис, йөгереп барып ишек ачуга, шатланып кычкырды:

— Ур-ра! Алма апа килде! Туш уйнагыз, туш!

Гөлəндәм дә Рафисны бусага төбендә үк кочаклап алды да битеннән үпте.

— Исәнме, кара чутыр! Сине күрмәгәнгә биш былтыр булды. Гөл-Төркемгә баргач та очрата алмадым, балыкка киткән идең.

Шул арада Ләйсән дә килеп житте.

— Исәнме, алма апа! Әйдә, уз.

Рафисны кочагыннан ычкындыргач, Гөләндем Ләйсәннең иңнәреннән сыйпады һәм эш бүлмәсеннән килеп чыккан Хафиз белән сәламләште.

— Хәерле кич, җизни. Һич өйдә туры китерер хәл юк сезне. Урак өсте дип, дөньядан үтеп йөрисез, әй. Котлыйм, августның бишенче бишкөнлегендә безнең Аккүл районы ашлык сату буенча дүртенче урынга чыккан икән ич. Беренчелекне алырга насыйп булсын!

— Яхшы сүзеңә рәхмәт, Гөләндәм. Уз, әйдә. Мактап йөрисең. Чәй өлгергәч килдең.— Ул Гөләндәмнең кулындагы сумкасын алып куйды, җиңел плащын чөйгә элде.— Ашлыкны планнан тыш сатарга керешкәч, беренче урынга чыгарга да ният бөтенләй үк юк түгел. Урасы да күп, тезмәнәргә салганы да аз дип булмый. Көннәр генә чырай сытмасын. Көнбатыштан бик зәһәр болытлап маташа. Әйдә, әйдә, түр якка уз. Өстәлне анда көйлибез.

Гөләндәм залга узды, һәм киң, якты бүлмәгә үзе белән нур балкышы алып кергәндәй булды. Сизелер-сизелмәс кенә кара бөрчекләр төшкән ак тестәге җиңел йон күлмәге, затлы кара туфлие, җилбәзә сыман гына итеп тоткан кечкенә кул сумкасы аңа бик килешә иде. Ак кием кояшта янган озынчарак йөзен ачып тора. Карлыгач канатыдай кашлары зур зәңгәр күзләренә кара кайма булып тора. Керфекләре куе һәм нур сөңгесе төсле. Төз борын. Чәчәк таҗы кебек иреннәре пешкән чия төсенә кереп, күперебрәк тора. Җитмәгән җире калмасын дигәндәр, зифа буй-

лы, нечкә билле бу чибәрнең сул битенә тасигать көрәнсу-кара бер миң дә төртеп куйган. Чәч дигәндә — хәзинә менә кемдә. Туздырып салса, аның толымнары җилкәсенә ефәк шәл бөркәнгәннән ким булмас иде. Яшь чагында Гөлмәрьям дә шундый иде. Юк, Гөләндәм чибәрлек ягыннан апасы ише генә түгел бугай ла!

— Чәй янына мин күчтәнәч алып килдем,— диде ул бик гади, бик тә үз итеп.— Алмалар дип уйлыйсызмы? Алма да бар, менә дигәне. Вазаң кайда әле, Ләйсән акыллым? Шып тутырыйкчы. Алмадан бүтәне дә бар. Менә!

Гөләндәм зур сумкасыннан алмалар бушатты һәм өстәлгә бик матур шешәле шәраб китереп куйды.

— «Абхазия букеты»! Бухгалтерыбыз Нина Николаевна ялдан кайтты. Сухумидан. Аның күчтәнәче. «Мин моны кем белән авыз итим инде?» дип уйладым да сезгә күтәреп килергә булдым. Сезгә насыйп сый икән.

Хафиз әтисе һәм туганнары турындагы уйлардан арынып беткән иде инде, кәефе яхшырып бара иде. Гөләндәмнең тәкъдимен ул хуп күрде.

— Виноның асылы. Аннан баш тартып булмас. Балдыз алып килгәч, бигрәк тә...— дип көлде.

Чәй янында һәркем соңгы яңалыгын уртаклашты. Рафис белән Ләйсән телендә яңа уку елы, яңа укытучылар булды. Хафиз Гөләндәмнән җиләк-җимеш питомнигындагы хәлләрне белеште. Азактан Ләйсәннең пианинода уйнавын сорадылар.

— Алма апа җырласа, мин уйныйм,— диде Ләйсән. Я, әйтегез, нәрсә уйнарга? — Кыз көрән төстәге елкылдап торган пианино янына барып утырды, капкачын ачты һәм озын, нәфис бармаклары белән клавишалардан йөгереп узды. Кинәт исеп куйган җилнең су өстен шадралатып үтүен искә төшерә торган авазлар яңгырады.

— «Өмет»не уйна, акыллым! — Гөләндәм аз гына да назланып тормыйча җырларга ниятләде. Җырлыйсы килә иде аның. Шәраб тәэсире идеме, гомумән, җанының таләбе булдымы, анысын үзе дә өзеп кенә аңлата алмас иде. Ләкин җырлыйсы килүе хак. Җырлаганда бары бер җырны — «Өмет»не җырларга тели ул. Бүген фәкать шул җыр ошый аңа, чөнки... чөнки ул җырны Хафиз да ярата.

Рафис тиз-тиз магнитофонын көйләде. Аннары микрофонны пианино өстенә китереп куйды. Алма апасының җырлавын бик ошата ул, магнитофон тасмасына язуы да тәүге тапкыр түгел. Азактан язманы тыңлап карыйлар, яңгырашның ничегрәк килеп чыгуын бәялиләр.

Ләйсән кереш аккорд алуга, Гөләндәм җыр башлады.

Язгы күкрәү булып күкрәрмен дә
Төнге яшен булып яшьнәрмен;
«Мин исән!» дип шулай хәбәр итеп,
Өмет канатында яшәрмен.

Алсу чәчкә булып атармын да
Юлларыңа хуш ис чәчәрмен;
Күңелемдә сине мәңге назлап,
Сүнмәс өмет белән яшәрмен.

Җырлый торгач, уйга бирелдеме, әллә булмаса сүзләре хәтереннән чыгып киттеме, соңгы дүрт юлны ул тиз генә башлый алмый торды. Кереш музыканы Ләйсән кабатларга мәҗбүр булды. Аннары гына Гөләндәм, аңа ияреп, җырын дәвам итте.

Таң нурыдай сиңа үрелермен дә
Сайрар кошлар булып дәшәрмен;
«Син — гомерлек йөрәк ярам!» диеп,
Өмет үзми сагынып яшәрмен...

Җыр тәмамлангач, беравык тын тордылар.

Тынлыкны Ләйсән бозды. Ул атаклы жырчы язган көйне — «Гөлмәрьям»не уйный башлады. Ләкин жырга кушылучы булмады. Шуңа үпкәләпме, кыз ул көйне зур киеренкелек тоеп тагын бер кат уйнады да ялт итеп урыныннан торды һәм күрше бүлмәгә чыгып китте. Кечкенә чүкечләр гүя пианино кылларына сукмыйлар, аның чигәсенә кыйнап торалар иде шикелле. Кай арададыр Рафис юкка чыкты. Балдыз белән жизнәсе түр якта икәүдән-икәү генә калдылар.

Хафиз, папирос көйрәтеп, ачык тәрәзә буенарак елышкач, Гөләндәм, беләкләрен өстәлгә куеп, бармакларын «йозак» ясады да жизнәсенә текәлде.

— Беләсенме, жизни, мин киңәшкә килдем бит. Тик, зинһар, ачыктан-ачык, тел төбендә бер ни дә калдырмыйча сөйләшик әле.

Хафиз баштарак шаяртып бакты. Нинди уйлар-төште икән балдызым башына, янәсе. Шулай да Гөләндәмнең гадәттәгедән артык житдиләнүе, хәтта төсе китә башлавын күреп, Хафиз да елмаймас булды.

— Тыңлыйм, Гөләндәм, сөйлә.

Гөләндәм сумкасыннан пәрәвез кебек кенә нәфис кульяулыгы алды, аның читенә тоткан челтәрдән ычкынган жеп очын бармаклары белән бөтереп торды. Әйтерсең ул үзенең язмышын да нәкъ әнә шул тотрыксыз челтәргә тиңли һәм ялгыш кына эшләнгән саксыз хәрәкәтнең дә аның бөтенләй сүтелеп китүенә сәбәп буласын белә.

— Тыңлыйм, Гөләндәм.

— Мин, жизни, яшәүнең ямен тапмый башладым бугай. Нииндидер чиктә басып торам шикелле. Бер ягында — бәхетле, тулы канлы тормыш, икенче якта — бушлык. Сөрем кәтә. Шул сөремле төнне ертып-тузгытып ташларга кулымнан килми. Томан эчендә яшәү дә туйдырды.

— Сер итми генә сәбәбен дә әйт инде, Гөләндәм.

— Сәбәбен сорама, жизни. Кем сораса да сорасын, әмма син сорама. Үзең төшенергә тиеш идең шикелле...

Хафиз Гөләндәмнән теләсә нинди үткен сүз көгелмәгән фикер ишетергә әзер иде, әмма аның болай батыраеп, куш мәгънәле ым кагуын көтмәгән иде. Шуңа күрә, Гөләндәмнең тел төбен асылда төшенгәне хәлендә, кинәт кенә ачылып китәргә теләмәде. Белмәмешкә салышыбрак төпченә бирде.

— Эшеңдә зур чатаклык бармы? Директорыгыз белән килешми башладыгызмы әллә? Алай дисәм, Александр Порфирьич сине мактап кына тора.

Гөләндәм йөзендә ризасызлык билгесе сизелде.

— Директор яхшы кеше безнең. Аның белән эшләргә дә эшләргә генә... Шәп работник. Гадел.

— Коллектив белән, белгечләр белән ботка пешми башладымы әллә?

— Пешә, бик пешә. Безнең питомник коллективы кебек коллективны эзләп табасы бар әле аны.

— Соң шулай булгач? Районда яисә Казанда берәр рыцарь пәйда булдымы? Шашкын хисләр өермәсенә шул сәбәпчеме?

Гөләндәмне ярсу алды, ләкин ул кычкырып бер сүз дә әйтмәде, Хафизга томырылып-томырылып карап торды да, башын беләкләренә салып, сулкылдап елый башлады. Хафизны ток суккан шикелле булды. Ул тиз-тиз атлап Гөләндәм янына килде, аның жилкәсенә кагылды.

— Нишләвең бу, Гөләндәм? Тынычлан, зинһар. Ярамый болай. Тынычлан.

Шунда Гөләндәм кинәт башын күтәрде, аның битен яшь тамчылары чылаткан иде. Ике күзе тулы яшь. Ул, тагын елап жибәрмәс өчен, иренен тешләгән.

Хафиз, аның маңгай чәчен сыйпап, тынычландырырга теләгәндә, Гөләндәм дәррәү генә урыныннан торды да жизнәсенең күкрәгенә капланып үкси башлады.

генә күрмәмешкә салышасың...

— Гөләндәм, акылына кил! — диде Хафиз. Аннары Гөләндәмне ипләп кенә диванга утыртты. Гөләндәм исә диван култыксасына капланып елый бирде һәм гайре табигый пышылдау белән:

— Бүлдермә мине! Авыз ачканмын икән, бөтенесен әйтим: гомерлек үкенеч булып калмасын! — дип тезеп китте.— Апа исән чагында бу хакта сүз дә була алмый иде. Ә хәзер бит инде, хәзер... Без икебез дә ирекле кешеләр.

Турысын әйткәндә, Хафиз шушы рәвешле булмаса да, мондый сүзнең чыгарын көткән иде. Сизенә килде ич ул. Әнисенең читтән чөй кагуы да юкка гына түгелен аңлап торды. Ниһаять, менә Гөләндәмнең түземе төкәнер минутлар житте, күрәсең. Димәк, ачыктан-ачык, туп-туры сөйләшергә кирәк.

— Безнең арада бәйләнеш булуга исәп тотуның үзеңне балалы иргә гомере буена бәйләү икәнен уйлаганда ни дәрәҗәдә җитди син, Гөләндәм?

— Кирәк дәрәҗәсендә.

— Гаҗәп!

— Ни сәбәпле мондый катгый карарга килдең әле син, җизни? — Гөләндәм диванга җайлап утырды, күлмәк итәген тез башларына тартып куйды, күзен-битен сөртте, чәчен рәтләде.— Ни сәбәпле?

— Беренчедән, Гөләндәм, мин үземне, үз характерымны яхшы беләм. Һәрхәлдә, үз-үземне тулысынча аңларлык, хәрәкәтләрем, башкарган эшем өчен җавап бирерлек яшьтә.

— Тагын?

— Тагынмы? Сине дә беләм. Минем күңелемдә сиңа карата сагаю бар. Гафу ит, сүз тормыш юлдашы, хатын итү турында барган очракта диюем. Балдыз буларак бер сүзем дә юк...

— Сине мин кай ягым белән шул тикле куркытам, җизни? Җиңел акыллыга исәплисеңме мине? Тотнаксызга чутлыйсыңмы? Әгәр минем язмыш сукмагым синең тормыш юлың белән кушылса иде, җирдә яшәү хакым белән ант итеп әйтәм, синең йөзеңә кызыллык китермәячәкмен.

Хафиз кирәкле сүзләр сайлый иде бугай. Аның зур кара күзләрен уйчанлык басты. Белә ул: орды-бәрде итеп, ярсыган күңелгә мәңге кичермәслек яра салуың бар. Алай ярамый. Тик, хәтер саклыйм дип, ярты-йорты гына җавап бирү дә ир кешеләрчә булмаячак.

— Мин сиңа азаккача ышанып җитә алмыйм, Гөләндәм. Гафу итә күр, ләкин бу шулай. Бик теләсәм дә, бетереп ышана алмыйм. Ә соңына кадәр чын күңелдән инану булмаса, бер-береңне ир белән хатын бәйләнешенә кертеп кую тамырдан хата эш. Йөрәкләр берлеге, Гөләндәм, фикерләр уртаклыгы, карашлар аерылгысызлыгы гаҗәеп олы нәрсә ул. Кайберәүләр гомерләре буенча шуңа ирешә алмыйча дөньядан китәләр. Ямьсез тормышлы семьялар юкмы? Алар әнә шул бер җае булып яшәү юклыктан килеп туа.

— Ирдән аерылган булуым гына миңа ышанычны җуярга нигез бирмидер дип уйлыйм, җизни.— Гөләндәм, аяк астында җир тетри башлавын тойгандай, Хафизны сабыр гына тыңлый алмас булды.— Яшьлегендә хаталанган бер мин генәме?

— Ирең белән аерылышуны мин сиңа гаеп итеп куярга уйламыйм да, Гөләндәм. Юк, хикмәт синең табигатеңнең, холкыңның асылында. Нигезендә дип әйтимме?

Шуны ишеткәч, Гөләндәм, мангаена каты итеп чиерткән кебек капыл гына башын артка атты. Хафизның шул сүзләрен йөрәгенә артык авыр алды, ахрысы.

— Аңлашыла. Кайчаннан бирле миңа ышанмыйсың инде син, җизни? Дүрт елдан бирле, әйеме?

Хафиз салмак кына, ихтимал, артык салмактыр, җавап кайтарды.

— Үзең дә уйлагансың икән алайса. Уйлану, атлаган адымыңа чит кеше күзе белән карарга тырышып бәя бирү, кылган эшеңне кабат уйлап карый алу — котылгысыз зарур сыйфат, Гөләндәм...

Гөләндәм чәнчүле итеп елмайды. Мондый елмаю да килешә иде аңа. Хафиз балдызына туп-туры карап торды.

— Самоанализ сәләтем бар әле, димәк, минем. Кешеләр исемләгәндә калам әле, димәк? — Гөләндәмнең ачуы чыга язды.— Дүрт ел элек мин ахмаклык эшләдем, икърар итәм. Кирәксә, кешеләр алдында сөйләп, ахмаклыгымны таныйм. Аңа да көчем җитә. Тик ул эшкә барыбер энә очы кадәр дә үкенмим. Үкенмим! Син моны аңларлык түгелмени соң, җизни?

Инде Хафиз көлемсерәде.

— Әйе, аңлый алмыйм. Сеңелесенең туган апасына хыянәт итүдән тайчанмавын акылым сыйдырмый. Шуннан соң аңа ничек итеп ышанмак кирәк? Әйтәм ич, без холкыбыз-фигылебез ягыннан да, дөньяда була торган хәлләргә бәя бирү мәсьәләсендә дә бер-беребездән ерак кешеләр. Икебез ике котыпта димәсәң...

...Моннан дүрт ел элек, августның беренче көннәрендә, Гөлмәрьям Казанда спецбольницада ятканда булган иде ул хәл.

Шимбә көн кичен, балаларны карашырга, йорт эшләрендә булышып китәргә дип, Гөләндәм килде. Әниләре дә больницада булгач, балалар аңа чытырдап сарылдылар. Ул кунып калды.

Хафиз өйдә озак кына эшләп утырды. Төн уртасы авышкач кына ятты. Таң якынлашканда булса кирәк, ул янына елышкан җылы гәүдәне абайлады. Бер генә мизгелгә, йокысыннан айнып киткәнче генә, янәшәсендә Гөлмәрьямен тойгандай булды һәм читкә тайпылып, аңа урын биргәндәй итте. Ләкин бит бу Гөлмәрьям түгел иде, Гөлмәрьям була да алмый. Аңа сарылып, кайнар сулышы белән аның битенә ябырылучы... Гөләндәм иде.

Хафизның йокысы бик тиз ачылды. Ачылды гына дип әйтү аз, бөтенләй качты, юкка чыкты. Әмма ир уртасы кеше, йорт башы, төн берендә үз квартирасында үзе тавыш күтәрмәс бит инде. Моның сукыр бер тиенгә кирәге юклыгы да ачык иде. Ул урыныннан төшмичә генә Гөләндәмне читкә этәрде һәм колагына пышылдады: «Бар, урыныңа барып ят. Бүтән бер кайчан да болай хаталанма. Бүгенге ялгышың да булмады дип сана. Ул буталчык төш кенә иде диген»,— диде.

«Буталчык төш»тән Гөләндәм ни дәрәҗәдә шомлангандыр, («...ахмаклык эшләдем, икърар итәм... Тик барыбер энә очы кадәр дә үкенмим. Үкенмим!» ди ич әнә), әмма Хафиз күңеленә ул хәл калын юшкын булып утырды. Аның кайдадыр әрсез чык тамчысы турында укыганы бар. Кояш нурлары белән тартыша торгач, ул тамчы үлән сабагындагы күбекле лайлага — «пәри төкерегеңнә әверелә. Аңа күзең төшеп, кайвакыт җирәнеп куясың, ирексездән кулыңны тартып аласың. Хафиз да Гөләндәм белән икесе арасындагы чык бөртеге сыман саф мөнәсәбәтнең кинәт дуамал бер адым аркасында «пәри төкерегеңнә әйләнүен кыен кичерде. Гөлмәрьям алдында да үзен нииндидер гаепле кеше кебек санаган минутлары булмады түгел.

Бүген исә ул хәлне үз исеме белән атамый мөмкин түгел иде инде, чөнки мондый мәсьәләдә иртәме-соңмы йомгак сүзе булмый калмый.

Гөләндәм үз фикерен әйтеп бетермәгән иде әле.

— Син буяуларның куесын, аргументларның суккач баш тишәрдәен яратасың, җизни. Иҗтимагый тормышта, партия эшендә шулай хәерледер дә ул. Без бит иң интим мәсьәлә хакында сөйләшәбез. Син атаган «котыплар»ны якынлаштырырлык көч бар бит әле. Ул — балалар. Синең улың һәм кызың минем сеңелем һәм энем, туган апам балалары,— диде Гөләндәм.

Хафиз ага шундук аңлатасы итте.

— Беренчедән, мин шәхси тормышымны ижтимагый тормыштан аерып карый алмыйм. Шунлыктан мин бер генә лексиконга ия кеше. Балаларга килгәндә, син үзеңә артыграк ышанмыйсыңмы икән? Синең ниятеңне алар, әйтик, Ләйсән, ай-һай, хуплармы? Мин, мәсәлән, өзеп кенә әйтә алмыйм.

— Нигә хупламасын, җизни?

— Чөнки Ләйсән — койган да куйган Гөлмәрьям. Холкы белән дә, хәтта, әйтер идем, әле бик яшь булса да, тормышка карашлары ягыннан да... Кыскасы, минем сиңа, туган апаң белән гомер иткән кеше буларак, бер киңәш бирәсем килә, Гөләндәм.— Хафиз тагын папирос көйрәтеп җибәрде һәм каршысында утырган Гөләндәм генә ишетерлек итеп тыныч кына сөйли башлады.

— Син яшь әле. Сау-сәламәт, тап-таза, чибәрлегең дә бар, үзеңә бер төрле акыллы син, кешеләр белән сыешып, уртак тел табып эшли аласың. Иренчәк түгелсең, эштән курыкмыйсың. Бер җөмлә белән әйткәндә, тормышны менә дигән итеп көйләп җибәрер өчен кирәк сыйфатларның күбесе бар синдә. Мин синең семья бәхетенә ирешүеңне күрсәм, чын күңелдән шат булачакмын. Соңламаска тырыш, тәҗрибә туплар өчен икенче кат туып булмый.

Киенергә чыкканда, Гөләндәм күрше бүлмәдә Ләйсән белән Рафисның онытылып китеп сөйләшеп утыруларын искәрде. Алай гынамы соң — я хода! — аз гына ачык торган ишектән йөрәгенә агулы ук булып кадалган сүзләр ишетте.

— Әнкәй булмый инде ул барыбер! — диде Ләйсән энесенә.— Әткәй янында шулай озакламаса...

Гөләндәм алар белән хушлашмыйча ук чыгып йөгерде. Әйтерсең лә кемдер аны якасыннан алып чыгарды. Ә бит ничә елдан бирле аны ул йортта ачык йөз белән каршылыйлар, ул килгәндә сөенәләр иде.

Урамда яңгыр җиле исә, еракта яшен яшьле-чуклы тамырларын җиргә суза иде.

Бүлмәсен ачып кергәч, ул аягындагы туфлиен генә салып ыргытты да җыеп куйган урын-җир өстенә чишенми-нитми барып ауды. Хурлык, кимсетелү, кешелек дәрәҗәсенә, намусына тукыну буа иде аны. Ул хәтта елый да башлады.

Ут кабызырга уйламады да. Күзләрен караңгы түшәмгә төбәп тик ятты. Шушы минутта аны берәрсе читтән күзәтеп торса, мөгаен, акылдан язган кешегә чутлар иде.

Ләйсән... Ләйсән ни ди бит! Әтисе хаклы, димәк. Бик хаклы! Кызыйның бөтен фикере, фокустагы кебек, «әнкәй» дигән тылсымлы сүзгә тупланган. Балалыктан чыгып бетмәгән кызның барлык хыяллары, истәлекләре, сөенечләре һәм көенечләре җепселләр булып шул сүздән тармаклаша. Сүзнең шунысына ни тикле саф, риясыз мәхәббәт салынган. Андый мәхәббәт олы кешеләрнең берсендә дә була алмый торгандыр, шәт.

Апалы-энеле туганнарның сөйләшүен ишетү аның йөрәгеннән ниндидер бер нечкә тамырны тартып өзгән шикелле итте.

Йокыга киткән кебек булган иде, Гөләндәм бик тиз уянып китте. Төш күрергә дә өлгерде шул арада. Имеш, бер кочагына Ләйсәнне, икенчесенә Рафисны алмак була, ә тегеләр рәшә эченә кереп югалалар. Гөләндәм аларны, эзләп, янына чакыра, ә балалар, аны үчекләргә теләгәндәй, күренеп алалар да янә томанга төренәләр. Гөләндәм аларга талпынып-талпынып аңлатмак була: «Сез бит балалык белән генә шулай итәсез. Беләм, әниегез хатирәсе якын, әйтеп аңлаткысыз якын сезгә, тик ул юк бит инде, бер вакытта да кире кайтмаячак. Мин янығызда булсам, сезне җил-яңгырдан мәңге ышыкларга тырышачакмын», дияргә исәбе. Юк кына, тегеләр якын да килмиләр, Гөләндәм сүзләрен колак очына да эләргә теләмиләр. Дала бөркетеннән качкан куян шикелле юкка чыгалар.

дый сүз кузгатыр идеме?! Акыллы һәм ихтыяр көченә ия булганы өчен ярата ул жизнәсен. Хафиздагы эчке тупланганлык, оешканлык, максатка омтылучанлык әсир итә аны. Дөрес, Хафиз Кадергулов инде яшь түгел, чибәрлеге дә уңып бара. Шулай да ул Гөләндәмгә очраган бер иш егетләрдән һәм ирләрдән күп мәртәбә күркәмрәк. Гөләндәм акыл көченә баш ия, чөнки үзендә көч сизә, тик ул көч кирәкле үзәненә төшеп, файдага гына ашмый әлегә. Әгәр ул Хафиз белән бергә була алса, көн үтсенгә генә яшәмәячәгенә нык ышана.

Гөләндәм бу төнне йокысыз кичте. Төн янгырлы һәм караңгы булды. Бакчада куаклар шомлы шаулады, гүя еракта дингез дулкыннары таш кыяларга бәрелеп ярсына иде. Эре тамчылар, учлап борчак сипкән шикелле, тәрәзә пыялаларын рәхимсез чәбәкләп торды. Рамнарга кадәр дерелдәде. Табигатьнең шулай илерүеннән зарланып, кайдадыр иясыз эт улады. Тонык кына булып күк күкрәде, жил тына төште һәм чиләкләп койгандай янгыр ява башлады. Бераздан һәммәсе тынды. Сирәк тамчылар куакларның юеш яфракларына, юллардагы изрәгән комга һәм бүртенеп киткән такта түбәләргә суга-суга әкрен генә тавышлап торды. Тик бу вакытлыча тыну, давыл алды тынлыгы иде. Менә күзне камаштырырлык ялтырап яшен чыбыркысы уйнаклый, бинһая зур тау ишелеп төшкән төсле күк күкрәде. Тагын тынлык булып алды. Аннары, күк гөмбәзен аркылыга-буйга шытырдатып ерткандай, бер-бер артлы яшен еланы боргаланды, сугыш кырын хәтерләткән дөбердәү чутсызга китте. Гөләндәм яшеннән курыкмый иде. Күзләрен зур ачып, бүлмәнең бер мизгелдә яктырып китүен, аннары тагын кабер караңгылыгына чумуын карап ятты. Башындагы уйлар өермәсе дә яшенле давылдан ким айкалмый иде аның.

## 7

Хафиз Кадергулов сишәмбе көнне райкомга гадәттәгедән иртәрәк тә, жилкенебрәк тә килә. Һәр атнаның шушы көнендә бюро утырышы уздырыла. Тик аның жилкенүе «җыелыш җене кагылганлыктан» яисә утырышларда рәхәткә тарып, ләззәт табудан түгел. бюро членнары җыелгач, күмәкләшеп киңәшкән, фикер алышкан, район хәлләрен уртага салып тикшергән, иң мөһим мәсьәләләрне күмәк акыл белән хәл иткән минутларны яратудан туа.

Кагыйдәгә әйләнгән тәртип буенча, нәкъ иртәнге сәгать унга бюроның жиде члены да килеп житә. Райкомның өч секретаре, район советы башкарма комитеты председателе, авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы, райкомның оештыру бүлеге мөдире һәм «Гөлстан» колхозы председателе — һәммәсе үзенең урынында була. Икенче секретарь Яков Васильевич кына соңгарса бераз соңгара. Ана һәр бюро алдыннан биш минут вакыт житми кала. Үзе болай искиткеч төгәл кеше: тәүлекнең егерме дүрт сәгатен дә минутлап бүлеп куйган. «Гөлстан»нан Гаделҗановның кичегеп килгән вакытлары була. Хафиз аны моның өчен әллә ни шелтәләми. Зур колхозның башлыгы, хуҗалыкта нинди генә четрекле мәсьәлә килеп чыкмас, нинди генә эш табылып куймас...

Хафиз, бюро утырышына кадәр сөйләшеп алырга дип, комсомол райкомының беренче секретарен чакыртты һәм эшче көчләр житешмәгән ике-өч колхозга веттехникумнан, медучилищедан студентлар жибәрергә кирәклекне, техник училищеныкыларны да читтә калдырып булмаслыгын әйтте. Комсомол райкомы секретаре бу эшне инде оештырып өлгергәнлекләрен сөйләде.

Телефон чылтырады.

— Әйе, Кадергулов. Исәнмесез! Ураздан? Хәерле иртә, Фәкыйһә апа.— Хафиз Ураз коммутаторындагы телефонисткага сәлам бирде.—

Бирегез әле трубканы, бирегез. Иртүк ни йомышы төште икән?

Хафизны, киявен, Гөлмәрьямнең этисе Исрафил абзый сорый иде. Ул гел шулай, авыл советына да, колхоз идарәсенә дә кереп шалтыратмый, туп-туры элемтә бүлегенә килә дә:

— Факиһә, наный, кияү белән сөйләшәсе иде бит,— дип куя.

— Саумы, бабай! Нихәлләрдә ятасыз? Әби сау-сәламәтме? — диде Хафиз, трубкадан тоныкын кына ишетелгән сүзләргә җавап итеп.— Минме? Бүген көне буе өйдә булам, бабай. Бюро бүген. Бю-ро! Кичләтеп? Рәхим ит, кунак булырсың. Әбине дә алып киләсенме? Машина җибәримме соң? Кирәкми? Үзең генә? Ихтыярың алайса. Нәрсә бар иде соң? Телефоннан сөйләшеп булмый дисен. Кил алайса, кил, бабай. Көтәм... Рәхмәт, Факиһә апа! Хушыгыз!

Кадергулов бүленеп калган сүзен дәвам иттерде.

...Утырыш беткәндә сәгать көндезге өчкә якынлаша иде. Исрафил абзый Хафизның бушаганын шактый озак көтеп утырды. Кабинетта кияве ялгызы калгач кына керде. Исәнлек-саулык, хәл-әхвәл сораштылар, кул кысышып күрештеләр. Хафиз Исрафил абзыйга утырып торырга да җай бирмәде.

— Киттек, бабай, әйдә өйгә! Чәй янында гәпләшербез. Әйдә, югыйсә, минем эчтә Каршавыл этләре өрә башлады. Син дә юл килгән...— диде кияү кеше. Тик Исрафил картта тамак кайгысы юк иде әле. Бөтен кыяфәте аның алҗып-тинтерәп калуын әйтеп тора иде. Ул стена буена тезелгән урындыкларның берсенә лап итеп утырды. Башындагы эшләпәсен салып янына куйды. Аннары, тиресенә сыеша алмаган кебек, әүвәле пинҗәк төймәләрен, шуннан күлмәк изүен чишеп җибәрде. Чалбар кесәсеннән зур кульяулыгы алып, тап-тапкыр кырдырган башын, тирән җыерчыклар буразналаган киң маңгаен сөртте. Бүген иртән генә җиренә җиткереп кырыккан-төзәткән түгәрәк ак сакалын, чал куе мыегын сыпыргалады.

— Өегездә булып чыктым инде мин, кияү,— диде ул үзенә сагаеп карап торган Хафизга.— Кабат кереп тормыйм. Чәйләдем дә, оланнарны да күрдем. Сөбханалла, әзмәвердәй үсеп киләләр. Бик ачыккан булсаң да безәрик сабыр ит, кияү. Гозеремне тыңла.

— Болай ятышсыз була ич инде, бабай. Гомерләрендә бер очрашкан казенный кешеләрчә кабинетта сөйләшеп утырырга ни! Кайтыйк өйгә, чәйлик шәпләп. Шунда да сөйләшеп була ич.

Исрафил карт, урындыгыннан купмаска берекән кебек, кымшанмады да. Сул кулын гына селтәде.

— Хикмәт кайда сөйләшүдә түгел, кияү. Сөйләшүнең мәгънәсендә, барып чыгарында. Безнең Иршатның эшләре көйсезләнеп тора бит әле.— Карт, менә-менә елый башларга торган сабый сыман, авызын мимылдатып куйды.— Савсим көе китеп тора.

— Кайнишненме?

— Әйе шул, кайнишеннең, кияү, кайнишеннең. Бүтән Иршатлар артыннан сакал сәлперәйтеп, йөз суы түгеп йөрер чакларым үткән бит инде минем, кияү...

— Нәрсә, растратасын таптылармы? Күпме? Бик тиз түләргә диюендер.

Исрафил абзый киявенә гаҗәпсенеп карады. Аның карашы: «Бала да бала, син дә бала кебек беркатлы булырсың икән!» ди иде. Аннары теләп әйтте:

— Растрата ясый торган малаймыни ул, кияү! Белмәгән кеше төсле сүз сөйлисең. Министр башы бит анарда. Эчми, тартмый. Каян чыксын растрата?! Җилдән тумый ла ул. Растрата гына булса, сыерымны, сарыгымны, кирәк булса патша сараедай йортымны бүген тотып сатар идем дә арыныр идем. Аяк астыннан чыккан бәла бүтән, кияү, бүтән, каһәр суккыры!

— Юк ла! Авызыннан җил алсын. Исрафил малае Иршат дәүләт кесәсенә тыгылган дисәләр, бөтен Рәсәйгә пазур лабаса...

— Аңламыйм. Эше нигә көйсезләнде соң? Хатыны белән ызгыштымы? Аерылышалармы әллә?

Карт янә сул кулын селтәп куйды.

— Тузга язмаганны. Семья шау-шуы нәселебездә булган хәл түгел. Сукыр Самат малаен кыйнаган. Унынчыда укып йөрүчесен.

— Ник кыйнаган?

— «Чаян»га язган өчен. Самат малае язып җибәргән, Исрафилов Иршат, Аккүл районы, Ураз сельпосының завскладь ике мех туны, өч аш сервизын Казанга һәм Ураз станциясе начальнигына илтеп сатты, кибеткә акчасын гына тапшырды, дигән. Совет сәүдәсен бозу, дигән, спекуляция түгеллегенә кем ышандыра ала, дигән. Вәт берәү шуны тикшерергә килде.

— Һәм кем язып җибәргәнне Иршатка әйткән дәме? — Хафиз сабырсызланып, бабасының сүзен бүлде.— Әллә хатны биреп укытканмы?

Исрафил абзый сәерсенеп елмайды.

— Сер чишәргә журнал кешесе дуракмыни?

— Алайса Иршат хатның авторын кайдан белгән? Күрәзәче изге түгел ич ул.— Хафизның күңел эчкәресендә, тирәндә, кайнишенә карата ачу оеткысы уянып килә иде. Шул нәрсә йөзендә дә чагылды кебек. Исрафил абзый күзләрен бер читкә борды.

— Кибеттә Саматның олы кызы эшли. Энесенә шул чишкән булырга кирәк. Ә теге малай, бишенче класста укый башлаганнан бирле, районга да яза, яшьләр гәҗитенә дә. Иршат кыек атып, туры тидергән. Теге малайны урамда очраткан да, «Чаян»га минем өстән язгансың икән», дигән. «Яздым. Дөресен яздым. Барысы да расланачак», ди икән. Шуннан безнең ахмак типкәләп кыйнаган тегене. Гәүдәсе гәүдә генәме, кулы кул гынамы юньсезнең! Сукса җиренә өзә торган. Самат малаеның башы тишелгән, күз төпләре кара янган. Аягы каймыккан. Больнистан справка алганнар. Следователь килде. Менә шундый бәлагә тардык, кияү. Язмыштыр, күрәсең...

— Язмыш түгел, бабай, түгел... Азмыш! Азмышның да кычкырып торганы.— Хафиз сүгенүдән чак тыелып калды. Кара син геройны! Башта үзе теләп тизәккә бата. Сасый башлагач, гаепсез кешене кыйнап имгәтә. Ба-ты-ыр! Әйтерең бармы?!

Кадергулов, урыныннан торып, бүлмә буйлап арлы-бирле йөренә башлады. Кайнишенең кыргыйлыгы башына сыймадымы, я булмаса шул юньсезне йолып калырга йөрүче бабасына җене чыктымы, анысы караңгы иде, чөнки ул ләм-мим сүз эндәшмәде. Болай тел тешләп торуның хәерлегә булмасын чамалаган Исрафил абзый үзе сөйләвендә булды. Авызына су кабып утырырлык булгач, сөяк селкетеп йөрисе дә юк иде.

— Исерек тә түгел бит, ап-аек килеш шул чама кызарга кирәктер, гөнаһ шомлыгы... Эчми, авызына да алганы юк.

Хафиз бабасының каршына килеп туктады.

— Аракыга акча әрәм итүдән Иршат күптән узган инде, бабай.— диде ул, Исрафил картның йөзенә туп-туры карап.— Мал кортының бик дәве кергән аңа. Андыйлар эчмиләр дә, тартмыйлар да. Акча колы ул хәзер, әйбер колы...

— Алай гына дип тә булмый, кияү. Безнең авылда моннан берничә дистә ел элек Олтан Сафи булган. Хәерченең хәерчесе. Шул гелән «Дөнья малы — дуңгыз каны» дип йөргән, ди. Мал барыбызга да кирәк.

Хафиз үз урынына барып утырды.

— Син мине төшенеп җитмәдең, бабай.— диде аннары.— Йорт-җирнең шәбе, суыткыч, тузан суырткыч, автомобиль кешегә рәхәт өсти, авыр эштән бушата. Радио, телевизор, магнитофон ял бирә, культураны арт-

булганга, шундый кыргыйлык эшли алган ич ул. Көпә-көндез үзеннән көчсез кешене һич гаепсезгә изеп ташласын әле, ә?!

— Матур булмады шул, кияү, бер генә дә матур булмады.

Хафиз бабасының сүзләрен игътибарга алып өлгермәде, фикерен дәвам иттерде:

— Көннәрнең берендә тәртә арасыннан чыгарын кышын ук сизенгән идем мин аның. Өендә булган идем ич кышын. Телевизорның экран пыяласына юеш кулы белән тотынганы өчен, өч яшьлек кызын суктырды бит. Мөниръне, хатынын, кара халат киеп, складта эшләргә мәҗбүр итә. Нәрсә хакына дип беләсең? Склад эшчесе итеп яздырганнан гына түгел, акча читкә китмәсен ди... Ә хатыны — педагог! Укучылар аны күреп тора.

Исрафил абзый:

— Анысы бер хәер иде, кияү. Килен эшкә булган безнең. Эштән курыкмый,— дип сүзне икенчегә борырга теләгән иде, Хафиз аңа авыз ачтырмады:

— Тагын аңламадың, бабай. Мөнирә эштән өркәдер димим. Аны теләсә кайда иза чиктермәскә кирәк дим. Иршатка ирек куйсаң, күлмәк итәген биленә кыстырып, тирес кирпече сугарга да чыгарыр ул аны.

Бабасының үгет-нәсихәт тыңлап торыр тәкате калмады. Ул үгезне мөгезеннән алды:

— Инде нишләргә дисең, кияү? Иршатның эше нәрсә белән бетәр? — дип сорады.

— Сәүдә тәртибен бозуы белән бер гаепле. Бәясен арттырып саткан булса, икенче гаеп. Тик торганда кеше кыйнаган — хәбәрче егетне! — монысы барыннан да битәр зур гаеп. Утыртачаклар. Менә шул.

Хафиз милициягә шалтыратты. Уразда булган «ЧП»ны җентекләп сорашты. Милиция начальнигы берәмтекләп сөйләгәндә, Кадергулов ияк кагып тыңлап торды. Исрафил абзый исә, күзләрен челт-челт йомгалап, әле киявенең җитди йөзенә, әле телефон трубкасына карап утырды. Аңа бу минутта зәңгәрсу-ак трубкада тылсым көче бардыр төсле күренде. Әйтсен иде шул трубкадан тавышы килә торган кеше: «Ничава, иптәш Кадергулов, җайларбыз. Эшеннән выговор чәперләр, без җилле генә штраф түләтербез. Сукыр Саматлардан гафу үтенер», дисен иде. Выговорына чыдар иде, муенга аскан чуен тәре түгел. Вакыт җиткәч, списать итәләр аны. Эшләгән кеше хаталана. Иблис бит мич башында йөрми, конторда, складта бутала. Штрафына да чыдар. Исәрләнгән икән, кашынсын. Икенче сабак булыр. Сукыр Саматка да башын иеп барыр. Тормыш дигән явыз нәмәстә Иршат ишеләрнең генә муенын бөгәме?! Барыр, ялыныр. Киресенчә, Саматын да, малаен да сыйлар. Юк, сыйлавын сыйламас. Сыйларга ярамый. Юмалау була, ришвәткә керә. Аннары бит инде штрафны каезлап алган булалар. Иршат кесәсеннән шунысы пулный җиткән...

— Ярый, хушыгыз!

Хафиз нык иттереп телефон трубкасын куюга, Исрафил абзый үзе дә сизмәстән дөрт итеп сискәнеп китте һәм чекерәеп киявенә карады.

— Я, нәрсә ди, ходаның хикмәте?

— Судка кадәр үк кулга алырга да мөмкин иде, бер кая да чыгып йөрмәү шарты белән әлегә ирекtә калдырдык, ди. Кыйналган егет урын өстендә ята икән әле. Бөтен классташлары шау-шу күтәргәннәр, гаепсез иптәшләрен яклыйлар. Мөнирә менә шушы мәктәптә ни йөз белән укытырга тиеш инде? Эх, шайтан алгыры!

Исрафил абыйның өметендә өзелеп җитмәгән бер генә кыл калды. Фәкать бер генә.

— Син булыша алмыйсыңмыни соң инде, кияү? Иплән бер-ике авыз сүз әйтсәң, Иршатның хәле җиңеләер иде. Штраф-мазар белән калдырырлар иде бәлкем.

юк.— Хафиз бик борчыла иде, тагын урыныннан торды һәм папирос кабызырга җыенды. Шырпы кабы күкертенә ышкып, бер шырпы сындырды, икене... ут кабынмады. Аннары ул өстәл тартмасыннан зажигалка-пистолет алды һәм чакмасына басты. Зажигалкада чыпчык теледәй генә ялкын күренде. Әмма ул ялкын гүя Хафизның папиросына түгел, Исрафил абзыйның бәгыренә эленде дә дөрләп яна башлады. Картның гәүдәсен калтырау алды, тавышы да калтырап чыкты.

— Теләсәң, кулыңнан килә бит инде, кияү. Властең бар. Әйтсәң, тыңламый булмаслар,— диде ул, соңгы чиккә җиткәндәй ялварып.— Кил, зинһар, ярдәмеңнән ташлама. Синнән башка сүз кушар кемем бар инде минем? Әбиен дә шул каһәрле хәбәрдән урынга егылды.

Хафиз кырысланды. Бабасына каты бәрелергә теләмәсә дә, бүтәнчә булмый иде.

— Миңа бирелгән власть кирәк җирендә тиешенчә эш итәр өчен ул, бабай. Гаеп итмә, Иршатны хөкемнән йолып калуда берничек тә булыша алмыйм. Иршат сабый бала түгел, унны-сулны аера белә...

— Төрмәгә ябып куйсалар, өч баласы бар бит, кияү. Аларны кеше итәсе, үз көннәрен үзләре күрерлек итеп аякка бастырасы бар. Ул сабыйларны кем карар, кем тәрбия кылыр дисең?

— Бик зур авырлык эниләре җилкәсенә төшәчәк, бабай. Аннары сиңа булышырга туры килер. Бүтәнчә кем карашсын аларны. Картлык көнеңдә җилкәңә тагын бер таш баса икән, ни хәл итәсең. Иршатның азынуына үзең юл куйдың. Яшьтән үк, төпчек дип, учыңда сикертеп үстердең...

Исрафил карт киявенең бу сүзләренә чын-чынлап рәнҗеде. Купмас төсле утырган җиреннән күтәрелде, эшләпәсен кулына алып, ботарлый башлавын абайламады да. Үзе һаман сукранды. Хафиз аны чын күңелдән кызганды, тик бу очракта ярдәм итә алмавын да кояшлы көн төсле ачык аңлый иде.

— Шулай инде, кеше хәле кешегә ни! — диде ышанычы бетеп барган бабасы.— Хәзрәткә курай нәрсәгә, кулында әфтияге, дип әйткән ди борынгыда бераү... Синең эшләр җайлы. Каланчадан торып сөйләшәсең. Кайнишең менә төрмә шулпасы чөмерсә дә ярый, ә?

Исрафил абзый атлап түгел, очып дигәндәй, Хафиз алдына килеп басты.

— Мәңге бәхил түгел, кияү!

Аннары карт дәррәү дуамалланып ишеккә таба китеп барды.

— Бәхилләмәсәң, Иршатны бәхилләмәссең инде.— Хафиз шулай дияргә генә өлгерде. Исрафил абзый, ярыкка төшеп югалган терекөмеш тамчысы төсле, эһ дигәнче чыгып та китте. Яртылаш ачык калган ишектән техник секретарь килеп керде. Аның кулында конверт иде.

— Сезгә заказной хат, Хафиз Галиевич. Одессадан,— диде ул.— Күптән түгел генә китереп киттеләр.

Хафиз өенә шалтыратты һәм Ләйсәннең аш әзерләп торуын үтенде, озакламый кайтып җитәсен әйтте. Ләкин тиз генә кайту насыйп түгел булып чыкты. Одессадан килгән хат аның чәчләрен үрә торгызды...

Тормышта көтелмәгән хәлләр була тора, тик Хафиз кайчан да булса бу тикле көтелмәгән хәбәр алырмын дип хыялына да кертмәгән иде.

Техник секретарь кертеп биргән хатны укыгач, Кадерrуловның бөтен тормышы, ком чүлендәге мираж шикелле, булып узган барлык вакыйгалар, кичерешләр, шатлык һәм кайгылар белән күз алдына басты. Бу кадәресе дә аңлаешлы. Ә инде хатның авторы Владислав Кадергулов булуын үтерсәләр дә аңлар хәле юк иде.

*Ахыры бар*

## Зөлфәт

### Хәрәкәттә йөрәк

Шыгрым тулы һава йолдыз белән,
Күк гөмбәзе, кара, нинди тере!
Хәрәкәттә җиһан... Кагыл гына —
Ачылырга тора бөтен сере.

Күзләренә багам йолдызларның,
Алар миңа карый мөлдерәшеп;
Шушы карашларның яктысына
Чакырасы иде сине дәшеп.

Шыгрым тулды йөрәк йолдыз белән,
Күкрәгемдә яна, нинди тере!
Хәрәкәттә йөрәк... Кагыл гына —
Ачылырга тора бөтен сере.

### Авыр...

Сүзләр матдә түгел, дисез икән,
Мин бәхәстә, мәңге бәхәстә!
...Төнге нурлар төшеп чагылдылар
Керфегеңә кунган ак бәскә.

Син калырга тиеш, минем исә
Самолетка билет кесәдә.
Аерылабыз... язмыш үзе килеп:
«Аерылмагыз берүк...» — дисә дә.

Син өеңә кайтып керерсең дә,
Төн йокысыз калган бәндәгә,
Җавап сорап каршыңа ук баскач,
Кул селтәрсең: «Я, кит... бәйләнмә...»

Күзләреңнән куркып, ул, мөгаен,
Мин гаеплемени, дигәндәй,
Чигәләрен кысар кулы белән.
Шәлең төшеп китәр идәнгә...

Шәлең төшәр... Күңелләрең төшәр...
Сыенырсың килеп тәрәзгә.
Биек күктә ак самолет эзе
Таралмыйча торыр бик әзгә...

Күзләреңне миннән капламый.
Китәр якка аяк атласа да,
Атласа да...
Йөрәк атламый.

Бер сүз әйттең:
— ...мәңгелеккәмени?!.—
Шундый авыр булды бу сүзең.
Гомеремдә мондый авыр йөкне
Күтәрмәгән идем мин үзем.

Тулды күңел авыр матдә белән —
Сүзләр матдә түгел, дисәгез —
Шул сүз тулы авыр йөрәгемне
Алыгыз да бүген, үлчәгез!

## Кичер

Назларымны кичер — соңардылар,
Язларымны кичер — соңардылар,
Күзләремне кичер — соң бактылар,
Сүзләремне кичер — елаттылар...

Буш булганы өчен — кулларымны,
Кушылмавы өчен — юлларымны,
Ашыкканы өчен — елларымны,
Ашыкмавы өчен — уйларымны...

Барысын да кичер елап-көлеп,
Мин кичергән, гафу иткән кебек.

## Күпердә

Яңгыр сибә көзге пляжларга.
Җәйге өннәр кая олаккан?
Җанда җырлар бәйрәм иткән иде,
Аһәннәре китми колактан.

Су кызлары көлде төнге ярда.
Ут яктысы ятты суларга.
Синсез ачык калган тойгыларга
Бертуктамый көзге яңгыр ява,
Ышык табып булмый шуларга...

Шаулап бәрә яңгыр,
Дөньяда бит
Яшәп була иде яктырак!
Бәрә яңгыр —
Киткән юлларыңа
Бер-бер артлы пуля батыра.

Тойгым ачык — керендерә яңгыр...
Җилләр йолкый сине хәтердән.
...Чагылышың — суда.
Үзең исә
Күптән киткән инде күпердән.

— Фатыйма, тимер капкаң ач, әч!
Киявең килә, кач, кач!
...Чуар бөҗәк очып китте.

...Ак чәчәкләр кырда шундый куе.
Бал кортлары безли. Гөлләр туе!
Ат өстендә — морза. Җәйге көннәр.
Фатыйманы көтә ап-ак мендәр.
Таждан тажга куна бер бал корты.
Фатыйманы көтә морза йорты.
Зәңгәр көянтәсе җирдә ята —
Фатыйманы язмыш ни уйлата?
Ак чәчәкләр быел шундый куе,
Кемне көтә сылу еллар буе?
Туй атлары килә туп-туп басып,
Дугаларга шөлдер-чуклар асып.
Чишмә янында кыз түгә яшен,
Фатыйманы, язмыш, нишләтәсең?
Чуар бөҗәк кунды шулчак кулга.
— Әйтче, бөҗәк, кемнәр килә юлда?
— Чәчәкләргә басып атлар килә,
Ат өстендә сиңа ятлар килә!
— Күзләрендә кояш бармы әллә?
Шахталарга киткән ярмы әллә?
— Көлүендә алтын чыңлап тора,
Мең ялчысы шуны тыңлап тора.
Шул мең ялчы сиңа башын ияр:
— Син — бикәбез безнең, сылу!» — дияр!
— Күзләрендә кояш бармы, бөҗәк?
Ул — шахтага киткән ярмы, бөҗәк?
— Кияү булып килә бүтән егет,
Килгән юлын алтыннарга күмеп.
Ә сөйгәнең... күптән шомлы базда...
Шахта басты аны узган язда...
Килде хәбәр бәгырьләрне телеп,
Кыз сыгылды көянтәсе кебек:
— Килде хәбәр... Авыр, авыр хәлләр...
И табигать, көчең житсә әгәр,
Очсын жаным чуар бөҗәк булып,
Ак чәчәктән ак чәчәккә кунып...
...Яр буенда калды көянтәсе,
Көянтәне тапты тик әнкәсе.
Чуар бөҗәк кунды шулчак кулга,
— Әйтче, бөҗәк, кызым кайсы юлда?
— Мин буламын, әни, синең кызың,
Очып йөрим хәзер бер ялгызым...
Сыктый ана. Шулчак еракларда
Җиз кыңгырау чың-чың чыңлап бара.
— Киявең килә, капка ачыйммы?
Ачмыйм, кызым, тизрәк кач инде...
...Кулдан кулга куна нәни бөҗәк —
Ул Фатыйма йөри ярын эзләп.
Әгәр кунса сезнең кулга килеп,
Әйтмәгезче аңа сез: «Кач!» — диеп...

Капкагызга килеп туктар атлар,
Нишләрсез соң атта булса ятлар?..

Төш юрата авыл хатыннары,
Әби-карчык тынлый шым гына.
Көннәр сыман артка шуа тора
Дисбе төймәләре кулында.
Мисыр күгәрчене кунган, имеш,
Очып килеп, тәрәз төбенә...
Юрый карчык:
— Төшең изге, кызым,
Тиздән кайтыр, берүк, түз генә...
Ә берсенең муеныннан чорнап
Кара елан чаккан йөрәген.
Юрый карчык:
— Төшең изге, кызым,
Елан түгел, мин юл күрәмен...
Төш юрата авыл хатыннары,
Арада бар иң яшь кыз бала,
Төш сөйләргә килә,
Килә,
Ләкин
Берни сөйләмичә кузгала.
— Үлгән! — дисә ул ышанмас,
Ләкин:
— Кайтмас! — дисә
нишләр йөрәге?
Учак көлләрендә посып калган
Куз шикелле өмет көйрәде.
Миналардан арынып
икмәк бирер,
Еллар үтәр,
булыр җир тыныч.
Сөйләнмәгән бу төш —
шартламыйча
Онытылып калган мина сыман:
Кагылырга хәтта куркыныч!
...Төш юрата авыл хатыннары,
Ә карчыкның җавап бер генә:
— Кайтыр, кызым,
Кара елан түгел,
Кайтыр юлы аның күренә...
Төш сөйләргә килә,
Килә,
Ләкин
Берни сөйләмичә кузгала
Беренче кат сөеп,
Елап калган
Арадагы иң яшь кыз бала.
Төш юратты авыл хатыннары,
Юраганның күбе юш килде.
Ул чордан соң ничә кояшлы җәй,
Ничә тапкыр карлы кыш килде...
Еллар үтте, ә төш сөйләнмәгән,
Берни сөйләмичә кузгала
Ерак илдә үлеп калган ярның

Төшләренә кергән кыз бала...
Көн саен ул төш юратмак була,
Тик сөйләми кала көн саен.
Өмет дигән нәрсә
Изге төштер,
Юралмаган төштер, мөгаен.

## Тынлык

Тарантастан аяк салындырып,
Урман күзләп бара комиссар.
Ябалдаштан ябалдашка күчеп
Йөри язгы, якты тавышлар.

Гимнастерка изүләрен чишеп,
Ат юырткан көйгә тын гына
Җырлап бара...
Тук бөреләр исе...
Ат юырта урман юлында.

Ялкын йоткан илнең үзәгендә
Шундый сәер иде бу тынлык:
Урман түреннән үк, салмак кына
Күке күкелдәргә тотынды.

Ачлык та юк, гүя үләт тә юк,
Язга чумган урман нибары.
Күкне капшый язгы ябалдашлар,
Ак болытлар ауный югары.

Җепселләрдән өскә сулар үрли,
Көннәр тәмам язга авышкан.
Тарантастан аяк салындырып,
Урман күзләп бара комиссар.

Бер мизгелдән
нәкъ йөрәге аша
Үтеп чыккан кулак кургашы
Юл чатында торган зур имәннең
Үзәгенә кереп урнашыр.
Еллар үткәч,
шушы урман юлы
Барып чыга торган авылда,
Өмә җыеп, мәчет урынына бер
Зур йорт салып яткан чагында,
Өрлек булып ятар шушы имән,
Шуңа балта чапкан берәве
Гаҗәпләнеп дәшәр дусларына:
— Кургашынга чаптым, күр әле!..
Учтан учка күчәр шушы кургаш.
...Ә хәзергә әле комиссар
Җырлый-җырлый бара тарантаста.
Тып-тын урман.
Язгы тавышлар.

## Көлү-елау

Күп көлгәнгә күрә күп еладым,
Күз яшьләрен йотып эчемә,
Еладым мин башны ташка салып,
Көлдем ятып үлән өстенә.

Үкси-үкси елау кирәк чакта
Көлгәнем бар авыз күтәреп —
Шуңа күрә авыр йодрыкларның
Хатирәсе миндә җитәрлек.

Рәхәтләнеп көлү кирәк чакта
Йодрык кысып ялгыз еладым.
Еламады дөнья, көлмәде дә,
Тып-тын гына мине сынады.

Юк, елама, димәде ул миңа,
Өйрәтмәде мине көлмәскә,
Тик өйрәтте — тоташ еламаска,
Һәм, шулай ук, тоташ көлмәскә.

## Кайтмый калган

Яз гөлләре шаулый кар астында...
Сырындылар буйлап ыргый буран.
Алда — авыл. Шул авылга табан
Ярты рота чыгып килә кырдан.

Тырылдарга әзер автоматлар.
Ярты рота ятып калган артта.
— ...торыгыз... тор...—
ап-ак буран җиле
Һаман канлы чабулардан тарта.

Чыгып килә кырдан ярты рота,
Кереп килә хәтер түрләренә.
Дошман патронында кургаш үлем
Сикерергә әзер йөрәгенә.

Яз гөлләре шаулый кар астында.
Сырындылар буйлап ыргый буран.
Бер минуттан...
— торыгыз... тор...— диеп,
Буран йолкыр канлы чабулардан.

Рота бара соңгы атакага.
Менә берсе атлый. Икенчесе.
Беренчесе ауды. Егылалар.
Үҗәтләшеп атлый соңгы кеше...

Ул егылмый,
үлемсезме әллә?
...Кара, эти, күзләренә кара —
Таныйсыңмы, танйсыңмы — синен
Кайтмый калган туганың бит бара!

Һәм кушылды утлар дөрләвенә.
Кереп китте. Аягүрә килеш
Хәтерләрнең ерак түрләренә...

## Сүз

Гөлләр, ахры, йолдыз телен белә,
Шул ук телдә сөйли кылганнар,
Тибрәнмәгән сыңар гөл дә калмый
Күктә яңа йолдыз туганда.

Яшь кеше — дөнья сүзен белә,
Базар сүзен, урам сүзләрен,
Сөйли кеше
зур трибуналардан,
Һәрбер сүзнең белә бизмәнен.

Һай, күп сүзләр өйрәтә бу дөнья!
...Гомернең бер аулак мәлендә
Дөнья сүзләреннән арып-талып
Җиргә чалкан төшкән хәлендә

Хәйран кала кеше:
йолдыз белән
Гөлләр сөйләшәләр үзара!
Тылсымлы тел... Аңлый алмый кеше,
Беренче кат, бәлки, кызара...

Тетрәп кала кеше һәм шул чакта
Ул дәшәргә тели гөлләргә,
Сөйләшергә тели йолдыз белән,
Сүз кушарга тели җилләргә —

Ләкин дөнья артык иләгән шул,
Биеткән ул төрле кубызга.
Кеше өчен гөлләр кызаралар,
Кызаралар күктә йолдызлар.

Юкса, үзе күпме сүзләр белә,
Базар сүзен, урам сүзләрен,
Сүгенүдән —
шигырьләргә кадәр
Белә һәрбер сүзнең бизмәнен.

Мәшәкате, низаглары белән
Дөнья шундый усал алдаган:
Күп караган кеше гөл-йолдызга,
Күп караган...
Колак салмаган!..

## Мостафа Ногман

### Умырзая

Умырзая жырын бераү жырлый,
Китергәндәй моңсу бер хәбәр.
Нигә, нигә шуны тыңлаганда
Ямансулыйм икән бу кадәр?

Мәскәүләргә барсам, ашыгып атлыйм
Арбаттагы бер тар урамга,
Әхмәт Фәйзи, гаҗәп гүзәл кеше...,
Гомер сөргән иде ул анда.

Менә йорты,
Ул шушында торды.
(Комфорт-фәлән ана нәрсәгә?!)
Мин урамнан үрелмичә карыйм
Ул утырган түбән тәрәзәгә.
Тар гына бер бүлмә — шагыйрь урыны!
Мин таң калып сорыйм хыялдан:
«Ничек монда Кырлай урманнары,
Казакъ җәйләүләре сыялган?!»
Күңелем әрни,
Күпме истәлекләр
Сакланганнар шул тар бүлмәдә!
Мин сагынып кайчак бара идем
Шагыйрь елмаюын күрмәгә.
Бераз моңсу күзләр сөйли иде
Гомер юлы шактый үткәнне.
Һәм ул якты күзләр
Белми иде
Хуш теләктән башка бүтәнне.
Ә беркөнне аның тәрәзенә
Үлем угы килеп кадалгач,
Шул агулы уктан йөрәкләрдә
Төзәлмәслек яра яралгач,
Ул сәфәргә чыкты...

Соңгы көннәр житүен белә торып,
Бирелмичә бер дә аһ-зарга,
Үз аягы белән кайтып керде,
Бәхилләшер өчен Казанга.

«Төкерен йөрдем әлек дөньясына,
Хәзер инде бигрәк эш худга.
Төкерен ятам шушы савытка!»

Дип, янына килгән дус-ишләрен
Таң калдырды шагыйрь шул чакта,
Син аңарга әрнү белән килгән,
Ә ул сине көлеп юата.

Без озаттык аны соңгы юлга...
Тукай һәйкәленнән үткәндә,
Бер сандугач кинәт яңа бер җыр
Яңгыратты зәңгәр күкләргә:
Ул — шагыйрьнең «Умырзая» җыры,
Без тыңладык аны җыелып,
«Юк, мин үлмәс идем
Умырзая кебек,
Умырзая кебек боегып!»

## Киек казлар китә

Кыйгак-кыйгак «Киек казлар» яңгырый...
Бу кем җыры агыла йөрәккә?
Әрни-әрни түгелеп тора моңнар,
Үзәкләрне өзеп тетрәтә.

«Кыйгак-кыйгак!» киек казлар кайта,
Мин аларның юлын эзләнәм,
Казлар кебек, Туфан кайтып килде
Озак гизеп йөргән эзләрдән.

Гөрләп агып торган тау чишмәнең
Киселеп кала юлы яртыда.
Чишмә тынмый,
Ярсу ташкын булып,
Бәрелеп чыга тагын яктыга.

«Кыйгак-кыйгак! Киек казлар китә»...
Туган якларыннан аерылып,—
Киек казлар китә,
Шагыйрь кала
Шигърияте белән яр булып.

## Төн патшасы

Төн патшасы, гүзәл түгәрәк ай,
Йокламыйсың төннәр буена.
Бар табигать җирдә, хозурланып,
Көмеш нурларыңа коена.

Күпме еллар җирнең гашыйклары
Сиңа карап күңел юаткан!
Сер бирергә теләмәгән сыман
Елмайгансың гына ерактан.

Ул серләрең хәзер ачыла һаман,
Һәр күренешең — безнең дәфтәрдә.
Җир уллары күксел тауларыңа
Бер-бер артлы чыга сәфәргә!..

## Вакыйф Нуруллин

# УЛ ЯШӘРГӘ ТИЕШ ИДЕ

хикәя



Күземнән йокы качканга бүген өченче тәүлек китте.

Моннан ике көн элек әнидән хат килгән иде. Шул хатында әни, авыл хәлләренә дә кагылып: «Узган атнада күршебез Хәмидә апаң да үлеп китте. Жиңеләебрәк киткән чагында агу йоткан»,— дип язган иде.

Менә шул хәбәр качырды йокыны. Чөнки бертуган апамдай якын булган Хәмидә апаның шул хәлгә барып житүенә иң элек мин гаепле.

Тик мине беркем дә гаепле дип санамаячак. Хәмидә апаның дөньядан туяр дәрәжәгә килеп житү сәбәбен миннән башка һичкем белми.

Ә шулай да йокы качты менә. Күземне йома башладыммы — мәрхүмә Хәмидә апа каршыма килә дә баса. Сөрмәле кара күзләрен мөлдерәтеп, нәкъ кырык өченче елның июнь аендагыча итеп, мине каргарга тотына: «Синең арканда гына шушы хәлгә төштем мин, имансыз малай! Тырнак очы кадәр дә гөнаһым юк иде. Шул синең керми калуың гына харап итте тормышымны! — ди.— Шул чакта син кергән булсаң, мин дә башкалар төсле рәхәтләнеп яшәгән булыр идем. Ә хәзер менә, кырык тугыз яшем дә тулмас борын, кара гүрдә ятарга туры килә инде!» — ди.

Кешенең тормышын бозу да, аны дөньядан туяр хәлгә китереп житкерү дә бик ансат икән. Мин үземнең мәңге төзәтеп булмаслык хата ясавымны чирек гасырдан артык вакыт узгач, әнидән әлеге хат килеп төшкәч кенә аңладым.

Ә Хәмидә апа күз алдымнан китми дә китми.

Менә без аның белән Зәйнетдин абыйны озата барабыз. Зәйнетдин абый — Хәмидә апаның ире. Аның сугышка китеп барышы. Ул бераз кызмача. Шуңа күрә, миннән артык тартынып тормыйча:

— Әй, бәгырькәем, каласың бит! — дип, барган уңайга Хәмидә апаны әледән-әле үбеп ала.

Бу малайның да хәтерен калдырмыйм, диптер инде, ара-тирә минем дә аркамнан каккалап куя. Аннары янә Хәмидә апаны кочып үбә дә, аны үпкән чагында арбадагы печән өстенә куеп торган тальян гармунын кулына алып, дәртләнеп, үзе уйнап, үзе жырлап жибәрә:

Барасы юлларым ерак,
Арымас микән атларым.
Исән йөреп, саулар кайтыр
Микән газиз башларым...

Моңлы итеп, үзәкләрне өзәрдәй итеп, шулай берничә жыр жырлый да кинәт тукталып кала һәм, Хәмидә апаның күзләренә текәлеп:

— Кара аны, Хәмидә, мин югында матур гына йөр, яме! Кайта алмас дип уйлама, менә күрерсең, исән-сау әйләнеп кайтачакмын мин анан! — ди.

Хәмидә апа башта иркә генә итеп елмаеп куя. Аннары ул да, Зәйнетдин абый кебек, житдиләнеп китеп:

— Ни сөйлисең, Зәйнетдин? Күңелеңә дә китермә андый нәрсәне, күз нурым! — ди.

— Мин сиңа ышанам, Хәмидә,— ди Зәйнетдин абый.— Ну шулай да ялгызың гына яшәмә, яме. Көндезләрен ялгыз торсаң да, төнлә үзең генә кунма. Әбизәтелне, берәр ышанычлы кеше белән куна торган бул!

— Кемне чакырырмын икән соң, Зәйнетдин? Бер дә туган-тумачабыз юк бит безнең бу Укмаста.

— Анысы шулай инде,— ди Зәйнетдин абый, уйга калып. Бераздан кинәт ачылып китеп, мине күтәреп алдына утырта да, Хәмидә апага карап:— Менә безнең иң якын дустыбыз, Хәмидә! — ди.— Шулаймы, Сафиулла?

— Шулай, Зәйнетдин абый! — дим мин, аның олы башы белән мине үзенә дус итеп санавына куанып.

— Әйт әле, Сафиулла,— ди ул миңа, чыннан да, үз энесенә дәшкәндәй ягымлы итеп,— бүгеннән башлап, мин сугыштан әйләнеп кайтканчы, Хәмидә апаң янына кереп кунып йөрерсеңме?

Мин аптырабрак калам. Бер яктан караганда, Хәмидә апа янына кереп куну миңа рәхәт кенә буласы, чөнки безнең өйдә миннән башка да ике абыем, бер сеңелем бар, шунлыктан һәр көн кич урын-җир өчен тарткалашырга туры килә. Ә Хәмидә апаларда куна башласам — йомшак урында ятачакмын. Икенче яктан караганда, Хәмидә апаны күнелем нигәдер бик үк өнәп тә бетерми шикелле. Дөресрәге, ул үзе миңа салкынрак карый сыман. Менә бүген Зәйнетдин абый үзен озатканда мине районга тикле утыртып алып барырга булгач та, Хәмидә апаның кәефе кырылыбрак киткән төсле тоелды. Хәтта ул:

— Бала-чага ияртеп йөргәнче, икебез генә барсак әйбәтрәк булмасмы соң? — дип, Зәйнетдин абыйга әйтеп тә караган иде. Бары Зәйнетдин абый: «Зыян юк, барсын. Син мине озатып йөргәндә ат саклап, арбада утырып торыр!» — дигәч кенә ризалашырга мәҗбүр булды.

Ә менә Зәйнетдин абый безнең авылга килгән көннәреннән үк үз малаеннан да болайрак яратты мине. Алар безнең авылга әле узган ел гына килеп урнаштылар. Ачыграк итеп әйткәндә, Зәйнетдин абыйны безнең авылга эшкә — балалар укытырга җибәргәннәр иде. Анарчы алар бүтән районда эшләгән булганнар. Безнең авылга килгәч, күршебездә буш торган өйне сатып алдылар да нигез күршебез булып куйдылар. Менә шул чактан ук ярата башлады мине Зәйнетдин абый. Урамда күргән саен, башта күтәреп алып сөя, аннары үзләренә алып кереп я конфет, я башка шундый тәмле әйберләр белән сыйлап чыгара торган иде. Тагын ике елдан бишенчегә күчәчәгемне белеп, бишенче класста татар телен миннән укыйсың инде, Сафиулла, дип, мине куандырып йөри башлаган иде. Ләкин укытырга туры килми инде болай булгач. Шул инде ул, яхшы кешеләр кайда да ин алдан кирәк. Сугышта да андыйларсыз булмый торгандыр, күрәсең. Шуңа болай тиз алып китәргә булганнардыр Зәйнетдин абыйны... Тукта, ни дип җавап бирергә соң әле аңа?..

— Мин керүен керер идем дә бит, Хәмидә апа риза булырмы икән соң, Зәйнетдин абый?

Күрәсең, минем җавабымнан канәгать булыптыр, Зәйнетдин абый рәхәтләнеп елмаеп куя да, Хәмидә апага карап:

— Ишетәсеңме, Хәмидәкәй, син риза булсаң, Сафиулла каршы түгел! — ди.

— Риза булмыйлармы соң инде! — ди Хәмидә апа, кинәт мин һич тә көтмәгәнчә яктырып китеп.— Кунып кына йөрү түгел, бөтенләй минем

янымда торса — тагын да яхшырак булыр иде әле: кибеттән кайтканда бикле ишеккә түгел, ачык ишеккә кайтып керер идем!

Зәйнетдин абый зәп-зәңгәр күзләре белән миңа карый да:

— Я, Сафиулла,— дип, тимердәй нык куллары белән мине күккә чөеп ала,— я, әйт әле, мин сугыштан кайтканчы Хәмидә апаңның малае булып торырсыңмы?

— Гармуныңны уйнарга рөхсәт итсәң, торырмын! — дим мин. Хикмәт шунда, мин Зәйнетдин абыйның гармунына алар безнен авылга килгәннән бирле кызыгып йөрим инде. Тик уйнап карарга дип сорарга йөрәгем генә житми.

Зәйнетдин абый шундук гармунын миңа суза:

— Менә, энем, хәзерге минуттан башлап синеке бу гармун! Тик син аны өегезгә алып чыкма, анда абыеңнар ватып бетерер аны. Бездә генә тот, и рәхәтләнеп, туйганчы уйна! Хәмидә апаңны гына ялгыз калдырма — куркыр ул. Аңладыңмы, Сафиулла, мин әйткәннәрне?

— Аңладым, Зәйнетдин абый!..

Ярый әле, Зәйнетдин абыйның әйтәсе сүзләрен юлда әйтеп калырга башы житкән, югыйсә, юньләп сөйләшергә дә өлгерә алмаячакбыз икән. Без районга килеп кереп, военкомат янына барып туктаганда, сугышка китәчәк кешеләрне инде сафка тезеп бетереп торалар иде.

— Сау булып торыгыз! Мин әйткәннәрне онытмагыз! — дип, Зәйнетдин абый тиз генә башта Хәмидә апаны суырып үпте, аннары мине кочаклап башымнан сыйпады да, биштәрен кулына алып, китүчеләр сафына барып басты...

Зәйнетдин абыйны озатып кайтканнан соң, атылып өйгә кердем дә:

— Әни, бүгеннән башлап, мин Хәмидә апа малае булам, аларда тора башлыйм,— дидем.

Әни, беркавым исе китеп, ни әйтергә белмичә миңа карап торды. Аннары:

— Ниткән юк сүз сөйлисең син, малай актыгы? — дип сорады.

Мин кабалана-кабалана мәсьәләне аңлатып бирдем һәм:

— Миңа шуның өчен Зәйнетдин абый гармунын да биреп калдырды! — дидем.

Әни башта бик каты торды: «Кунарга да кермисең, малае да булмыйсың, кешегә бирерлек артык балам юк минем!» — диде.

Ә мин һаман үземнекен тукыйм:

— Мин Зәйнетдин абыйга сүз биреп калдым, сүземдә тормасам — егетлек булмый бит ул, әни! — дим.— Әгәр мине Зәйнетдин абый кайтканчы Хәмидә апа малае итеп торасың килми икән, давай, ул чакта әтигә әйт, минем үземә гармун алып бирсен! Син әйтсәң, тыңлый ул, минекен генә колагына да элми,— дим.

Дөресе дә шулай. Йөз тапкыр сораганмын инде мин аннан, гармун алып бир әле, әти, дип. Ләкин ул алып бирергә уйламый да.

— Йөрмә әле, малай, эчне пошырып, аннан башка да кирәк нәрсәләр бетәсе түгел! — дип, минем үземне орышты.

Үзара байтак сүз көрәштергәннән соң, әни миңа Хәмидә апаларда куна башларга рөхсәт итте, ләкин көндезләрен гел өйдә булырга кушты. Нишлисең, ризалашырга туры килде, чөнки әни сүзе — изге сүз. Ана сүзеннән чыккан кеше гомер-бакый рәхәт күрми, ди безнең әни.

Озакламый әтине дә сугышка алып киттеләр.

Көз житте. Мәктәптә укулар башланды. Мин мәктәптән кайтышлый да Хәмидә апаларга кагылгалый башладым. Шуңа кагылам, чөнки мин кайтканда Хәмидә апа һәрвакыт өйдә була һәм беркайчан да ашатмыйча чыгармый.

— Бер дә тартынмыйча яхшылап аша, энем, сиңа житәрлек кенә бар, шөкер! — дип кенә тора.

Кибеттә эшли ул. Сельпога барып кайткан көннәрендә хәтта бүтән малайларның төшенә дә керми торган өрек яки йөзем җимешләре белән дә сыйлый.

Дәресләрне мәктәптән кайткач ук әзерләп куям. Ә кичләрен, Хәмидә апа янына кунарга кергәч, ул әйдә ятыйк инде, энем, дип әйткәнгә кадәр гармун кычкыртам. Кычкыртам гына түгел, «Әпипә» белән «Авыл көе»н хәйран гына сукалый да башладым бугай инде: кәефе яхшы булган чакларда, Зәйнетдин абыйга бияләй яки оекбаш бәйләп утырган җиреннән дәртләнеп китеп, Хәмидә апа мин уйнаганга биеп тә алгалый. Аны биетә алырлык булгач — ярап тора инде ул!..

Тора-бара минем хәлләр тагын да шәбәйде. Теге чакта әни: «нигә юкны сөйләп торасың, улым», дигән булса да, кырык икенче елның чамасыз салкын кышы килеп җиткәч һәм безнең келәтнең бура төпләре дә бик нык саегып калгач, ул үзе миңа Хәмидә апаларга төн кунарга гына түгел, бәлки көндезләрен дә ешрак кергәләп йөрергә кирәклеген аңлата башлады. Ә миңа шул гына кирәк тә инде! Һәм мин өйгә сирәк кенә, әнине сагынганда яки абыйлар белән бер котырышып аласым килгәндә генә чыгып кергәли торган малайга, дәү абый сүзе белән әйтсәк, кибетченең иркә малаена әверелеп киттем. Өс-башны да Хәмидә апа карый. Урын-җир өчен дә борчыласы юк: икебезгә болын хәтле түшәк һәм зур йомшак ястык. Юрганнары да минемише алты малай ябынып йокларга җитәрлек. Шулар өстенә, Хәмидә апа көн саен иртән олы миччкә, кич бәләкәенә ягып тора һәм һәрвакыт мине май шикелле йомшак кулы белән кочаклап ята. Кайбер көннәрне көрсенеп-уфтанып ала да:

— Их, Сафиулла! Кайтып керсен иде менә хәзер Зәйнетдин абыең! — дип, ут кебек кайнар күкрәгенә кыса.

Зәйнетдин абый ул кайтканчы үзләрендә торып торырга кушкач, теге чакта юкка гына икеләнеп маташкан булганмын икән. Хәмидә апа мине көннән-көн күбрәк ярата бара. Ул кибеттән кайткан чагында өйләрендә булмасам, бикле ишекләрен дә ачмыйча һәм мине эзләп тапмыйча торып, бусагасыннан аяк та атлап керми.

— Син минем үз улым шикелле хәзер, Сафиулла, синсез бер минут та яши алмыйм мин бу өйдә! — дип, әледән-әле үземә дә әйтеп тора...

Шулай кырык икенче ел үтеп китте, кырык өченчесе килеп җитте. Минем эшләр иплә генә тәгәри дә тәгәри. Өйдә яшәмәсәм дә сизенәм, абыйларның хәле көннән-көн мөшкелләнә: кием-салымнары да күзгә күренеп туза, ашау-эчү яклары да һаман кысыла, сыегая бара. Бер минем абыйларныкы гына түгел, авылдагы бүтән малайларның да хәлләре яман. Ләкин мин аларның барсына да булыша алмыйм шул. Ә үземнең абыйларга кулдан килгәнчә ярдәм иткән булам шунда. Я Хәмидә апа кибетенә киткәндә миңа дип калдырган ипине алып чыгып бирәм, я, үзләрен алып кереп, аштыр, бәрәңгедер ашатып чыгарам.

Бер караганда сөенеп, рәхмәт кенә әйтеп торырлыклары бар инде, кана. Бүтән малайларга анысы да эләкми бит әле. Ләкин, юк, барыбер ярап булмый абыйларга. Чак кына сүзгә килештекме, хәзер «сатлык җан», «куштан тәре, бер гармун белән бер тамак өчен кеше малае булып йөрисең!» дип теңкәгә тияләр. Бик белеп торам: көнләшүдән шулай дип әйтә инде алар. Үзләренә тәтемәгәнгә.

Шулай да ачу килә. Әллә Хәмидә апа янына керми башлыйм микән дип уйлап куйгалаган вакытларым да була. Ләкин Зәйнетдин абыйга биргән вәгъдәм искә төшә дә, ачуымны эчкә йотып, ашау белән гармун өчен генә йөрмим ич мин, сүз тыңлап, амәнәт үтәп йөрим дип, үземне-үзем юатып-рухландырып, ул уемнан кире кайтам...

Чыннан да, яхшы уйный башлаганмынмы әллә, аракы эчә торган кеше түгел, очсызгарак төшәр диптерме — анысын өзеп кенә әйтә алмыйм — соңгы вакытларда авылда мәҗлес үткәрергә ниятләгән кешеләрнең барысы да диярлек, гармунчы итеп, мине дәшәргә тотындылар.

Ә мине дәшү — Хәмидә апаны да чакыру дигән сүз. Чөнки, я салмыш баштан берәрсе гармунны ватар, яисә Сафиулланың үзенә бәйләнеп китүләре бар дип, Хәмидә апа беркайчан да мәҗлескә минем үземне генә җибәрми.

Минем үземнең бер дә барасым килеп тормый торуын. Олылар мәҗлесендә утыруның минем ише ун-унбер яшьлек малай өчен ни кызыгы булсын? Ләкин чакырганда барырга туры килә шул. Чөнки мәҗлескә йөрүне Хәмидә апа бик ярата. Шуңа күрә, бармыйча калып, аны үпкәләтәсем килми. Аннары тагын шунысы да бар: мәҗлестә утырган чакларда Хәмидә апаның җырлавын тыңлап кайтам мин. Ә ул тегенди-мондый гына җырчы түгел. Күңелләрне әллә ни кыландырып айкап, йөрәкнең иң нечкә кылларын тибрәтерлек итеп җырлый ул! Бер мин генә түгел, мәҗлестә утырган кешеләр, хәтта инде шактый «йомшап» бара торган агайларга кадәр, ачкан авызларын ябарга да онытып, сокланып тыңлап торалар аның җырлаганын.

Ләкин шунысы гаҗәп: кичләрен өйдә икебез генә утырганда бик сирәк җырлый ул. Ә менә мәҗлесләрдә исә, җырла дип әйткәнне дә көтмичә, үзе башлап җибәрә. Һәм өйгә кайткач әйтә:

— Әй, Сафиулла энем, рәхәтләнеп бер күңелемне бушатып кайттым бит әле бүген, рәхмәт инде сиңа! Әле ярый син гармун уйнарга өйрәндең! — ди.

— Анда барып йөргәнче, өйдә генә җырлап утырсаң, яхшырак булмас иде микән? — дисәң, тирән итеп көрсенеп куя да:

— Юк, энем, булмый: халык тыңлап тормаганда җырлыйсым да килми, җырлаганда да юньләп булдыра алмыйм! — ди.

Зәйнетдин абыйның соңгы айларда язган хатлары шактый өметле: һәр хатында диярлек, бәлки, кунакка да кайтып китә алмаммы әле дип яза. Һәм, әлбәттә, һәр хатында, ничек анда Сафиулланың хәлләре, сүзендә торамы, кунарга керәме синең яныңа? — дип сорашып тора. Моңарчы бер көн дә кермичә калганым юк иде. Ә хәзер, Зәйнетдин абый шулай менә кайтам, менә кайтам дип торганда, сүземнән чыгаммы соң? Кунарга керми калу турында уйлаган да юк инде анысы, хәтта аена бер-ике кинода утырган чагымда Зәйнетдин абый кайтып төшәр дә, мин аларда булмагач, кәефе кырылып, әллә ниләр уйлап куяр төсле тоела. Шундый күңелсез хәл килеп чыкмасын өчен, кичләрен генә түгел, көндезләрен дә, абыйлар янына да кереп чыкмыйча, гел Хәмидә апаларда үткәрә башлаган идем соңгы айларда...

Ләкин...

Җете кызыл тиз уңа, дип бик дөрес әйткән икән борынгылар. Үлгәндә дә онытасым юк, кырык өченче елның июнь ае, көннәрнең чамасыз нык кыздырган чагы иде. Минем ише малай-шалай бер караңгыдан алып икенче караңгыга тикле судан чыкмый ята.

Бер дә бер көнне шулай су коенып кайтып керсәм — күзен тозландырып, Хәмидә апаларда бер ят ир кеше утыра. Зур гына гәүдәле, капкара бөдрә чәчле, өстенә зәңгәр күлмәк, кара чалбар, аягына ялтыравыклы кара туфли кигән, калын кашлы, кылыч борынлы һәм зур колаклы шул кешене күргә, әллә нишләп, куркып-аптырап, ишек төбендә каттым да калдым. Ул да миңа текәлде. Бер-беребезне тикшереп тик торабыз: ул да дәшми, минем дә сүз башларга кодрәт җитми. Ә Хәмидә апа күренми. Мин су коенырга киткәндә дә өйдә юк иде ул. Ишекне үз кулым белән бикләп киткән идем. Шулай булгач, бу бәндә безнең өйгә ничек керә алды икән? Әллә ишек янагындагы ярыкка кыстырып киткән җиремнән ачкычны табып, ишекне үзе ачып кергән берәр угры-фәләнме бу? Порт басучы караклар шәһәр җирендә нәкъ менә шушылай яхшы киенеп йөриләр икән дип сөйлиләр иде, шуларның берсе монда да килеп чыкканмы әллә?

— Нигә син куркасың, малай? — диде ул кеше, минем уйларымны

белеп торган сыман итеп.— Курыкма, мин татарча беләм, мин — татарин. Кем сиңа кирәк. Хәмидә апасына килдәммә?
Хәмидә апаның исемен әйткәч, җинел сулап куйдым: димәк, карак түгел!
— Курыкмыйм, нигә куркыйм! — дим мин, батыраеп китеп.— Ә Хәмидә апа кая китте?
— Ул су артыннан китте, скоро килер.
Мин, түзә алмыйча, кычкырып көлеп җибәрәм.
— Ничек инде ул «су артыннан»? Су алып кайтырга китте дип әйтмәкче буласыңмы син?
Ул да рыясыз гына елмаеп куйды. Аннары хәйран әйбәт итеп татарча сөйли башлады — теләсә булдыра икән, шайтан!
— Әйе, әйе, син дөрес әйтәсең,— диде ул.
— Син кем буласың соң? Ник килдең безгә?
— Эш белән килдем.
— Нинди эш белән йөрисең, дим мин?
Ул миңа районнан Хәмидә апаның кибетенә ревизия ясарга килгәнлеген аңлатып бирде дә:
— А син үзең кем малае? Монда нишләп йөрисең? — диде.
Мин аңа күрше малае булуымны, ә хәзер Хәмидә апаларда яшәвемне әйттем. Ул шуннан соң күзгә күренеп яхшырып китте һәм:
— Бик яхшы, бик яхшы, давай, кил монда! — дип сөйләнеп, аксыйаксый яныма килде.
Унбер яшьлек малайның күңелен табу өчен күп нәрсә кирәкмени? Хәмидә апа су алып кайтып кергәндә, мин инде теге абзыйны тәмам үз итеп, күптәннән аны белгән сыман сөйләшеп утыра идем. Болай итүем Хәмидә апаның күңеленә дә хуш килде, ахрысы:
— Карале син аны! Шактый батыр малай икәнсең бит син, Сафиулла! — дип мактап та алды.
Көндезге аштан соң Хәмидә апа кибетенә китте, ә Роберт абый:
— Көн дә бик эссе, юл килеп арытты да. Бүген мин магазинга бармыйм. Ревизияне иртәгә башларбыз,— дип, минем белән өйдә калды.
Сакау күп сөйләр, дигәндәй, татарчасы бик шома булмаса да, сүзгә япьтәш адәм булып чыкты ул. Үзенең ничек итеп кырык беренче елның ахырына чаклы фашистларга каршы сугышып йөргәннәрен, ничек итеп разведкага барып, «тел» алып кайтканнарын, аягы кайда һәм ничек яраланганлыгын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Үзе татар була торып, ни өчен татарча бик үк яхшы белмәвенең сәбәпләрен дә әйтте. Бик яшьли — нибары алты яшь ярымда — ятим калган да шуннан соң балалар йортында, руслар арасында тәрбияләнгән икән.
— А хәзер сиңа ничә яшь? — диде ул миңа, нигәдер кинәт кенә минем белән кызыксынып.
Минем унбер яшьтә икәнемне белгәч:
— Но-о! — дип, калын кашларын сикертеп, белмим, никтер куанып куйды да:— Беләсеңме, Сафиулла, детдомнан мин какраз синең шикелле унбер яшьтә качтым! — дип, үзенең малай чаклары турында сөйләргә кереште.
Балалар йортыннан качканнан соң, үзебезнең Татарстаннан китеп Ташкент якларына барып чыккан да, «Папаша» кушаматлы бер өлкән яшьләрдәге карак җитәкчелегендәге шайкага юлыккан һәм, шул шайкадагылар белән бергәләп, бурлык-мутлык белән көн күреп йөргән икән ул. Сөйләвенә караганда, күбрәк базар тирәсендә чуалганнар. Туры килгәндә, башка төр әйберләрне «сөртүдән» дә тайчанмаганнар, әмма төп кәсепләре кесә «чистарту» булган. Анда да очраган бер кешенекен түгел, бәлки спекулянтларныкын һәм баерак кешеләрнекен генә чистартканнар. Әнә шул «кәсеп» белән шөгыльләнеп йөргән вакытта үзе юлыккан маҗаралар турында бик күп сөйләде ул миңа.

ик күп нәрсәләр турында сораштырып утырды. Ләкин, барыннан да игрәк, ул минем ни өчен Хәмидә апаларда яшәвем белән кызыксына де, ахрысы. Аның, син нигә монда торасың, нигә үз өегездә тормыйсың? ип соравына мин башта, болай гына, Зәйнетдин абый кайтканчы гына эрып торам дип, серне бик үк ачып бетермичәрәк котылмакчы булган дем. Ләкин Роберт абый аның белән генә канәгатьләнмәде: «Кем алай тәргә кушты? Хәмидә апаң үземе, әллә Зәйнетдин абыеңмы?» — дип кентекләргә тотынды. Мин Зәйнетдин абый үзе шулай кушып киткәнле-ен әйтергә мәҗбүр булдым. Шуның өчен хәтта гармунын да миңа кал-ырып киткәнлеген әйттем.

Мин шуларны сөйләп биргәннән соң, Роберт абый ничектер күңелсез-әнебрәк киткән сыман булып, байтак кына уйланып утырды. Аннары:

— А син төнлә Хәмидә апаң янында йоклыйсыңмы? — дип сорады.

— Анысы сиңа ни пычагыма кирәк инде? — дидем мин, аның шушы-ай чамадан тыш кызыксына башлавына ачуым килеп.— Сине бит кем-нең кайда йоклаганын тикшерергә түгел, кибет тикшерергә дип кенә җибәргәннәрдер, шулаймы?

Ул минем бу соравымнан соң аптырабрак калды, ахрысы, дәшмәде. Ә мин шул арада әйттем аңа:

— Алай бик беләсең килгәч — бел инде, алайса: без көн дә Хәмидә апа белән бергә йоклыйбыз! — дидем.

Болай да киң танавы тагын да киңәебрәк китсә дә, ул, тыштан артык исе китмәгән атлы булып күренергә тырышып:

— Яхшы, яхшы, син дөрес эшлисең, шулай кирәк! — диде һәм елмай-гандай итте.

Аннары кесәсеннән минем баш бармак юанлыгы кара ручка чыгарып, шуны ачып-ябып уйнарга тотынды. Минем беркайчан да андый шәп ручка күргәнем юк иде әле. Шуңа күрә, әле яңа гына ачуымны китерүен дә онытып, тыелгысыз рәвештә, Роберт абыйга якынрак барып бастым. Берәр минут шулай торгач, үзем дә сизмәстән, тегенең ручкасына үрел-дем. Ул һичнинди каршылыксыз, хәтта сөенебрәк тә бугай әле, ручкасын шундук миңа сузды. Куанычымнан тыннарым кысылып, калтыранган кулларым белән ручкасын әйләндерә-әйләндерә карый башладым. Роберт абый бик канәгать кыяфәт белән елмаеп куйды да:

— Беләсенме, Сафиулла, бу нинди ручка? — диде һәм, минем җавап-ны да көтеп тормастан, үзе барысын да аңлатып бирде. Аның ул руч-касы гади ручка гына түгел, бәлки карага манмыйча да көне буе яза торган ручка икән ләбаса! «Авторучка» дип атала икән ул.

— Ә кайдан алдың син моны, Роберт абый?

— Фронттан алып кайттым. Немецныкы бу ручка.

— Шушы бәрәү генәме синең мондый ручкаң? Тагын юкмы өегездә?

— Юк, Сафиулла. Нәрсә, сиңа да кирәкме әллә?

— Өегездә тагын булса, монысын миңа сатарсыңмы әллә дип сора-вым иде... Ә ничә таңкә тора бу ручка, Роберт абый?

— Мең сум, Сафиулла.

— Һо-о! Алай булгач, өегездә тагын шушындый ун ручка булса да, миңа тәти торган түгел икән! Аның кадәр акча миндә түгел, минем әнидә дә булганы юктыр әле!

Роберт абый, минем шушылай шаккатып калуыма кәефе килеп, юка иренле авызын җәелә алган кадәр җәеп, рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Аннары кинәт көлүеннән туктады да:

— Телисеңме, мин сиңа бу ручканы бушка бирәм? — диде.

— Ы-ы, көт синнән бушлай! Чукынсаң да бирмәячәксең син аны! — дидем мин, бирәсе булса тизрәк бирсен өчен, юри шулай аның канын кыздырырга ниятләп.

Дөрес ниятләгәнмен икән.

— Минме? Мин бирмимме? — диде ул, бик нык әсәрләнеп.— Мә, хәзер үк ал и ул сиңа була!

Ялт итеп кулыннан тартып алудан көчкә тыелып калдым да, шаяртмыймы икәнен белер өчен:

— Белеп тор, Роберт абый: бер алсам кире бирмим мин аны,— дидем.

— Ә мин больше синнән сорамыйм да аны, мә ал! — диде ул, әле һаман ручкасын сузып торган килеш.

— Рәхмәт, Роберт абый, бик зур рәхмәт! — дип, ручкасын тиз генә эләктереп кесәгә салдым да, су буена төшеп, су коенып ятучы малайлар каршында мактанып кайтмакчы идем. Ләкин алай ук итеп йөрергә насыйп булмаган икән. Атылып капка төбенә генә чыгып җиткән идем, Роберт абыйның:

— Сафиулла, син кая йөгерәсең? — дигән тавышы ишетелде.

Мин шып туктап борылып караганда, ул тәрәзәдән башын тыгып карап тора һәм кыяфәте, өйдә ялгызы гына калырга курыккан кешенеке төсле, куркынып-агарынып киткән иде.

— Курыкма, Роберт абый, мин хәзер: ручканы иптәш малайларга күрсәтеп кенә кайтам! — дидем мин, аны тынычландырмакчы булып.

Ләкин ул үзен ялгыз калдырып киткәнгә түгел, ниндидер бүтән сәбәп аркасында пошаманга төшкән иде булса кирәк.

— Киләле монда! — диде ул, чыраен сытып.

— Нәрсә, Роберт абый?

— Беләсеңме мин сиңа ни өчен бирдем бу ручканы?

— Ни өчен соң?

— Мин сине яратам, Сафиулла. Вот и бирдем. Ә син мине яратасыңмы?

— Бик яхшы кеше син, Роберт абый!

— Во, во, Сафиулла! Мин шулай уйладым да синең турыда. Беләсеңме, сиңа бүген нәрсә эшләргә кирәк?

— ?

— Син бүген Хәмидә апаңнарда кунма, ярыймы!

— Юк, Роберт абый! Хәмидә апаларда кунмыйча ярамый миңа! — дидем мин, күңелем нигәдер хәвефләнеп китеп.— Зәйнетдин абыйга бер көн дә Хәмидә апа янына керми калмаска дип сүз биреп куйган кеше бит мин!

— «Сүз» дә «сүз»! Нәрсә ул сүз! — диде Роберт абый, ачуын тыеп тора алмыйча кызарынып-бүртенеп.— Чепуха ул сүз! Ә мин сиңа мең сумлык ручка бирдем. Син, понимаешь, шулай да мине тыңламыйсың!

Әһә, тел төбе аңлашылды моның: шушы авторучкасын биреп, мине алдалап, Хәмидә апа белән икәүдән-икәү генә кунасы килә икән ич бу кылыч борынның. Юк инде, абзыкаем, булмас инде анысы ук! Синең әллә нинди фашист кулларында йөргән бер ручкаңа гына түгел, шундый йөз ручка бирәм дисәң дә Хәмидә апа янына керми калачак кеше түгел мин! Сиңа ышанып калдырсаң...

— Мә алайса ручкаңны!

— Нәрсә, сиңа кирәкми, да? — диде ул, мин әле генә чамасыз нык куанып алган ручкасын кире сузганга аптырап.

— Кирәген бик кирәк иде ул миңа. Мондый ручка белән язсам, гел бишле куярлык итеп, матур язар идем. Минем үземнең ручка — агач ручка гына. Аның да каләме биш былтыр элек бозылып бетте инде. Шулай булса да, мин синең бу ручканны ала алмыйм, болай булгач. Чөнки мин Зәйнетдин абыйга сүз биреп калдым. Мин — совет укучысы. Ә совет укучысы беркайчан сүзеннән чыкмаска тиеш!

Шуннан соң Кылыч борын минем белән күп сатулашып тормады: кулыннан килсә кабып йотардай булып, күзен акайтып карады да:

— Ах, син — татарчонок! — дип, ручкасын тартып алды һәм тәрәзәне шапылдатып ябып ук куйды

үзе татар башы белән шулай дип эчпошырып торганы өчен, минем дә бик яман ачуым чыкты.

— Мин татарчонок булсам, син ишәк колак! — дидем дә, чатыр чабып, су коенырга төшеп киттем.

Юри озак йөрдем мин ул көнне су буенда. Бер авторучка биреп, мине ахмакка чыгарып калдырырга теләгән теге Кылыч борын күзенә күренәсем килмәде.

Мин кайтып кергәндә Хәмидә апа инде самоварын кайнатып өстәлгә үк китереп утырткан һәм табын хәзерләп йөри иде. Кылыч борынның да кәефе шәп: авызын колагына кадәр ерып көлә-көлә Хәмидә апага нидер сөйләп утыра. Көндезге ачуын оныткан иде, ахрысы: мин килеп кергәч тә чырае караңгыланмады. Инде өстәлгә китереп куелган бер банка балык консервасы, бер ит консервасы янына Хәмидә апа бер таба йомырка тәбәсе дә алып килеп утырткач, тегенең йөзе тагын да яктырып китте һәм ул, кулларын уып:

— Эх, мондый яхшы закуска астына йөз грамм да булса! — дип, күзләрен майландырып, калын кашларын сикертеп куйды.

Аның шушы сүзләреннән соң, Хәмидә апа кинәт уңайсызланып, кызарып, беркавым уйланып торды. Аннары идән астына төшеп китте һәм аннан Зәйнетдин абый заманыннан ук калган, ул кунакка кайткач аны сыйларга дип саклап тоткан бер «чәкүшкә» аракысын алып менде.

«Чәкүшкә»не күргәч, Кылыч борынның авызлары ерылып китте. Хәзерге кыен заманада шешәле чын аракыны авыл җирендә түгел, Мәскәүнең үзенә барсаң да табулары бик кыен булуын, ә Хәмидә апа менә авылда торып та әлеге «әҗәл даруын» юнәтүен әйтеп, башта аны татарча мактады. Аннары, бер стаканны йомырка тәбәсе астына салып куйгач, русчалатып мактарга тотынды...

Ул сөйләгәннәрнең барысын да аңлап бардым дисәм — ялган булыр. Шулай да тел төбен чамалап утырдым мин аның. Кылыч борынның сүзләренә караганда, безнең Хәмидә апа дөньяда иң уңган һәм иң матур хатын иде. Мондый хатынның ире, ягъни Зәйнетдин абый була инде, үзен җир йөзендә иң бәхетле кеше дип санарга тиеш. Ә менә Кылыч борын үзе ул яктан бик бәхетсез икән: хатыны искиткеч усал булып чыккан аның. Шуңа күрә Кылыч борынның ул хатын янына кайтып керәсе дә килми икән. Әгәр дә Хәмидә апа үзенә кияүгә чыгарга риза булса, Кылыч борын иртәгә үк хатынын аерыр иде дә Хәмидә апа белән рәхәтләнеп тора башлар иде. Алардан да бәхетлерәк семья булмас иде, имеш, бу дөньяда.

Ул шулай тузга язмаганнарны лыгырдап утырган вакытта мин, Хәмидә апа бу ахмакның тасма теленә ышанып куймаса гына ярар иде дип, куркып, гел аңа гына карап утырдым. Бәхеткә каршы, бер дә андый-мондый хәвефле нәрсә күренмәде аның йөзендә. Киресенчә, соңга таба Кылыч борынның хәттин аштырып лыгырдавына аның да эче поша башлады сыман тоелды миңа. Ләкин, шул ук вакытта, ул ачуын Кылыч борынга сиздерергә дә теләми, шуңа күрә, үзен көчләп булса да, елмайгандай итеп утыра. Ревизор булганга шикләнә иде, ахрысы, ул аннан. Югыйсә, Хәмидә апаның талканы бик коры була торган иде башка чакта. Болай зурдан кимсетү турында әйткән дә юк инде, хәтта аның кибетендә чак кына урынсызрак сүз ычкындырган кешеләрнең дә авызларын бик тиз томалап куя торган иде.

Әй, бу адәм баласының нәфсекәйләре! Кара инде син аны, ә? Сүз белән ялагайлануы гына җитмәгән, Хәмидә апаның иңенә кулын салырга да итенә башлады бит теге Ишәк колак!.. Хәмидә апаны да әйтер идем: әле һаман шуның кыланышларына түзеп тора бит. Үзенең ачуы тимгел-тимгел булып битләренә үк бәреп чыккан, ә шулай да дәшми, түзә, агай! Шулай ук куркыныч кеше микәнни соң бу Ишәк колак?.. Кит

инде, кит, ревизор дигәч тә, әллә кем түгелдер лабаса!.. Әллә инде мич алдыннан берәр утын агачы алып килеп, сизмәгәндә генә...

Сиздермичә генә муен тамырына берне сыйлыймммы икән әллә дип кенә торганда, ниһаять, түземе төкәнде булса кирәк — Хәмидә апа, телгә килеп, башта:

— Житте, Роберт агай, бераз шаярдын — булды! — диде. Аннары тегенең кулын кискен читкә кагып, кече якка кереп китте.

Шуннан соң Кылыч борын кулын озайтмады, ләкин теле белән инде йокларга яткач та әллә ни гомер җыен юк-барны сөйләп, лыгырдап ятты. Нигәдер мине йоклатып җибәрәсе килә иде аның. Әледән-әле:

— Сафиулла, йокла инде, йокла! — дип үгетләп маташты.

Ә мин, аңа юри үч итеп, күзләрем йомыла башласа үземне чеметә-чеметә булса да, түздем һәм ул тәмам эреп гырлап китмичә тәки йокламадым.

Шулай итеп, ул төндә мин җиңүче булып калдым. Ләкин менә икенчесендә!..

Иртән мин йокыдан торганда кояш инде әллә кая күтәрелгән иде. Хәмидә апа да, Кылыч борын да өйдә юк, кибеткә ревизия ясарга киткәннәр иде булса кирәк. Көн тәкатьсез кыздыра. Җилнең әсәре дә юк. Тиз генә тамакка капкалап алам да су коенырга чабарга кирәк дип, өстәл янына килеп утырсам — ике күзем дүрт булды: күрәсең, берәр нәрсә язарга алган җиреннән онытыптыр инде, Кылыч борын теге авторучкасын өстәл өстендә калдырып киткән иде!

Бу көтелмәгән шатлыктан йөрәгем гөрс-гөрс типкән хәлдә, башта мин ул ручка белән язып карарга тотындым. Менә ручка иде ул, ичмаса! Шундый шома, шундый тигез итеп яза — шаклар катарлык. Ничек кулга төшерергә соң моны?.. Әллә инде яшереп куярга да. Кылыч борын сораса, күрмәдем-белмәдем, мин йокыдан торганда өстәлдә бернинди ручка да юк иде дип, алдашып, үземә алып калыргамы моны? Бигрәк тә шәп нәрсә бит, чукынган! Кылыч борын барыбер кадерен белми бугай аның, тәки менә шушылай, бүгенге шикелле, берәр төштә онытып калдырып харап итәр. Яки берәрсенә үзе бушка биреп калдырыр. Әнә кичә Хәмидә апа янына кермәскә риза булган булсам, миңа да биреп калдырасы иде бит ул аны!..

Шулай тәвәккәлләп алып калган булсам, ак сакаллы карт буласы икәнмен. Кылыч борын бер тузынып алыр иде дә шуның белән вәссәлам булыр иде. Хәмидә апаның намусына да тап төшмәс, тормышы да җимерелми калыр иде. Ләкин, гомергә алдашканым булмаганлыктан, ул көнне дә ялганларга йөрәгем җитмәде. Уйладым, уйладым да ахырдан Кылыч борынның ручкасын, кибеткә илтеп, үзенә тапшырырга кирәк дигән нәтиҗәгә килдем. Тик шуңарчы, су буена алып төшеп, дус-иш малайларга күрсәтеп, алар алдында бераз мактанып, дәрәҗәне күтәреп менмәкче булдым. Һәм менә шул шайтан коткысына бирелү харап итте дә инде бөтен эшне.

Су буена төшеп җитеп, ручканы кесәмнән чыгарган гына идем — бер көтү малай сырып та алды үземне. Аларның күбесе миннән зурраклар, ә минем абыйларның берсе дә күренми. Күренергә тиеш тә түгелләр, чөнки алар икесе дә колхоз эшенә йөри хәзер. Теге малайлар мине сырып алдылар да, кая, тотып кына карыйм әле, Сафиулла дус, дигән булып, башта берсе кулын сузды, аннары икенчесе, аннары өченчесе... Ул да булмады, тизрәк тотып карарга тырышып, бер-берен этешергә-төртешергә тотындылар. Чын-чынлап талаш китте һәм... башта шырт иткән тавыш ишетелде, аннары кайсыдыр:

— Сындырдыгыз бит, тәре каракларь! — дип ачыргаланып кычкырып җибәрде.

Мин кем сындырганын белергә дә өлгерә алмыйча калдым: минут эчендә җыелган егермеләп малай, өреп очыргандай таралышып, секунд

эченә суга сикерешеп тә беттеләр. Ә ручка кыл урталай сынган һәм аны тезәтеп-сиплән кенә игә китерерлек түгел иде инде.

Шушы хәлдән соң бик нык аптырашка калдым мин. Шайтан да кушмаган көенчә, мактанчыкланып, су буена төшүем өчен иң элек үземне сугып үтерерлек булдым. Аннары яр буена барып басып, малайларны бик каты итеп сүктем. Алай да ачуым басылмагач, үзебезнең өйгә кайтып, тезмәгә мендем дә, печән өстенә сузылып, бу чамадан тыш кыен хәлдән ничек котылырга икән дип, уйланып яттым. Уйлана торгач менә мондый карарга килдем: Хәмидә апа янына кунарга кермәскә риза булсам, кичә теге Кылыч борын миңа ручкасын бирергә уйлаган иде бит. шулай булгач, нигә бүген дә шуңа риза булмасын икән? Әйе-әйе, тотарга да, ревизия ясый торган жиренә — кибеткә барып, ялгыш мин синең ручканны сындырдым, Роберт абый, шуңа күрә мин синең кичә әйткән сүзеңә риза, дип әйтергә кирәк...

Менә шушылай итмәк булган идем мин. Ләкин анысына да йөрәгем житмәде. Һәм мин, ул көнне беркемгә бер сүз дә әйтмичә, беркемгә дә күренмичә, тезмәдә кундым.

Иртәгесен мин барып кергәндә Хәмидә апаларның өе ачык, ләкин өйләрендә беркем дә юк иде. Әмма мин өйләре ачык һәм анда кеше булмаганга түгел, ә өйнең яме качканга аптырап калдым. Әле кичә генә чип-чиста һәм бар нәрсәләре тәртибе белән тиешле урынына куелган, картлар әйтмешли, көлеп торган өй эчен бүген бөтенләй танып булмый: караваттагы урын-жир башка көннәрдәгечә пөхтәләп жыеп куелмаган гына түгел, киресенчә, туздырып ук ташланган, бер мендәр хәтта идәндә үк ята; йодрык-йодрык кадәрле кып-кызыл чәчәкләргә күмелеп, моңарчы тәрәзә төбен балкытып утырган яран гөле дә кемгәдер комачаулаган, ахрысы — аны да, бәреп төшереп, чүлмәген чәлпәрәмә иткәннәр. Хәтта кече мичне олы мич белән тоташтыра торган калай торбаны да бәреп төшерә язганнар: баш-башларыннан сылап куелган урыннары кубып, идәнгә коелган, торба үзе дә чак-чак кына эләгеп тора. Ләкин барыннан да бигрәк мине менә нәрсә өнсез итте: Зәйнетдин абый миңа калдырып киткән гармун да тәмам эштән чыгарылып, уртага аерылып ташланган иде!..

Кыскасы, Хәмидә апалар өенең асты-өскә китерелгән иде.

Ә эшләр менә болайрак булган икән ул төндә. Инде кайчаннан бирле менә кайтам, менә кайтам дип безне өметләндереп йөргән Зәйнетдин абый, ниһаять, шушы үткән төндә кайтып төшкән. Кайтып төшкән дә, Хәмидә апаны уятып, ул каршына чыкканны көтеп торырга да түземе житмичә, иң элек ишек алды як тәрәзәсенә килгән һәм, кул фонарен яктыртып, өй эченә караган. Караган да, Хәмидә апа яткан карават янында бер ир кеше басып торганын күргән һәм, күкерт урынына кабынып, атылып өйләренә барып кергән. Барып кергән дә иң элек теге Ишәк колакны сугып еккан, аннары Хәмидә апаны туздырырга тотынган. Ихтимал, кызулыгы белән ул аларны шунда тынсыз ук та иткән булыр иде, ләкин әлеге Кылыч борынның куркып бик каты кычкыра башлаган тавышын ишетеп, безнең әни барып кергән дә, Зәйнетдин абыйны жайлап-көйләп, эшне алай ук зурга жибәрергә ирек бирмәгән.

Теге Ишәк колакның коты шул тикле алынган булган бичараның — әни килеп керүгә, киемнәрен култык астына кыстырган да, ишеккә дә барып тормастан, тәрәзәдән генә чыгып сызган!

Йодрык кадәр кызыл чәчәкле яран гөле әнә шул чакта харап булган инде.

Кылыч борын чыгып качкач, кем иде ул, синең яныңда нишли иде, дип Зәйнетдин абый Хәмидә апаны тыкырдатырга керешкән. Хәмидә апа, күз яшьләрен түгеп:

— Кибеткә ревизия ясарга килгән кеше ул. Кичә ревизия бетеп житмәде дә шуңа күрә кунарга калган иде. Ләкин безнең арабызда бер-

ни дә булмады. Җир йотсын әгәр ялганласам, менә шушы урынымда яшен суксын, берни дә булмады! Минем янымa әле яна килеп баскан гына иде ул. Алай-болай кагыла-нитә калса, тибеп очырырга дип тора идем мин аны. Менә шул чакта син килеп кердең. Ипинең чыраен күрмим, шулай гына булды! — дип әйтеп-аңлатып биргәч, бераз гына йомшый-сүрелә төшкән шикелле дә булган икән. Ләкин берадан тагын кызып китеп:

— Ярый, монысы шулай да булган булсын ди! Ә Сафиулла кая соң? Син аны һәркөнне минем янда куна дип яза идең бит хатларында! Бүген нигә юк соң ул, нигә алып кермәдең аны? — дип, Хәмидә апаны тагын тинтерәтә башлаган.

— Башка көннәрне гел үзе керә торган булгач, кичә дә шулай кайтып керер дип белдем мин аны. Ишекне дә шуңа бикләми калдырган идем,— дигән Хәмидә апа.

— Ә кермәгәч нигә үзең алып чыкмадың? — дигән Зәйнетдин абый, һаман үз туксанын туксанлап.

— Күрәчәгем шулай булгандыр инде,— дигән Хәмидә апа, тагын да ныграк итеп елап җибәреп.— Көн буе ревизия белән азапланып, башларым катып беткән булгангадыр инде, Сафиулланы кереп алырга бөтенләй уема килмәгән шул. Растрата зур булыр төсле, шуңа күрә башкайларым бер дә юньләп эшләмәгәндер инде! Югыйсә син киткәннән бирле бер генә төн дә Сафиулладан башка ялгыз кунганым юк иде!

— Хәмидәң бик дөрес әйтә, наным Зәйнетдин: әйе, Сафиулласыз кунганы булмады аның. Куну гына түгел, гел Хәмидәң янында яшәде ул. Мин аны бүген дә Хәмидә янындадыр дигән идем әле,— дип минем әни дә әйтеп-аңлатып караган икән каравын.

Ләкин Зәйнетдин абый аларның сүзенә ышанмаган. Ярсыган үгез шикелле җенләнеп, башта гармунны аерып ыргыткан, аннары шул сәгатендә үк авыл Советы председателен һәм андый чакта шаһит булырга тиешле кешеләрне чакырттырган һәм Хәмидә апаны аерган да кайткан юлыннан кире китеп тә барган. Әти-әниләре Биектауда яши дип сөйләгәннәр иде аның. Аларны күреп китәргә дип шунда юнәлгәндерме, әллә туп-туры үзе хезмәт итә торган частька юл тоткандырмы — анысын беркем дә әйтә алмады.

Шул китүеннән ул безнең авылга бүтән кайтмады. Кайберәүләр аның турында: Хәмидәне аерып киткәннән ары озак та тормыйча сугышта үлеп калган, имеш, дип, икенчеләре, киресенчә, бик зур батырлыклар эшләгән икән дә шул батырлыклары өчен герой исеме алган икән дип сөйләделәр. Бу имеш-мимешләрнең кайсысы дөрес икәнен тәгаен генә әйтеп бирә алмыйм. Шунысын гына кистереп әйтә алам: Татарстан геройлары турындагы китапта Шириязданов Зәйнетдин Шакир улы дигән герой юк. Миңа ышанмасагыз — үзегез тикшереп карагыз. Кем белсен: бәлки, ул үлмәгәндер дә, герой да булмагандыр. Меңнәрчә совет солдатлары кебек үк, герой исемен алмаса да, сугышның ахырына тикле батырларча сугышып йөргәндер дә, сугыш беткәч исән-имин туган авылына кайтып, яраткан эшенә — балалар укытырга керешкәндер. Ихтимал, әле хәзер дә укытуын дәвам итәдер... Кем белә, бәлки, ул әле дә теге чактагы юләрлеге өчен үкенеп, Хәмидә апаны сагынып-саргаеп яши торгандыр. Үлеп ярата иде бит ул Хәмидә апаны. Әнә, кырык беренче елны сугышка киткәндә юл буе сөеп һәм үбеп туя алмаган иде...

Ә Хәмидә апаң нишләде соң, дисезме?

Зәйнетдин абый аны аерып киткән көнне мин аларга кереп, өйләренең туздырылган кош оясына охшап калуына шаккатып торган чакта, Хәмидә апа елый-елый шешенеп бетеп, кайдандыр кайтып керде дә:

— Их, малай, малай! Кичә кайларда гына булдың соң син? — дип, бик үк каты булмаса да, шактый сизелерлек итеп, артыма тибеп чыгарып җибәрде.

Ул чакта мин бит әле эшнең нәрсәдә икәнен белмим, шулка күрә, бердән, өйләренең шулай пыр туздырылган булуыннан, икенчедән, Хәмидә апаның орышып, артыма тибеп озатуыннан чыгып, мин аны бер төн эчендә акылга җиңеләеп калган, ахрысы, бу, дип уйлаган идем. Ләкин мәсьәләне әни анлаткач ачыкланды: ул көнне үз акылында булган әле ул. Ә менә соңыннан...

Төнне кайда үткәргәндер һәм көндез төш авышканчы кайларда йөргәндер — анысын шайтан белгән, әмма төштән соң теге Кылыч борын, ревизияне ясап бетерергә кирәк дип, Хәмидә апаның кибетенә килеп кергән. Менә шунда Хәмидә апа, бичаракаем, бик зур хата ясаган. Зәйнетдин абый белән булган хәлләрдән соң нервылары какшаган булгангадыр инде, күрәсең, Кылыч борын ревизия турында авыз ачуга, кинәт ярсып киткән дә:

— Менә сиңа ревизия, сасы кәҗә тәкәсе! — дип, ящик ача торган тимер белән тондырган тегенә.

Кылыч борынның сыйрагына барып тигән дә сыйрак сөяген азрак күгәртеп чыгарган тимер. Аның урынында башка бер адәм рәтлерәк кеше булса, бу эшне әллә ни зурга җибәрмәс, бер кычкырып алыр иде дә шуның белән онытыр иде. Ләкин Ишәк колак хатын-кыздан да вакчылрак бәндә булып чыккан. Минуты белән башта Хәмидә апа үзенә бәргәндә кибеттә булган кешеләрнең исем-фамилияләрен язып алган, аннары авыл фельдшерыннан сыйрагы күгәреп чыкканлыкка белешмә алып, аксый-аксый районга чапкан.

Шуннан соң райпотребсоюздан өч кеше килеп, атна буе төпченеп, ревизия ясап интектерделәр Хәмидә апаны. Ләкин эшен чиста алып барган булып чыкты ул: телгә алып сөйләрлек гаебен таба алмадылар.

Ул мәшәкатьләрдән котылган гына иде, теге Кылыч борын мәсьәләсе буенча бимазаларга тотындылар. Бимазалап кына да калмадылар, хулиганлыкта гаепләп, ел ярымга утыртып та куйдылар бичараны.

Әнә шул хәлләрне башыннан кичергәннән ары акылга җиңеләеп калды ул. Болай карап торырга ипле генә, акыллы гына күренә иде ул үзе. Колхоз эшендә дә җен урынына эшли торган иде. Ләкин вакыт-вакыт кинәт кенә ычкынып китеп, үз алдына нидер сөйләшә, кайт, тилереп йөрмә, Зәйнетдин, җир йотсын әгәр, минем сиңа хыянәт иткәнем юк, дип кычкырып-кычкырып куя башлый. Аннары кызганыч һәм моңлы итеп җырлап җибәрә:

Их, Зәйнетдин, күрдең микән
Алма чәчәк атканын?
Соңгы сулышыма кадәр
Көтәм синең кайтканың.
Иделләрне иңләп-буйлап
Йөзәрсең, урдәккәем.
Бүген кичкә дә кайтмасаң —
Түзмәс бит йөрәккәем...

Җиңеләеп китеп, шушы җырларны җырлый башладымы, Хәмидә апаның холкын белгән ир-атлар аның тирәсеннән ераграк булу ягын чамалыйлар. Андый чакта ир-ат затын һич тә күрә алмый, аларны ата-казлар, тормыш бозгычлар дип пыр туздыра торган иде.

Инде менә әни шул Хәмидә апаның вафат булуын әйтеп язган...

Ә бит аңа әле кырык тугыз да тулмаган иде. Яшәргә тиеш иде әле ул. Рәхәтләнеп яшәргә тиеш иде! Теге чакта Роберт-ишәк колактан куркып тезмәдә качып ятмаган булсам, һичшиксез, рәхәтләнеп яшисе кеше иде. Аның шушылай вакыты җитмичә үлеп китүенә иң әлек мин гаепле ләбаса!..

Дөрес, мине беркем дә хөкем итмәячәк. Чөнки закон күзлегеннән караганда җинаятьче түгел мин. Тик шулай да йокы качты менә.

Өч тәүлек тула инде күзне йокы алганы юкка.

## Фаил Шәфигуллин

### Яшьлек

Мин кичмәгән әле океан-сулар,
Иркендерме дөнья, киңдерме...
(Миңа әле бары егерме.)
Учка кысып издем чуерташны,
Тезгә куеп бөктем тимерне.
Мин давылдан өлгер булмак булдым,
Ә ул каршы төшеп өлгерде.
(Миңа әле бары егерме.)
Күкрәк киереп давыл аша киттем,
Һәм ул җиңелеп артка чигенде.

«Җаның алам» — диеп Әҗәл килде,
(Миңа әле бары егерме.)
«Җаның алам!» — дидем мин Әҗәлгә,
Әҗәл башта теш ыржайтып көлде,
Аннан тынды...
Тәмам каушап калды...
Соңра кинәт борылып йөгерде.
(Миңа әле бары егерме.)

### Таныш түгел эткә

Тимер җене кагылгандыр, ахры, сиңа,
Нигә килеп иялә штең безнең цехка?
Түшең дә ак, тырнакларың, маңгаең да,
Күзләреңдә шатлык та юк, юк кайгы да.
Тезләреңә баш куярлык юк дусларың,
Өреп-әрләп озатырлык юк дошманың.

Анысы дөрес: урының җылы, тамагың тук,
Ләкин этләр көнләшерлек этлегең юк.
Җил-яңгырда ачлы-туклы йөргән этләр
Синнән, җаным, күп мәртәбә бәхетлеләр.
Назланма да, акланырга да тырышма,
Һәркемнең дә бар үз урыны бу тормышта.

### Кою цехында

Тимер тавышы бөтен җирдә,
Тимер кебек кызган һава.
Исеп тора утлы җилләр,
Тимер очкыннары ява.

Бар нәрсәгә көче җиткән
Мифик алла, титан төсле,
Яраткан да тимер дөнья
Тик елмаеп тора кеше.

Үлеп гашыйк булучылар
Яныл сөйгәннәр:
«Онытылмый,— диләр,—һич тә
Яшьли сөйгән яр».

Юк сүз икән, ә мин менә
Оныттым сине.
Йөрәк өзгәләнми генә
Үзгәне сөйде.

«Оныттым»,— дип кабатлыйм мин
Көн саен, һаман.
Тик күрәсе иде әле
Сине яңадан.

Күкрәгемә кысып-кысып
Әйтәсе иде:
«Оныттым мин, оныттым,— дип,—
Оныттым сине».

## Каеннар

Серләшеп туймый каеннар
Яшел хәтфә аланда.
Каен телендә сөйләшү
Рәхәт, ахры, аларга.

Корган каен гына сүзсез
Тирән уйларга чумган.
Ана телен белми торган
Кызганыч кеше сыман.

●

Исеңдәме, ак көймәгә утырып,
Ап-ак җилкән корып, ак таңда
Ак дулкыннар ярып киткән идек
Диңгездәге ап-ак атауга.

Текә ярлар мәрмәр иде анда,
Ә кыялар — ялт-йолт: нәкъ көзге.
Әкияттәге серле кала кебек
Күптән тарткан иде ул безне.

Ераклык та, җил дә, дулкыннар да —
Дуслар булды башта барысы да.
Кара болыт төяп кара давыл
Чыкты ләкин безнең каршыга.

Ак ишкәкләр кара суга акты,
Кара җилгә очты ак җилкән.
Күңелләрдә кара шик яралды:
«Ерактагы атау ак микән?»

«Ак түгелдер»,— дидек давыл аша
Күрә алмасак та без аны.
«Ирешәлмәслек ерак хыял сыман
Алдап торгандыр ла ул бары».

...Ярга чыккач тагын хәйран калдык
Карап теге серле атауга:
Тау башлары җем-җем энҗе чәчә,
Кыялардан көмеш нур ага.

Үкенсәк тә, кызыксак та ләкин
Кабат анда бара алмадык.
«Ерактагы атау ак түгел»,— дип,
Үзебезне үзебез алдадык.

## Рөстәм Мингалимов

### Көзге төндә

Күргәнем юк иде мондый төнне —
Төн дисәң дә бүген төн менә!
Су төбендә яткан шәһәр төсле,
Казан бүген яңгыр төбендә...
Күмелгәннәр мине борчыр хәлләр,
Караңгылык барын яшергән.
Шуның өчен бугай җаным тыныч,
Туган кебек мең ел яшәргә.
Ә юеш төн шулай йөзен юа
Мина күренәсе көннәрнең.
Көзге яңгырдан соң шытып чыгар
Яз шытмаган сөенеч гөлләрем...
Күргәнем юк иде мондый төнне —
Төн дисәң дә бүген төн менә.
Су төбендә яткан шәһәр төсле,
Казан бүген яңгыр төбендә.

1970

### Сәбәп

Чын яшемнән мин яшь күренәмдер —
Җитди генә сәбәп бар моңа:
Миңа афәт җиле өргән чакта,
Әнкәм басты җилнең каршына.
Салкын җилләр аны кыйнадылар,
Кайнар җилләр аны пешерде.
Фашист бомбасыннан ауган һәр йорт
Аның иңнәренә ишелде...
Бу дөньяда ул эшләгән эшне
Мин санап та чыга алмамын.
Ул төясә — арба сыгыла иде,
Каян шундый куәт алгандыр?!
Шәп атлары ак күбеккә батып,
Олы юлда егылып үлделәр.
Үзе тартып китте атлар йөген —
Бишек тирбәтәсе кул белән!
Шундый әнкәм булган өчен дә мин
Үз яшемнән бераз яшь калдым.
Әнкәм генә менә...
Картайды шул,
Үз яшеннән күпкә картайды.

1970

Рәхәтләнеп көлеп яшәгәндә
Күкрәгемә авыр уй баса:
Бу дөньяда әле бер көлүең
Җинаятьтер, бәлки, уйласаң.
Җинаятьтер, бәлки, уйласаң?!

Г...мер итү әллә нинди нәрсә,
Үзе татлы, үзе әрнетә.
Елап яшәүчеләр шуңа күп ул —
Көлеп яшәүләргә ни җитә.
Көлеп яшәүләргә ни җитә?!

Ак көнеңне буса төн карасы,
Төнне арттан буып ала таң.
Бу дөньяда әле бер елавың
Җинаятьтер, бәлки, уйласаң,
Ул шулайдыр әле, уйласаң?!

1970.

## Төзәтеп тә булмый тиз генә

Ирек өчен көрәшүче илләрнең
тотканлыкка төшкән улларын уйлап.

Дөнья дидек һаман, дөнья дидек.
Ничек дөнья дидек без моны?!
Дөнья түгел икән, бу — кешенең
Өстендәге соңгы костюмы.
Берәүләргә — бүген килеп бетми,
Бераз үсә төшкәч, тап-таман.
Берәүләргә, алар үскән саен,
Кечерәя бара бу һаман:
Кысанлана бара — алышы юк,
Ямьсезләнә бара — түз генә...
Моны салып ташлау җинел түгел,
Төзәтеп тә булмый тиз генә.

1969

## Карчык

Ире дә югалган яңын,
Уллары да югалган.
Аларны эзләр өчен тик
Зур-зур күзләре калган.

Һәм бара ул эзләгәнен
Таба алмасын белеп...
Бара ул инде яңадан
Тураймаска бөгелеп.

Урнашкан сугыш йөге —
Хәтерсез хирург онытып
Калдырган пычак кебек.

Бара ул, ялгыз көймәдәй,
Бара офыкны куып.
Күзләреннән тула кебек
Көймәгә вакыт суы.

1968

●

Күптән болай булганым юк иде —
Бер сәбәпсез хәтта елмаям,
Туктап-туктап сулыйм төн һавасын,
Алма исе килә дөньядан.

Бер якташым арттан житеп очрый,
Берсе чыгып очрый каршыдан.
Һәр очраган миңа туган кебек,
Бетмәс шатлыгыбыз бар сыман.

Киң урамнар шәп муенса итеп
Ефәк бауга тезгән утларын.
Тәрәзләрен, пәрдәләрен ачып
Миңа карый Казан йортлары.

Туктап-туктап сулыйм төн һавасын,
Бер сәбәпсез хәтта елмаям.
Күкрәгемә көч һәм бәхет тула,
Алма исе килә дөньядан.

1970

## Юл бирегез

Таулар,
Озын гомерле таулар —
Жирдә күп алар.
Ә таулардан аста елгалар —
Кайнап-кайнап агалар...
Сикереп-сикереп агалар...
Уралып-уралып агалар...
Арып агалар —
Ләкин агалар,
Һаман агалар елгалар.
Кемнәрнеңдер кайгы утын сүндерергә
Баралардыр алар —
Юл бирегез, зинһар, юл бирегез, таулар!

1970

Су буйлары бүген
Карап тора
    узып барган җәйгә,
Ләззәтле бер тынлык
Әкрен генә
    кырларыма җәелә.
Көз бармагы тиеп,
Күңелем кылы
    күкрәгемдә чыңлый,
Шуны тыңлый таллар,
Сандугачлар —
    тынып шуны тыңлый.

1970

## Ташлар

Утырдык Тукай янында...
Утырдык Кабан ярында...
Бу очрашу моңлы иде...
Тәүге иде... Соңгы иде...
Сизми калды төн үзе дә
Безнең уйны да, сүзне дә.
Танышлыкны без таш иттек,
Кабан-күлгә ташлап киттек.
Уйнады суда бөҗралар...
Ничә ел уйныйлар алар —
Миңа килеп кагылалар,
Болай диеп кагылалар:
«Кил син әйдә, кил Кабанга—
Су өстен сыйпап карарга.
Өметләнмә шуннан күпкә,
Син үрелмә, егет, төпкә!
Үрелеп нигә тармассың...
Аралап ала алмассың...
Бик күп анда серле ташлар —
Кемгәдер кадерле ташлар!»

1970

Хәй Вахит

# КҮК КАПУСЫ АЧЫЛСА

КОМЕДИЯ-ВОДЕВИЛЬ, ӨЧ ПӘРДӘДӘ[1]

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Якшәмбе. Өстәлнең ике кисәге дә, бер-берсеннән шактый ераклыкта, аерым өстәлләр итеп әмәлләнгән. Госман үз өстәлендә Гайфине сыйлап утыра. Өстәл өстендә аракы шешәләре, алма, апельсиннар.

Госманның кулында Арслановның чертежы. Ул аны җиргә җәеп сала да аракы шешәләре белән бастырып куя.

Госман. Ай-яй, зур эш бу синең.

Гайфи *(саклык белән генә)*. Госман Ганиевич, сез теге этнең хуҗасын белә алмадыгызмы?

Госман. Сораштым. Гайфи исемле кеше икән, автовокзалда шофер булып эшли, ди. Тфү, исемен телгә аласым да килми, дуңгызның. Эттән туган эт нәмәрсә! Күрсәтәм әле мин аңа. Судка бирәм! Болай калдырамны соң! Әй этен, ю-юк, аттырмыйм да, астырмыйм да. Терелэтэ тиресен тунатам мин аның. Сантиметрлап, миллиметрлап. Тәүлек буе җан бирсен. Ә хуҗасын, кабахәтне, койрыгыннан тоттырып торгызам.

Гайфи. Гайфи, Гайфи... Беләм мин ул кешене.

Госман. Танышыңмыни?

Гайфи. Ул минем личный шоферым булып эшләгән иде.

Госман. Шулаймыни. Әгәр дә якын танышың икән, ул чакта мин... синең хакыңа...

Гайфи. Танышымны яклап калырга теләүдән түгел, Госман Ганиевич, сезнең үзегез өчен борчылып әйтәм. Бер башкисәр ул. Дуслары, шайкасы бер көтү. Караңгы төндә очратулары бар. Ташлагыз сез аны, вакланмагыз.

Госман. Ю-юк, мине шүрләтә алмас. Бетәм икән үзем дә бетәм, аны да бетерәм. Инде мәгәр судка бирмәскә дибез икән, бары синең танышың булганга күрә генә коткарам мин аны. Синең хакыңа гына.

Гайфи. Рәхмәт, Госман Ганиевич.

Госман *(рюмка күтәреп)*. Килештек!

Гайфи. Килештек! *(Чәкештереп эчәләр.)*

---

[1] Ахыры. Башы 7 санда.

килеп терәлгән иде. Ай, экономия юлларының берәр әмәлен ничек табасы дип йөргәндә, синең тәкъдимең килеп керде. Ялваруларым күк капусы ачылган моментка туры килгән, диярсең.

Г а й ф и. Күк капусы?

Г о с м а н. Элек картлар әйтә торган иде, бәйрәм кичендә күк капусы ачыла, имеш. Шуның ачылганын күреп, теләгеңне әйтеп калсаң, шул кабул була, янәсе. *(Көлә.)* Менә миңа күк капусы ачылды. Теләгәнем кабул булды. Менә ул! *(Чертежны җәя.)* Кара бу могҗизаны, конвейер! *(Рюмка күтәреп.)*

Эх-ма, әйт шуны,
Күк капусы ачылды.
Күк капуслары ачылды,
Кайгыларым басылды.

*(Чәкештереп эчә.)*

Г о с м а н. Әт-әт-тә! Моны ходка җибәрсәк, цехлар графикны боза алмый шул инде. Үзең өстерәләсең икән, күршеңне дә өстерисең. Шулай булгач, өлгер! Әһә, аңлашыла, синең монда редуктор куелган. Табам мин аны, җиде кат җир астыннан булса да табам. Ә бусы нәрсә?..

Г а й ф и *(рюмкага коньяк салып)*. Күк капусы ачылды, Госман Ганиевич. Борчуларым басылды. *(Күтәреп эчеп җибәрә.)*

Г о с м а н. Бу ни соң?

Г а й ф и *(карарга мәҗбүр)*. Бумы? Ә бу... тимер юлы.

Г о с м а н. Нәрсә?!

Г а й ф и *(ялгыш әйткәнен аңлап, төзәтмәкче була)*. Соң инде... Шоссе.

Г о с м а н *(карап аптырап торгач, кисәк көлеп җибәрә)*. Ха-ха-ха... Шаяртасың икән. *(Гайфи дә, бераз икеләнеп торгач, көлә башлый, икесе дә җәелеп көлешәләр.)* Молодец. Искитмәле синең бу чертежың. Озак утырдыңмы?

Г а й ф и. Юк, бик тиз эшләнде бу.

Г о с м а н. Газапсыз гына туган икән.

Г а й ф и. Ниткән газап, ди, ул, рәхәтенә чумдым. Күк капусы ачылды, Госман Ганиевич!

Г о с м а н. Әйе, акыллы фикер көтмәгәндә килүчән була.

Г а й ф и. Бөтенләй көтмәгәндә, үзем аңламыйча да калдым. Уйламаганда. Кешегә сөйләсәң, кеше ышанмас.

Г о с м а н *(чертежны төреп)*. Байлык бу, уңыш, премия! Без моның белән комбинатны олы юлга чыгарачакбыз.

Г а й ф и *(исерә төшкән)*. Вперед!

Г о с м а н. Мондый чертежга селедка төрмисең шул инде. *(Газизләр ягына баш айкый.)* Юкса, бар бит бәндәләр. Белми ул чертежының селедка төрүдән башкага ярамаганын, ә борын чөя. *(Гайфинең җилкәсенә кул салып.)* Көч миңа. Техника бүлегенә. Бергәләп гөрләтеп эшләр идек.

Г а й ф и. Анда кеше юкмыни?

Г о с м а н. Бар да, мәгънәсе юк. Шуның өстенә, кеше уңышын күрә алмаучы. Менә синекенә дә ике аягын терәп каршы чыкты. Шул ярый торган эшме? Үзе күтәреп аласы урынга. Юк, мин андый кешене ул эштә калдыра алмыйм.

Г а й ф и. Уйларга кирәк булыр.

Г о с м а н. Менә рәхмәт. *(Чертежны кертә китә.)*

Баскычта Ш ә м с и я туктала. Яңа күлмәктән. Г а й ф и г ә күз төбәп тора. Гайфи аның каршында чечетка суга. Аннан җырлап та ала.

Гайфи.

Керфеклэренне тибрэтеп
Тик бер генэ күз аттын,
Йөрэгемдэ тынып калган
Давылларны кузгаттың.

Шэмсия. Арсланым, хискэ бирелеп китеп оныттың, ахры.

Гайфи. Онытмадым. Сиңа әйтәсем килгән сүзләрне һаман да әйтеп бетерә алмыйм.

Шэмсия. Я, хәзер нинди машина уйлап чыгарырга җыенасың?

Гайфи. Минме? Ә, әйе, мин. Ул шундый машина булачак, үзе шырпы тартмасына сыя, үзе кешенең яшерен серен сөйли дә бирә. Менә. *(Кесәсеннән шырпы тартмасы алып Шәмсиянең күкрәгенә куеп тора.)* О!..

Шэмсия. Нәрсә?

Гайфи. Тойгы белән бөтен йөрәгең тулган. Мөлдерәмә булган. Карап тотсаң өч кешегә җитәрлек. О! Ялкын! Урләп китеп бөтен тәнеңә ут кабына күрмәсен, сүндерик. *(Шәмсияне кочаклап үпмәкче була, Шәмсия, ирләр көче белән кочып алгач, көчкә ычкына.)*

Шэмсия. Болар берсе дә сер булмады. Тойгымны мин синнән яшермим.

Гайфи. Ашыкма, хәзер. *(Сызгыра-сызгыра, шырпы тартмасын Шәмсиянең маңгаена куеп тора.)* О!.. И-и-и...

Шэмсия. Нәрсә, ди?

Гайфи. Бу хатын зур акчалы ир артыннан куа икән, ди.

Шэмсия. Кит, җүнсез. *(Гайфине, иңеннән басып, җиргә тезләндерә дә, өстеннән атлап чыга.)*

Гайфи. Чү, чү... Син миңа кияүгә чыгарга ашкынасың икән лабаса.

Шэмсия. Булмады, ялганлады. Тагын кияүгә чыксам, эти мине өйгә дә кертмәс.

Гайфи. Ә без өйләнешкәнебезне берәүгә дә әйтмәбез.

Шэмсия. Бала булса?

Гайфи. Балага әйтербез, әлбәттә.

Шэмсия. Кит, булмаслыкны сөйләнмә! Синең кебек хатын аерып йөрүче белән чәчләреңне бәйләсәң...

Гайфи. Нишләргә иде соң миңа, бала тапмады ич.

Шэмсия. Минеке дә кысыр булып чыкты шул.

Гайфи. Күрдең, икебез дә бер үк бәхетсезлеккә дучар булганбыз. Димәк, безнең язмышларыбыз уртак. Я, ни дисең?

Шэмсия. Әгәр юк дисәм.

Гайфи. Менә аяк астыңда егылып үләчәкмен.

Шэмсия. Әйе дисәм.

Гайфи. Ул чакта шатлыктан үләм. *(Музыка башлана.)* Эх, Шәмсиям, тик сине сөям.

Бир кулыңны сандугачым,
Сөярлек булсаң гына,
Гомерлеккә үземнеке
Диярлек булсаң гына.

Пар күгәрченнәр шикелле
Гөрләшик кенә әле,
Дөньясының кадерен белеп
Серләшик кенә әле.

Шэмсия.

Бир кулыңны, арысланым,
Сүрелмәс булсаң гына.
Ал чәчәктән гөл чәчәккә
Үрелмәс булсаң гына.

Бергә.

Пар күгәрченнәр шикелле
Гөрләшик кенә әле,
Дөньясының кадерен белеп
Серләшик кенә әле.

*(Куплетлар биюгә күчә.)*

Гайфи. Киногa билет алып килэм.
Шәмсия. Йөгер, Арсланым.

Гайфи урамга чыгып китә. Шәмсия өенә керә. Музыка яңгырый. Бераздан әкеле-кәкелешә, Шакир, Газиз, Ризван ишек алдына чыга. Ризван юнырга әзерләнә. Аның күңеле күтәрелеп киткән, монда ишеткән хәбәр ана кызык булып тоела.

Шакир *(сөйли-сөйли чыга)*. Югыйсә, Газизгә ышанмыйлар. Исәпкә дә алмыйлар. Менә шуна күрә ул бу хезмәтен икенче фамилия белән — Арсланов исеменнән биргән.

Ризван. Минем исемнән? Ха-ха-ха. Кызык бу, кызык.

Газиз. Хезмәтне болай ошаттылар, әмма әлегә кабул ителмәгән. Андый-мондый эш фамилиягә терәлеп калса...

Шакир. Арслановның үзен көтик, үзен күрик дип киреләнсәләр?

Газиз. Менә шул чакта синең кирәк булуың бар.

Шакир. Төрле хәл булуы ихтимал. Әзер булып торганың яхшы. Саклангaнны алла саклаган.

Ризван. Алайса, миңа синең ул хезмәтең белән танышып чыгарга кирәк булыр. Сораша башласалар, төртелеп калмаска.

Газиз. Әлбәттә. Миндә копиясе калды.

Ризван. Ә шулай да ни өчен син именно минем фамилияне сайладың?

Газиз. Ни әйтсәң дә, син туганрак тиешле. Аннан үзең дә чертежлар белән маташкалыйсың.

Ризван. Анысы дөрес. Мин үзем дә новатор. Тик юл гына бирмиләр. Әле менә тозак-йозак уйлап чыгардым. Әти мәрхүм бүреләргә капкын куя иде. Хәзер бүре зоопаркта гына калды. Шуңа мин капкынны кешеләргә көйләдем. Кодагый, кодагый дим! Кая, алып бир әле минем капчыкны.

Әсма Ризванның юл капчыгын алып чыга. Анда әллә ниткән механизмнар белән эшләнгән капкын.

*(Ризван аны саклык белән генә җиргә куя.)* Менә, тозак-йозак дип атала. *(Шакир белән Газиз капкын янына бара башлагач.)* Әйт, сак булыгыз, каптырып алмасын!.. Менә колхоз амбарларына каравылчы урынына шуны гына куясың. Карак килсә, аягы белән басуга — шалт! Пружинасы ычкынып та китә, аякны богаулап та ала. Йозагы бикләнеп тә өлгерә. Бер элэктенме инде, ычкынырмын димә. Ачкыч белән генә ачарга мөмкин. Ә ачкычы аның председатель кулында булыр. Безнең тегендә — сельхозтехникада аны ходка җибәреп булмый. Сездә эш башка. Производство! Җайлыйсы кешесен җайласаң, майлыйсын майласаң, дигәндәй, меңәрләп ясап чыгарырга була. Синең начальства тирәсендә сүзең үтәдер. Ярдәм итәргә теләсәң...

Газиз. Куй әле, кода, кеше көлдермә.

Ризван. Теләмисеңмени? Аңлашылды.

Шакир. Юк әле, юк, кода, аңлашылмады. Шаярта ул. *(Газизгә.)* Дәшми кала алмыйсың мәллә?!

Ризван. Менә шул: сез миңа ярдәм итәсез, мин сезгә. Бәйрәм ашы — кара-каршы.

Шакир. Шулай булмыйча!

Р и з в а н. Алып куегыз.

Ш а к и р *(капкынны читеннән генә тотып күтәрә дә шунда ук хатынына кычкыра)*. Әнкәсе, тиз бул, тот!

Әсма капкынны капчык белән каплап тота да алып кереп китә.

Р и з в а н. Арслановны кем дип беләләр соң алар?

Ш а к и р. Зур дәрәҗәле кешегә исәплиләр, күрәсен.

Р и з в а н. Ә нигә, Арсланов кечкенәләрдән түгел. Суммасы зур булачакмы инде аның?

Г а з и з. Кызыксынмадым.

Ш а к и р. Аз булмас дип уйлыйбыз.

Р и з в а н. Минемчә дә, шактый булырга тиеш. *(Әсма чыга.)*

Г а з и з. Без сине, кода, кирәген чыкса гына борчырбыз. Әлегә ял ит. Кунак бул.

Ш а к и р. Хәзергә тыгылып йөрергә кирәкмәс. Эшне бозып ташлавың бар. Күршеләр алдында да тугарылып китәргә ярамый.

Р и з в а н. Күршеләрегез белән тату тормыйсызмыни? Хәер, күрше белән кем тату яши.

Ш а к и р. Алар белән бик катнашып китмәвең хәерлерәк булыр. Сорасалар, без сине авырып тора диярбез.

Р и з в а н *(аңа барысы да кызык)*. Ничек, минем сездә авырып ятуыммыни?

Ш а к и р. Әйе, син хәзергә авырыйсың. *(Көлә.)*

Р и з в а н. Булдырабыз аны, авырыйбыз. Бик рәхәтләнеп, җиренә житкереп авырыйбыз. Тик сез авыру артыннан яхшырак карагыз инде. Авыру кеше ризыкны да талымлаучан була, башкасын да дигәндәй. Минем авыруга күбрәк коньяк килешә.

Ш а к и р. Әткән мәрхүм...

Р и з в а н. Монда эткәйнең катнашы юк, кода. Сүзегезне тыңлап кына килдем. Югыйсә, сабан туена әзерләнеп ята идем.

Ә с м а. Әчәч, сабан туена да әзерләнеп торалар димени? Чыгасың да карыйсың.

Р и з в а н. Чыгарлыгың булса, көрәшергә аңа, ай-һай, көч кирәк. Ел саен бер ай алдан әзерләнә башлыйм. Өч көнгә бер сарык.

Ә с м а. Алайса, килмәскә кирәк булган икән шул.

Р и з в а н. Килдем инде, зарланмыйм. Аны бит монда да әзерләнеп була.

Ә с м а. Өч көнгә бер сарык дисең түгелме соң?

Р и з в а н. Сарыгы булмаса, тавыклары булыр.

Ә с м а. Өч көнгә берме?

Р и з в а н. Ә юк, тавыгы бер көнгә өчәү. *(Юынып бетерде. Өйгә атлый.)*

Ш а к и р *(кереп барышлый Әсмага)*. Син, битараф икәнсең, битараф бул, телеңә хуҗа була бел.

Өйгә кереп китәләр. Ишек алдында савыт-саба белән маташып Әсма үзе генә кала. Өйләреннән Ш ә м с и я чыга. Күлмәген алмаштырган, киногa барырга әзерләнгән. Күңеле күтәренке. Як-ягына карана, урамга күз төшереп ала.

Ш ә м с и я. Әсма апа, теге күренмәдеме?

Ә с м а. Кемне әйтәсең?

Ш ә м с и я. Арслановны. Килеп житәргә тиеш иде. Озакланды.

Ә с м а *(текәлеп кала)*. Ни арада әле аның белән танышып та өлгердең?

Ш ә м с и я. Һәй, аңа күп кирәкмени?

Ә с м а *(ачылып китмичә генә)*. Бездә.

Ш ә м с и я. Кара, нишләп утыра анда? Әсма апа, әллә ул сезгә туган тиешлеме?

Әсма. Туган. Чыбык очының очының очы. Син аны бик борчып йөр-э инде, Шәмсия, авырып тора.

Шәмсия *(борчылып)*. Әле генә сау-сәламәт иде. Ни булган?

Әсма. Эченең кәефе киткән.

Шәмсия. Һай аллам икән. Кинога барабыз дип кенә торганда.

Әсма. Коньяк сорап ята. Оятны белә торган бәндә түгел, ахры.

Шәмсия. Коньякның шифасы тия иде шул. Тукта әле, этинең кал-ды икән? *(Өенә кереп китә. Әсма да үз алдына мыгырдана-мыгыр-зна өенә атлый.)*

Әсма. Җиләккә йөрермен дип кенә тора идем, каян килеп чыкты.

ршына Ризван очрый. Әсма кереп китә. Ризван да аның артыннан кермәкче е, күрше йорттан килеп чыккан яшь хатынны күреп туктала. Шәмсиянең кулын-да ярты шешә коньяк. Ул туры террасага атлый.

Шәмсия *(узып барышлый)*. Исәнмесез.

Ризван. Белсәң иде, кая болай ашыгалар икән.

Шәмсия. Авыру янына.

Ризван. Әйтүләренә караганда, бу өйдә авыру кеше мин бугай.

Шәмсия. Юк, миңа Ризван кирәк.

Ризван. Ризван?

Шәмсия. Әйе, Ризван Арсланов.

Ризван. Бу коньяк аңамы?

Шәмсия. Аңа иде шул. Эче китә.

Ризван. Әсма апа әйткән инде алайса. Кая әле. Әйе, моның шифасы ими калмас. *(Коньякны стаканга сала башлый.)*

Шәмсия. Гафу итегез... *(Шәмсия артык бер сүз дә әйтә алмый, аҗәпләнеп Ризванга карап тора. Ә Ризван ашыкмыйча гына коньякны үтәреп эчә дә бик ошатып авызын сыпырып куя.)*

Ризван. Әйбәт нәрсә. Аяк бармакларыма хәтле тәгәрәде. *(Тагын чәсе килеп.)* Ә үзе өч кенә йолдызлы.

Шәмсия. Нишләп өч кенә булсын, биш йолдызлы.

Ризван. Кая, кая?

Шәмсия. Менә, бер... ике... өч... дүрт... биш...

Ризван йолдызлар санашкан булып, шешәнең башын аска — стаканга табан авыштыра.

Ризван *(коньяк шешәдән стаканга агып беткәч)*. Биш икән шул. *(Стаканны күтәреп, эчеп җибәрә.)*

Шәмсия. Бу ни эшегез булды инде?!

Ризван. Ә нигә? Үзегез, Арслановка алып килдем, дисез ич.

Шәмсия. Арслановка шул, сезгә түгел.

Ризван. Арсланов абыең мәнә мин булам да инде.

Шәмсия. Ә? Сез?

Ризван. Мин.

Шәмсия. Арсланов?

Ризван. Арсланов.

Шәмсия. Ризван?

Ризван. Ризван.

Шәмсия. 25 яшьтә? Новатор?

Ризван. Егерме биштә. Новатор.

Шәмсия. Арсланов...

Ризван. Ышанмасаң менә паспортым.

Шәмсия. Ой... тотыгыз мине, егылам. *(Чайкала башлый.)*

Ризван. Сезгә ни булды? Чү! *(Шәмсияне ике җилкәсенә күтәреп ала да кая куярга белмичә ишек алды буйлап йөри. Аннан өстәлгә ки-тереп утырта. Эшләпәсе белән җилләтергә тотына.)*

Шәмсия *(айнып)*. Башым әйләнеп китте. *(Күзен ачып.)* Зинһар, дөресен әйтегез, бу сезме?

Ризван. Баскан урынымда җир упсын менә, әгәр дә мин мин булмасам.

Шәмсия. Сез шулай зур кешеме?

Ризван. О, сез минем турыда ишетерсез әле!

Әсма чыга.

Әсма. Кода, керәсеңме?

Ризван. Жаркой кетәме? Нәрсә итеннән?

Әсма. Чеби итеннән.

Ризван. Яшь чебидәнме?

Әсма *(ошатмыйча).* Урта яшьтәгеләрдән.

Әсма белән Ризван өйгә кереп китәләр. Шаян музыка яңгырап ала.

Шәмсия *(сөенеп).* Ул! Үзе! *(Икеләнеп.)* Әллә түгелме? *(Кычкыра.)* Рәмзия, Рәмзия!

*(Рәмзия килә.)*

Шәмсия. Сеңелкәем, эш харап, тагын бер Арсланов килеп чыкты.

Рәмзия. Тагын?

Шәмсия. Әнә, болдырда.

Рәмзия. Ә кайсы чын Арслан?

Шәмсия. Һай, белә алсам. Үзем дә шул турыда баш ватам шул. Кайсы новатор? Икесе дә күзләрен чекерәйтеп «мин» дип торалар. Тегесенә ышанып беткән идем инде, монысы да ышандыра. Паспортын күрсәтә. Бар, бел кайсысы чын аларның. Нишләргә инде? Берсен сайлар идең, ә новаторы икенчесе булып чыкса? Юк, мондый чакта осечка бирергә ярамый. Үзең утырган ботакны үзеңнең үк кисеп ташлавың бар. Нишлим, бер Арсланны тәмам кулга ияләндереп бетергән идем инде, эш пешә дип кенә йөргәндә монысы пәйда булды.

Рәмзия. Әй, апа, бер дә килешкән эш түгел бу. Мәхәббәт шулай буламыни. Төкер икесенә дә.

Шәмсия. Синең яшеңдә төкерергә дә була. Минем яшькә җиткәч, бик төкеренмәссең. Син менә апаңа киңәш бир: менә хәзер бер Арслан капкадан килеп керер дә кочагын җәеп торыр, икенчесе әнә террасада елмаеп, тешләрен ыржайтып торыр. Кайсына барып башымны тыгыйм?

Рәмзия. Әй!.. *(Өйгә кереп китмәкче була.)*

Шәмсия. Тукта! Беренче Арслан белән киногa минем урынга син барасың. Ә мин монда икенчесен дрессировать итәргә керешәм.

Рәмзия. Юк, юк, миңа ышанма, минем вакытым юк.

Шәмсия. Апаң әйткәч, табарсың. Икесен дә кулдан ычкындырырга ярамый. Кара аны, аң бул, башкаларга күз төшермәсен, үз яныңнан беркая да җибәрмә.

Рәмзия. Апа дим... мин Газиз белән барырга сүз бирдем.

Шәмсия *(ике сөйләргә калдырмыйча).* Әйткәнне үтә. Әгәр дә анысы чын Арсланов булып чыкса, ахырдан мин аны үземә алырмын. Килә, җибәреп торма.

Өйгә кереп китә. Капкада Гайфи күренә. Шул вакытта террасага Әсма чы... Моңарчы да савыт-саба тирәсеннән бушамаган йорт хозяйкасына кунак килгәч бигрәк тә күбәеп киткән, күрәсең. Гайфи Әсма янына бара.

Гайфи *(шоколад суза).* Апа, җәберсенмичә генә ал әле. Сер саклый беләсең икән.

Әсма. Шәмсия өченме? Бөтенләй урлап ук китсәң дә бер сүзем юк. Рәхмәт кенә әйтермен. *(Шоколадны алмыйча.)* Кирәкмәс иде.

Гайфи. Ал инде, ал. *(Шоколадны тумбочка өстенә куя.)* Наморд... никны чыгарып бир әле. *(Үзе Рәмзия янына килә.)*

Рәмзия. Апа әйтергә кушты, киногa бара алмый. Көтелмәгән ма... шакать пәйда булды.

Гайфи. Шулаймы... Калдич, калдич Казан сөлгесе, апасыннан чи-
р сеңелесе. *(Кулын сузып.)* Арсланов! Әгәр дә апасы урынына сеңе-
сен чакырсам, ни дияр икән.

Рәмзия. Ә сез башта чакырып карагыз, иптәш Арсланов.

Гайфи *(тезләнеп)*. Үтенеп сорыйм.

Рәмзия. Җиңдегез. Әмма киного теләгем юк. Күл буйларын, бакча-
арны әйләнеп кайтыйк, дисәгез генә инде.

Гайфи. Бигрәк тә шәп булыр.

Рәмзия. Апа!..

Гайфи. Апаң кирәкми. Әйдә киттек.

сма намордник алып килә. Гайфи аны кулы белән генә ишарәләп калдыра да Рәмзияне алып чыгып китә.

Әсма *(кычкыра)*. Газиз, Газиз!

Газиз өйдән чыга.

әмзияне алып китте бит, әнә!

Газиз карый, әмма бер ни күрми. Подзорный труба дип белеп, энисе кулындагы убасын ала да Рәмзияләр киткән якка карый башлый, ләкин ул самовар трубасы лып чыга. Газиз аны җиргә ташлый да чыгып китә. Шаян музыка. Террасада изван күренә. Тумбочка өстендәге шоколадка күзе төшә. Алып ашый ук башлый.

Ризван. Кодагый, кечкенә якка нәрсә әзерләрсең икән?

Әсма *(шаяртып)*. Әчәч, ятыр вакыт җитә түгелме соң инде.

Ризван. Миңа көненә алты мәртәбә эбәд итәргә кирәк.

Әсма. Шул сабан туе өчен тырышасыңмы? Бигрәк җәфалы нәрсә кән.

Ризван. Мөмкин кадәр тырышырга туры килә. Булдыра алган адәр.

Әсма. Сыйган кадәр?

Ризван. Шунсыз ярамый. Мәйданга чыккач сынатасы килми. Ту-
ысын әйтим, кодагый, мин оят саклап тора алмыйм.

Әсма. Ә мин тагын ятыр корсак ятыр дип юанып йөрим. Ярар,
имәнке мае салып бирермен. Ипи манып ашарсың.

Ризван. Синең шулпалы бәлешең тәмле була торган иде. Мин авы-
у кеше, симәнке маеннан йөрәгем кыза.

Әсма. Шоколадтан кызмыймы соң?

Ризван *(аңлап алып)*. Кара, үзем дә сизмәстән алып ашый баш-
аганмын. Кечке якта шулпалы бәлешкә өлгерә алмассың, тутырган та-
кка да вакыт күп кирәк. Бардыр әле шунда, балыкмы, каймакмы,
учка итеме.

Әсма. Чучка? Йортка кергән нәрсә түгел, дуңгыз.

Ризван. Бифштекс, рулет, антрекот...

Әсма. Ишетмәсәң ишет. Син, көйсез кияү, бик талымлама инде.

Ризван. Мин авыру кеше. Ә бәлки мин авыру түгелдер, ә? Алай
сән, әйтегез, мин кайтам да китәм. *(Кычкыра башлый.)* Китәм...

Әсма. Юк, юк. Авырыйсың, авырыйсың. Ярар инде, нишләмәк ки-
. Кунак килсә таптырыр, актык кәҗәнне саттырыр, диганнәр. Чуч-
асы да булыр, алла бирсә, башкасы да. Кичкә пилмән бөгеп бирермен.
абан туе елга бер килә ләбаса.

әмсия күренә. Эченнән генә җыр суза. Ниндидер эш белән шөгыльләнгән була, ә үзенең күңеле Ризванда.

Әсма *(тәрәзәгә кычкыра)*. Сиңа әйтәм, Шакир, плитәдә шулпам
лды. Мин биш минутка гына күршеләргә кереп чыгам. Кайнап бет-
әсен, берәр сәгатьтән алып куярсың. *(Капкадан чыгып китә.)*

Р и з в а н.

Кай жирдә тудың син,
Кай илдә үстең син.
Нинди саф чишмәнең
Суларын эчтең син.
Буйларың — тал зифа,
Карашың сер генә.
Карачы үземә
Елмаеп бер генә...

Нишләп йөри икән бу бәндәләр, үрдәк шикелле йөзеп кенә?

Ш ә м с и я. Божра эзлим. Йортка Арслан килеп кергән, шуны божра аша сикерергә өйрәтмәкче булам.

Р и з в а н. Сикерер дисезме?

Ш ә м с и я. Сикерер, алла боерса. Әмәлен беләм. Ал-ло, хоп!..

Куллары белән Р и з в а н муенына чылбыр ыргыткан шикелле хәрәкәт ясый. Әйтерсең чылбыр муеныннан эләктереп алды. Р и з в а н тартылып куя. Ул да булмый, Ш ә м с и я Ризванны «чылбыр» буйлап үзенә тарта башлый, ә Р и з в а н буйсына, Ш ә м с и я-гә якыная. Килеп житкәч, кочаклап үк ала.

Р и з в а н. Сезнең шикелле чибәрләр сораса сикерерсең дә шул. Аннан соң?

Ш ә м с и я. Өйрәтеп бетергәч, циркка алып барып уйната башлыйм.

Р и з в а н. Ялыннан сыпырырсыз, борыныннан үбәрсезме?

Ш ә м с и я. Өстенә атланып йөрермен.

Р и з в а н. Аннан соң?

Ш ә м с и я. Аннан соң күз күрер.

Р и з в а н. Әгәр дә ул сезгә ияләнеп китеп, артыгыздан тагылып йөри башласа, эт кебек?

Ш ә м с и я. Ә чылбыр нәрсәгә?!

Р и з в а н. Чылбыр? *(Музыка.)*

Дуэт.

Р и з в а н.

Китер әйдә чылбырыңны,
Менә муеным!
Зинһар, уйныйк инде тизрәк
Гыйшык уенын.
Кайда, бармы утлы божраң,
Әйдә сикерәм.
Синең өчен янып торган
Утларга керәм.
Ах, минем гүзәлем,
Өзеләдер үзәгем.
Син янымда чакта дөньям ямьле,
Синсез ничек түзәрмен?

Ш ә м с и я.

Гомергә якын сердәшем,
Юлдашым булсаң,
Сүзләремнән чыкмый торган
Юашым булсаң,
Йөрер булсаң артларымнан
Калмыйча гына,
Күзләремнән күзләреңне
Алмыйча гына.

Р и з в а н.

Ни теләсәң шуңа риза,
Зинһар, куш кына.
Синең өчен жаным фида,
Булыйк дус кына.

Ш ә м с и я.

Бигрәк сабырсыз күңелең,
Йөрәгең ярсу.

Ризван.

Белсәң иде синнән башка
Ничек ямансу.

Бергә.

Ах, минем гүзәлем,
Өзеләдер үзәгем.
Син янымда чакта дөньям ямьле,
Синсез ничек түзәрмен?..

…плетлар танец-биюгә күчә, Ризван белән Шәмсия азартка бирелә баралар. Террасага Шакир чыга. Ул Ризванның Шәмсия белән очрашуыннан риза түгел.

Шакир. Кода, бу ни эшең? Сиңа ярамый. Авыру кешегә.
Ризван. Дәвасын таптым мин.
Шакир. Язмаганны. Бар-бар, кереп ят. *(Ризванны өйгә этәрә.)*
Ризван. Кода дим, тукта әле, кода...
Шакир. Ярамый, ярамый. *(Көчләп диярлек кертеп җибәрә.)*

Шәмсия дә бер карарга килеп, Арсланов артыннан кереп китмәкче була.

Шакир. Шәмсия! Булышмассыңмы, каптырмамны каптыра алыйм.
Шәмсия. Кая. Муеныңны боргалама.
Шакир *(шаярта)*. Сиңа гына, тик сиңа карап торам.
Каптырмамны каптырамсың?
Шәмсия *(ул да шаярта)*. Каптырам, каптырам.
Шакир. Сиңа гына, тик сиңа карап торам.
Каптырмамны каптырамсың?
Шәмсия. Каптырам, каптырам.
Шакир. Сиңа гына, тик сиңа карап торам.

…анец-биюгә күчәләр. Арт капкадан килеп кергән Әсма бу хәлче күреп туктапып ала, кулына әйбер ала. Ә Шакир белән Шәмсия аны күрмиләр, биешүне дәвам итәләр.

— Каптырманы каптырамсың?
— Каптырам, каптырам.
— Сиңа гына, тик сиңа
Карап торам.
Шакир *(Әсманы күреп алып)*. Ай, шулпам ташый торгандыр. *(Өйгә йөгерә.)*
Әсма. Каптырырмын мин!

…ның артыннан атлый. Бакчада Гайфи белән Рәмзиянең көлешкән тавышлары …ишетелә. Шәмсия Гайфигә күренмәс өчен тиз генә өенә кереп китә. Музыка тукталмый. Гайфи белән Рәмзия бакчадан чыгалар.

Гайфи *(җырлап-биеп килә)*.

Керфекләреңне тибрәтеп
Тик бер генә күз аттың,
Йөрәгемдә тынып калган
Давылларны кузгаттың.

Рәмзия. Иптәш Арсланов, синең сәхнәдә уйнаганың бармы әллә? *(Гайфи аптырап кала.)* Бик килештерәсең.
Гайфи. Син миһербансыз, Рәмзия. Ә мин ихлас күңелемнән.
Рәмзия. Кыю. Үз-үзенә бик ышанган кеше генә шулай кыю була ала.

Г а й ф и. Ә мин ышанам. Кеше ышанмаслыкка ышанам. Әйтсеннәр, дөньядагы барлык кызлар да сиңа үлеп гашыйк булган дисеннәр, ышаныр идем. Әйтсеннәр, ни теләсәң шуны кылан, сиңа килешә дисеннәр, ышаныр идем. Чөнки миңа күк капусы ачылды. Картлар әйтә иде: имеш, күк капусы ачылса, теләгеңне әйтеп калсаң, шуңа ирешәсең дип. Мин моңа элек әкият дип кенә, көлеп кенә карый идем. Ә кичәгедән бирле ышана башладым. Кичә миңа күк капусы ачылды. Ни теләсәм шул кабул була. Менә шуның өчен бүген мин тартынмыйча, курыкмыйча сине телим. Һәм ышанам, бу тормышка ашачак. Башкача булуы мөмкин дә түгел. Әйтәм ич, миңа күк капусы ачылды. *(Тезләнеп, Рәмзиянең кулын үбә.)*

Р ә м з и я *(шаяртып)*. Туктагыз әле, сезнең капкачыгыз ачылганга минем ни гаебем бар.?

Г о с м а н *(өеннән кычкыра)*. Иптәш Арсланов!

Г а й ф и. Мин хәзер.

Кереп китә. Р ә м з и я Г а з и з н е күреп ала.

Р ә м з и я. Газиз, син дә киногa бармадыңмыни?

Газиз дәшми, радиола төзәтә.

Барырга иде, кызыклы картина диләр. Билет та алган булгач.

Газиз дәшми.

Минем аркадамы?

Газиз дәшми.

Вакытым булмады бит.

Газиз дәшми, Рәмзия китә алмый.

Үпкәләгән кешеләр.

Г а з и з. Каян алдың? Ни хакым бар?!

Р ә м з и я. Ачуланма инде, гафу ит. Мин гаепле.

Г а з и з. Синең бер гаебең дә юк.

Р ә м з и я. Барырбыз дип ышандырдым да сүземдә тормадым. Мин тиеш идем.

Г а з и з. Юк, тиеш түгел идең. Теләмәгән кешең белән бармассың бит?! Киресенчә, мин үзем гаепле. Чакырмаска тиеш идем, аңларга тиеш идем. Ялгышканмын. Моннан соң булмас, беренчесе-соңгысы. Андый ялгышлыкны кабатламам!

Р ә м з и я *(югалып кала)*. Ә син, курыкма... Аның ояты юк. Тагын ялгышсаң да була, мин ачуланмыйм.

Г а з и з. Бер вакытта да! Ялгышып кына да ялгышмам!

Р ә м з и я. Аңлашылды. Киногa да ялгышып кына дәшкәнсең икән. Алай булгач, ялгышмаска кирәк булган шул.

Г а з и з *(чәнчеп)*. Унсигез ел буе күргәнмен.

Р ә м з и я. Унсигез ел белми йөргәнмен.

Б е р г ә. Карашларың өзеп ала икән,
Йөрәкләрдә эзе кала икән.

Г а з и з. Унсигез ел буе күргәнмен,

Б е р г ә. Унсигез ел белми йөргәнмен...

Г о с м а н белән Г а й ф и ишек алдына саф һавага чыга. Г о с м а н н ы ң кулында бер шешә коньяк. Р ә м з и я закускага алма, рюмкалар чыгара.

Г о с м а н. Эх, киявем итәр идем мин сине. Берсеннән-берсе чибәр ике кызым бар, әйдә, теләгәнеңне сайлап ал.

Г а й ф и. Сеңелесен.

...ләп, тәҗрибәсе бар. Әйдә, ике куллап бирәм.

Гайфи. Рәмзияне.

Госман. Чү, аның үзенең ризалыгы кирәк. Рәмзия! Кызым, я, ни disең?

Рәмзия (*Газизгә ишеттереп*). Әти ихтыярына карышмам инде.

Госман. Тукта, кызым, ашыкма. Мин сине көчләмим.

Рәмзия. Арслановка чыгарга кем теләмәс?!

Госман. Риза алайса. Шайтан икәнсез, ни арада бер-берегезне табышып та өлгердегез әле?

Шул чакта Газиз радиоланы, колак яфрагын ярырлык тавыш чыгартып, эшләтә башлый. Госман дәрестән дә ике кулы белән колакларын каплый, тузына.

Госман. Ни эшең бу, ташла!

Гайфи. Туктат!

Госман ярсынып өенә кереп китә. Менә без аны тәрәзәдән күрәбез: телефоннан номер жыя. Бераздан террасада телефон шалтырый. Әсма килеп трубканы ала.

Әсма. Әллү...

Госман трубкага нәрсәдер акыра, әмма аның сүзләрен аерып булмый. Радиоланың тавышы күмә.

Әсма (*трубкага кычкыра*). Ә? Кем бу?

Трубканы Шакирга бирә. Шакир кулы белән ымлап Газизгә радиоланы сүндерергә куша.

Әсма. Берни аңлап булмый. Бик ерактан.

Шакир (*трубкага*). Алло! Тыңлыйм сезне.

Госман (*трубкага*). Бандитлык! Ишек алдында тынычлап кына сөйләшеп утырып та булмый.

Шакир. Ә бу синмени әле, күрше? Жалобаң булса, хатка язып почтага сал! (*Трубканы куя.*)

Әсма. Якыннан гына икән. Жирле, аны аңлап булмый.

Шакир (*Гайфине күрсәтеп*). Бусы нинди бәндә моның? Гел болар тирәсендә сырпалана?

Әсма. Ул үзенең этен коткарырга йөри.

Шакир. Ә-ә-ә... Әле эте исән калганга гына риза түгел, Рәмзияне дәгъвалыймыни? Кара син аны, йомры баш.

Госман чыга, Шакирлар ягына карамыйча гына өстәл янына килеп утыра.

Госман. Нервага тияләр, понимаешь.

Әсма. Кая барасың инде, килешмәгәнне.

Шакир Госманнар янына килә.

Шакир. Телефонга ябышкач, әллә өстәлгә чакырамы дип торам.

Госман. Әйдә, рәхим ит. Мин алай тар күңелле түгел.

Гайфи. Исәнме, бабай. (*Кул бирә.*)

Шакир (*кулын кысып*). Исәнмесез. Кайдадыр күргән кебек булам.

Гайфи. Юктыр. Мин сезне белмим, сез мине белмисез. (*Кулын тартып ала.*)

Шакир. Кайда очраткан идем соң? Исемегез ничек әле?

Госман. Арсланов. Ризван.

Шакир. Арсланов? Юк, ул чакта сезнең исемегез башка иде. Кем иде соң әле. (*Гайфи маңгаеннан тирен сөртеп куя.*)

Госман. Син нәрсәдер бутыйсың, күрше.

Шакир. Юк, бутамыйм. (*Хәтерләгән булып.*) Точно. Теге урамда органда бер егет бар иде, сиңа бик охшаган иде. Койган да куйган.

*тынып кала, ә Госман кабынып китә.)*

Г о с м а н *(сикереп үк тора)*. Бу ниткән эшең инде, Шакир ага, балага саныйсыңмы — бертуктаусыз үртәргә?! Күрше хакы дип тормам мин, в конце-концов!

Ш а к и р. Как хошь. Әйттем исә кайттым.

Г о с м а н. Маташма, кәефемне боза алмассың. Бүген миндә бәйрәм!

Г а й ф и *(аракы салып бирә)*. Бабай, әйдә, давай.

Ш а к и р. Давай. *(Эчә.)*

Г а й ф и *(тагын салып бирә)*. Давай, бабай.

Ш а к и р. Юк, ни давай... күрше, бүген дә балыкка барырга уйламыйсыңмы? *(Госман арты белән борылып утыра.)* Ә, әйе, анда овчарка бар бит әле. Төн буе эт белән этләшеп ятмассың инде. Эткә нәрсә турында сөйлисең, ни әйтсәң дә аңламый бит ул.

Г о с м а н *(кабынып китә)*. Әйе, аңламый. Ялындым, ялвардым, тынламады. Көл әйдә, көл, сөен. Төн буе суда тотты.

Ш а к и р. Колактан?

Г о с м а н. Колактан.

Ш а к и р *(һаман да сабыр гына, берни булмагандай)*. Балык тотып булмаган икән алайса?

Г о с м а н. Булмады. Шатлан.

Ш а к и р. Булмагандыр шул. Селкенергә дә ирек бирмәде, дисең бит. Хәер, су астында кул белән генә тотсаң инде.

Г о с м а н *(дәшми калырга исәпләгән иде, түзә алмады)*. Тоттым. Чалбар кесәсенә үзләре килеп керделәр. Я, күңелең булдымы инде?!

Ш а к и р. Шулайдыр, андый чакта балык кайгысы буламы...

Г о с м а н *(сикереп тора, бугазы ярылганчы кычкыра)*. Житте! Мальчишка таптыңмы?! Сакалыңнан оялыр идең, әдәпсез пенсионер! *(Кереп китә.)*

Г а й ф и *(куа)*. Давай, бабай! Давай!

Ш а к и р *(кузгала)*. Ах, син, шельма. Һав-һав!

Ш а к и р китә. Г а й ф и н е Ш ә м с и я туктата.

Ш ә м с и я. Кем син?

Г а й ф и. Әтиеңнең булачак кияве.

Ш ә м с и я. Апасыннан сеңелесе яшьрәк, дисең икән.

Г а й ф и. Калдич, калдич Казан путасы, ташлап китте мине тутасы. Син үзең миңа хыянәт иттең, туганым апа, үзеңә үпкәлә. *(Госман артыннан кереп китә.)*

Ш ә м с и я. Оттырам, ахры, ялгыштым, ахры... *(Рәмзияне туктата.)* Ә!.. Мин сиңа аны кинога бару өчен генә биреп тордым, ә син...

Р ә м з и я. Ике көймәнең койрыгын тотмыйлар аны.

Ш ә м с и я. Хәйлә дә үзеңдә. Арсланов икәнен белеп алган да... ул үземе? Чыннан да ул чын Арслановмы? Каян белдең, кемнән, ничек?.. Яшерәсең? Апаңның алдына төшәсең.

Р ә м з и я. Ә бәлки мин аны яратамдыр.

Ш ә м с и я. Акчасын.

Р ә м з и я *(Газизгә ишеттереп)*. Шундый талантлы кешене кем яратмас икән?!

Өйгә кереп китә. Ш ә м с и я аһ-ваһ килеп кала. Әле Ш а к и р г а, әле Г а з и з г ә бармакчы була, аннан Р ә м з и я артыннан атлый.

Г а з и з. Арсланов... У-у-у! Мин аны тудырдым, хәзер ул минем үз башымны ашый. Күз тоткан кызымны ала. Мин уйлап чыгармасам, ул кем иде? Буш куык. Куләгә. Атып та, дуэльгә чакырып та булмый бит аны. Кем ышаныр, язучы китап язганда бер бандит образын уйлап чы-

имеш?! У-у-у, Арсланов. Түзәрлегем калмады, керәм дә әйтәм.

Шакир. Кемгә?

Газиз. Госманга.

Шакир. Син аның Арсланов түгел икәнен каян беләсең?

Газиз. Ничек белмим, үзем була торып.

Шакир. Ах, син шуны Госманга әйтмәкче буласыңмыни? Арсланов мин дип күкрәк киермәкче? Бар-бар, ә Госман синең чертежыңа селедка төреп кайтыр. Онытма, әле эшең кабул ителмәгән.

Газиз. Нишлим?

Шакир. Ышандыра алуың да икеле. Әнә мин әйтеп карадым ич, ышандымы? Ул аны Арсланов дип тәкатьсез калган. Үзең, син Госман түгел, башка кеше дип тизрәк ышандырырсың. Ә Арслановтан шикләндерә дә алмассың.

Өйдән Ризван килеп чыга. Ниндидер уй белән иләсләнгән. Кулында Газизнең чертежы.

Ризван. Бик зур эш икән ич бу. Ай-яй-яй, хөкүмәткә күпме файда китерәчәк. Стоящий бу.

Газиз. Шул башыма житте. Рәтсез булса, Арслановны күтәрмәсләр дә иде.

Ризван. Сузарга ярамый. Барырга кирәк. Хезмәте өчен түләргә тиешләр. Суммасын да, премиясен дә...

Шакир. Ашыкма, ашка пешәрсең.

Ризван. Бөтенесен үк үземә алмам, курыкмагыз. Мин комсыз түгел, сезгә дә өлеш чыгарырмын. Әйдә, яхшылык миннән булсын, унбиш... ярар, егерме биш проценты сезгә.

Шакир. Ничек?!

Ризван. Югыйсә, нәрсә дип мин монда вакыт уздырып ятам? Карточкага төшерерләр дидем, күренми. Газетка язарлар дидем, ишетелми. Тозак-йозакны да ходка жибәрергә жыенмыйсыз.

Шакир. Ташла әле, кода, кеше көлдермә.

Ризван *(кызып китеп)*. Күп көлделәр инде миннән. Уйлап тапкан бар эшемне юкка чыгара килделәр. Хәзер акыллырак булырга уйлыйм.

Шакир. Кеше хезмәте белән!

Ризван. Ачуымны китермә, кода, бардым әйттем булыр. Чертежыгыздан бөтенләй колак какмагаегыз.

Газиз. Ә?

Шакир. Ах, оятсыз.

Ризван. Алаймы? Оятсызмы? Оятсыз булса, менә шул: чертеж минеке! Үзем уйлап таптым, үзем сыздым, үзем китереп тапшырдым да. Суммасы да, премиясе дә минеке, патенты да. *(Газиз белән Шакир сүзсез калдылар.)* Ә ник? Кем фамилиясе тора анда? Арслановмы? *(Күкрәк кагып.)* Менә мин ул Арсланов. Ышанмасагыз, паспортым!

Шакир. Әстәгъфирулла.

Ризван *(Газизгә, көлеп)*. Син үзеңне Арсланов дип күрсәтергә жыенмыйсыңдыр ич? Ә бәлки син мине, чертежны белми, диярсең? Сора. Кайсы тармагын сөйләп бирим? Я?

Газиз. Танышып өлгердең?

Ризван. Әсин бу ташбаштан булмас дип исәп тоткан идеңме? Ачуымны чыгардыгыз, кода, үзегезгә үпкәләгез: чертеж минеке! *(Ярсынып өйгә кереп китә.)*

Газиз. У-у-у!.. Берсе житмәгән иде, икенчесе. Нишләтим бу котырган Арслановларны?!. Кайда тегенең эт ата торган мылтыгы?

Шул чакта күңелле музыка башлана. Шәмсия өйдән чыга. Өсталгә ризык куя. Ә үзе һаман да ике Арслановны аера алмыйча азаплана.

Кайсы монын Арсланов,
Тегесеме, монысымы?
Һай,
Ниләр генә кылмас идем
Белә алсам менә шуны.

*(Әсма янына килә).* Әсма апа, боларның кайсы чын Арсланов соң?

Ә с м а. Икесе дә.

Ш ә м с и я. Ничек инде алай?

Ә с м а. Госманның өч кызы булса, алар өчәү булыр иде әле.

Ш ә м с и я. Шакир абый?

Ш а к и р. Берсе дә түгел.

Ш ә м с и я. Газиз, синеңчә?

Г а з и з. Бөтенесе дә. Син дә, мин дә, ул да, теге дә. Урамдагы һәр кеше күземә Арсланов булып күренә башлады. Менә хәзер капкадан бер-бер артлы төркемнәре белән килеп керерләр төсле. Әнә керәләр түгелме соң? Әллә күземә күренәме?

Ш ә м с и я. Ходаем, шаярма, болай да башым әйләнеп бетте. *(Өстәлгә килә.)*

Кайсы монын Арсланов,
Тегесеме, монысымы?
Һай,
Ниләр генә бирмәс идем
Белә алсам менә шуны.
Кайсына багышлыйм икән
Күңелем ышанычын.

*(Тамашачыларга.)*

Әйтсәгезче, бу икенең
Кайсы ялган, кайсы чын?

Бокаллар күтәреп Р ә м з и я чыга.

Р ә м з и я *(тамашачыларга).*

Күк капусы ачыла,
Белмим кемнең башына.
Әйтсәгезче, бу йөрәгем
Нигә шулай ашкына?

Өстәл янына килә. Өйдән Г а й ф и килеп чыга. Музыка дәвам итә.

Г а й ф и *(тамашачыларга).* Я, әйтегез, шушы хәлләрдән соң да күк капусы ачылуга ничек ышанмассың?!

Ачылды, ачылды,
Һаман ачылып тора.
Нинди теләгең бар, Гайфи,
Тартынма, әйдә, сора:
Биеп торсын атасы,
Көлеп торсын апасы.
Сенелкәе кочагында
Бәгәрләнеп ятасы.

Өйдән Г о с м а н килеп чыга. Кулында шампанское.

Г о с м а н.

Күк капусы ачылды,
Борчуларым басылды.

Кияү, мә әле, ач әле *(Шампанское бирә.)* Күршеләр, рәхим итегез, бүген бездә олы бәйрәм!

Күк капусы ачылды,
Борчуларым басылды.

Гайфи.

Ачылды, ачылды,
Һаман ачылып тора.
Кемнең нинди теләге бар,
Тартынма, әйдә, сора.

Рәмзия.

Күк капусы ачыла,
Белмим кемнең башына.

Шәмсия.

Кайсы ялган, кайсы чын,
Кем минем ышанычым?

Газиз.

Бар да минем башыма,
Кем гаепле барсына?..

*Пәрдә*

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Дүшәмбе. Кич. Музыка. Газиз Рәмзиянең тәрәзәсенә килә. Өй стенасына сөялеп җырлый.

Газиз.

Йөрәгемдә ташкан хисләр
Тулыр да бер, түгелер дә.
Күз алдымда йөрмәсәң дә,
Йөрерсең күңелемдә.
Яңа минем йөрәгем,
Өзеләдер үзәгем.
Әйтелмичә калыр микән инде
Әйтер сүзләрем.
Онытмам дип сөйгән ярым
Тик син генә, бер син генә.
Күләгәңнән күзем алмыйм,
Үзең белмисең генә.
Лә-лә-лә, лә-лә-лә.
Лә-лә, лә-лә-лә-лә...

Терраса янында Әсма самоварга ут салып яткан җирендә, улын кызганып, елап җибәрә. Газиз өйгә кереп китә. Тәрәзәдән Рәмзия күренә. Ул да моңлана.

Рәмзия.

Кердең дә син күңелемә
Былбылым булып сайрадың.
Сине генә, тик бер генә
Гомерлеккә сайладым.
Лә-лә, лә-лә-лә-лә...
Лә-лә, лә-лә-лә-лә...

Рәмзия *(самоварга күрсәтеп)*. Электрда гына кайнатсагыз ни була, пожар чыгуы бар.

Әсма. Чыкса, янар. Сабан туйлары белән кычкыра-кычкыра янсын шунда. Бер сүзем юк. Безне ташлап китәргә булдыңмыни инде, Рәмзия? Ярата идем үзеңне. Апаңа охшамагансың. Киленем булырсың дип йөри идем. Сагышка салдың Газизне. Ашы аш түгел, йокысы йокы түгел.

Рәмзия. Юктыр ла. Син арттырасың инде.

Әсма. Кем белән язмышыңны бәйләгәнеңне үзең беләсеңме соң?.. Чык әле, чык.

Рәмзия ашыгып Әсма янына килә. Әмма шул чакта ук террасада Газиз күренә. Әсма Газизне күргәч, Рәмзияне бакча ягына алып китә.

Әйдә әле, әйдә.

Бераз баргач, Рәмзия тагын борыла.

Әйдә дим!

Чыгып китәләр. Капкадан Шәмсия килеп керә. Яна күлмәктән. Кулында продукты сумка. Эштән кайтып килеше. Туп-туры Газиз каршына атлый.

Шәмсия. Анда конвейерның язмышы хәл ителә, ә ул киңәшмәне ташлап өенә тайган.

Газиз. Мин үз фикеремне әйттем инде. Язып та бирдем.

Шәмсия. Укыдым. Туры әйткәнгә ачуың килмәсен, күрше, мин синебу кадәр үк кара эчле кешедер дип уйламаган идем. Имеш, Арслановның тәкъдиме әллә ни шаккатарлык ачыш түгел. Имеш, аң карагыз, ялгышмагыз.

Газиз. Бер мәртәбә кискәнче җиде мәртәбә үлчәсеннәр.

Шәмсия. Һай, бу көнчелек! Нинди кешеләрне харап итә бит.

Газиз. Проектны кабул итәрләр микән соң?

Шәмсия. Итәчәкләр! Менә күрерсең!

Өй артыннан Ризван килеп чыга. Итәгенә яшелчә салган. Газиз каршына килеп баса.

Ризван (*усал*). Арслановның хезмәтен юкка чыгарып йөрисеңмени? Мина аяк чаласыңмы?! Минем уңышымны күрә алмыйсыңмы?! Утыр!

Шәмсия. Утыр! (*Газизне көчләп утырталар.*)

Газиз. Мин үземне үзем тәнкыйтьләдем.

Ризван. Ул хезмәтне бөтен комбинат ошатканда, бер син генә килештермәгән буласың. Оят түгелме, кода?! Чебен дулап тәрәзә ватканны кайда күргәнең бар! Барыбер берни чыгара алмассың. Менә күрерсең, хезмәтне кабул итәчәкләр. Ә сиңа... үкенергә туры килмәгәе.

Газиз кисәк кузгала да бөтенләй чыгып үк китә.

Ризван (*бераздан*). Р-р-р-р... (*Арыслан булып ырылдый*).

Шәмсия. Ни булган минем Арсланыма?

Ризван. Зарыккан... Р-р-р... Муенына чылбыр салып, йөрәгең арканлап куйдын да оныттын.

Шәмсия. Ой, минем кыргыем, әй, минем түземсезем. (*Арсланның «сыртыннан, ялыннан» сыпыра.*) Зарыгып беткән ул, ябыгып беткән. Бер кишергә генә калдырганнар.

Ризван. Йөрергә алып чыгар идең.

Шәмсия. Алып чыгарга кирәк шул. Бераздан, соңрак, ямь?

Ризван. Кайчан? Ничек очрашабыз?

Шәмсия. Хәбәр бирерсең.

Ризван. Сызгырырмын.

Шәмсия. Сызгыруның чакыру икәнен кем аңламый.

Ризван. Алайса, эт булып өрермен. Өч мәртәбә. (*Өреп күрсәтә.*)

Шәмсия. Шулай итәрсең. Бик килештерәсең дә икән. (*Шәмсия өйгә кереп китә.*)

Ризван (*үз алдына*). Мина аяк чалып маташамы? Ярар, син алай итәсең дә, мин менә болай итим әле. (*Кычкыра.*) Кодагый, Әсма апа! Кодагый дим!

Әсма керә.

Кайда йөрисең, ә?

Әсма. Кая, юып бирим.

Ризван итәгендәге кишерләрне савытка сала.

Ризван. Кодагый, мина Газиз эшли торган конторанын телефон номерын табып бирмәссең микән?

Әсма. Ул анда булырмы икән соң? Эш сәгате бетте.

Ризван. Бүген булмаса иртәгә булыр. Тап әле, тап. Берәр жирдә язылгандыр. Әмма кемгә дә сиздермичә генә.

Әсма. Карармын. *(Яшелчә юа башлый, Ризван өйгә юнәлә.)*

*(Әсма үз алдына ачуланып.)* Житәсе булмады бу сабан туеның да. Бөтен түтәлләремне утап бетерде. Кара инде боларны, өлгереп тә житмәгәннәр бит әле.

Урамнан Шакир кайтып керә.

Нәрсәләр алдың?

Шакир. Монысы чучка сыйраклары, холодец пешереп бир теге бирәнгә. *(Шампанское суза.)* Монысын яшереп куй, күрә күрмәсен.

Әсма шампанское ала да алъяпкыч итәге белән каплый.

Үзе ни эшли?

Әсма. Сабан туена әзерләнә. Арсланов түгел, Обжоров ул. Анысы ошамый, монысы килешми. Тавыктан туйды, үрдәк ите сорый.

Шакир. Үләксә ите пешереп бир син аңа.

Әсма. Нәрсәгә кирәк булгандыр, Госманның телефонын сорый.

Шакир. Шулаймыни? Алайса ул аның күршедә икәнен белми әле. *(Газета читенә номерлар яза да ертып алып Әсмага бирә.)* Мә, тоттыр! *(Үзе плащын, эшләпәсен салып террасадагы кадакка элә дә, як-ягына карана-карана, күршеләренә кереп китә, тәрәзәләреннән Ризванны күзәтә.)*

Ризван өйдән чыга.

Ризван. Булдымы? *(Әсмадан телефон номерын алгач.)* Я, бар тай, бар инде, бар!..

Әсма кереп китә. Ризван, тирә-юньдә кеше юклыгына тәмам ышангач, тиз генә телефонга килә. Номер жыя. Бераздан Госман өендә телефон шалтырый. Шакир ашыкмый, өч-дүрт тапкыр гудок ишетелгәч кенә трубканы ала.

Шакир *(тавышын үзгәртеп, эре генә)*. Алло.

Ризван *(трубкага)*. Конторамы?

Шакир. Үзе.

Ризван. Госман Ганиевичны мөмкин булмасмы?

Шакир. Госман тыңлый.

Ризван. Исәнмесез, Госман Ганиевич.

Шакир. Ни бар?

Ризван. Сезне Арсланов борчый.

Шакир. Ә-ә, килеп чыктыңмы, күптән көтә идек.

Ризван. Моңарчы килә алмадым, авырып киттем. Кинәшмәләре бетте микән, минем хезмәтне кабул иттеләр микән, дигән идем... Аның өчен сумма тиеш булыр бит.

Шакир. А как-же.

Ризван. Баксаң-күрсәң, шактыйдыр ул әле?

Шакир. А как-же.

Ризван. Шуның беразын алып булмасмы дигән идем. Аванс рәвешендә.

Шакир. Ә нигә аванс? Бирсәк без аванслап кына тормыйбыз, бөтенесен берьюлы тондырабыз. *(Кулын йодрыклап)*. Берәгәйле итеп!

Ризван *(сөенеп)*. Шулаймы? Паспортым үзем белән. Хәзер килсәм, соң булмасмы икән?

Шакир. Ашыгасыңмыни?

Ризван. Узып барышлый гына тукталган идем.

Шакир. Әһә, алайса, тизрәк алырга да таярга икән исәп, Ристан иптәш.

Ризван *(төзәтеп)*. Ризван.

Шакир. Алай бик ашыккач, чыгып йөрмә. Үзем машина җибәрермен.

Ризван. Борчылмасагыз ла.

Шакир. Ябулы машина.

Ризван. Ә?

Шакир. Ике милиционеры белән.

Ризван. Ми-ли...

Шакир (*тавышын күтәреп*). Адресың кайда?

Ризван. Адрес?

Шакир. Кайда яшеренеп ятасың, дим?

Ризван. Ә-ә... ә...

Шакир. Безне монда бер нәрсә дә белмиләр дип уйладыңмы? Тәпсез көймәгә утыртып китәргә исәпләдеңме? Ах, шельма! Мошенник! Аферист!

Ризван. Ә...

Шакир. Синең нинди авыру белән авырганыңны бик яхшы беләбез. Менә көн буе инде минем кешеләр сине эзлиләр. Урыныңнан кузгаласы булма! Бел аны, чыгып таярга чамаласаң, эзеңә тиз төшәрбез!

Ризван шүрләп кала. Бер сүз дә әйтә алмый. Трубканы куя да артка чигенә. Башыннан салам эшләпәсен салып ыргыта да Шакирның террасада эленеп торган эшләпәсе белән плащын кия. Бу арада Шакир да, күршеләреннән чыгып, сиздерминчә генә урам якка үтә. Ризван, рәшәткә өстеннән генә сызарга чамалап, шул якка юнәлгәндә, капкадан Гайфи килеп керә.

Гайфи. Бу нинди тип? Рәмзия тәрәзәсе төбендә нишләп йөри ул? А ну, әфәндем!

Ризван каушап кала, эскәмиягә егыла. Гайфи үзе белән бер баянчыны да иярткән.

Гайфи. Таныш булыйк, Арсланов!

Ризван. Юк, мин Арсланов түгел. Ә, әйе, Арсланов шул.

Гайфи. Арсланов? Исемең Ризван, егерме бишләрдә, өйләнмәгән, новатор?

Ризван. Әйе, ә юк... әйе, әйе.

Гайфи. Беләм мин синең нинди Арсланов икәнлегеңне.

Ризван. Ышаныгыз, зинһар, минем бертөрле дә гаебем юк. Мине бутадылар.

Гайфи. Так, анысын да беләм. Таныш.

Ризван. Таныштыр, сөйләгәннәрдер. Ләкин сез аларга ышанмагыз. Гафу итегез. (*Кузгалып китмәкче.*)

Гайфи. Юк, мин гафу итмим. Бер Казанга ике тәкә башы сыймый. Биредә нисең калган? Кайсына күз тотасың, ә? Апасынамы, сеңелесенәме? (*Каршына атлый.*)

Ризван. Сез нишләмәкче буласыз?

Гайфи. Мин сине шартлатам. Син буш куык. Бармак белән төртү җитә. Кем алдына төшәргә чамалыйсың?!

Ризван. Аңлагыз, зинһар... Мин авыру. Мин кайчакта авышып китәм. Акыл ягы такыррак. Әйе, әйе, мин акылга тулы түгел. Шуңа күрә мине судка да бирә алмыйлар.

Гайфи. Җүләрләргә закон язылмаган. Алайса, син дивана?

Ризван. Диваналың диванасы.

Гайфи. Күреп торам. Акыллы кеше шулай сөйләмәс.

Ризван. Шуны бел, мине куркытырга да ярамый. Минем өянәгем тота. Менә, менә тота башлады. Ай!.. (*«Өянәге тота» — җилкәсе белән бер кулын җыерып ала да кисәк айкап җибәрә, җыерып ала да айкап җибәрә. Аягы чалышая. Ул шулай чатанлап бакча ягына чыгып китә.*)

серенада жырлый.

Гайфи.

Керфекләренне тибрәтеп
Тик бер генә күз аттың,
Йөрәгемдә тынып калган
Давылларны кузгаттың.

Рәмзия чыга. Гайфи аны баянчы белән таныштыра да, култыклап алып, музыка астында бакчага табан алып китә. Әмма аларны Рәмзия туктата.

Рәмзия. Туктагыз!.. Туй мәсьәләләрен хәл итәсе иде.

Гайфи. Туй? *(Көтмәгән иде, баянчы белән карашып ала.)* Мин үзем дә зарыктым да бит.

Рәмзия. Зарыккач, урла да алып кит. Үзем булышам.

Гайфи. Син риза?

Рәмзия. Кайчандыр буласы туйны көтеп ятканчы.

Гайфи. Әйдә, киттек соң!

Рәмзия. Шушында гына көтегез. Минем барысы да әзерләнгән. *(Өйгә кереп китә.)*

Гайфи. Күк капусы ачылды!

Шул чакта капка буенда машина килеп туктаган тавыш ишетелә. Гайфиләр яшеренәләр. Капкадан Госман керә. Эштән кайтып килеше. Машина кузгалып китә. Атасы каршына өйдән Шәмсия килеп чыга, кулыннан портфелен ала.

Шәмсия. Әти, нинди хәбәр алып кайттың, кабул иттегезме?

Госман. Кайда ул?

Шәмсия. Кем?

Госман. Арсланов!

Шәмсия. Кайсы?

Госман. Синенчә ул берничәмени?!

Шәмсия. Мм...

Өйгә кереп китәләр. Озак та үтми, Рәмзия тәрәзәдән чемодан суза, аны Гайфи тотып ала. Бераздан Рәмзия үзе дә ишектән килеп чыга.

Рәмзия. Менә шулай, яраталар икән мине — урлап китсеннәр.

Гайфи. Очтык, күгәрченем. *(Чемоданны күтәреп, Рәмзияне җитәкләп капкага омтыла.)*

Рәмзия. Ой!..

Гайфи. Ни булды тагын?

Рәмзия. Костюмымны оныттым, ахры. Әллә салдым микән.

Гайфи. Ачып кара соң. Тиз генә.

Рәмзия. Монда ачсаң чуалып бетә инде ул.

Гайфи. Өенә кире керәсеңме?

Рәмзия. Кире керсәң юл уңмый. Әйдә, күршеләргә генә. Анда, ичмасам, иркенләп актарырга була.

Гайфи. Дөрес. Әйдә.

Гайфи чемоданны күтәреп өйгә юнәлә. Террасага җиткәч, Рәмзия, чемоданны алып, Газизләр өенә кереп китә. Гайфи баянистны такси алырга җибәрә. Үзе өй тирәсендә Рәмзияне көтеп йөрenә, Рәмзия чыкмый. Аптырагач үзе дә такси эзләп китә. Ул күмелүгә, Ризван күренә. Кеше юклыгына ышангач, эй читенә посып, өч мәртәбә эт булып өрә. Аңа ияреп күрше-тирәдәге барча этләр өрә башлый. Госманнар өендә шау-шу күтәрелә. Менә ишектән котырынып Госман килеп чыга. Кулында ау мылтыгы. Артыннан Шәмсия чыга.

Госман. Тагын йокы бирми икән, үләт кыргыры. Пушал! Үз башына өрәсеңме?

Шәмсия. Әти, эт түгел бугай ул.

*(Шул чакта ишек алдыннан урмәләп йөгергән Ризванны күреп ала да артына төзәп ата.)* Эләкте! Ха-ха-ха... *(Сөенеченнән сикеренгәләп куя.)*
Шәмсия. Нәрсә белән аттың, нәрсә белән, ядрә беләнме?
Госман. Тоз белән. Ха-ха-ха...

Өйгә кереп китә. Шәмсия Ризван янына ашыга.

Шәмсия. Ни булды?

Ризван бер сүз дә әйтә алмый, телсез калган, ыңгыраша. Утыра торган жиренең кычытуына чыдый алмый, курәсең. Эскәмиягә утырып кашына.

Ризван. А... а... а... а...
Шәмсия *(куркуга кала)*. Әй, ходаем, харап итте бит кешене. Я инде, я, тынычлан... Нигә дип киден бу кеше киемен?
Ризван *(сүзләрен көчкә әйтә)*. Сакланганны алла саклаган, ли.
Шәмсия. Я, тынычлан. Жырла, әйдә жырла. Басылмасмы.
Ризван *(җырларга азаплана)*.

Кай ил...дә тудын син,
Кай жир...дә үстен син...

Алар шулай парлашып бакчага кереп китәләр. Бераздан өеннән Әсма килеп чыга. Шатлыгы эченә сыймый.

Әсма. Кара бу сөенечне. Атасы кая сон? Шакир, Шакир дим. Кая олактың, шунда гына чуала иде бит. Ша... *(Еракка — бакча эченә текәлә.)* Чү, теге кемнәр? Шәмсиясе белән ул түгелме сон? Эшләпәсе, плащы... Ах, бәдбәхет! Азгын! Сеңелесе малаема, апасы үземә дию,ләре хак икән. Нишлим? Ничек үч алыйм? Болайга киләләр түгелме?.. Тукта! *(Ярсынып өйгә кереп китә. Ризванның тозак-йозагын күтәреп чыга.)* Эскәмиясен дә тикмәгә ясамаган икән. *(Эскәмия янына барып тозак-йозакны аяк астына сала. Аннан килеп баганада янган утны сүндерә.)* Йокладылар дип уйласыннар. *(Өйгә кереп тәрәзәдән күзәтә.)*

Менә бакчадан Шәмсия белән Ризван чыга. Эскәмия янына киләләр. Утыралар.

Ризван *(онытылып сөйләнә)*. Бүреләргә куя торган капкынны мин кешеләргә көйләдем. Тозак-йозак дип атала. Менә, Шәмсиюшкам, ул шундый: кеше килеп бастымы, аягын буып та ала, йозагы бикләнеп тә өлгерә. Эләктенме, ычкынырмын дип уйлама инде... *(Эскәмия астындагы тозакка баса да капкынга эләгә.)* Ай!..
Шәмсия *(көлә)*. Ха-ха... Кызык та соң.

Шул чакта Әсма өеннән чиләк алып чыга, ашыгып килеп, аны «Шакирының» башына киертеп үк куя.

Әсма. Азгын! Тол хатынга күзең төштеме?! *(Кычкыра.)* Әй, кем бар анда, чыгыгыз, күрегез!

Газиз керә. Өеннән Госман чыга. Иңендә мылтыгы. Шәмсия читкә тайпыла.

Госман. Ни булды?
Әсма. Карагыз бәдбәхетләрне... *(Барып баганадагы утны яндыра.)*

Шул чакта арт капкадан Шакир кайтып керә.

*(Шакирны күргәч, Әсма чигенеп үк куя, лап итеп җиргә утыра.)* Әстәгъфирулла.
Ризван. Нишләвең бу синең? Бу ни эшең?
Әсма. Ай алла, бу син булдыңмыни әле?
Шакир. Ни бар?
Ризван. Ачкыч кайда?

Әсма. Кызулыгым белән әллә ташладым инде.
Ризван *(куркуга калып)*. Ыргыттыңмы? Кая, кайсы якка?
Әсма. Кем белгән инде аны.
Ризван.. Аңлыйсыңмы син нишләгәнеңне?! Ачкычсыз моны ачып булмый бит.
Әсма. Әй ходаем икән.
Шакир. Богауга эләктеңмени?
Ризван. Мин нишләргә тиеш хәзер, шушыны өстерәп йөрергәме? Йоклаганда да, урамга чыкканда да...
Шакир. Хатыныңн янына кайтканда да.
Шәмсия *(моны ишеткәч, кычкырып ук җибәрә)*. Ә?..
Шакир. Ычкындырмыйммы? Син, алайса, шатлан инде, кода, тозак йозагың ышанычлы икән.

Ризван бер кулы белән богауларны жыеп-күтәреп тота да, аксаклап, шалтыр-шолтыр килеп, өйгә кереп китә.

Әсма. Кода, кода.
Шакир. Үз тозагына үзе килеп эләккән. Кешеләрне каптырырга дип йөри иде. Ах, минем битараф хатыным. Болай булгач, син битараф булып калмадың. Көрәшче булып чыктың син, әнкәсе.
Госман. Аказия сезнең белән. *(Күккә атып җибәрә.)* Кайда соң бу Арсланов?
Шәмсия. Икенчесеме? Хәзер табып килəм. *(Чыгып китә.)*
Госман. Нәрсә ул үз бәхетеннән качып йөри. Шатлыклы хәбәрне беренче булып үзем әйтермен дигән идем. Аның хезмәте кабул ителде.
Шакир. Шулаймыни? Комиссия тарафыннанмы?
Госман. Беравыздан расланды.
Шакир. Приказ да бирелде, имза да салындымы? Булган. Шампанскоены белеп алганмын икән.
Госман. Син нәрсә шул кадәр очынасың? Аның акчасы синең кесәнә керми торгандыр ич?
Шакир. Белмәссең.
Госман. Арсланов хәзер бездә эшләячәк. Техника бүлегендә.
Шакир. Ә Газиз?
Госман. Аңа икенче эш эзләргә кирәк булыр. Яңалыкка аяк чалып килгән кешене без техника бүлегендә тота алмыйбыз. Менә бүген дә... Комиссия утырышында катнашып, үз фикерен әйтәсе, яклап чыгасы урында ул нишли? Кайта да китә. Шул кадәр салкын карау булырмы?
Шакир. Ай-һай, Арсланов тикле Арсланов шундый кечкенә зарплатада утырырга риза булыр микән. Газиз түгел бит ул.
Госман. Ә без аның зарплатасын арттырдык.
Шакир. Шулаймыни? Менә анысын әйбәт эшләгәнсез.
Газиз. Дөрес булган. Күптән сүз бара иде.
Шакир. Шәп булган. Әйтәм ич, шампанскоены бик белеп алып кайтканмын. *(Госман Шакирга гаҗәпләнеп карап куя.)*
Газиз. Болай булгач, эти, ике шешә аласың калган.

Госман шулай ук гаҗәпләнеп Газизга да карап куя.

Шакир. Янына тагын бер акны диген.
Госман. Кайда соң үзе?

Шамсия белән Гайфи керә.

А-а-а, герой! Синнән сөенче! Тәбрик итәбез, котлыйбыз үзеңне! Кызлар, әйдәгез табын әзерләгез. Мондый вакыйганы юмыйча ярыймы. Төн безнеке! Күрше, чыгар шампанскоены!

Госман (*Гайфигә*). Син нәрсә сүзсез калдың, куанычыңнан телеңне йоттыңмы әллә? Әйдәгез өйгә, иптәш Арсланов.

Шул чакта богауларын өстерәп террасага Ризван килеп чыга. Ачуы кабарган, ярсулы.

Ризван. Кем анда үзен Арсланов дип таныта? Күрсәтсен паспортын!

Госман. Бу ни дигән сүз?!

Ризван. Менә мин ул Арсланов. (*Паспортын чыгара.*) Карагыз! (*Госман аның янына килеп паспортын карарга мәҗбүр була.*)

Госман (*укый*). Арсланов... Ризван... (*Гайфигә.*) Ә син кем? Кем син?

Гайфи. Белмим. Мин үз исемемне оныттым да инде. Арсланов та Арсланов дидегез... (*Хәтерләгән булып.*) Ә-ә-ә, әйе, мин Габдрахманов идем бугай.

Госман. Аптыратканыңны үзем дә аңладым. Исемең?

Әсма. Гайфи, син монда әтеңне коткарырга дип килгән кеше идең. Син аны әнә Шәмсия белән коткар инде.

Госман (*кычкырып ук җибәрә*). Гайфи?! (*Сүзсез кала. Аннан акыра.*) Судка! Үзеңне дә, әтеңне дә!

Гайфи. Ашыкмыйсың микән, кайнатай?

Госман. Кайнатай? Тю-тют сиңа Рәмзия. Үзе теләсә дә бирмим.

Гайфи. Ә без Рәмзия белән аерылыштык инде. Күңелемә менә Шәмсиясе ошыйрак бирә.

Госман (*Шәмсиягә*). Ә син?

Шәмсия. Мин... (*Уйлап тора да Гайфигә якыная.*)

Госман (*башын тота*). Ой!.. (*Гайфигә.*) Алайса син министерствоның эчендә утыру түгел, тирәсендә дә йөрмисең?

Гайфи. Кызганычка каршы. Безне Кремльгә кертмиләр, мин грузовикта эшлим бит.

Госман. Шофер?..

Ризван. Я, ышандыгызмы инде?

Госман. Арсланов... Өр-яңасы. Әле генә мичтән чыкканы. Хәерле булсын. Әйдәгез, рәхим итегез, иптәш Арсланов, өйгә. Ә, әйе, тәбрик итәргә онытып торам икән. (*Янына бара.*). Котлыйм, котлыйм. (*Ризван багаулары белән шалтырый башлагач.*) Акылдан шашырсың. (*Дулап.*) Тагын берәр Арсланов юкмы? Я, кайсыгыз? (*Кызларына.*) Сез түгелме? (*Әсмага.*) Синме? (*Шакирга.*) Бәлки син дә Арслановтыр?

Шакир. Юк, мин Арслановның әтисе генә.

Госман. Ә?.. (*Бераздан, ялынып.*) Кодасы диген ичмасам.

Шакир. Әтисе. (*Госман хәлсезләнеп утыра.*)

Госман. Тагын ниләр ишетәсем бар икән.

Газиз. Кода, син шулай гомергә богау белән йөрергә булдыңмыни?

Ризван. Ачкычы, ачкычы, ачкычы югалды бит.

Газиз. Миндә.

Ризван. Ач, зинһар. Коткар.

Газиз. Ачам. Тик башта бер сорауга җавап бир: тәкъдим кемнеке? Синекеме, минекеме? Кем чын Арсланов?

Ризван. Ачкыч...

Газиз. Җавап!

Ризван. Син, син чын Арсланов.

Шакир. Менә хәзер шампанскоены ачарга да була.

Госман. Чәчеп үстерәләрме әллә бу Арслановларны? (*Газизгә.*) Димәк, син?

Газиз. Күпме тәкъдим кертеп карадым, Госман Ганиевич. Берсен дә санга санамадыгыз.

Газиз. Сез кешенең эшенә караудан бигрәк, исеменә карыйсыз. Дәрәҗәсенә. Аптырагач, соңгы хезмәтемне икенче фамилия белән бирергә мәҗбүр булдым.

Госман. Ах, мин җүләр.

Шакир. Менә монысын дөрес әйттең, күрше. Шулай да, Газизнең зарплатасын арттырып, бер акыллы эш эшләгәнсең.

Госман. Газизнекен?

Шакир. Безнең өчен тырышып йөргәнгә рәхмәт инде, күрше.

Госман. Газизнең... Ә-ә, әйе, аныкы булып чыга шул.

Ризван *(ялварып)*. Кода...

Газиз. Хәзер, хәзер. *(Барып Ризванның богавын салдыра.)*

Ризван *(богаудан ычкынгач)*. Үз башыма алып килгәнмен икән.

Шәмсия *(Гайфи янында)*. Арсланга атланып йөрергә иде исәп, булмады. Ярар, хәерле булсын, бер туйганчы машинага утырып йөрермен, ичмасам.

Госман. Грузовикка.

Гайфи. Кабинасына.

Шәмсия. Шоферы белән янәшә.

Госман. Шуны бел, этен коткару өчен генә өйләнә ул сина.

Гайфи. Һәркем үзенчә балык тота, Госман Ганиевич. *(Кычкыра.)* Әсма апа, кая, чыгар әле намордникны. Эт җөгәнен!

Шәмсия. И-и-и, син бигрәк инде.

Әсма *(өйдән чыга)*. Газиз, безгә нинди чемондан кертеп куйганнар? Кем дә булса килмәгәндер ич.

Газиз башта берни дә аңламыйча тора, аннан сизенеп өйгә ташлана. Аннан Рәмзия килеп чыга. Туй күлмәге киеп алган.

Газиз. Рәмзия! Димәк?

Рәмзия. Күрше хакы алла хакы, диләр. Күршене ничек ташлап китәсең. Аннан, аерылырга туры килсә дә, ансат. Мәшәкате аз: чемоданны бу өйдән бу өйгә генә күчерәсең.

Әсма. Рәмзия килен, әйдә, табын әзерлик. Газиз уңышы хөрмәтенә.

Рәмзия. Әйдә, әнкәй.

Госман. Килен?

Шакир. Әт-тә-тә-тә, без әле килен төшердекмени? Бәракалла. Төкле аягың белән, килен.

Рәмзия. Рәхмәт, әткәй.

Шакир. Безнең йортка берьюлы ничә шатлык алып килдең. *(Маңгаеннан үбә.)* И-и-и, Газиз, шампанскоены өч шешә алырга кирәк булган ич.

Рәмзия *(әтисенә килә)*. Әти?

Госман *(иңенә кул салып)*. Бер сүзем юк. Үзең беләсеңдер. Бәхетле булыгыз.

Рәмзия. Рәхмәт, әти.

Госман *(Газизгә)*. Кил, алдакчы. *(Газизнең маңгаеннан үбә.)*

Шакир *(өстәлнең үз якларындагы кисәген күтәреп)*. Я әле, күрше, китер әле икенче яртысын. Болай булгач киселгәнне ялгарга туры килә.

Госман. Ябыштырабыз аны, кода. *(Госман өстәлнең икенче кисәген алып килә. Әмәлен табалар, ике кисәкне бергә кушып, ябыштырып куялар.)*

Шакир. Менә шулай.

Госман. Кайда соң бокаллар?

*(Музыка башлана.)*

Шакир. Барысы да парлашып бетте, безгә дә, әнкәсе, никах янартмыйча ярамас. Шул кадәр көнләшүләреңнән соң?

Рәмзия белән Газиз үзләренең җырын башлыйлар. Аларга башкалар да кушыла.

Йөрәгемдә ташкын хисләр
Тулыр да бер, түгелер дә.
Күз алдымда йөрмәсәң дә,
Йөрерсең күңелемдә.
Яна минем йөрәгем,
Өзеләдер үзәгем.
Таң атканчы сөйләсәм дә бетмәс
Әйтер сүзләрем.

Өстәлдә бокаллар булмаса да, һәркайсы өстәл янына килеп, куллары белән бокал күтәргәндәге кебек хәрәкәт ясыйлар. Музыка дәвам итә.

Лә-лә, лә-лә-лә-лә,
Лә-лә, лә-лә-лә-лә...

Эчке пәрдә төшә. Әсәрдә лейтмотив булып килгән музыка башлана. Эчке пәрдә ачыла, артистлар баш иярга чыгалар, ә музыка һаман яңгырап тора.

Сокланалар миңа карап дуслар,
Ямь табасың диеп тормыштан.
Шат яшәргә сездән өйрәндем мин,
Шаянлыгым минем тумыштан.

Яннарымда якын дуслар барда
Гөрләп уза җәем, кышларым.
Зәңгәр күктә күпме йолдыз булса,
Шул кадәрле җирдә дусларым.

Моңаерга күнекмәгән күңлем,
Дөнья мине көләч яраткан.
Туганчы ук минем күгемдәге
Кайгы томаннарын тараткан.

Минем өчен исә таң җилләре,
Минем өчен сайрый кошларым.
Зәңгәр күктә күпме йолдыз булса,
Шул кадәрле җирдә дусларым.

Җырлап басам сагышларым булса,
Җырлап ачам ярсу күңлемне.
Җыр юлдашым минем, җыр сердәшем,
Болытлардан арчый күгемне.

Лә-лә-лә-лә, лә-лә-лә-лә, лә-лә,
Лә-лә-лә-лә, лә-лә-лә-лә, лә-лә.
Зәңгәр күктә күпме йолдыз булса,
Шул кадәрле җирдә дусларым.

Хор астында Шакир белән Әсма бер-ике адым алга чыгып баш иялар.

Шакир (*залга*). Малаемны өйләндерәм, һәркайсыгыз туйга рәхим итегез!

Хор дәвам итә. Шакир белән Әсма башкалар янына барып баскач, алга Газиз белән Рәмзия чыга. Баш иялар.

Газиз. Унсигез ел буе көргәнмен...
Рәмзия. Унсигез ел белми йөргәнмен.

Баш иярга Госман чыга. Чыга да иңендәге мылтыкның курогын тартып җибәрә. Мылтык атыла. Госман урынына барып баса. Хор дәвам итә. Баш иярга Ризван чыга.

Ризван. Ут себергере тозак-йозагын, үз башыма алып килгәнмен икән.

Баш иярга Шәмсия белән Гайфи чыга.

Шәмсия. Барыбер чын Арысланов ана эләкте.
Гайфи. Күк капусы ачылды.

*(Хор дәвам итә.)*

*Пәрдә*

## Камил Мостафин

### Алиһәләр

Без чыгарган гүзәл экиятләрдән
алиһәләр киткән.
Карачәчләр бөтен дөнья буйлап
безне эзли икән.

Пәризатлар бүләк иткәнмени —
кыйгач кара кашлар!
Эзләп йөри безне такыр юлдан,
тәхетләрен ташлап.

Йөзләрендә — серле, җазибәле,
без яраткан күзләр.
Тәхетләрен ташлап, бәхетләрен
йөри алар эзләп.

Алтын башмакларын югалтканнар
ташлы сукмакларда.
Ялан аяклары эз калдырган
Сахраларда, карда.

Ялан аяклары эз калдырган
безнең йөрәкләрдә.
Алиһәләр — безнең газаплар да,
безнең теләкләр дә.

●

Бала чактан бирле
өйрәнгәнбез:
чирәм яшел була,
дошман юк ителә яки әсир була,
юллар озын була,
байрак кызыл була.
Ә бер көнне
кинәт беләбез без:

чирәм кайчак утта кара корым була,
кайчак дошман безне үзе әсир кыла,
юллар өзелә...
Байрак кына
кызыл булып кала.

Туксан тугыз жиргә кадак кага кеше,
туксан тугыз жирдә хикмәт таба кеше,
туксан тугыз тауга менеп баса кеше,
туксан тугыз җанның серен ача кеше.

Тик йөзенче кадак кайчак төшеп кала
кесә ертык булганга,
хикмәтләрнең йөзенчесе посып кала,
күренмичә томанда.
Йөзенче тау менелмәгән әле һаман —
бик шугалак бозлары.
Йөзенче җан никтер аңлашылмый ана:
үз җаны.
Ә үзсүзле кеше һаман өметен өзми;
хикмәтләрнең йөз дә беренчесен эзли.

## Поши

Ак көртләрне ерып, бер яшь поши чыкты
агач арасыннан.
Кинәт туктап калды, күзен алмый миннән,—
адәм баласыннан.

Олы башын алга, — миңа таба сузган,
үзе дер-дер килә.
— Ярдәм кирәкмиме? — димен аңа карап, —
нәрсә булды? Сөйлә!..

Ә ул карны исни олы борыны белән,
дерелдәми инде.
Кара күзе аның, ахры, әйтте миңа:
— Рәхмәт, рәхмәт, — диде.

Ак көртләрне ерып, кире кереп китте
агач арасына...
...Җылы сүзгә мохтаҗ поши баласы да,
адәм баласы да...

## Җыр турында баллада

Кеше откан баррикада гимнын,
кеше откан газап-үлем моңын,
кеше откан ачы жилләр давын,
кеше откан эшелоннар шавын...

Ә соңыннан кеше җыр чыгарган,
янып-көеп, гаҗәп җыр чыгарган,
һәм ул җырны бүләк иткән кызга,—
бүләк иткән җырны гади кызга.

Аны моңсу гына җырлаган кыз...
Ни турында ул җыр — сорамагыз,
аны откан җырчы эшелоннар,
аны откан кырыс батальоннар.

Кыен көндә син юлыксаң ана,
көрәштәшем, жырны тыңлап кара...
...Чү, мәхәббәт жырын
акрын гына
жырлый әнә төнге баррикада...

●

Тормыш — лотерея, диган кемдер.
Ни чыкса да түзәр-чыдарсың!
Ләкин, дустым, синең билетыңны
халкың үзе тартып чыгарсын.

●

Шәфәкъ гүя кызыл шәлен булып
иннәреннән шуган.
Битләренә кагыласым килә,
сукыр кеше сыман.

Син карыйсың күлэгәләр аша,
гүя нидер көтеп.
Төсләреңнән синең илһам алам,
антик сынчы кебек.

Илһам алам, каеннардан очкан
яфрак белән түләп...
Син тумаган әле, син тумаган,
сиңа сынчы кирәк.

Шәфәкъ гүя кызыл шәлен булып
иннәреннән шуган.
Сары яфракларның кыштырдавы —
тәүге сүзең сыман.

Чү! Йөрәгем белән уйларыңны,
хисләреңне тоям...
Мин бу кичне жылы сулышымнан
сине үзем коям.

●

Син оныткан ап-ак яулык
жансыз куян кебек ята...
Мин атмадым. Мәхәббәтне
һәлак итте нинди хата?

Кем гаепле? Бар патрон да —
патронташта... Без атмадык.
Чыгып киттең хушлашмыйча.
Өстәлемдә — ап-ак яулык.

Син оныткан ап-ак яулык, —
жансыз куян кебек ята.
Бүлмәдә — кич, дөньяда — кич,
ә мин уйлыйм синең хакта.

Яулыгыңа карап торам, —
юләр, — сине дәшәм тагын...
...һәм күтәрде колакларын
ап-ак куян!

# *ИБРАҺИМ САЛАХОВКА 60 ЯШЬ*

# ҮРЛӘРГӘ КЫЮ АТЛЫЙ

*Үзенең табигате, холкы белән сабыр һәм гаять тыйнак булган Ибраһим Салахов, 1928—1931 елларда Казан педагогия техникумында укыганда, балалар-яшьләр матбугатында шигырьләре, әдәби парчалары белән катнаша башлый. Соңрак ул үзе катнашып килгән «Яшь ленинчы», «Кызыл яшьләр» газеталары редакцияләрендә эшли дә.*

*Без, замандашлары, аның Кызыл Армия сафларында хезмәт иткән елларын да ачык хәтерлибез. Өстенә соры шинель, башына кызыл йолдызлы шлем кигән бу шат күңелле, тере карашлы егет иҗат эшчәнлегең һаман көчәйтә, адымнарын тизләтә барды. 1935 елда аның «Ярату» исемле пьесасы басылып чыкты. Бу әсәргә карата үз вакытында матбугатыбызда җылы сүзләр әйтелде. Пьеса Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелды.*

*Тормыш ага торды, Ибраһим да заман адымнарыннан калышмаска тырышып каләм тибрәтә торды. Аның педагогия институтында укыган еллары да бер-бер артлы артта калды. Язучының Кызыл Армия тормышыннан алып язылган повесте «Дуэль» шулай ук китап укучылар тарафыннан ярыйсы ук җылы каршы алынды. Язучы, елдан-ел каләмен ныграк чарлый барып, 1937 елда «Сакта» исемле шигырьләр җыентыгы бастырып чыгарды. Шул елларда аның кызылармеецлар тормышын сурәтләгән «Мәхәббәт һәм өмет» дип исемләнгән повесть язуын да хәтерлибез. Бу әсәрнең кайбер бүлекләре «Кызыл Армия» газетасында басылып чыкты.*

*Бөек Ватан сугышыннан соң язучы үзенең туган җире Казагыстан якларына китә. Шунда яшәп, чирәм җирләр үзләштерүчеләрнең тырыш хезмәтен өйрәнә. Моның нәтиҗәсе буларак, Ибраһим Салаховның «Дала дулкыннары» исемле яңа шигырьләр җыентыгы мәйданга килә.*

*Шулай да, минем уемча, Ибраһим Салаховны язучы буларак таныткан әсәр чирәм җирләр күтәрүчеләрнең катлаулы характерын ачкан «Кукчәтау далаларында» романы булды. Бу әсәр, киң полотнода язылып, вакыйгаларның оста үрелүе, матур теле, шактый мавыктыргыч сюжеты белән аерылып тора. Әсәрне әдәби тәнкыйть тә төксе чырай белән каршы алмады. «Кукчәтау далаларында» романының уңышлы әсәр булуы Татарстан язучыларының VII съездында да билгеләп үтелде.*

*Һәр кошның үз тавышы, үз моңы булган кебек, И. Салаховның да байтак кына иҗат үзенчәлекләре бар. Аның киң далаларны сөюен, тугандаш казакъ халкына тирәнтен ихтирам белән каравын ул язган әсәрләрнең байтагында күрәбез. Язучы бер урында таптана башласа яки катып калса, үз-үзен кабатлый башласа — бу фаҗига. Бәхеткә каршы, безнең Ибраһим андыйлардан түгел. Ул, тынгысыз җан, эзләнә, уйлана, тапталган сукмактан бармаска тырыша. Ибраһим дус болай өлкән яшьтә булса да, үткән юлы белән әле ул карт түгел. Аның иҗат канатлары һаман ныгый баруын күреп, күңелдә куанычлы хисләр туа.*

*И. Салахов — иге-чиге күренмәгән Казагыстан далаларында туып-үскән кеше. Туган якларның үзенә тарту куәте көчле була. Ул, баштарак әйткәнебезчә, тагы менә хәтсез еллардан бирле шул үзе туган газиз туфрагында гомер сөрә, эшли, иҗат итә. Язучының иҗат офыклары киңәю белән бергә, аның әсәрләрендә драматик мотивлар камилләшә һәм каһарманнарның психологик сурәтен ачуда уңышлары арта бара.*

*Яшьләре олыгайган саен иҗат мөмкинлекләре чикләнә барган язучылар да бар дөньяда. Безнең Ибраһим андый язучы түгел. Аның иҗат чишмәсе елдан-ел куәтлерәк ургый, иҗат активлыгы бер дә сүрелми. Бу аның «Кукчатау далаларында» романы дөньяга килгәннән соң да дистәләгән хикәяләр, очерклар, шигырьләр язуында ачык күренә. Язучы үзенен шигырьләрендә казакъ далаларының матурлыгына, аларның күңелдә изге хисләр уятуына («Казан утлары» журналы. 1967 ел. 3 сан) мәдхия укый. Ул һәр яктан киң карашлы булырга тырыша. Әдәби әсәрләр язу белән бергә, язучыны әдәбият тарихына кагылышлы мәсьәләләр дә кызыксындыра. Мәсәлән, мин аның «Фәхретдин бине Мифтахетдин» дигән мәкаләсен нык кызыксынып укыдым. («Казан утлары» журналы. 1968 ел. 8 сан.) Ибраһим Салахов кирәк карт гвардия вәкилләре, кирәк яшьләр, бүгенге көн каһарманнары турында язсын («Казан утлары» журналы. 1968 ел. 2 сан һәм 1970 ел. 7 сан), аның кешеләргә, табигатькә чын күңелдән гашыйк икәнен төсмерлисең, каләменең үзенчәлекле икәнен тоймый калмыйсың. Аның очерклары да хикәяләр кебек җиңел укыла, җанга ятышлы булып чыга.*

*Язучы хәзер шул үзе яшәгән Кукчатау якларында революция елларына, казакъ һәм татар халкының ирек өчен көрәшенә багышлап зур күләмле әсәр өстендә эшли. Ышанырга кирәк — ул аны уңышлы тәгәлләр.*

*Сәббух* РАФИКОВ.

Ибраһим Салахов

# КАРЛЫГАЧ

чын хикәя

## I

Моңлы бер җыр тавышына уянып киттем. Әллә инде уянмадым да — һаман төш күрәм, бигрәк тә моңлы ич бу көй. Ул бик ерактан килә, җырның сүзләре аңлашылмый, ә моны, моңы йөрәкне телгәли, күңелне ашкындыра, сихерли ул.

Түзмәдем, сикереп тордым да, чатырның ишек япмасын каерып, һавага чыктым. Җәйге, җылы төн. Шылт иткән тавыш юк — урман йоклый. Чатыр әйләнәсендәге карт карагайлар аяк өсте генә калгыйлар. Күк йөзе күренми, карагай чуклары бер-берсенә тыгызланып аны каплыйлар. Ләкин кайдандыр күгелҗем нур түгелә. Урман серле бер төс ала. Ә моң? Моң кинәт юк булды. Әллә инде куркыттым ул илаһи тавышны, әллә инде чынында тәмле бер төш кенә булды микән, югыйсә?..

## II

Күзләремне ачсам — чатыр эче яп-якты. Бәй, йоклап калганмын ич. Таңнан торып, урманда яңа көннең тууын карармын дигән идем бит. Теге сихерле моң белән саташып бик озак йоклый алмый яттым шул. Тукта, чынлап та ишеттемме, әллә хыялымда гына тудырдыммы мин аны?

— Житәр, расписаниең кайда соң синең, ял итүче кеше?! — дип үз-үземне шелтәләп урыннан тордым. Юкса, мин бит монда килгәнче үк, тәүлекне сәгатьләргә бүлеп ял итүнең гыйльми расписаниесен төзегән кеше. Ә менә чынбарлыкта, беренче көнне үк беренче пункт мәтәлде. Йокы чүлмәге! Инде, ичмасам, икенче пунктны үтәргә кирәк. Сөлгене җилкәгә салдым. Су коенырга!

Сукмак елан кебек боргаланып карагайлар арасыннан бара да түбәнгә төшә. Мин менә шул сукмактан беренче тапкыр су коенырга барам. Нинди тәмле хуш ис! Сулыйм, сулап туя алмыйм. Йотлыгып эчәм, ширбәт эчәм мин. Бөтен тән рәхәтләнеп китә, егәр өстәлә.

— Һай, һай, ай!..

Тавыш дулкынланып, урман эчен калтыратып еракка китте дә, тауларга сугылып-яңгырап кире кайтты:

— Һай-ай...

Кешеләр инде урман аралап бер-берсен чакыралар. Ә мин...

Сукмак боргаланды-боргаланды да баскычланып яткан гранит ташлар өстенә килеп чыкты. Гаҗәп, күлгә төшәргә җайлы булсын өчен, берәү түшәп чыккан диярсең... Ике яктан баскычка ияреп карагайлар бара. Алар гранит өстенә басып үскәннәр, читкә атларга — гранит ташларны ташлап китәргә кыймыйлар, кызганалар кебек. Бу ни бу, шүрәле кебек ялгыз, берәүгә дә кушылмыйча, урманда адашып йөри, ди торгансыздыр, сизәм. Алай булгач, пәрдәне ачыйк. Дөресен әйткәндә, монда әллә ни сер дә юк.

Мин коенырга төшеп бара торган күлнең аргы башында, моннан җиде-сигез километр чамасында, Имәнтау авылы тора. Күлнең бу ягындагы безнең чатыр торган тау Казантау дип атала, чөнки аның нәкъ түбәсендә таштан үелгән казан бар, ди. (Югыйсә, үземнең әле ул казанны күргәнем юк. Ничек тә күрәсе иде.) Бу тау үзе берсенең җилкәсенә берсе басып күтәрелгән таш кыялардан тора. Ул калын карагай урманы белән капланган. Бу урман Имәнтау авылының нәкъ уртасыннан башлана да, күлне урап килеп, Казантау аша Арыкбалык күленә таба сузыла. Бу тау турында тирә-як авылларда кызыклы гына легендалар да сөйлиләр.

...Моннан бик күп еллар элек, бу тау башындагы казанда туп-тулы, мөлдерәмә су торган, ди. Шул суда алтын балык йөзеп йөргән. Ә бу су үзе шифалы су булган. Нинди генә авыру белән авырмасын кеше, бу казандагы суны эчсә, шунда ук сихәт таба, авыруыннан арына икән. Шуның өчен бу тауга бөтен Сары-арка җиреннән кешеләр килгән. Алар тауга күтәрелеп, таш казандагы шифалы суны эчкәннәр һәм сихәт тапканнар. Казантауның даны бөтен казакъ иленә таралган. Барлык авырулар шушы сихәт казанына ашыкканнар. Кешеләр күпме генә эчсәләр дә, үзләре белән алсалар да, казандагы шифалы су кимемәгән, һаман тулып мөлдерәп торган. Ниһаять, көннәрнең берендә, монда комсыз бер кеше килеп чыгып, таш казан эчендәге алтын балыкны урларга ниятли һәм казан эченә җәтмә төшерә. Менә шунда казан ярыла да шифалы су да, алтын балык та юк була...

Бәй, легенда белән мавыгып төп сүздән тайпылганмын ич. Нигә мин монда япа-ялгыз каңгырам? Шуны әйтәм диган идем бит. Имәнтау авылында туып үскән Гыйззәт исемле дустым бар минем. Ул соңгы елларда Алма-Атада эшли, әмма һәр җәйне ял итәргә Имәнтауга кайта. Гомумән, Имәнтауга җәй көнне ял итәргә килүчеләр күп була. Күкчәтау өлкәсеннән генә түгел, Омскидан, Томскидан, тагын әллә кайлардан киләләр дә Казантау итәгенә, күлгә якынрак җиргә чатыр коралар. Күлдә — балык. Урманда — җиләк-җимеш. Җәйләүдә — кымыз. Авылда — ит-май. Су. Кояш. Урман. Шифалы саф һава. Моннан артык тагын ни кирәк ял итүчегә. Менә минем дус та, хатыны белән Алма-Атадан килеп, Казантау битенә чатыр корган булган. Бер

атна үтми — артларыннан телеграмма: «Улыгыз авырый, тиз,рәк кайтыгыз». Менә шуңа күрә алар кичә, бик ашыгыч рәвештә, Алма-Атага очтылар. Ә мин фәкыйрегез, алар үтенече буенча, чатыр саклыйм була инде. Менә шуның өчен дә мин ялгыз.

Күлгә житәр алдыннан, яр кырыенда дөя кебек ике үркәчле зур таш тора. Менә шул дөя-таштан сукмак икегә аерыла. Берсе — түбән, күлгә төшә, икенчесе яр кырыйлап уңга, ял итүчеләрнең чатырлары торган якка китә. Менә хәзер, юлымны кисеп, әнә шул чатырлар ягына бер кыз үтте. Уйланып килеп абайламыйча калганмын. Аяк тавышына башымны күтәргәндә, ул инде дөя-таштан борылып бара иде. Нигәдер бу кыз миндә кызыксыну уятты. Үзем дә сизмичә, кызу атлап дөя-таш чатына килеп туктадым. Әнә ул ашыгып, йөгереп атлый, әйтерсең лә болан. Чыннан да, бу кыз буе-сыны белән яшь боланны хәтерләтә. Буйга үзе озын түгел, уртача гына. Чандыр. Аяк балтырлары чарланган орчык кебек. Нәфис, вак сөякле. Әллә кайдан сизелеп тора: спорт белән шөгыльләнеп, артык авырлыгын ташлаган кыз. Ул җиңел-җиңел атлап миннән ераклаша бара. Ә мин һаман аннан күземне ала алмыйм. Дөресен әйткәндә, мине хәзер бу кызның чын гимнасткаларга хас нәфис гәүдәсе түгел, өстендәге киеме гаҗәпләндерә иде. Аның башында ковбойларныкы сыман киң читле камыш эшләпә. Алсу тасма очлары җилфердәп, ялкынланып бара. Өстендәге җиңсез ак ефәк накидка йөгергәндә җилкән кебек кабарып күтәрелә. Урман эчендә, ял иткәндә нигә инде мондый онытылып беткән накидка? Теге «иске көйне яңа итеп әйтәләр Мәрьямнәрдә» дигән җыр сыман, иске моданы яңартудыр инде бу. Эх, кызлар, кызлар!..

Мин сокланып, гаҗәпләнеп торганда, теге накидкалы болан карагайлар арасына китеп тә югалды. Кая ашыга? Баягынак кемдер бөтен урманны яңгыратып аваз салган иде бит, мөгаен, шушы кызны чакырган булгандыр.

Мин күлгә бара торган сукмак белән ярдан түбән төшеп киттем.

## III

Чумып, йөзеп арыгач, чалкан ятып, аякларны сузып җибәреп, кулларны бар колачка җәеп су өстендә тирбәлүгә ни җитә! Бөтен тән, бөтен әгъзалар ял итә. Җылымса йомшак су тирбәтеп иркәли. Күзләрне йомып юри йокымсыраган буласың. Иртәнге кояш нурлары синең битеңнән сыйпый, үбә. Нинди рәхәт!

Шулай су өстендә ятып бераз ял иткәч, тагын йөзеп киттем — утрауга таба. Әнә алда — гранит ярлар. Алар өстендә, канатларын җәйгән бөркет кебек, киң ботаклы, кара-кучкыл карагайлар басып тора. Үзләре якын гына кебек — йөзеп кара! Анда хәтле кимендә өч километр бардыр. Мактанып әйтүем түгел: үзем болай оста гына йөзәм. Әмма утрауга кадәр — булмый. Куркам. Суда аз гына туңа башладыммы, хәзер аякларны көзән җыера. Менә хәзер дә чирканып киткәндәй булдым. Җитәр. Ярга таба борылырга кирәк!

Йөзеп килгән кызулык белән күл кырыендагы сандык таш өстенә шуып чыктым. Таш кайнар мич өсте сыман — кояшта кызган. Сузылып, рәхәтләнеп яттым. Җил юк. Тын. Күл өсте көзге кебек ялтырап күзне чагылдыра. Борылып, кояшка аркан яттым. Нинди гаҗәп тамаша күл төбе. Мамык булып кабарган ак болытлар. Алар өстенә йөз түбән яткан Казантау, карагай урманы, таш кыялар. Ничек соң инде авып су төбенә төшеп китмиләр икән? Гаҗәп! Казантау, карт карагайлар, биек таш кыялар кинәт калтыранып чайкалдылар. Тетрәнеп киттем. Кара, зур бер чуртан күлдән сикереп чыгып, ярым ай булып ялтырады да кире дән суга төште. Күзгә челпәрәмә килеп ватылды.

Алдымда Имәнтау күле җәйрәп ята, диңгез диярсең. Мин яткан гранит ярдан каршыдагы, авыл кырындагы сөзәк комлы ярга хәтле сигез километр булыр. Бу инде — күлнең киңлеге. Ә озынлыгы? Аңа инде күз күреме генә җитми. Ул тау итәге буйлап китә-китә дә офыкка күмелә. Әллә егерме километрга, әллә инде аннан да артыкка сузыла. Баягынак коенганда искә алдым бит: бу күлнең уртасында әле зур гына утрау да бар, озынлыгы өч, киңлеге ярты километр чамасында, диләр анда булган кешеләр. Бик мактыйлар үзен, җиләк-җимешкә, шифалы үләннәргә бик бай, диләр. Бу якта һич күренмәгән артыш агачы да үсә икән анда.

Коенып чыккач, җылы таш өстендә яту җан рәхәте бит. Бөтенләй эреп киттем. Керфекләр үзләреннән үзләре йомылдылар. Дөнья алсу нурга чумды. Әйдә, кыздыр, кыздыр мине, иртәнге кояш!

Күзләрем эленеп бара икән, мотор тавышына чәчрәп торып утырдым. Теге дачниклар тора торган яктан моторлы көймә чыккан — туп-туры утрауга ярып бара. Көймә тулы халык. Шау-шу киләләр, кычкыралар, кемгәдер кул болгыйлар. Әнә, иң алда, көймәнең борынында, зур камыш эшләпәле берәү утыра. Мөгаен, теге дөя-таш чатында юлымны кисеп үткән кыздыр. Әйе, әйе, шул ич. Әнә, эшләпәсендәге кызыл тасмасы ничек ялкынлана. Менә бит ул алтын яшьлек! Син нинди гүзәл, гамьсез һәм шук. Мин сокланам сиңа, яшьлек. Сагынам...

— Яшьлек, күксел таулар тәлле
Киткән саен матур, ягымлы.
Томаннарда калган яшьлегемне,
Мин сагынам кайнар чагымны...

## IV

Һай, мондый да тәмле чәй булыр икән. Эчәм, эчәм, һич тә сусыным басылмый. Менә инде бакыр чәйнек бөкрәя дә башлады. Ә мин тагын ясыйм. Ак таш чәйнекне сөлге астыннан чыгарам да (урап тотсаң, үз буы белән буланып, хуш ис аңкытып пешә бит ул чәй дигәнең) касә төбенә һинд чәен тамызам, бик кара итеп түгел, чамалап кына. Аннан бал кашыгы белән генә каймак төшерәм. Менә шуннан соң гына бакыр чәйнек ходка китә. Сез, бәлкем, каймакка мансаң чабата да үтә, дип мыек астыртын гына елмаерга да җыена торгансыздыр. Башымны кисәргә бирәм: хикмәт һинд чәе белән каймакта гына түгел. Түгел! Нәрсәдә дисезме? Суда, әйе, чәйне кайнаткан суда. Ә менә ул тәмле суны кайдан алганны беләсезме? Мөгаен, белмисездер. Мин үзем дә башта күл суын эчәләрдер дип уйлый идем. Аның суы да йомшак, әйбәт — әмма чәйгә монда башка, махсус су бар икән.

Безнең чатыр артыннан гына тау өстенә таба сукмак үтә. Менә шуның белән барасың да стена булып капма-каршы торган ике таш кыя арасына керәсең. Шул таш коридорның иң түрендә — таш сандык. Шул сандык эчендә терекөмеш кебек ялтырып, нурланып торган су. Үзе салкын, үзе тәмле, лимонадларың бер якта торсын. Күпме генә алсаң да, сандыктагы су кимеми, һаман мөлдерәп тулып тора. Минем бакыр чәйнектә нәкъ менә шушы сандык чишмәдән алынган су инде. Булмаса, тагын бер касә ясыйм әле, нәфес — шайтан, һаман туймый.

— Әссәләмәгаләйкүм! — Сискәнүдән кулымдагы касәм төшеп китә язган иде, кемдер тотып калды.— Гафу итәсез, ага.

Гаҗәпләнеп башымны күтәрдем. Каршымда яшь бер егет басып тора. Ак чалбар, ак майкадан. Уртача буй, чандыр гәүдә, түгәрәк йөз. Чәчләре кап-кара, кабарып тора. Кысык, соргылт күзләр.— Гафу,— диде егет, кабатлап, уңайсызланып,— дәмегездән[1] бүлдем, гой.

[1] Дәм — аш. Казакъ горефе буенча иртәнге дәмгә утырмау, тәм татымау зур гаеп.

— Уйбай, бу ни дигәнегез, егетем? Иртәнге аш, тәм татыгыз.

— Рәхмәт,— дип, егет минем янга, киезгә аякларын бөкләп утырды да дәстарханда яткан бавырсактан берсен алып капты. Мин коеп куйган касәдәге чәйне бер йотып куйды.

— Минем атым — Өметжан. Безнең чатыр монда якында гына.

— Алайса күрше булабыз. Бик әйбәт. Балыннан авыз итегез. Күчтәнәч, Уфадан.

— Хөрмәтегезгә рәхмәт, ага. Ашыгыч бер йомыш белән килгән идем. Юлдашым каекта көтеп тора.

— Йомышыгыз ни, әйтегез. Тыңлыйм, юлдаш Өметжан.

— Без, монда ял итүче бернича егет, сирнәгә баш кушкан идек. Юлдашларым сезне шул сирнәгә чакыруны миңа тапшырган иде.

Мин аптырап калдым. Сирнә — үзара акча кушып, куй алып сую. Шуны ашап, уйнап-көлеп утыру. Мин икеләнә калдым.

— Гафу итегез, энем, ничек инде, мин бит сирнәгә акча кушмадым.

— Уйбай, ага, ни диюеңез? Сирнә — яшьләрнеке. Сез — кунак.— Өметжан аягүрә басты.— Рәхим итәсез, ага. Мин — илче.

Нишләмәк кирәк.

— Рәхмәт,— дидем. Җыена башладым. Чакырганда бармасаң, чакырылуга зар булырсың, диләр бит.

Дәстарханны җыйдык. Учактагы утны сүндердек.

## V

Балтабек, озын буйлы, казакъта бик сирәк очрый торган янып торган кызыл чәчле, ябык, ак йөзле егет, безнең өстәлгә зур табак белән туралмаган, ләкин буынлап бүленгән, әле генә сирнәгә суелган куйның итен китереп куйды. Итнең кисәр кара калҗасы күренми — ап-ак май. (Ничек ашарбыз?!) Шул майлы ит өемендә сап-сары итеп өтелгән куй башы.

Безнең өстәлдә алты кеше: дүрт студент, Өметжан һәм мин. Өметжан үзе Күкчәтау педагогия институтында физика фәненнән укыта икән. Ә бу егетләр — аның шәкертләре. Алар безне утрау ярында ук көтеп торалар иде — хөрмәтләп, сәлам биреп каршы алдылар һәм хәзерләп куелган өстәлгә чакырдылар.

Өстәл дип, монда, күл буенда, нинди өстәл булсын. Калын карагай төбенә күләгәгә клеенка — дәстархан җәелгән. Без аның тирәсендә аякларны бөкләп утырабыз. Бу — беренче өлкән өстәл.

Икенче, кече өстәл — чия куаклыгы артында. Анда хатын-кызлар гына күренә. Ул өстәлгә дә Балтабек бер табак ит алып барып куйды. Болай ике табынга бүленеп утыру миңа һич тә ошамады. Нигә инде бер өстәлгә җыелып, уйнап-көлеп утырмаска? Нибары ун кеше. Үзләре бергәләп ял итәргә, күңел ачарга килгәннәр бит, житмәсә. Ачуым килде, бигрәк тә Өметжанга. Үзе яшь, үзе укымышлы. Ә үзе һаман борынгы гореф-гадәтне куалый. Мондый бүленеп утыруга риза булмавымны белдерим дип тел тибрәтсәм дә, батырып әйтергә җөрьәт итмәдем. Мин — кунак, хуҗаның ишәге. Алар — хуҗа. Өстәл-сый — аларныкы. Гореф — аларныкы.

— Ага, сез безнең өлкән кунак. Бу башны,— Өметжан табактагы куй башын алып минем алдыма куйды,— егетләр сыйлап сезгә осына. Менә пәкегез.

— Рәхмәт,— дип баш идем.

Монда инде карышу ярамый. Баш — ин кадерле сый. Башны кулга алдым да колагыннан, ирененнән калҗалар кисеп әүвәл Өметжанга, аннан егетләргә осындым: — Дәм татыгыз.— Үзем уң колагын кисеп авызыма салдым да башны Өметжанга суздым.

— Кече өстәлгә өлкән дәстарханның сые...

Тагын Балтабек, егетләрнең иң кечесе, сикереп торып, башны хөрмәт белән Өметжан кулыннан алып хатын-кызлар өстәленә илтеп килде. Ул яктан «рәхмәт, рәхмәт» дигән тавышлар ишетелде.
Өметжан белән Балтабек кисәләреннән пәкеләрен чыгарып, ачып, һәрберсе табактан берәр кисәк ит алып турарга керештеләр.
Гаҗәп тәмле, хуш исле булып пешкән. Бу хәтле симез итне ничек ашармын дигән идем — бара икән. Бер калҗа артыннан икенче калҗа, бер кабырга артыннан икенче кабырга китеп кенә тора. Сизми дә калдым — бер табак ит юк булды. Ит артыннан касәләр белән куҗашурпа китерделәр. Тәмләп кенә карыйм дип авызыма алган идем, эчеп бетергәнемне тоймый да калдым — корт изгән ачы куҗә икән. Симез иттән соң күңелне ача бит ул.
Шурпадан соң — кымыз. Май кымызы. Иң татлы, иң шифалы кымыз. Егетләр икешәр касә эчтеләр. Миннән алай ук булмый. Шулай да тагын берәр касә эчәргә ният юк түгел. Өметжан думбыра алып килгән икән, аны кулына алып чирткәли башлады. Дыңгыр-дыңгыр. Тавышы да чыкмый. Әллә инде уйный да белми. Шулай да думбыра тавышы чыга башлагач, кече өстәлдәгеләр безнең янга килделәр. Әүвәле бер-бер артлы дүрт кыз — Кукчәтау педагогия институты студенткалары килде. Тулы гәүдәле, түгәрәк битле, мөлаем гына кызлар. Алар миңа карап «сәламәтсезме» дип баш иеп, яр читенәрәк — таш өстенә утырыштылар. Егетләр шунда ук җанланып алар ягынарак авышты, сүз ыргытышып үзара көлке чыгардылар. Өметжан һаман думбырасы белән маташа — колакларын бора, эчәк кылларны тартып дыңгыр-дыңгыр китерә. Эчем поша башлады — уйный белмәгәч, нигә инде азапларга...
Безнең түгәрәккә иң соңгы кеше булып теге, мин урман эчендә күреп калган эшләпәле кыз килде. Аның иңендә һаман әле шул ук ефәк накидка. Җитмәсә әле, кулларында перчаткалар. Исем китте, шундый җәйге челләдә... Әнә, юка накидка аша күренеп тора — терсәккә хәтле кара-челтәрләнеп торган куллар. Кайдан килгән тутый кош соң бу? Бигрәк тә кыланчык икән. Түгәрәккә җитәр-җитмәс ул, тукталып калып, сүзсез генә миңа баш иде. Нинди зур, мөлдер кара күзләр. Юк, аларда һавалылык, масаю күренми, моң, тирән яшеренгән бер сагыш сизелә. Тукта, кем соң ул үзе? Чегән кызы түгелме? Матур гына туры борын, юка иреннәр, аз гына алга бәреп торган түгәрәк ияк. Карлыгач канаты кебек кыйгачланып күтәрелгән кашлар бөтен йөзгә җитдилек, салмак характерлы булу шәүләсен ташлыйлар.
Мин баягынак ялгышканмын икән, бу яшүсмер кыз түгел, ана, мөгаен, егерме биш яшь, бәлкем аз гына артык тадыр.
— Карлыгач, Карлыгач! — Кызлар берьюлы урыннарыннан кузгалып, бу эшләпәле, сәер киемле кызны үзләре янына чакырдылар.— Кил, үзебезнең янга утырып, думбырага кушылчы, Карлыгачҗан.
Карлыгач, ашыкмый, гәүдәсен бик туры тотып, акрын гына атлап барып кызлары янына утырды, Өметҗанга күз ташлады:
— Гаеп булмасмы?
Бу инде миннән — олы кешедән тартыну һәм рөхсәт сорау иде. Шуның өчен җавапны үзем бирергә ашыктым:
— Ул ни дигәнегез, кызым? Сирнәнең кызыгы уен-көлке, үлән, гой. Әйтегез. Рөхсәт.
Думбыра кылларына җан кергәндәй булды — дерелдәделәр, нечкә һәм калын тавышлар чыгардылар, тынып калдылар, аннан соң миңа таныш булмаган озын бер көй яңгырады. Өметҗанның бармаклары бер өскә, бер аска күчеп эчәк кылларны тибрәтәләр һәм... искиткеч моңлы көй тудыралар. Исем китте. Кара, ничек уйный! Мин юкка аның гөнаһысына кергәнмен икән. Чү! Каяндыр ерактан моң килде, үсте, җыр башланды:

Нигә һаман чырылдап карлыгасың?
Тямим ич мин синең балачыкларыңа,
Нигә миннән ярдәм сорап ялынасың...

Күл өсте яңгырап, яктырып китте. Җыр үсте, күтәрелде, карлыгач уулып очынып, бер иксез-чиксез күккә атылды, бер түбәнгә дулкыннар өстенә ташланды.

...Чит җирләрне син очып араладың,
Балаң өчен күпме тапкыр яраландың.
Инде бераз тынычланчы, карлыгачым,
Нигә һаман чырылдап карлыгасың?

Күл өстендәге тынгысыз-елак акчарлаклар зарлы кычкыруларын оныттылар. Бөтен утрау, тып-тын калып, искиткеч якты, гүзәл җырны тыңлады. Менә кайда икән ул үткән төнне мине йокыдан уяткан, аатырдан алып чыккан һәм кинәт юк булган тылсымлы моң.

...Мин дә беләм аналарның йөрәк серен,
Бала өчен янып-көеп йөрәксүен.
Нигә һаман чырылдап карлыгасың,
Мин дә бит бала бераүгә, карлыгачым...

Карлыгачтан соң башка кызлар, егетләр үләң әйттеләр, думбыра чирттеләр. Тагын кымыз килде. Тагын уен-көлке, үзара (егетләр белән кызлар арасында) җыр белән, думбыра әйтеш — бәйге бәйләнеп китте. Мин бик күп яңа көйләр, җырлар ишеттем.

Кояш Казантау артына төште. Без коенып, хәл җыеп, чәй эчеп бераз ял иткәч, ике көймәгә утырып үзебезнең чатырлар торган ярга таба кузгалдык. Карлыгач башка җырламады. Менә хәзер кайтып барганда, ул көймәнең борынына утырып, баеп барган кояшка карап уйга калды. Ләкин аның тавышы, моны һаман минем колакта яңгырап, күңелемдә нур булып яктырып, балкып торды...

## VI

Мин әле йоклап ята идем, Өметҗан килеп уятты:
— Ага, тормыйсызмы, кичәге вәгъдә кайда?
— Уйбай! — дип сикереп тордым.— Онытып та җибәргәнмен ич.
Мин: «Чәй кайнатып, чәй эчеп китик»,— дигән идем, Өметҗан: «Хәзер әле ашыйсы килми, ярты юлда тукталып йөрәк ялгарбыз, мин аны-моны алдым»,— диде. Чыннан да, аның җилкәсендә — туристлар сумкасы. Күрәсең, буш түгел.
Киттек. Кичә утрауда йөргәндә, Казантау түбәсенә күтәрелсәк әйбәт булыр иде, дип сөйләнгән идем. Уен-көлкегә алданып Өметҗанның тәкъдименә колак салмаганмын, ахрысы. Юкса, йоклап ятар идемме соң. Ярый әле, Өметҗан онытмаган, сүзендә торып килгән.
Имантау урманы артыннан кояш күтәрелә. Кошлар сайрый. Хуш ис. Рәхәт. Нинди рәхәт! Бер кайгы, бер хәсрәт юк — бары тик сөенеч кенә. Якты, канатлы сөенеч... Яфраклар өстендә терекөмеш булып чык тәгәри — таң шәрабы, бөгел дә эч. Менә шушыдыр инде ул кешеләр гасырлар буенча эзләгән су, мәңгелек суы...
Сукмак һаман югары күтәрелә. Өметҗан алдан бара, мин арттан. Кайда карагайга ябышып күтәреләм, кайда Өметҗан кулын суза. Шулай бара торгач, бер вак куаклыкка килеп чыктык. Унда — берсе җилкәсенә берсе баскан кыялар, баганалар һәм таш хәрабәләр. Сулда — яр, җәһәннәм чокыры, төбе күренми. Менә шушы тыкрыкта — карлыганлык.

жәп. Бер куакта — яныпторган кызыл карлыган. Ә шуның янында уқ икенче куаклыкта — күз кебек мөлдерәп торган кара карлыган. Иң эреләрен генә чүпләп авызга салабыз. Ә менә өзелми калганнары бигрәк тә эре, пешкән — авызга үзе тамам дип тора. Бара торгач, бер таш арасында янып торган кура җиләгенә килеп чыктык.

— Ага! — ди Өметҗан, сөенеченнән нишләргә белмичә.— Караңызчы, малинаның оясы, гой. Инде авыз ачарга була, сусын канып. Утырыгыз.

Ул үзе бер куак астына чүгәләп утырды да кып-кызыл кура җиләкләрен авызына сыдырып кына төшерә. Мин дә икенче баштан утырдым. Сусаган идем... Кура җиләгеннән дә татлы җиләк бар микән дөньяда! Авызга төшүгә эреп китә.

Кояш кыздыра башлады. Тирләдем. Күләгәгә ятасы килә — арылган. Көч-хәл белән нәфесне тыеп, яр кырыендагы бер таш күләгәсенә килеп утырдым. Ботинкаларны, оекларны салып кояшка ташладым. Кипсеннәр. Кара, тубыктагы тамырлар ничек кабарган.

— Ага, су эчеп корсак тулмас, ия? — дип, Өметҗан минем янга килеп утырды.— Инде бер аукатланып алыек.

— Мин каршы түгел.

— Алайса, аллага тапшырдык...— дип елмаеп, Өметҗан сумкасын актара башлады.

Иң элек термос чыгып утырды. Мөгаен — чәй. Аннан — ике төргәк. Болары ни? Мин күрәзәчелек иткәнче, Өметҗан төргәкләрне ачып җибәрде. Берсендә — өрек шикелле вак, сап-сары итеп майда кыздырылган бавырсак, икенчесендә — бер бөҗра колбаса. Өметҗан алдына газета җәйде дә теге колбасаны турый башлады — тәгәрмәчләр тәгәри. Кара-кучкыл каклаган ит һәм гәрәбә кебек сары май. Хуш ис аңкый, төтен катыш, ниндидер аппетит кузгата торган тәмле ис.

— Алыгыз, ага, үзебез симертеп суйган җылкының чожыгы.

Нәфесне тыя алмадым — бер тәгәрмәчне авызга салдым. Май эреде дә китте. Ә ите, чак кына төтен исе сеңгән, каклаган симез ит чәйнәгән саен татлылана. Телеңне йотарсың.

— Инде кымыз эчеңез, чожык белән кымыз иң әгълә авкат, гой, ул, ага.

Өметҗан термосны ачып ике кечкенә касәгә кымыз коя башлады. Минем чәй дигәнем кымыз булып чыкты. Бигрәк тә яхшы. Үзе салкын, үзе әчкелтем — борынны ярып керә. Юкка гына казакълар аны русларга шампан дип тәкъдим итмиләр. Каклаган симез чожык ашыйбыз да кымыз эчәбез. Менә кайда икән ул тәгамнең асылы.

Ашап-эчеп туеп, сузылып ятып бераз хәл дә җыеп алгач, тагын тауга күтәрелә башладык. Өметҗан җиңел бәдәнле, ташка ябыша да мәче кебек үрмәләп менеп тә китә. Мин алай җитез үрмәли алмыйм шул. Я киртләч почмак эзләргә, я Өметҗанның кулын котәргә туры килә. Бер текә, биек кыяга менәбез дә, инде җиттек дисәк, алдыбызда тагын да текәрәк, биегрәк кыя тора. Тагын үрмәләргә тотынабыз. Иллә кыен да, куркыныч та икән бу кыяларга-тауларга күтәрелүе. Ләкин чигенү юк. Читен булган саен дәрт көчәя, азарт туа. Яңа сиздем тауга күтәрелүнең тәмен. Менә ни өчен альпинистлар үлем куркынычы астында тауга үреләләр икән. Азарт, азарт!

Казантауның урта биленә килеп җиттек дигәндә, каяндыр еракта тонык кына бер гөрелдәү ишетелде. Мөгаен, геологлар берәр шурф шартлата торганнардыр дип игътибар итмичә, киез өй кебек түгәрәк бер ташның түбәсенә үрмәли башладык. Гөрелдәү якынаеп кабатланды, бу юлы көчлерәк һәм озаграк булды. Аннан кинәт Казантау бөтен кыялары, урманнары белән бергә чайкалып китте дә, ниндидер башка тауларга сугылды һәм бөтен дөньяны дер селкетеп шартлады. Яңгырау

белмибез. Ул арада яңгыр ява башлады. «Киез өй»нең астында, чыннан да, зур куыш бар икән, шунда яшерендек.

Тирә-як томаланып, караңгыланып китте. Яңгыр көчәйде, чиләкләп койган кебек туктаусыз түгә башлады.

— Карлыгач Имәнтауга киткән иде, бу яңгырны юлда очратмаса ярый инде,— диде Өметҗан пошынып, куышка кереп утыргач.

— Кайчан китте соң ул?

— Иртән минем белән бергә торды. Мин сезгә, ә ул — авылга.

— Куркыныч юк, әллә кайчан барып житкәндер, бигрәк тә Карлыгач. Ул очып кына йөри, бигрәк җиңел гәүдәле бит ул.

— Анысы алай да...— диде күршем. Әллә минем сүзне дөресләде, әллә инде үзенекен... Аннары ул кесәсеннән папирос чыгарып кабызды. Тәмәке тартуын беренче күрәм. Сорау бирмичә булдыра алмадым:

— Өметҗан, сез тартасызмыни?

— Эч пошканда...

Ул папиросны берничә суырды да уйга калды.

Кичә студентлардан ишеткән идем, Карлыгач Өметҗанның тормыш иптәше икән. Шулай булгач, аның борчылуы бик табигый. Житмәсә, яңгыр буранлап-буранлап ява. Куыш алдындагы агачлар да күренми башлады.

— Борчылмагыз, Карлыгач яңгырга гына җеби торган кыз түгел ул.— Сүзне тагын ялгап җибәрер өчен бер папирос та сорап алып кабыздым. Мондый вакытта парлап тартсаң ничектер күңеллерәк була бит ул.— Карлыгач миңа бик ошады, сылу кыз, тавышы нинди матур! Бик моңлы җырлый икән... Сорыйм микән, сорамыйм микән? — дип аз гына тынып, икеләнеп тордым. Ярар, ятып калганчы атып кал.— Өметҗан, гафу итегез, бер соравым бар иде, гаеп булмас микән?

— Бу ни дигәнегез, ага? Сорагыз. Сорауда гаеп юк.

— Бу инде кешенең шәхси үзенчәлеге. Карлыгач миңа бик ошый. Ләкин... ләкин мода белән артык мавыга, ахрысы...

— Нигә алай уйлыйсыз, ага?

— Ничек инде... Менә, әйтик, урманда, табигать кочагында накидкадан, перчаткалардан йөрү.

Өметҗан сискәнеп, калтыранып киткәндәй булды. Әллә инде шулай тоелды гынамы? Башын түбән иде. Сүнгән папиросын кабызып берничә тапкыр озак-озак итеп суырды.

— Ага,— диде Өметҗан, миңа һич тә таныш булмаган калтыраулы тавыш белән.— Карлыгачның алай киенүе мода имәс, киресенчә, өлкән трагедия...

## VII

— ...Карлыгач белән танышуым үзе кызык кына булды. Ул елны мин әле Алма-Ата пединститутының беренче курсында гына укый идем. Кышкы каникулда аталарыма — Кушкарбайга кайттым. Сез, ага, безнең авылны беләсез, гой. Ул моннан ерак түгел, Зирәнде районында. Гаҗәп гүзәл җир. Тау. Урман. Агып яткан болак. Врачлар үзләре миңа шундый җирдә ял итәргә кушканнар иде. Сәбәбе — неврастения белән авыруым. Мөгаен, бик арыганмын. Әүвәле конкурслы экзамен. Аннан, укый башлагач, башкалардан калышмыйм дип баш күтәрми уку. Арыйм. Күзләрем йомыла. Йокы баса. Ятам, ләкин йоклый алмыйча төн буена аунап чыгам. Иртә белән, йокламаганга, баш чатный. Чынлап авыру басты. Менә шуның өчен авылга кайту белән чаңгылар сатып алдым да, таудан тауга йөреп, чаңгы шуа торган булдым. Ялгыз гына. Ул гиздә казакъ егетләре чаңгыга якын да килмиләр иде. Аларга — ат, бәйге, кыз куу булсын.

текә. Көчкә-көчкә менәм. Ә аннан төшкәндә... чаңгылар бер якка, үзем икенче якка... һич туры гына торып шуып төшә алмыйм бит — тәгәрим. Ачуым килеп бетте. Җан тиргә төштем. Ә күңел — батыр, инде менсәң обязательно шуып төшәсең, егылмыйсың, ди. Котырта. Тагын тауга күтәрелдем. Шуып киттем. Очам. Очам! Инде юлга чыгам дип куанганда гына кадалып барып төштем — көрткә кереп киттем. Берничә минут тын ала алмыйча хәлсезләнеп яттым. Бераздан кузгалдым. Торырга телим, булмый. Шулай азапланып ятканда, арттан берәү килеп күтәреп торгызды.

— Бер җирегез авыртмадымы, егет?

Күтәрелеп карауга, оятымнан җиргә инеп китәрдәй булдым. Тәнем бер туңып, бер кызып китте. Каушамаслык та түгел бит. Нинди оят! Алдымда яшь кенә бер кыз басып тора. Үзе миңа карап аз гына көлемсери. Чаңгыда йөри торган костюмнан. Якында гына чаңгылары ята.

— Бер җирегез сынып калмадымы, батырым? — дип пырхылдап көлеп җибәрде теге кыз. Камчы белән суккандай булды. Бу усал кызга сугып җибәрәсем килсә дә, тыелып калдым. Бер сүз дә әйтмәдем, чаңгыларга бастым да бар көчемә шуып авылга таба киттем.

Икенче көнне мин ул кызны тагын шул тау битендә очраттым. Ачу бераз кайткан иде, исәнләштем. Сораштым. Аты — Карлыгач. Атасы — Ватан сугышында вафат. Анасы белән генә тора икән, Күкчәтауда. Безнең авылга бер туганына кунакка дип килгән. Карлыгач хәзер Күкчәтау медучилищесының соңгы курсында укый икән. Спорт ярата, бигрәк тә йөзүне, йөгерүне. Кышын сөйгәне — чаңгы.

Ул көнне без кичкә кадәр бергәләп чаңгы шудык. Икенче көнне тагын. Шулай мин киткәнче. Дөресен әйткәндә, бергә йөрсәк тә, миндә аңа карата нindидер бер көнләшү туды. Мин аны күралмый башладым. Ни өчен диярсез. Әйтергә уңайсыз. Ихлас күңелдән йөрәгемне ачканга гафу итәсез, ага. (Мин, әңгәмәне бүлдермәс өчен, сүзсез генә баш иеп: «Рәхмәт, дәвам итегез» дим ымладым.) Карлыгач мине, егет кешене, егылып яткан җирдән күтәрде. Карлыгач чаңгыда миннән яхшырак шуа. (Таудан ук кебек атылып төшә — егылмый.) Карлыгач — сылу. Менә нәрсә өчен мин аны күралмадым. Бу — эгоизм. Ләкин нишләтим. Ул вакытта шулай булды, яшерә алмыйм. Күрәсең, егет намусы кызлар алдында аунап ятуны күтәрә алмады.

Каникул срогы бетеп, инде иртәгә Алма-Атага китәм дигән көнне без бик озак шудык. Ай күтәрелде. Таулар, урманнар күгелҗем нурга күмелеп серле бер тынлыкка баттылар. Мин гарьләнүдән кара тиргә батып тырыштым — Карлыгачтан калышмый башладым. Ә менә таудан... һаман барып чыкмый. Инде хәтәрне үттем дигәндә генә... чәнчелеп барып төшәм бит.

Менә бер тапкыр Карлыгач тау итәгендә калды, ә мин югары күтәрелдем. Туктап хәл җыйдым. Чаңгыларга бастым, «я алла!» дип киттем. Очам! Очам! Урманны узып киттем. Юлга барып чыктым. Егылмадым бит. Авыз колакка житте. Ашыгып, сөенеп, Карлыгач басып калган җиргә килдем. Юк, тирә-якка карыйм — күренми. Кычкырам — җавап юк. Курыктым — әллә инде бүре алып киттеме? — дим. Ашыгып, чаңгыларны урман эченә таба бордым.

Урман кырыенда — ялгыз карагай. Карлыгач шул карагайга сөялгән дә башын түбән игән. Якынрак килдем — кызның иреннәре дерелдәп, сикереп-сикереп китә. Инде якын ук килгән идем, аптырап калдым. Карлыгач үксеп-үксеп елый. «Ни булды?» — дим,— дәшми. «Берәр җирең авырттымы?» — дим,— җавап юк. Үзе һаман елый. Нишләргә белми аптырап торганда, Карлыгач кинәт, тиз генә чаңгыларына басты да авылга таба атылды.

Икенче көнне мин юлга кузгалдым.

— Юк. Күңелем кеткән иде килер дип... килмәде. Тәкәббер кыз.

Шушы китүем белән Карлыгачтан бөтенләйгә киттем дип уйлаган идем мин. Алай булып чыкмады. Кызык. Үзем әчтән аны сүгәм, яманлыйм. «Институтта синнән сылу, синнән акыллырак кызлар тулып ята. Исем киткән сиңа!» — дим. Ә күңел нигәдер сызлана, кемнедер эзләп юксына. Кайчак урамда барганда аны уйлап кешеләргә сугылам. Кайчак лекция барганда аны күз алдына китереп онтылам да, мөгаллимнең соравын ишетмичә көлкегә калам. Күпме чыгымласам да булмады, Күкчәтауга хат язарга туры килде. Билгеле инде, үземнең хыяллануларым турында ләм-мим юк. Ничек инде ул тәкәббер алдында егет башын белән тезләнәсең?!

Икенче җәйне мин тагын Кушкарбайга кайттым. Күкчәтау якын, ике арада автобус йөреп тора. Карлыгач белән очраштым. Ул, инде училищены тәмамлап, Кызылтау район больницасына эшкә килергә тора икән. Үзегез беләсез, агай, Кызылтау Күкчәтаудан өч йөз километр ары, ай-далада яткан караңгы район. Анда авыл арасы ерак, кимендә йөз-йөз егерме километр. Ул якта күбрәк мал-куй совхозлары. Малчылар күчеп йөри. Мин кайтып житмәдем, аны районга китәргә ашыктыра башладылар. Билгеле инде, медперсонал житешми, бигрәк тә ул вакытта. Яшь кадрлар ул якка әйләнеп тә карамыйлар, ә Карлыгач шунда барырга ризалык биргән. Яхшылык белән дә, яманлык белән дә әйтеп, анда барудан баш тартуын сорадым. Булмады. Кире бит. «Мин дә бармасам, кем бара?! Оят бит»,— ди. Тәки үзенең кирелеген итте, китте бит шул җәһәннәм чокырына, Кызылтауга.

Ул елгы кыш чатнама суык булса да, безнең хатлар көннән-көн жылырак була башладылар. Да, ага, мин сезгә тагын бер детальне әйтергә оныткамнын икән. Хәтерлисезме, Карлыгачның ялгыз карагайга сөялеп елап торуын. Менә шул турыда сорап язган идем мин аңа. Беләсезме, ничек керпе кебек кадалды ул миңа. «Егет, имеш, кызларның ни өчен елавын да төшенми»,— дип язган. Ә хатның икенче битендә вак кына хәрефләр. Көчкә укыдым. «Синнән аерылуга жыладым, сәүләем»[1] дигән...

Кинәт безнең куышка атылып кояш кергәндәй булды. Ялт итте. Күзләр чагылды — йомдык, инде күзләрне ачсак — дөм караңгы. Берберебезне күрмибез. Мин күзләремне уып куышның ишегенә таба авышкан идем — жиргә сеңеп киттем. Әйтерсең лә тирә-яктагы барлык таулар жимерелеп безнең өскә төштеләр. Колаклар тонды. Ингемингә булып киттем. Ул арада жил борылып, янгыр куыш эченә камчылый башлады. Куышның түрәнәрәк күчеп утырырга туры килде. Ничектер таралып калдык. Сүз ялганмады. Өметжан папирос кабызды — озак-озак итеп суыра. Папирос көйрәгән яктыда аның йөзе чагылып кала. Караңгы чырай, бер ноктага төбәлгән хәрәкәтсез күзләр. Маңгайда жыерчыклар. Борчыла. Өзелгән әңгәмәне ничек итеп ялгап жибәрер икән? Бу изге, беренче мәхәббәтнең алдагы битләрен дә ачасы килә бит.

Ниһаять, Өметжан папиросын тартып бетерде. Мин түзмәдем — сорау бирдем.

— Ничек, шуннан соң өйләнештегезме?

— Юк, ага, безнең өйләнешү башкаларныкы шикелле булмады шул,— диде Өметжан, авыр сулап. Өстемә салкын су койгандай калтыранып киттем. «Нигә мин кешене азаплыйм?» Әмма бераз тынып уйга калып торганнан соң, Өметжан үзе сүзен ялгады: — Сөйләве дә авыр. Ни кыласың, башлагач аяклау кирәк. Өченче язда миңа Карлыгач белән очрашырга туры килмәде. Мин Күкчәтауга кайтмадым

[1] Сәүләм — сөеклем.

бөтен курс белән. Билгеле инде, ялгызым гына аерылып калу — оят. Икенчедән... Нисен яшерәсең, костюм да, пальто да тузган иде. Дөрес, әүвәле, «кайтмадың» дип үпкәләп, Карлыгач хат язудан да туктады. Ләкин соңыннан төшенде, ахры, минем хәлне. «Ярый инде, алайса, кышкы каникулда кайтырсың»,— диде. Килештек.

Көз җитте. Тагын уку башланды. Мин инде дүртенче курс студенты. Өстә ярыйсы ук костюм, пальто. Яңа ботинкалар. Инде Карлыгач янына кайтсаң да йөз кызарырлык түгел. Тик менә каникул тизрәк җитсен иде. Ашкынып көтәм каникулны. Ул арада кинәт Карлыгачтан хат килми башлады. Гадәттә, аена ике, кайвакытта өч хат килә иде. Ә менә декабрьда — берәү дә юк. Яңа ел котлап җибәргән открыткам да җавапсыз калды. Аптырадым. Башка әллә нинди уйлар килә. Бәлкем, ул башканы тапкандыр. Күпме көтәргә була?.. дим. Бәлкем, авырып калгандыр, дим. Вообщем, кырык төрле уй — баш катты. Нишләргә дә белмим. Уку туарылды. Ахырында, апам авырый дип ялганлап, деканга гариза яздым да, биш көнгә отпуск алып, әүвәл Күкчәтауга, аннан Кызылтауга очтым. Күкчәтауда үзебезнең туышларга да туктамадым... Ашыктым. Йөрәк нидер сизә, ярсый, җилкенә.

Кызылтауга кояш баеганда килеп төштек. Адрес буенча Карлыгач торган өйне эзләп киттем. Авылның иң читендә икән, карга бата-чума көчкә барып кердем. Өй буп-буш. Салкын. Почмакта көпегә уранып бер хатын ята. Сәламемә сискәнеп башын күтәрде.

— Уйбай! Карагым, Өметҗаным... кайдан сине тәңрем алып килде...— дип такмаклап елап килеп, кочаклап алды. Башта танымадым. Соңыннан тавышыннан төсмерләдем. Карлыгачның әнисе Көмеш апа икән. Ябыккан, картайган. Исем китте.

— Апа, сезгә ни булды? Тынычланыгызчы.

Ул ярсып китте — акырып елый башлады. Шулай да бераздан күзләрен кимәгәченең итәге белән сөртеп елаудан туктады. Мин, гореф буенча, өлкәннәрнең аманлыгын сорап, сәлам әйткәннән соң гына Карлыгачның атын атадым. Көмеш апа тагын үкереп елап мине кочаклады.

— Балам!.. Карагым, син инде Карлыгачҗанны эзләмә... Тәңрем, нигә минем җанымны алмадың...— дип ходага ялварып, кулын сузган килеш, хәлсезләнеп авып төште. Озак тынсыз ятты. Аннары акрын гына күтәрелеп, тагын мине кочаклап такмаклый башлады.

— Инде ни кылыем, ходаем... Канаглары сынды, гой, Карлыгачымның... Канатлары...

Көмеш апа: «Уф!» — диде дә урынына шуышып барып, көпесенә уранып ятты. Минем кабат-кабат биргән сорауларыма җавап кайтармады. Мин аптырадым. Нәрсә булган Карлыгачка? Әллә инде үлгәнме?! Кемнән белергә? Әнисе инде сөйләшүдән калган. Ни булса да Карлыгачның эшләгән җиренә барыйм, бер хәбәр әйтерләр дип, больницага киттем. Анда мин, ага, коточкыч хәбәр ишеттем.

Яңгыр һаман шыбыр-шыбыр ява, туктамый. Ләкин элекке кебек камчылап түгел, сибәләп кенә ява. Каядыр еракта күк күкрәгәне ишетелде дә тынды. Өметҗан бер нәрсәгә дә игътибар итми — башын түбән игән дә уйга чумган. Сын төсле хәрәкәтсез утыра. Ниһаять, уянды.

— Менә нинди фаҗигале хәбәр ишеттем мин, ага, ул төнне,— Өметҗан тавышына охшамаган тоник, бәгыреңә боз булып сугыла, өшетә торган суык тавыш килде колакка.— Бу хәл яңа ел алдыннан 31 декабрьда була. Ерак даладагы бер авылдан бер хатынның бәбәйли алмавы, «ашыгыч ярдәм» кирәклеге турында телефоннан шалтыратып әйтәләр. «Башка врачларның гаиләләре бар, яңа елда өйдә булсыннар. Син әле яшь, сиңа кайда да кызык, үзең генә барып кил инде, кызым»,— ди баш врач Карлыгачка. Билгеле инде, ул карышмый,

тиз кичкә авыша. Ул арада кар явып, буран күтәрелә. Шофер бу якка күптән түгел генә килгән яшь кеше була, юлны югалта. Адашалар. Уралып йөри торгач, бензин да бетә. Машина буранда, ай-далада туктап кала. Шофер түзми — авыл эзләп китә. Озакламый аның артыннан Карлыгач та чыга. Иртәгесен Карлыгачны авыл янындагы көрт эченнән казып алалар. Аның ике кулы өшегән була. Карлыгачны киредән шушы ук больницага китерәләр һәм ике кулының да бармакларына ампутация ясыйлар. Күпме генә ялынсам да, врачлар мине Карлыгач янына кертмәделәр: «Авыру рөхсәт итми»,— диделәр. Мин ул төнне шул больница коридорында йөреп уздырдым. Карлыгачка озын итеп хат яздым, белгән киңәшләремне әйттем, күңелен юатырга тырыштым... Ә үзем үземне тота алмыйм,— янам, көям, калтыранам. Иртән өлкән врач килде, мине тынычландыргандай булды. Билгеле инде, тыштан гына сүрелгәндәй булдым. Ә йөрәк әрни, сызлана, ярсый, тыпырчына.

Алма-Атага кайткач, мин Карлыгачка атна саен бер хат язып, китаплар җибәреп тордым. Ә аннан бер җавап юк — әйтерсең лә суга ташлыйм — бер тавыш ишетмим. Укуның да рәте китте... Үзе соңгы, диплом яклый торган ел бит, бәхетсезлеккә каршы.

Җәйге каникулда мин Кушкарбайга кайттым. Тагын неврастения... Авылда кымыз эчеп хәл җыйгач, Кызылтауга барырмын, дидем. Авыру килеш ничек барасың анда. Мондагы бер куанычым — Карлыгач белән чаңгы шуган җирләргә бару иде. Кайвакытта тау башында кояш баеганчы утырам — аның белән сөйләшәм кебек...

Бер көнне шулай тау араларында озак кына йөрдем дә кичкырын гына кайтырга борылдым. Йөрәк сикерә. Күңел ярсый. Әллә нишлисе килә... Бер йөгерәм, бер туктыйм. Читтән бер кеше күрсә, бу акылдан шашкан, дияр. Менә шулай саташып килә торгач, урман кырындагы ялгыз карагайга якынлаштым да кадалган кебек туктап калдым. Агач төбендә берәү утыра сыман. Тагын бер-ике атладым, җентекләбрәк карадым — утыра. Хатын-кыз. Башында зур камыш эшләпә. Өстендә — зәңгәр балоний плащ. Кем булыр? Йөрәк дерт итеп китте. Акрын, бик акрын атлап якынлаштым. Бу ни бу? Әллә инде күземә күренә. Сулыш алудан туктадым. Карлыгач! Йөгереп килеп, артыннан ике кулым белән күзләрен кыстым. Ул, «ах!» дип, куркып-сикереп торды. Мин кулларымны җибәреп, алдына чыктым.

— Курыкма, Карлыгачҗан, бу — мин.

Ул кычкырып җибәрде:

— Өметҗан! — Күзләреннән мөлдерәп яшь коелды.

Мин шашып нәрсә әйтергә белми торганда, Карлыгач кинәт борылды да авылга таба йөгерде. Мин аның артыннан чабам:

— Карлыгач! Карлыгачҗан, тукта! Тукта!..

Ә ул артына да әйләнеп карамады, туктамады, авылга кереп югалды.

Шул китүдән Карлыгач бер атна күренмәде. Мин һәр көн тауга бардым. Көттем. Эзләдем, бәлкем, килеп чыгар дип өметләндем. Ләкин ул килмәде. Ул торган өйгә, туышларының өенә барырга кыенсындым. Кеше алдында куып җибәрсә, яки еласа...

Беркөнне мин Күкчәтауга бардым. Үзебезгә кайта торган автобуска соңга калып, Зирәнде автобусына утырдым да Лавровкада төшеп калдым. Аннан Кушкарбайга ерак түгел, бер өч километр чамасы гына булыр. Җәяү киттем. Менә шунда юл чатында көтмәгәндә Карлыгачны очраттым. Ул Зирәндедән кайтып килә икән. Икәү бергә киттек. Әүвәл бераз сөйләшмичә, гаепле кеше кебек, алдыбызга гына карап бардык. Башлап китүе читен. Шулай да мин тәвәккәллек иттем. Ниһаять, менә

сөйләштек-серләштек.

Шул көзне мин аны, Алма-Атага алып килеп, кызлар пединститутының тарих факультетына укырга урнаштырдым.

Билгеле инде, Карлыгачка институтта уку җиңел булмады. Әүвәл кулсыз булуыннан кимсенү, оялу. Аннары, иң газаплысы — яза алмау, лекцияләрне конспектлаштырып бара алмау. Берничә тапкыр елап, укуны ташлап китәргә дә җыенды ул. Рәхмәт, курсташ кызлары булышты — аның өчен язып бардылар. Аның өйгә бирелә торган эшләрен бергәләп хәзерләделәр. Ә икенче курска күчкәч, институттагы барлык студентлар акча җыеп портативный язу машинасы алып бирделәр. Карлыгач, тырнаклары, иптәшләре йоклагач, уң кулында калган ярты бармак белән машинкада басарга-язарга өйрәнә башлады. Тырыша торгач, өйрәнде бит.

Былтыр Карлыгач шул институтны тәмамлап Күкчәтауга килде. Хәзер ул каладагы урта мәктәпләрнең берсендә тарих укыта...

Без куыштан чыкканда яңгыр туктаган, болытлар таралган иде. Билгеле инде, хәзер Казантауга күтәрелү һич мөмкин түгел — юеш, аяк тая. Көн дә кичкә авышып бара. Өметҗан һаман әле Карлыгач өчен борчыла. Шуның өчен, тауга күтәрелүне башка көнгә калдырып, хәзер кире, үзебезнең чатырларга таба борылдык.

Яңгырдан соң — кояш... Нинди матур! Бөтен тирә-як — агачлар, куаклыклар, таш кыялар яшәреп, ялтырап киткәннәр. Ә һава, һава! Тәмле, рәхәт, исертә торган хуш ис! Әнә безнең алда — урман өстеннән аллы-гөлле салават күпере төшкән. Ул бер офыктан башланып икенче офыкка хәтле сузыла. Нур чәчеп, балкып тора! Ни өчендер, бу күпер миңа Өметҗан белән Карлыгачны кавыштырган бәхет күпере булып тоела. Хәзер менә алар җитәкләшеп шул тылсымлы күпер өстенә күтәрелерләр кебек. Алар менә-менә хәзер елмаеп килеп чыгарлар сыман.

— Хәерле юл! Бәхетегезгә ашыгыгыз! — дип кычкырасым килә минем аларга. Ә салават күперенең аллы-гөлле басмалары тагын да ялтырак, матуррак булып яналар, бәхет-сөенеч нуры белән балкыйлар.

## VIII

Кичен күлгә төшеп коенып кайттым да йокларга яттым. Көн буенча йөрү — тауга күтәрелү арыткан икән, ятуга күзем элene башлады. Ләкин торып утырырга туры килде.

...Җәйге көндә балкыган
Яшькелт келәм — җир сылу.
Аккош йөзеп туймаган
Айдай нурлы күл сылу.
Башкалардан иң сылу
Гомерлек дус, тиң сылу.
Барыннан да син сылу,
син сылу...

Карлыгач тавышы! Никадәр моң, никадәр нур һәм самими, керсез сөю бу илаһи тавышта...

Нурын түгеп далага
Туып килгән көн сылу.
Җемелдәгән йолдызлы
Зәңгәр күкле төн сылу.
Башкалардан иң сылу
Гомерлек дус, тиң сылу.
Үзем сөеп яраткан
Барыннан да син сылу,
син сылу...

Жыр ераклашты. Ә минем күз алдымда һаман Карлыгач белән Өметҗан тора. Алар житәкләшеп салават күпереннән жиргә төшеп килэләр кебек... Менә ул фажигале язмышны жиңәргә, күтәрелергә көч биргән изге дуслык һәм олы мәхәббәт! Мин сокланам сезгә! Мин баш иям сезнең алда! Ә жыр тагын якынлаша...

Икенче көнне, бер дә көтмәгәндә, миңа Өметжан белән Карлыгачтан аерылырга туры килде. Үзләренә иялэшеп кенә беткән идем. Кызганыч!

Нишлисең, Карлыгач ашыга. Ашыгырлыгы да бар шул, яңа эш көтә аны. Сөенеч! Ул Күкчэтау пединститутының аспирантурасына керү өчен конкурс-имтихан үткән булган. Кичә ул Имәнтауга барганда институттан аспирантурага алынуы һәм тиз арада деканатка килергә тиешлеге турында рәсми белдерү-чакыру алган.

Мин озатырга дип килгәндә, алар инде китәргә тәмам хәзерләнеп беткәннәр, такси «Волга» аларның утыруларын гына көтеп тора иде. Икесе дә мине сәламләп каршы алдылар. Өметжан юл аякка бер шампанский ачты, дөресрәге — шартлатты, шәрабның яртысы диярлек ташып түгелде. Мин аны Карлыгачның алда бәхете ташуга, фән өлкәсендә уңышларга ирешүгә юрадым. Ул оялып кына: «Рәхмәт»,— диде.

Иң читене машинага утырыр алдындагы соңгы минутлар булды. Өметжан минем ике кулымны учлап кысып хушлашты. Карлыгач аз гына миңа таба атлады да тукталып калды — күзләрен тутырып карады. Зәңгәр накидка эчендәге кара ефәк перчаткалы куллар калтыранып киткәндәй булды. Карлыгач башын акрын гына түбән иде, эшләпә кыреннан төшкән кызыл ефәк тасмалары жилфердәп ялкынланып китте.

Рафаил Төхфәтуллин

# КОЯШНЫ ЮЛЛАРДА КАРШЫЛАП...



Шундый чаклары була аның... Тормышта, эшендә бик тә пөхтә, бик төгәл Әдибебез бер заман, ничектер, таркауланыбрак китә. Бөтен иҗаты, табигате белән оптимист шагыйрь авызыннан моң-зар да ишетелгәли башлый. Болай да какшаган сәламәтлеге борчый икән моны. Врачлар фәлән-фәлән дарулар, уколлар язып биргәннәр икән дә... Шайтан алгырысы, күбесен аптекалардан табып булмый икән. Шунда, сүз арасында, «бер дә язып булмый әле бу көннәрдә» дип тә әйтеп куя. Без аның мондый халәтенә җитдирәк игътибар итәргә дә өлгермибез, ул арада Әдибебез күзгә-башка бөтенләй дә күренмәс була. «Бикләнеп торып язарга утырдымы бу, әллә чынчынлап авырып киттеме» дисәк, юк икән... Әлеге табылмас дару-уколларга, тормышның эреле-ваклы борчу-мәшәкатьләренә кул селтәгән дә каядыр юл-сәфәргә чыккан да киткән егет.

Юл-сәфәр дигәче кайвакыт әллә ни ерак та булмый. Тирә-яктагы авыллар, буровойлар, скважиналар. Әмма шактый ерак юллар да һич әркетми шагыйрьне. Үзенең туган-үскән Башкортстан якларына юл тота, Татарстаннан китеп, Себер нефтен үзләштереп йөрүче якташларыбыз янына — ерак Лена буйларына барып чыга. Ә бервакыт Әдибебез «дөнья читенә» — Сахалинга кадәр үк китеп барды. Анда ул армиядә хезмәт иткән, Көньяк Сахалинны япон империалистларыннан азат итү сугышларында катнашкан. Әнә шул яклар, үзенең яшьлек эзләре сеңеп калган җирләр сагындырган икән шагыйрьне.

Шушындый юл-сәфәрләрдән тәмам үзгәреп кайта ул. Аяк атлаулары үк җиңеләеп киткән моның, гадәттәге җитди-уйчан йөзеннән шат елмаю китми. Барыннан да күңелләрәге — гадәттә сүзгә алай бик юмарт булмаган Әдипнең сөйләп һич сүзе бетми.

Сөйли шагыйрь. Кече күңелле, олы йөрәкле хезмәт кешеләре турында, катлаулы язмышлар турында сөйли. Кызыклы юл маҗараларын уртаклашып, көлдереп тә ала. Тормышчан, матур детальләр, энҗе-мәрҗән яңгырыдай, сибелеп кенә тора аның авызыннан.

Без йотлыгып тыңлыйбыз. Карачы, күңеле юкка гына кузгалмаган икән ич... Никадәр баеп кайткан бит шагыйрь.

> **Күңелем кош сыман**
> **очардай була,—**
> **Илтегез еракка,**
> **юлларым, юлларым! —**

дип тә юкка гына җырлап йөрми икән ич.

Тиздән бу бәрәкәтле юл-сәфәрнең нәтиҗәләре дә күренә башлый. Матур-матур шигырьләр языла, газета битләрендә кызыклы юл язмалары басыла. Тагы да бераз вакыт үткәч, шагыйрь безгә үзенең яңа поэмасын укый.

* * *

Иң матур уйлар юлларда туа, диләр шагыйрьләр. Гомумән, юллар үтү, яңа җирләр күрү, яңа кешеләр белән очрашу берәүнең дә күңелендә эзсез калмыйдыр. Әмма шагыйрь Әдип Маликов иҗатында юллар — аеруча әһәмияткә ия. Аның иҗат биографиясе дә нәкъ менә юлларда башлануы һич тә тикмәгә түгел, күрәсең.

...Беек Җиңү салютлары яңгыраганга әле санаулы гына көннәр үткән. Зарыгып, көтеп алынган шатлыкның иге-чиге юк. Ләкин күңел бик үк тыныч та түгел. Ерак Көнчыгышта япон сугыш чукмарлары йодрык төйнәп маташа... Нәкъ менә шул көннәрдә, нәкъ менә шул тынычсыз яклардан «Совет әдәбияты» журналы редакциясенә калын гына бер хат килеп төшә.

Хат илебезнең әнә шул тынгысыз ерак атавында хезмәт итүче совет солдатыннан. Хат эчендә күләмле генә поэма да бар.

Ул вакытта журнал редакциясендә эшләгән Ф. Хөсни авторга түбәндәге җавап хатын юллый:

«Хөрмәтле Әдип туган!

Сезнең «Атаудагы хисләр» дигән поэмагыз һәм аңа тагып җибәргән хатыгыз «Совет әдәбияты» редакциясенә (димәк, Казанга!) килеп җитте. Укып чыктык, хәтта берничә кеше, шулардан Кави Нәҗми, Газиз Иделле укыдык. Мортаза солдат юкка гына «во!» дип баш бармагын күрсәтмәгәндер, ахры, әсәр безнең егетләрдә дә яхшы тәэсир калдырды... Менә син, уйланмаган бер көндә яңа бер шагыйрь килеп чыгып торә һәм үз авазы, үз почеркы белән. Изге юл булсын!..»

Поэма тиздән «Совет әдәбияты» журналында басылып та чыга.

Хәзер инде дистәгә якын поэмасы, бик күп шигырьләре һәм җырлары, «Сахалин язмалары», «Кайнар эзләр», «Без кояшны юлда каршылыйбыз», «Кембрига юл салучылар» кебек үзенчәлекле очерк китаплары белән укучыларга яхшы таныш Әдип Маликовның зур әдәбиятка беренче адымы әнә шулай башлана.

Туу-язылу тарихы үзе бер әсәргә торырлык «Атаудагы хисләр» поэмасына тукталуны алгарак калдырып, без шагыйрьнең аңарчы үткән юлларына да бераз күз салыйк. Чөнки Әдипнең әдәбиятка килүе укучылар өчен, Ф. Хөсни әйткәнчә, чыннан да «уйланмаган бер көндә» булса да, әмма шагыйрьнең үзе өчен... Юк, бик зарыгып көтеп ала шагыйрь бу көнне, аңа кадәр күпме сикәлтәле юллар, ачы сынаулар кичә.

Минем алда битләренә инде вакыт сарылыгы сеңгән дүрт дәфтәр. Шигырь дәфтәрләре. Кайбер шигырьләр астына шундый сүзләр язылган: «Бу шигырем Янавыл район газетасы «Октябрь юлы»нда басылды. Ул көнне сөенечемнән аягым җиргә тими йөрдем»... «Моныгы «Яшь ленинчы»да... «Яшь төзүче»дә басылды»...

Дәфтәр битләре арасыннан астына «Ә. Маликов дип имза куелган, газетадан кисеп алынган кыска-кыска хәбәрләр дә килеп чыга. Шигырьләрнең һәм хәбәрләрнең исемнәренә күз салыйк: «Әле уйда гына очсам да...», «Котып җиңелде!», «Сакчы абыйга», «Өч героиня Осипенко, Гризодубова, Раскова апаларга», «Испания балаларына

безнең ярдәм», «Алга, югарыга!», «Тракторчы кызга», «Пушкинга», «Значкистлар булырбыз»...

Күренә ки, биредә кайсы еллар турында сүз баруын исемнәр үк әйтеп тора. Әйе, әйе... Челюскинчыларның, папанинчыларның төньяк котыпка кыю һөҗүмнәре, өч совет кызы — өч лачынның батыр очышлары дөньяны шаулаткан еллар бу. Испаниядә кара фашизмның кешелек дөньясына канлы һөҗүме башланган көннәр... Без бик тырышып оборона значокларына нормалар тапшырабыз... Бик зурлап бөек Пушкинның 100 еллыгын билгеләп үтәбез... Колхоз авылы ныклап торып аякка басып килә.

Тынгысыз еллар, катлаулы чор. Ил тормышындагы һәр вакыйга, көнбатыштан дары исе аңкытып искән хәвефле җилләр 14—15 яшьлек Әдипне дә бик дулкынландыра. Шатлык, өмет һәм бик үк ачык та булмаган тынычсызлык белән тулы күңел әдәбиятшигъриятькә омтыла. Күңел ярсулы, шигырь юллары булып, дәфтәр битләренә агыла башлый.

Балаларча самими, әле кемнәргәдер ияреп, купшырак әйтергә тырышып язылган бу шигырь юллары арасында матур-матур поэтик бизәкләр дә очрый, әлбәттә. Ләкин минем игътибарны аеруча җәлеп иткәне, беренчедән, үсмер Әдипнең әлеге ил-дөнья күләм вакыйгаларга үзенчә сизгерлеге булса, икенчедән, менә нәрсә... Шигырьләр астына язып-язып куелган: Аксәет, Янавыл, Пермь... Менә шушы адреслар миңа кинәт бер нәрсәне ачыклап җибәрде. Карачы, бик яшьләй юлга чыккан ич Әдибебез! Инде каләме ныгып җиткәч, тикмәгә генә менә болай дип җырламый икән ич шагыйрь:

**«Юллар, юллар, сабый чактан ук**
**Уйларымны тартып тордыгыз.**

**...Юлга чыксам, дөньям онытыла,**
**Кайта алмыйм урап тиз генә.**

Башкортстанның Югары Чат авылында укытучы гаиләсендә туган Әдип җиде класска кадәр Аксәет мәктәбендә укый да, аннары, атна саен 40 чакрым юл үтә-үтә, Янавыл урта мәктәбенә йөреп укый башлый. Тагы да бер елдан соң Пермь каласына ук китеп бара. Биредә ул педагогия училищесында укый, аны тәмамлагач, шул ук Пермь өлкәсенең Барда районына укытучы итеп җибәрелә. Шушыннан 1939 елның көзендә ул Кызыл Армия сафларына китә.

Шулай итеп, тагын юлга. Монысы инде юлның бик озыны. Кызыл вагоннарга төяләп, айдан артык баралар алар. Илебезнең көнчыгыш чигенә килеп җиткәч кенә ул дөбердек вагоннардан төшәләр. Вагоннардан төшәләр, ләкин юл шуның белән тәмамланмый әле. Солдат хезмәте даими юл үтү ул дисәк тә ялгыш булмас. Шуңа өстәп, бу озын юлның ахыры данлы поход белән, Көньяк Сахалинны япон империалистларыннан азат итү сугышлары белән тәмамлануын искә төшерик. Әдип бу сугышларның башыннан ахырына кадәр разведка отделениесе командиры булып катнаша.

Әнә шулай гел юлда булуга карамастан, Әдип бала чактан дуслашып өлгергән каләмен дә кулыннан төшерми. Дивизия, армия газеталарында аның әледән-әле хәбәрләре, очерклары басылып килә. Ә часть комсомол оешмасы секретаре буларак, язар сүзләре бик мул була аның. Юк, уй-хисләр газета мәкалә-очеркларына гына да сыеп бетми, алар шигырь юллары сорыйлар. Андый юллар акрын-акрын кәгазьгә төшә дә бара. Ләкин чын-чынлап иҗат эшенә чумарга, билгеле ки, солдатның вакыты бик чамалы.

Кайчак бәхетсезлек бәхет тә алып килә, диләр бит. Көннәрнең берендә хәрби хезмәт һәм җәмәгать эшләренә колакларына кадәр чумган Әдип җитди генә авырып китә. Менә ул госпитальдә. Авырып яту курортта ял итеп яту түгел, әлбәттә. Җитмәсә, врачлар аның чирен дә шактый хәтәр әйтәләр: үпкә авыруы булмагае, диләр. Ул вакытта әле ышанычлы гына дарулары да булмаган бит аның. Ләкин ныклап тикшерә башлагач, мондый юрау акланмый. Авыру акрынлап чигенә.

Һәм менә тазару шатлыгы! Өстәвенә, солдат өчен бик тә тансык буш вакыт, үзең генә хуҗа булган буш сәгатьләр. Гел кыбырсып, гел күңелне тынычсызлап торган каләмне иркенләбрәк кулга алырга нәкъ шарты килә түгелме соң?

Шулай итеп, моңарчы аерым шигъри юллары, кайбер поэтик детальләре генә кәгазь битенә төшә барган «Атаудагы хисләр» поэмасы языла башлый. Поэма инде

ланып китә. Әдип, госпитальдән чыгып, тиешенчә хәл алырга да өлгерми, аларның часте ерак походка кузгала. Нәкъ менә шушы авыр поход әсәрне чын поэма итеп җиткерә дә. Мәсьәлә менә нәрсәдә... Поэмасында Әдип кайчандыр Татарстан җиреннән сөрелеп киткән каторжан улы Мусин солдат образы аша ерак Сахалинның фаҗигале язмышын, аның батыр йөрәкле, кече күңелле кешеләрен чагылдырырга омтыла. Моңарчы әле әсәрнең күп кенә вакыйгалары аерым-аерым язылса да, шуларны матурлап кына бергә тезә торган үзәк җепнең очын һичничек таба алмый йөди ул. Һәм менә поход... Солдат капчыгына поэма өзекләре, уйларда тагын, тагын шигъри юллар, ә янәшә генә әсәренең герое атлый...

Поход никадәр генә авыр булмасын, аның гаҗәп матур минутлары да була. Ул — приваллар. Иңнәрдән авыр солдат дирбияләре салына, тәнгә дә, җанга да җылылык бөркеп, учаклар чытырдап яна башлый. Учаклар янында тамак та ялгап алгач, китә мәзәк сүзләр, китә эчкерсез сөйләшүләр.

Әнә шундый привалларның кайсысында, кайсы учактан чәчрәгән очкын шагыйрь күңеленә барып төште икән? Анысын әйтүе кыен, ләкин төшә андый очкын Әдип күңеленә. Поэманың әлеге табылмас «җебе» нәкъ менә шушы бит инде—поход юлындагы привал! Һәм Әдип поэманың бөтен вакыйгаларын Мусиннан походтагы привалда сөйләтә. Тормыш үзе китереп тоттыра шагыйрь кулына әдәби алымны, шуның белән бергә, поход әсәргә заманның кырыс сулышын да бөрки.

Әнә шулай, нәкъ әсәрендәгечә, поход юлындагы ял араларында, солдат учаклары яктысында, поэманың беренче бүлеге языла бетә.

Мин шул сафта.
Поход тузанын
Каккач,
тагын өстәп язармын,—

дип нокта куя автор бу бүлеккә. Һәм Әдип вәгъдәсен үти. 1946 елда армиядән демобилизацияләнеп Казанга кайтканда, аның солдат капчыгында поэманың инде икенче бүлеге дә була.

Утлы һәм хәвефле сугыш шартларында без беренче бүлектә үк яратып өлгергән Мусин белән кабат очрашабыз. Рота дошман тылына үтеп бара.

Сукмак та юк монда, юл да юк,
Очратмыйсың болан эзен дә.
Мусин бара алдан юл салып,
Җен белән бер икән үзе дә!

Алда — котелмәгән елга. «Йөзәр идең — патрон чылана, пычкысы юк күпер салырга». Мусин монда да югалып калмый. Әнә Мусин инде теге як ярда.

Чу, тукта...
Ул кем белән анда сөйләшә!
Ни күрсеннәр:
Мусин янында
Аю басып тора лабаса...
— Мусин, ахры, сиңа сер итеп,
Нидер әйтте тайга хуҗасы!
— Адәм кул салмаган җирләрдән
Адашмый, ди, ничек узасыз!..
— Ә син!
— Ник адашыйк, туган җир ич, ди.
Юл күрсәтә безгә наратлар...

Рота дошман тылына бәреп керә. Каты бәрелешләр. Япон генералын кулга алу. Дошманның тагын көтелмәгән мәкерлекләре. Ниһаять, капитуляция:

Атыш тынган.
Портлы шәһәргә
Укчы рота керә капкадан:
Кайсы бара мотоциклда,
Кайсы трофей атка атланган.

Әмма бу трофей ат дигәненең хәтәр ягы да бар икән. Рота урман аланында ял иткәндә бер ат килеп чыга. «Нидер ялварып, күзләрен мөлдерәтеп» торган кара кашканы күргәч, кеше җанлы Мусин, кулына икмәк сыныгы тотып, аңа каршы атлый.

Булды тезгенгә кул салуы —
Зыр-болама килде барысы да.
Коры көндә яшен суккандай,
Сыкрау үтте тайга эченнән...
Тапкан чарасын да, түбән җан,
Ат ялына мина яшергән.

. . . . . . . . . . .

Ауды солдат
Җиңү юлының
Соңгы сызыгына җиткәндә...

Бу юлларны укыганда, тайга эчен ярып үткән сыкрау укучы йөрәгеннән дә үтә. Их, никадәр алтын бәясе кеше һәлак булды. Авторга да үпкәлисе килеп китә. Бер дә мөмкин булмадымыни соң шушындый да кешене исән-аман саклап калырга?.. Ләкин, бераз суына төшкәч, уйлыйсың. Әсәр героеның һәлакәте сине шушы кадәр сыкрата икән, бу бит поэманың нәкъ уңышы. Авторның әйтер сүзе нәкъ шушы үлем белән тагы да көчәя: кыйммәткә, ай, бик кыйммәткә төште безгә бу җиңү, тынычлыкның бик тә кадерен белик һәм уяу була күрик!

* * *

«Атаудагы хисләр» поэмасына тәфсилләбрәк тукталуымның сәбәбе аңлашылса кирәк. Язучының беренче әсәре аның бөтен иҗатына якты бер нур сирпеп тора бит. Алдагы әсәрләрендә язучы беренче әсәренең тематикасыннан, хәтта күйган проблемаларыннан тегебу күләмдә читләшергә мөмкин. Алай да була. Ләкин беренче әсәре — язучының иҗатын төптәнрәк аңлауга һәрвакыт иң ышанычлы ачкыч ул.

Әдип Маликов исә беренче әсәренә тугрылыклы булып калган язучылардан. Алдагы иҗатында да ул шул ук солдат-разведчик, әсәрләрендә тормышның үзеннән алган поэтик детальләр, шул ук кырыс-салмак моң...

Иҗатындагы бу үзенчәлек аның шәхси биографиясе белән дә аңлатыла булса кирәк. Армиядән кайткач, ул берничә ел Казанда радиокомитетта утырып эшләп ала да, «Татарстан яшьләре» газетасының үз хәбәрчесе булып, Минзәлә каласына китә. Республикада нефть фонтаннары гөрләп ата башлаган елларда исә әле беренче ташлары гына салынып яткан Әлмәт шәһәренә күчеп килә. Ә инде газета хәбәрчесе үткән юллар шул ук солдат-разведчик үткән юллар белән бер бит. Газета хәбәрчесе — тормыш разведчигы, бүгенге һәм иртәгәге көнебез разведчигы ул. Әнә шул тормыш разведкасы шагыйрьнең киләчәк иҗатына мул азык бирә. Ә. Маликовның поэмалары, үзенчәлекле очерк китаплары — барысы да нигездә әнә шул елларның бәрәкәтле җимешләре.

Разведка дигәннән, Әдипнең ул чордагы тагын бер тынгысыз эзләнүе хәтергә төшә. Әлмәткә күчеп килгәч, Минзәләдәге гадәте буенча, биредә дә үз тирәсенә яшь каләмнәрне тупларга, аларны эзләргә һәм табарга керешә. Шулай итеп, нефтьчеләрнең М. Горький исемендәге клубы каршында беренче әдәби түгәрәк эшли башлый. Түгәрәккә нефтьчеләр, төзүчеләр, комсомол, культура-агарту хезмәте кешеләре бик теләп йөриләр. Әдипнең бу өлкәдәге разведка хезмәтенә аңлатма кирәкмидер. Шәһәр белән бергә туган ул түгәрәктә беренче чиркәнчек алучылардан хәзер күренекле шагыйрьләр, язучылар үсеп чыкты. Әлмәттә хәзер Татарстан язучылар союзының шактый җәлекле, шактый җимешле бер бүлеге эшләп килә икән, моның да тамырлары Әдип оештырган әнә шул беренче түгәрәккә килеп тоташа.

Хәтеремдә... Әдип әдәбиятка шаулап килеп керде дә бер заман тыныбрак калды, күпмедер вакыт аның шигырьләре, поэмалары матбугатта күренми торды. Авторның үзен күреп белми идем әле ул чакта. Авылда яшим, әдәбият кешеләре белән сирәк очрашам, әмма кемнең нәрсә язуын бик кызыксынып күзәтә бара идем. Әдип Маликовның тынып калуы миңа байтакка кадәр бер табышмак булып калды. Соңрак, илленче еллар башында, «Татарстан яшьләре» газетасында безгә бергә эшләргә туры килде. Дөрес, бергә утырып түгел, ул Минзәләдә газетаның үз хәбәрчесе булып йөри, мин редакциядә утырам. Шунда иптәшләр әйттеләр: «Әдип җитди авырып тора шул. Врачлар аңа язу-иҗат белән шөгыльләнүне хәзергә бөтенләй тыйганнар да бит... Бер каләм җене тигән кешене тыеп буламыни».

Чыннан да, шигырь-поэмалары күренмәсә дә, аның очерклары, зарисовкалары, мәкаләләре көн саен диярлек килеп тора иде.

Казанга бер килүендә үзе белән дә очраштык.

Алай авыру кешегә бик охшамаган үзе. Янып торган чиста чырай, гәүдә — бик тез-зифа. Әмма аз гына күперенке кабаклы, җитди, коңгырт күзләрендә тынгысыз очкыннар чагылуын да шәйләргә мөмкин. Аннары, әнә, чигәләрдә бик күпшы булып та, түбәдә шактый сирәгәйгән, чал йөгергән чәчләр дә нидер әйтә кебек. «Бәлки, газета материаллары гына һич канәгатьләндермидер аны. Шагыйрь күңеле — шигърияттә бит», дип уйлап куйдым.

Ихтимал, шулай булгандыр да... Озак та үтмәде, «Совет әдәбияты» журналында аның «Ташчы» поэмасы басылды, шигырьләре күренә башлады. Аннары «Гайшә апа» поэмасы һәм тагын, тагын поэмалар.

Гомумән, поэмалар Әдип Маликов иҗатында күренекле урын тота. Алар турында тулырак, нигезлерәк итеп, төпченеп-тикшеренеп язарга да бик вакыт җитте җитүен. Ләкин мондый эшне тәнкыйтьчеләр үз кулларына алсыннар иде, бу кадәресе минем кулдан бик килмәстер. Шулай да мин Ә. Маликов поэмаларының бер үзенчәлегенә тукталмакчы булам. Хәер, үзенчәлек дип әйтү бик үк дөрес тә түгелдер. Менә ун ел инде без Әдип белән бер кала урамнарын таптап, бергә әге-җеге килеп яшибез. Аның соңгы поэмалары минем күз алдымда туды. Әнә шулар турында берничә сүзем бар.

Шулай бер көнне, нигәдер күңеле кузгалган Әдип, гадәтенчә, тирә-як авылларны бер әйләнү нияте белән юлга чыгып китә. Шунда ул Салкын алан авылында мәктәп директоры һәм колхозның партоешма секретаре Нури Сибгатуллин белән очраша. Шагыйрь шуны сизеп ала: авылда яше-карты Нури аганы бик тә хөрмәт итәләр, бер күз карашыннан аны шунда ук аңлап алалар, әгәр бу карашта шелтә сизсәләр, моны бик авыр кичерәләр. Тагын шунысы сәеррәк. Салкын кыш, авылда барысы да киез итекләрдән, ә Нури ага ялтырап торган ботинкалар киеп йөри. Сөйләшә торгач, шул аңлашыла. Нури ага сугышка кадәр үк инде шушы авылда укыткан, сугышта ул ике аягын тез тиңентен калдырып кайта, авылдашлары аны колхозның партоешма секретаре итеп сайлаганнар, ә мәгариф эшендәге зур хезмәтләре өчен аңа Татарстанның атказанган укытучысы дигән мактаулы исем бирелгән.

Сабый күңелен өр-яңадан коеп ясый белүче, колхоз авылын күтәрешүче, авылдашларының һәр кайгы-шатлыгы «йөрәгенә тиеп үтә» торган укытучы-ил агасы турындагы «Салкын алан» поэмасының беренче очкыны әнә шул көнне кабынып кайта.

Әдип Маликовны катлаулы язмышлы кешеләр кызыксындыра. Бер вакыт ул шундый хәбәр ишетә: Әлмәт районының Колшәрип авылында Җиһангир карт белән Эмма-Әминә семьясы яши икән. Җиһангир үзенең Эммасы белән Германиядә әсирлектә чакта танышкан. Соңыннан, гражданнар сугышының иң авыр көннәрендә, ерак немец җиреннән шул кыз Колшәрипкә Җиһангирын эзләп килеп төшкән. Һәм Әдип Колшәрип авылына юл тота. Аннары тагын, тагын барып кайта... Олы мәхәббәт һәм интернациональ дуслык турындагы «Чигүле кульяулык» поэмасы шулай барлыкка килә.

Мондый белешмә-тарихларны Ә. Маликовның һәр поэмасы турында сөйләргә мөмкин. Әйе, һәр поэмасының сюжет нигезен, героен тормышның үзеннән ала ул, аның һәр әсәре, беренче поэмасы кебек үк, юлларда туа. Өстәвенә, Әдип һаман да, армиядәге кебек үк, разведчик. Татар поэзиясенә тезүче образын да («Ташчы»), нефтьче кыз образын да («Фәрдәнә») беренче булып Әдип Маликов алып килде. «Салкын

моңарчы кабатланмаган бик үзенчәлекле образлар. Разведчик дигәч, бу тарафтан аның «Дуслык юлы» балладасы бик характерлы. Бу балладаның да герое һәм сюжеты уйлап чыгарылмаган. Ватан сугышы ветераны, нефть чыгару остасы Сафуат Вәлиуллин белән Әдип «Татарстан яшьләре»нең хәбәрчесе булып йөргәндә үк таныша. Соңрак алар якын дуслар булып китәләр. Әнә шулай дусларча сөйләшеп утырган бер кичтә Сафуат кулына баян ала, көмеш телләргә эчке бер моң салып, уйнап җибәрә. Аннары, күңеле нечкәреп китеп, үзенең гармонь белән ничек дуслашуын да сөйләп ала. Чал Идел ярларыннан алып Карпат итәкләренә кадәр сугышып үткән Сафуат Чехословакия җирендә каты яралана. Уң кулының бармаклары хәрәкәтләнергә теләмиләр. Көннәрнең берендә чех кызлары яралы совет сугышчыларына баян бүләк итәләр. «Туй соңында биетерлек» аз-маз уйный да белгән Сафуат баянны бик еш кулына ала башлый. Баян телләре өстендә йөгереп, бармакларым язылмасмы дип өметләнә ул. Өмете аклана егетнең. Чех кызлары бигрәк саф йөрәктән бүләк иткәннәр икән баянны, рәхмәт яугырлары... бармакларга җан керә. Шулай язылган бармакларына Сафуат соңрак, нефть институтында каләм-карандаш ала, аннары, үзе сугышып үткән җирләр буйлап сузылган «Дуслык» нефть юлы буйлап, Европага «кара алтын» озата башлый. Менә нинди шигъри биографияле егет икән ич шагыйрьнең дусты! Һәм Әдип шушы турыда баллада яза.

Берничә еллар үткәч, шушы ук темага Сибгат Хәкимнең киңрәк күләмдә, киңрәк колачлы итеп язылган «Урләр аша» поэмасы басыла. Татар совет поэзиясенең бу күренекле поэмасы тууда Әдип Маликовның разведчиклык роле аңлашылса кирәк. Шушы җәһәттән, Әдипкә бер теләк тә белдерәсе килә. Разведчиклык бик әйбәт, әмма һөҗүмгә дә ешрак күчсәң икән. Шулай бит безнең бу якларда. Нефтьче-разведчиклар, яңа мәйданга килеп, беренче скважинаны бораулап китәләр, аннары, күп тә үтми, эксплуатация бораулаучылары «кара алтынга» юлны киң итеп ачып җибәрәләр, яңа мәйдан илгә байлыгын бик юмарт бирә башлый. Иҗат фонтаннарың кыюрак, муллрак ыргылсын! Бәйрәм көнендә теләгебез шул синә, Әдип дус!

* * *

Алай дигәч тә, әйтер сүземне түгәрәкләп куюым түгел әле бу. Юкса, Ә. Маликовның прозасы турында сүз булмады диярлек бит. Аның «Без юлда каршылыйбыз» дигән документаль повесте бар. Ул балаларга атап язылган. Аның нәни геройлары башта көймәләрдә, аннары автобуста һәм җәяүләп Алабугадан Әлмәткә чаклы кызыклы сәяхәт кичәләр. Юл маҗараларына, Болагай дигән шаян бер этнең мәзәк кыланышларына елмаеп куя-куя, уку барышында без шактый җитди нәрсәләр белән дә танышып барабыз. Татарстанның көньяк-көнчыгыш якларының бай тарихы да, бүгенге көннәре дә, матур табигате дә акрын-акрын күңелгә сеңә бара. Шунда ук күп кенә җанлы кешеләр — нефтьчеләр, тәзүчеләр, колхозчылар белән дә очрашабыз.

Кызыклы да, файдалы да китап бу.

Ә. Маликовның «Кембригә юл салучылар» дигән икенче күләмле проза әсәре безне тагын юллар буйлап алып китә. Бу сәфәр инде шактый ерак — Себер тайгасы, Лена буйлары. Анда безнең якташларыбыз Себер нефтен үзләштерүдә җиң сызганып эшләп йөриләр. Якташлар артыннан автор да шунда барып чыга һәм аларның фидакарь хезмәтләре турында рухланып яза. Шунда, бик җаен туры китереп кенә, Себер нефтенең тарихы белән дә таныштырып үтә. Китап юл язмалары жанрында язылган, ләкин образлар, аеруча, якташларыбыз Исхак Гыйләҗев белән Мәхмүт Мөхсинов, эвенк карты Сердиткин шактый калку итеп, истә калырлык итеп сурәтләнәләр.

Гомумән, Себер нефте һәм нефтьчеләре турында бик бөлеп, үз итеп, яратып яза Әдип. Себернең кырыс табигатен дә җанлы итеп, бөтен тәне белән тоеп тасвирлый. Аның Себер пейзажларын укыганда, битеңнән шул кырыс җилләр сыйпап үткәндәй була. Шуңа күрә дә, тагын бер кат кабатлап әйтәсе килә: Себер нефтьчеләре, андагы батыр якташларыбыз турындагы бик мөһим темага матур разведка ясадың, инде һөҗүмгә дә күчсәң икән, дускай. Бу турыда бик саллы, матур әсәр бирә алыр идең син.

Без аларда чәйләп утырабыз.

Кичә генә бик ерак юлдан кайтты шагыйрь. Көньяк Сахалинны япон империалистларыннан азат итү сугышларына 25 ел тулу тантанасына, шул сугышларда катнашучы буларак, запастагы капитан Әдип Маликовны да чакырганнар. Әйткәнебезчә, моннан ике ел микән элек, бер булып кайткан иде инде ул анда. Күңеле җилкенеп, яшьлеге эзләре буйлап бер әйләнгән иде. Бу сәяхәте тагы да тәэсирлерәк булган. Чирек гасыр вакыт үткәч, бергә утны-суны кичкән полкташлары, сугышчан дуслары белән очрашкан ул, бергәләп, үлем белән күзгә-күз очрашкан урыннарын, сугышып үткән җирләрен карап йөргәннәр.

Шагыйрь әнә шулар турында дулкынланып сөйли. Өстәлне Сахалин күчтәнәче — кызыл балык бик матур бизәп тора. Балык та бик тәмле, шагыйрьнең сөйләвен тыңлавы да бик күңелле. Тиздән бу сәяхәтнең дә әйбәт нәтиҗәләре күренә башлар, яңа зур әсәрләр туар. Без моңа ышанабыз. Кояшны юлларда каршылар таңнарың тагы да гүзәлрәк булсын, юлларың гел уң булсын, бик озын булсын, каләмдәш дустыбыз!

## Әдип Маликов

# КУРИЛЬ ЧӘЧӘКЛӘРЕ

### ЯЗУЧЫ БЛОКНОТЫННАН

*«Империалистик Японияне тар-мар итүгә 25 ел тулу уңае белән Сахалин өлкәсенә бер төркем сугыш ветераннарын, япон гаскәрләренә каршы сугышларга актив катнашучыларны, шулар исәбеннән татар шагыйре, СССР язучылары союзы члены Әдип Маликовны да чакырган идек. 1970 елның 29 августыннан 8 сентябренә кадәр ул, Сахалин өлкәсендә булып, төрле предприятие, мәктәп, Көньяк Сахалин гарнизоны коллективлары алдында уналты мәртәбә чыгышлар ясады, алар арасында масса-политик эшләр үткәрүгә катнашты.*

*Аның совет сугышчыларының япон басып алучыларына каршы сугышларда күрсәткән батырлыклары, Ватанга бирелгәнлекләре турындагы тирән эчтәлекле чыгышлары өлкәбез кешеләрен хәрби-патриотик тәрбияләү эшендә зур әһәмияткә ия булдылар... КПССның Сахалин өлкә комитеты Сахалинга һәм Куриль атауларына килгәне вакытында зур агитация-пропаганда эше алып барганы өчен Әдип Мәлик улы Маликовка рәхмәт белдерә».*

*(КПССның Сахалин өлкә комитеты хатыннан)*



Исән-имин Көньяк Сахалинга килеп җитеп, ике ял көнен очрашуларда уздырганнан соң, безне, кунакка чакырылган ветераннарны, партия өлкә комитетына дәштеләр. Кемнәр килде икән?

Мари язучысы Василий Степанович Юксерн белән, гостиницага килеп төшүгә, беренче кичтә үк таныштым. Дөресрәге, без күптәнге танышлар. Ул Кызыл Байраклы Сахалин дивизиясенең элеккеге пропагандисты, заманында актив журналист иде. Мин дә дивизия газетасы битләрендә аның белән бер чорда күренә, каләм тибрәтә башлаган кеше. Егерме биш елдан соң Сахалин туфрагында кочаклашып күрешеп, истәлекләр яңарттык. Ике көн эчендә аның белән алты очрашуда — пограничниклар, диңгезчеләр, хәрби элемтәчеләр, мәктәп балалары янында булырга өлгердек.

Партиянең Сахалин өлкә комитеты секретаре Терентий Петрович Селявский, каршыбызга чыгып, ике кул белән күрешә-күрешә, безне дусларча, бик җылы каршы алды.

— Хуш килдегез, азат итүчеләр!

Елмайганда, аның сул яңагы буйлап сузылган тирән яра җөе дугаланып куя, авызы сизелерлек кыйшая. Мина яки снаряд ярчыгы «сөреп» киткәнгә охшый...

Йомшак урындыклар тезелгән иркен, якты кабинетка барысы уңлап кеше җыйналдык. Гадәт буенча, танышулар, таныштырулар китте. Бу вазифаны өлкә комитеты секретаре үзе башкара:

— Сахалин дивизиясенең элеккеге полк командиры, запастагы подполковник Нигъмәт Җумакаевич Курманов!

Нигъмәт ага — чәчләренә чал кергән, киң маңгайлы, урта буйлы казакъ — шаян елмаеп, «смирно» басты. Аның күкрәк тулы орденнары елкылдашып, медальләре бер-беренә тиеп, чыңлашып куйдылар. Ул җавапсыз калмады:

— Хәзер Алма-Атада яшим, алмалар үстерәм, кунакка рәхим итегез!

Ике якка салынып төшкән мыеклары һәм юан гәүдәсе белән диңгездәге моржны хәтерләткән кеше — Лев Михайлович Демин булып чыкты. Биредә үзен хуҗаларча тоткан Нигъмәт Җумакаевич әйтеп салды:

— Син, җаным, элек тупчы чагында шәм кебек егет идең. Ат өстендә ничек уйнаклап чапканың да күз алдымда. Хәтерең калмасын, хәзер сине фил дә күтәрә алмастыр. Индонезия климаты килешкән, килешкән...

Һәммәсе көлешеп алды. Деминны мин үзәк матбугатта басылып килгән, башлыча халыкара хәл турында язган мәкаләләре, очерклары буенча яхшы белә идем. Хәзер менә үзен күрдем. Ул озак кына еллар Индонезиядә «Правда» газетасының үз хәбәрчесе булып эшләде.

— Тарих фәннәре кандидаты, Патрис Лумумба исемендәге институтта укыта,— дип өстәде аның турында Селявский.

Татарстан һәм Мари республикалары вәкилләре белән таныштыруга (Юксерн Мари республикасында чыга торган сатирик-көлке журналның баш редакторы), ишектә бишенче кунак күренде. Сөйләшергә яратучан, җор күңелле казакъ дустыбыз түзмәде, монысына да реплика очырттын:

— Шутов һәркайда соңга кала,— диде ул, кочагын җәйгән хәлдә аның каршысына омтылып. Теге чакта — Курильне азат иткәндә дә бездән бер атнага соңлап башладыгыз эшне...

Ике ветеран кочаклашып үбешкән арада, һәммәбез көчле дулкынлану кичереп, аягүрә басып тордык. Нечкә озын гәүдәле, как яңаклы Шутов ахырдан баягы репликага җавап бирде:

— Без ул чагында Верховный белән бер судә идек, кадерле Нигъмәт Җумакаевич.

Аннары ул калын бас белән гафу үтенде:

— Кичерегез, шахтерлар яныннан кайтуым гына...

Шушы икән инде Петр Иванович Шутов, Южно-Сахалинск музеена мәрмәр бюсты куелган герой! Ул бездән бер атна алдан килгән, инде ярты Сахалинны урап чыккан. Чакырылган кунаклардан вице-адмирал Андреев Южно-Сахалинскида бер көн булган да үз стихиясенә — Тын океан моряклары янына «тайган». Без барыбыз бишәү булып чыктык, дүрт милләт вәкиле. Ә бүтән иптәшләр — хуҗалар икән.

Терентий Петрович, гаҗәпләнүемне сизгән сыман, моңа ачыклык кертте:

— Элек-электән Россиянеке булган бу җирләрне азат итүче батырлар белән без араны өзмибез. Юбилей алдыннан Советлар Союзының төрле почмакларына меңнән артык котлау телеграммасы җибәрдек. Сугыш ветераннары бирегә ел саен килеп торалар. «Белем» җәмгыяте

кулына эләксәләр, аларны телләре талганчы, икешәр смена эшләтәләр...

Терентий Петровичның сул як яңагындагы ялтыравыклы җөе дугаланып куйды. Ул безне утрау хәлләре белән таныштырырга тотынды:

— Әле күптән түгел Сахалин ярлары буйлап цунами үтте. Сезгә аны аңлатып торуның кирәге юктыр...

Цунаминың дәһшәтле нәрсә икәнен монда утыручылар, әлбәттә, яхшы беләә. Гадәттә, җир тетрәүләр вакытында шул районгагы дингез дә хәрәкәткә килә. Аның төбе урыны-урыны белән шәп-шәрә булып ачыла. Унар катлы йортлар биеклегендәге дулкыннар реактив самолет тизлеге белән ярга ташланалар. Дулкыннар яр буендагы өйләрне, хәтта поселокларны юып алып китә. Елгалар ташып, ярларыннан чыга...

Өлкә комитеты секретаре бераз паузадан соң сүзен дәвам итте:

— Пограничникларга рәхмәт, су уртасында калган мәктәп эченнән биш йөз баланы коткардылар. Корбансыз булмады... Табигать быел шактый тискәре ягы белән килде. Кышын, гомергә булмаганча, бурап-бурап кар яуды. Шәһәрләр кар астында калды. Урамнарда хәрәкәт туктады. Берничә көн элемтәсез, утсыз-сусыз яшәдек. Совхозларда терлекләр «ачлык бунты» күтәрде. Сыерларны бина түбәсеннән төшеп саудылар. Табигать тудырган бәла-казаларга карамастан, Сахалин өлкәсе дәүләт планнарын уңышлы үтәп килә. Ит, май, сөт, яшелчә — үзебезнеке. Элекке шикелле, зур җирдән көтеп ятмыйбыз. Ә җир асты байлыклары һәм дингез продуктларына килгәндә, алары белән бөтен ил, хәтта дөнья базарында мактана алабыз.

Терентий Петрович бу сүзләрне раслау өчен бик гыйбрәтле берничә мисал китерде:

— 1925 ел белән чагыштырганда,— диде ул,— балык тоту — 157, ә ташкүмер чыгару 360 тапкырга үсте. Сахалин хәзер илгә 1913 елда бөтен Россия комбинатлары эшләп чыгарган кадәр күләмдә кәгазь бирә. Өч көнгә бер миллион банк балык консервасы — менә эшләрниндигә китте!

Сахалинда бик күп милләт вәкилләре бер туган семья булып яшиләр. Октябрь революциясенә кадәр үлемгә йөз тоткан гиләкләр арасыннан күренекле язучы Владимир Санги, галим Чунер Таксами, балыкчы Пойтан Чайка кебек бөтен илгә танылган кешеләр үсеп чыккан.

Селявский Пойтан турында аеруча бер җылылык белән сөйли:

— Гаҗәеп ягымлы кеше ул безнең Пойтан Герасимович. Нинди дер тылсымлы көч белән балыкчыларны үзенә тарта, аларны хезмәткә рухландыра ала. Дингезнең серен белә...

Терентий Петрович бу урында кулларын уып, көлеп куйды.

— Пойтан беренче тапкыр 1939 елда Мәскәүгә — Авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә барганда яшь-яшь егет була, зур шәһәрдә адашып та йөри. Ә егерме елдан соң аны башкалабыз Социалистик Хезмәт Герое, партия съезды делегаты буларак каршылады. Көньяк Сахалин һәм Куриль атауларын Япония империалистларыннан азат итү сугышларында ничә кешегә Советлар Союзы Герое исеме бирелгән булса, хәзер бездә шул саннан артыграк Социалистик Хезмәт Геройлары үсеп чыкты,— дип сүзен дәвам итте Терентий Петрович,— атаклы балыкчы Александра Хан, нефть эзләү конторасы директоры, Татарстан улы, хәзер, әлбәттә, безнең кадр — Җәүдәт Муратов, яшелчә үстерү остасы Иван Тимофеев...

Аннары сүз маршрут планнарын ачыклауга күчте.

— Безнең уебызча, ике группага бүленү хәерлерәк булыр. Беренче юнәлеш — Төньяк Сахалин, икенчесе — Куриль.

Нигъмәт Җумакаевич шунда ук үз ниятен белдерергә ашыкты:

— Мин — Төньякка, дусларым,— диде ул, гәүдәсен хәрбиләрчә турайтып.— Үземә ышанып тапшырылган полкның сугышчан юллары буйлап үтәсем бар. Утрауда калган полкташларымның исәннәрен дә, кабердә ятканнарын да барлап чыкмыйча кайтмыйм.

ның тәкъдименә Демин да кушылды. Калганнарыбыз бер-беребезгә карашып алдык. Күрәм, Юксерннын шатлыктан күзлек пыялалары ялтырый. Чөнки без, һавалар әйбәт торган чакта, башта Куриль утрауларына барырбыз дип сөйләшкән идек. Петр Иванович Шутовның да хыялында шул икән.

— Мин — Курильгә,— диде ул, кулын күтәреп.

Аның авторитетлы канаты астында безгә жил-янгыр тимәс, сәяхәтебез уңышлы булыр дип уйлап бетерүгә, Петр Иванович киресен әйтте дә куйды:

— Янымда ике журналист булганда, мин җәһәннәм читенә барудан да курыкмыйм.

Күнелле генә көлешеп алганнан соң, Селявский, безне карта янына чакырып, шуны әйтте:

— Җәһәннәм булмаса да, нәкъ жир чите. Менә ул — сез барасы утрау, Япониягә терәлеп үк тора. Һава киреләнсә, командировкага киткән безнең иптәшләр берәр атна кайта алмыйча да яталар. Димәк, юбилей тантанасын монда уздыргач, Көньяк Куриль районына, Кунашир утравына очасыз!

Әйе, жир читенә. Камчаткадан алып Япония чикләренә кадәр сузылган Тын океан «муенса»сынын соңгы «төймә»сенә, иң көньяктагысына. Ул утраулар арасында Шутов исемен йөрткәне дә бар икән.

...Дингез өстендә куе томан йөзә, күктә катлы-катлы болытлар. Самолет кояш янына күтәрелде, болытлар, хәрәкәтсез кар тауларына охшап, түбәндә калдылар. Дөнья яктырып китте, керфекләрне күтәрсән— нурлардан күз чагыла.

Петр Иванович Шутов кинәт башын күтәрде, ым кагып, мине үз янына чакырды. Аның янәшәсендәге буш креслога килеп утыргач, колагыма кычкырып диярлек:

— Без якташлар икән ич,— диде, бер яңалык ачкан сыман дәртләнеп.— Минем дә бит «Тормыш университетларым» Казаннан башланды. Армиягә алынганчы грузчик, аннары кочегар булып эшләдем. Ә 1929 елда Казан пехота училищесына укырга кердем. Беләсезме, Казанка буйлары миңа аеруча таныш. Без Кремль гарнизонында идек. Занятиедән соң болынга, чәчәкле болынга чыгабыз. Хәзер ул урыннар дингез астында калган икән.

Мин Петр Ивановичтан сорыйм:

— Ә Казаннан китүегез?

— 1939 елда Уфада яна полк төзелде, мине шунда полк командиры урынбасары итеп күчерделәр. Ә бер елдан соң без Камчатка яр буйларына күзгалып киттек. Менә шулай, якташ.

Еракка киткән саен, якташлар күбәя бара. Азиягә чыксаң, Европалылар инде синең якташыңа әйләнә.

Сәгать ярым узуга, самолет, сикәлтәле очышка күчеп, түбәнәя башлады һәм, сыек томан эчендә «сукыр» килеш диярлек, жиргә төшеп утырды. Безне бер төркем пограничниклар каршы алды.

— Хөрмәтле пассажирлар, сез погранзонада,— дип кисәтте озын буйлы, мәһабәт йөзле капитан,— район үзәгенә баручыларны автобус көтә.

— Райком секретаре Григорий Данилович Никулин,— дип таныштырды үзен бер аягы протезлы урта яшьләрдәге кеше,— машинага рәхим итегез. Районга кадәр егерме биш чакрым селкенәсе бар.

Хәзер көндезге сәгать унбер, ә беренче яртыга безне Көньяк Куриль урта мәктәбе укучылары көтә икән.

— Гафу итегез,— диде райком секретаре, бераз кыенсынып.— Сезнең вакытыгызга без хуҗа булдык. Бүген бит 3 сентябрь — империа-

нистик Японияне Җиңү көне. Сезне пәркайда көтәләр. Кичен район культура йортында очрашу планлаштырылган иде. Пограничниклар да бик чакырды.

— Мин һәрвакыт хәзер,— диде, моңа җавап итеп, арабызда яше буенча да, чины белән дә иң өлкәне — отставкадагы полковник Петр Иванович Шутов.— Сез ничек карыйсыз, иптәшләр?!

Безгә, запастагы капитаннарга, «була ул» дияргә генә калды.

Машина, берничә агач йорттан, озын казармалардан торган поселокны узып, тау юлына элдерде. Төньяктан көчле җил исеп куйды, томан күтәрелә, күк йөзе болытлардан әрчелә башлады.

— Һава торышы бездә дингез сулышына карап йөри,— ди Григорий Данилович.— утрау үзе дә сулыш ала, вакыты-вакыты белән селкенгәләп тә куя. Асфальт та, бетон да түзми. Аэродромга тимер плитәләр түшәргә мәҗбүр булдык.

Райком секретаре, ерактагы вулкан сопкасына ишарә ясап:

— Әнә, «Тэтэ-яма», айну телендә «Таулар атасы» дигән сүз. Биеклеге 1819 метр,— диде дә шоферга машинаны туктатырга кушты.

Һәммәбез дә юл буена чыгып бастык. Мин «Таулар атасы»ннан карашымны һич тә ала алмыйм. Вакытлыча сүнгән булса да, янар тау бит. Беренче күрүем. Ул, зәңгәр конус сыман очлаеп, күк гөмбәзенә терәлгән. Сопканың урта бер җирендә ак болытлар кыймылдаша. Ә «конус»ның иң очы — кратер тирәсе — чүлмәккә охшаган.

Аннары хуҗалар игътибарыбызны дингез ягына юнәлттеләр:

— Әнә, «ут» күршеләребез күренеп кенә тора. Хоккайдо. Күрәсезме, тау итәгеннән поезд үтеп бара? Япон балыкчылары, мавыгып, кайчакта бөтен семьялары белән безнең ярларга килеп чыгалар. Ихтирам белән озатабыз үзләрен.

Григорий Данилович ачык күңелле кеше, үзен бик иркен тота. Ул безне мылтык урынына гади таяклар белән коралландырды да урман эченә таба алып китте. Кеше биеклеге булып, ниндидер ят, ямь-яшел камышлар үскән.

— Кәрлә бамбуклар,— дип аңлатты райком секретаре,— дингез кәбестәсе белән бергә турап, силоска салабыз. Сыерлар бик яратып ашый. Яшел кукуруз сабакларына торырлык. Япон медиклары аларны рактан дәвалау өчен файдалана башлаганнар.

Табигать монда бездәгегә караганда бөтенләй үзгә. Каеннарның кәүсәләре ак түгел, ә көрән эмаль, мәрмәр төсендә. Көньякның лианалары Себердә үсә торган эрбет чикләвекләренә уралып менгәннәр. Магнолияләр дә очрый. Кыргый виноград белән янәшә төньяк җимешләре: мүк, нарат җиләкләре пешеп утыра.

«Вездеход» комлы юлдан тагын алга ыргылды. Бер югалып торганнан соң, каршыбызда янадан дингез пәйда булды. Утрауның киңлеген, озынлыгын сорашабыз. Озынлыгы йөз километр чамасы, ә киңлеге төрлечә икән. Бик тар урыннары да бар. Район үзе сигез утраудан тора.

Юл буенда гына ун-унбиш метр чамасы биеклеккә пар фонтаны атып ята. Гүләгән, сызгырган тавышлар ишетелә, күкерт, торф исе борынга килеп бәрелә. Машина акрынрак бара башлады.

— Әле күптән түгел бораулапган скважина. Җир куеныннан бәреп чыккан кайнар парны биналар җылыту, теплицалар, дәвалау учреждениеләре өчен файдаланабыз,— диде Григорий Данилович.— Бездә шифалы табигый ванналар, кайнар чишмәләр дә җитәрлек. Совхоз эшчеләре печән хәзерләргә барган җирдән ванна кереп кайталар.

— Бераз дингез суын өстәргә кирәк, ансыз кайнар була,— дип сүзгә кушылды тын гына барган шофер да.

Урман борылмасын үтүгә, берәр-икешәр катлык йортлардан торган поселок күренде. Аның бер өлеше очлаеп, дингезгә чыгып торган борын-

га — ярыматауга урнашкан. Гел яңа йортлар. Ә искерәкләре уйсу җиргә, елга буена сибелгәннәр. Безне диңгез ярына таба алып киттеләр.

Машина ике катлы таш бина янына килеп туктауга, капка төбендәге «күзәтче»ләр күз ачып йомганчы юкка чыкты. Тиздән звонок шалтыраганы ишетелде.

Райком секретаре, безне вакытлыча пионерлар карамагына тапшырып, үзе китеп барды.

Мәктәп ишек алдында — чәчәкләр дөньясы. Махсус савытларга утыртылганнары да, сулы банкаларга букет итеп куелганнары да бик күп. Сабый бала башы зурлыгыдай, яшьп торган кырым розалары, япон чәчәкләре, төрле төстәге дәлияләр, ромашкалар... Тагын әллә нинди без белмәгән хуш исле чәчәкләр. Алар күз явын алып торалар.

— Бүген бездә чәчәкләр бәйрәме,— диде мәктәп директоры, зифа буйлы, сылу хатын.— Ул бәйрәм һәр елны өченче сентябрьдә үткәрелә.

Зал эчендә дә шул ук хәл: гүя дөньяның бөтен хуш исле чәчәкләре бирегә кунакка килгәннәр.

— Мин исердем, әсир булдым,— диде Петр Иванович, тирән сулыш алып. Көтелмәгән бу күренештән картның йөзе нурланып киткән. Чәчәкләр дөньясына кереп чумуыбыз бер хәл, каршыбызда әле ал галстуклы пионерлар дружинасы басып тора!

— Дружина, смирно!

Ак блузка кигән, күзләреннән очкын бөркелеп торган унсигез яшьләр тирәсендәге кыз, йөреше белән хәрбиләргә охшарга тырышып, мәктәп директоры каршысына барып басты, аңа рапорт бирде:

— Советлар Союзы Герое, Куриль атауларының почетлы гражданины Петр Иванович Шутов исемендәге пионерлар дружинасы сугыш ветераннары белән очрашуга әзер!

Петр Иванович кинәт каушап калгандай булды, аның ябык, сөякчел куллары сизелерлек калтырана башлады. Маңгаеннан эре тир бөртекләре бәреп чыкты. Ул, трибунага менгәч тә, әле тиз генә тынычлана алмады.

— Кадерле дусларым!..

Шул ике сүздән соң озак пауза булып торды. Президиум өстәле янында, янәшәбездә утырган мәктәп директоры, сөйләргә менүчегә көч, куәт бирергә теләгәндәй, кулларын кушырып, хәтта талпынгалап та алды.

Залдагылар кинәт дәррәү килеп кул чабарга, алгы рәттән урын алган октябрятлар исә «ура» кычкырырга тотындылар. Петр Ивановичка «җан» керде, ул инде елмаеп җибәрде, залга, укучылар арасына төшеп йөренә башлады.

— Карагыз әле, дусларым, беркайда да болай каушаганым юк иде... Йәгез, кемнәр биредә туып үскән, кул күтәрегез әле?

Бөтен зал диярлек бердәм кул күтәрде.

— Ә Зур җирдә булганыгыз бармы, сөеклеләрем?

— Безнең өчен Зур җир — Сахалин, Петр Иванович,— дип җавап бирде бер кыз, горур гына.— Анда һәр җәй саен булабыз.

Янәшәсендә утырган малай өстәп куйды:

— Сахалинга Зур җирдән поездлар йөри башлагач, поездга утырып, дружинабыз белән сәяхәткә чыгарга җыенабыз.

Татар бугазы аркылы, Ванино — Холмск арасында, диңгез паромнары ярдәмендә поездлар йөреп торачагын без белә идек инде. Иң чыдам пластмассалардан, металлдан ясалган паромнар Мәскәүдән, Хабаровскидан килгән поездларны диңгез аша чыгарып, утрау рельсләренә күчерәчәкләр.

Петр Иванович берни сөйләшмичә, шулай сораулар биреп кенә йөрсә дә, балалар моңа риза шикелле. Аларның үтә кызыксынучан җитез

карашлары геройның күкрәгенә төбәлгән: өч Ленин ордены, Алтын Йолдыз медале, тагын бик күп сугышчан орденнар, медальләр...

Петр Иванович балалар белән сөйләшеп йөргән арада, мин аның турында белгәннәремне күңелдән кичереп утырдым.

1945 елның 11 августы. Илленче параллель буенда Сахалинны ике дөньяга аерып торган чик баганалары ауды, утрауны япон илбасарларыннан азат итү сугышы башланды. Бу вакытта әле Куриль тезмәләрендә туплар дәшми, пулялар сызгырмый иде. Дошман, җиңелүгә дучар булуын төшенеп, аңына килер, бәлки капитуляция ясар, шулай итеп, Куриль утрауларында мәгънәсезгә кан коюлар, бәлки... Юк, самурайлар кан коюсыз бирелергә уйламадылар...

Бер атнадан соң Шумшу утравына хәрби диңгез десанты төшерү турында СССР Верховный командованиесенең приказы була. Пехотадан һәм Тын океан морякларыннан торган алдынгы отрядның командиры итеп майор Шутов билгеләнә. Шумшу утравын Камчаткадан Төньяк Куриль бугазы аерып тора. Японнар бу атауны еллар буена ныгыткаииар. Бик күп дотлар, җир асты галереялары төзегәннәр, мина кырлары булдырганнар, сопкаларны чәнечкеле тимер чыбыклар белән уратып алганнар. Анда Кытай әсирләрен көчләп эшләткәннәр. Соңыннан аларның язмышы фаҗига белән беткән — диңгез акулаларына азык булганнар. Шумшуны какшамас крепость дип санаган дошман.

— Без десант судноларына төяләп Камчатка ярларыннан аерылганда, тузандай яңгыр сибәләп тора, диңгез өстен куе томан баскан иде,— дип сөйли Петр Иванович.— Янибыздан гына япон траулеры үтеп китте. Ул безне күрмәде, ахры, бәрелеш булмый калды. Дөресен әйткәндә, моңдый уңайсыз һава шартларында самурайлар безне көтмәгәннәр дә. Шумшу атавына җитәргә ярты миль чамасы ара калгач, дошман тревога күтәрде, туплардан, минометлардан ут ачты. Десант баруын һаман дәвам итте. Безнең судноларда янгын чыкты. Кайберләре бата ук башлады. Салкын диңгез кочагына сикерүдән башка чара калмады. Арабызда яшь кенә санитарка кызлар да бар иде. Алар үзләрен ирләрчә тоттылар...

Петр Иванович бер мәлгә тынып калды, өч бармагы төптән үк өзелгән кулы белән маңгаен сыйпап алды. Чирек гасыр элек булып узган вакыйгаларны инде ничә тапкырлар, ничә урында кабатларга туры килсә дә, аларны яңадан терелтү җиңел түгел, күрәсең.

— Ничек тә ярга тотынырга, кигәвен кебек безелдәгән пулялардан яшеренү өчен беренче очраган кыя ташларына ышыкланырга — бөтен теләгебез, беренче максатыбыз шул иде,— дип сүзен дәвам итте ул.— Исән калганнарыбыз моңа иреште. Бармакларымның өзелгән булуын җиргә аяк баскач кына сиздем. Без, дошман үзенең көчләрен туплаганчы, шунда ук һөҗүмгә күчтек.

Десант отрядын диңгезгә батыра алмагач, самурайлар хәйләгә керештеләр, безне «капчык»ка алдап кертергә, аннары, кысрыклап, юк итәргә уйладылар.

...Шумшу утравына ике чакрымга үтеп кергән Совет десанты гаскәрләре өстенә японнар егермедән артык танкларын җибәрәләр, бөтен көчләрен ташлыйлар. Безнең моряклар һәм пехота граната бәйләмнәре, кул пулеметлары белән танкларга каршы тора. Шумшу биш тәүлек буе ут эчендә кайный. Өстәмә көчләр килеп җиткәндә, отряд командиры Шутов икенче тапкыр яраланган була. Әмма ул командалык итүеннән туктамый. Моряклар аны, плащ-палаткага салып, урыннан урынга күчереп йөртәләр... Бервакыт дошман танкларының берсе шул плащ-палаткада яткан Шутов өстенә ажгырып килә икән. Ачык люктан япон флагы җилфердн, император Микадо портреты күренеп бара. Совет сугышчылары, командирларын коткару өчен, пулеметлардан, автоматлардан ут ачалар. Танк өстенә соңгы гранаталар оча. Әмма болар гына

ярдәм итми. Танк плащ-палатка белән инде тигезләшкән арада, татар егете Солтанов юлбарыс тизлеге белән самурай танкысы өстенә сикереп менә һәм ачык люк авызына автомат уты сиптерә башлый. Батыр якташыбыз десант отряды командирын үлемнән саклап, үзе һәлак була.

— Шунысына игътибар итегез,— ди Петр Иванович,— танк эчендә япон полковнигы утырган, кыюлык өчен ул үзе белән хатынын да алган булган. Самурай рухын белсеннәр, янәсе...

Шумшу дошманнан азат ителгәч, Куриль утрауларында сугыш хәрәкәтләре тагын бер атнага сузыла. Шутов отрядыннан сигез сугышчы Советлар Союзы Герое дигән почетлы исем алалар. Куриль каһарманнарының исемнәре хәзер дингез пароходларына, поселокларга, урамнарга бирелгән.

Сугышчан дуслары Петр Иванович Шутовны Герой исеме белән котларга килгәндә, ул, аның җуйган хәлдә, хәрби кыр госпиталендә яткан була. Отряд командиры соңгы һөҗүм вакытында өченче тапкыр яралана. Дошман пулясы бу юлы аның үпкәсен тишеп үтә.

...Курильда бүген чәчәкләр бәйрәме. Һәм безнең каршыбызда тере чәчәкләр — пионерлар утыра. Петр Ивановичның трибунага аяк басуга күз яшьләре белән дулкынлануы бик аңлашыла. Ул моннан чирек гасыр элек төтен, сөрем, ут эчендә, канга баткан килеш плащ-палатка өстендә ятып, командирлык вазифасын үтәгән чагында, терекөмештәй хәрәкәтчән бу нәни сабыйлар туар көннәр әле бик еракта булган. Әмма совет солдатлары аларның дөньяга киләсен белеп сугышканнар, шулар бәхете өчен үлемгә кергәннәр. Безнең алдыбызда киләчәк утыра. Алар бирегә тәпи йөреп киткәннәр, беренче тапкыр тозлы диңгез суын татыганнар. Океандай зур хыяллар белән яшиләр.

Район культура йортында очрашуга кадәр безне көндезге ашка чакырдылар. Ризыклардан сыгылып торган өстәлдә ит заты күренми. Һәммәсе диңгез хәзинәсе.

Райком секретаре безгә диңгез байлыклары турында кечкенә «лекция»дә укып алды.

— Кета, горбуша, сайра сезгә таныш инде,— диде ул, зәңгәр күзләре белән елмаеп карап,— ә менә «диңгез тарагы»ннан авыз иткәнегез юктыр, мөгаен. Аксымга иттән баерак. Монысы — диңгез керпесе. Икрасы — уникаль штука, «акканлылык» авыруыннан менә дигән дәва. Монысы — акфельция, диңгез үсемлеге. Аңардан «агар-агар» эшләп чыгарыла. Болай да ашарга ярый. Ул медицинада киң кулланыла, кондитер әйберләренә хуш ис тәме бирә. «Агар-агар»ның кечкенә кисәген сөткә салсаң, сөт шунда ук каймакка әйләнә...

Григорий Данилович, Көньяк Куриль районының ил балансында торган урыны турында да аңлатмалар бирде. Сахалин өлкәсен юучы Тын океан, Охота һәм Япон диңгезе суларында диңгез мәчеләре, диңгез арысланнары, нерпалар яши, кит балыкларының унбишләп төре очрый икән. Куриль тезмәләренә калан дигән диңгез җәнлеге иялашкән. Затлы һәм чыдам булуы ягыннан аның мехына тиңдәш юк.

— Калан кешеләрдән курыкмый, үзенә бер гаҗәеп «шәхес»,— ди Григорий Данилович.— Ул музыка тыңларга ярата, хәтта мелодия ритмнарына ияреп, биегән сыман кылана башлый. Калан мехы дөнья базарында алтын бәясенә йөри. Японнар бу кыйммәтле җәнлекне заманында кырып бетерә язганнар. Хәзер калан көтүләре безнең ярларга килеп сыендылар... Төньяк Куриль районын илебезнең балык цехы дип йөртәләр. Сайра балыгы бирегә генә тотыла. Районда берничә балык комбинаты, унбиш йөзмә консервалар заводы бар. Узган ел илле биш миллион банка консерва эшләп чыгардык. Җиде мең халкы булган район өчен бу аз түгел шикелле, ә?

Григорий Данилович сүз белән дә, табындагысы белән дә сыйлый белә. Официант урынына ул һәммәсен күбрәк үзе хәстәрләп йөри.

Кунашир утравында иген икмиләр, ә яшелчәне мул үстерәләр икән. Районда берничә терлекчелек совхозы бар. Халыкның туксан проценты балык промыселларында эшли.

— Җәйләрен, материктан килеп, студентлар акча «суга»,— ди райком секретаре, шаян бер тон белән,— әйдә, баесыннар, студент халкы өчен балыгы да, акчасы да кызганыч түгел. Менә шулай, океан уртасында, дөнья акулалары тирәсендә яшәп ятабыз.

— «Ут» күршеләрегез тынычмы соң? — дип сорап куйды Петр Иванович.

— Ничек дип әйтергә? Дәүләт күләмендә скандал булмаса, без моны тынычлыкка саныйбыз. Иң үрнәк дигән шәһәрдә дә җәмәгать тәртибен бозучылар булмыйча калмый. Ә японнар алар үтә кызыксынучан халык. Үзара килешү буенча, алар безнең яр буйларына килеп диңгез үсемлекләре җыялар. Аз гына сизмирәк калсаң, шунда ук балык сөзәргә дә тотыналар.

Райком секретаре кызык кына бер эпизод сөйләп алды:

— Японнар, Совет хөкүмәтенең рөхсәте белән, ел саен диярлек туганнарының кабере өстендә гыйбадәт кылырга киләләр. Утрауда иероглифлы кабер ташлары арткannан-арта бара. Бер япон «балыкчысы» безнең хәрби объектлар урнашкан зонага кабер ташы куярга тырышып карады. Анда аллабыз Аматерассуның иң бирелгән колы — минем изге әтием күмелгән дип бара бу. Изге дә булгач, әйдә, каберен башка урынга күчерергә рөхсәт итик, дидек. Казып карасалар — ат сөякләре килеп чыкты... Кыскасы, үзегез беләсез, табигать монда кырыс, өстәвенә, дәүләт чиге, ярым сугыш, ярым тынычлык... Шуңа карамастан, мин бу җиргә гашыйк,— ди Григорий Данилович, уйга бирелеп.— Мәскәү гостиницаларына тукталган чакта, иртән Куриль этәчләренең кычкыруын сагынып уянам.

Никулин үзе Барнаул ягында туып үсә. Бөек Ватан сугышында катнаша, Волхов фронтында каты яралана. 1950 елда ул комсомол путевкасы белән Сахалинга килә, ВЛКСМ өлкә комитеты аппаратында эшли. Ә 1953 елдан башлап берөзлексез Кунашир утравында, партия эшендә.

Көньяк Куриль культура йортында очрашу алдыннан безне кисәтеп куйдылар: культура сарае әле яңа салынып кына бетте, халык биргә йөрергә өйрәнмәгән. Җитмәсә, яңгыры сибәли башлады, хәерсез...

Әмма без барып кергәндә, клуб шыгрым тулы иде. Урын җитмәгәннәре стена буена тезелеп басканнар. Юбилей көне бит, ирләрнең күбесе — орден-медальләрдән. Райком секретаре иң алгы рәттә утырган сугыш ветераннарын президиум артына чакырды. Петр Ивановичның күңеле күтәренке.

— Кызлар, гүзәлләрем, бушаган урыннарга алга күчеп утырыгыз әле,— диде ул.— Мәскәүдә миңа Куриль кызлары ничек киенә икән, мыегыгызга чорнап кайтыгыз әле, дип үтенеч белдергән иделәр. Бер карыйм әле үзегезгә туйганчы!

Залдагылар елмаешып алдылар. Шутов шаяртуын дәвам итте.

— Мәскәү кызларыннан бер дә калышмыйсыз икән, гүзәлләрем. Мини-юбкаларыгыз белән хәтта уздырып та җибәргәнсез.

Бу юлы зал шаркылдап көлеп үк җибәрде.

Кичә күңелле рух белән башланып китте. Беренче булып Юксерн сүз алды. Ул Көньяк Сахалиндагы сугыш хәрәкәтләре турында сөйләде, үзе күргән, кичергән истәлекләр белән уртаклашты. Трибунага чыгарга миңа чират житкәч, Петр Иванович Шутов үтенеп кенә сорап куйды:

— Син бит татар шагыйре, дустым, туган телеңдә дә берничә

Татарча шигырьләр укуым бик урынлы булып чыкты. Тәнәфес арасында минем янга берәм-берәм якташлар җыела башлады. Башкорт, мишәр акцентын да, саф Казан арты сөйләмен дә сизеп торасың. Аларның күбесе Бөек Ватан сугышына кадәр үк Төньяк Сахалинда яшәгән, күмер шахталарында, балык промыселларында эшләгәннәр. Бөек атаулар туган илгә кире кайтарылгач, биредә яңа җирләрне үзләштерергә килгәннәр. Якташларым миннән өзгәләнеп татарча китаплар җибәрүемне сорыйлар. Кунак өендә озак уйный торган татарча пластинкаларлыгын белгәч, кичәдән соң алар безгә ияреп кайттылар.

Кичәнең иң зур тәэсир калдырганы — концерт өлеше булды. Аның программасы «Курильченочка» дип атала. Унлап кыздан торган (кызларның да иң чибәрләре!) бу ансамбль бер сәгать буе залны әсир итеп торды. Мин янәшәмдәге Петр Иванович Шутовка ара-тирә күз салгалыйм. Ул бар дөньясын онытып, авызын да җыя алмыйча, гел елмаеп утыра, һәммәсеннән дә ныграк кул чаба. Бер дигән баянчылары, биючеләре, профессиональ осталык белән моңлы итеп җырлый белүчеләре бар. Комсомол райкомы инициативасы белән оештырылган бу коллектив моряклар, пограничниклар арасында аеруча зур уңыш казанган, аларны атаудан атауга гел чакырып торалар икән.

Кичәдән кайткач, беренче этәчләргә кадәр күземә йокы кермәде. Тынгысыз океан сулышын тыңлап, очрашулар тәэсире белән исереп яттым мин. Кая барсаң да үз өеңдәге шикелле җылылык тоясың. Һәркайда тормыш үзенчә матур. Кешеләр күңелендә рухи иркенлек, дәрт күтәренкелеге ташып тора.

Сузып-сузып, моңлы итеп этәчләр кычкыра. Куриль этәчләре. Туган илнең беренче таңын уятучы бәхетле этәчләр....

Без икенче көнне Юксерн белән яр тирәсенә төшеп киттек. Аргы башта пограничниклар будкасы күренә. Су өстендә тиз йөрешле кечкенә катерлар күзгә чалынып кала. Тын океан бер дә тын түгел. Ак башлы дулкыннар, бер-берсен куып, актарылып киләләр. Аннары юашланып, ярга башларын салалар. Сары ком өстендә иероглифлар язылган берничә судно, японча әйтсәк, кавасакилар аунап ята. Бу суднолар, күрәсең, бирегә кунакка килмәгәннәр. Алар бу тирәдә дөньяның әле дә тыныч түгел икәнлегенә ишарә ясап торалар.

Юксерн табышлы булды. Кулына чәй тарелкасыннан зуррак ялтыравыклы әйбер тоткан да шуны баш очында уйната, үзе балалар сыман сөенгән.

— Диңгез тарагы! Табындагы без татып караган закусканың сандыгы бит бу!

Иң затлы сервиз тарелкаларын бер читтә торсын. Бернинди рәссам да мондыйны уйлап чыгара алмас. Кабырчыкның эче ак эмальдән дә аграк булып елкылдап тора.

— Тәмәке көле салырга кызганыч хәтта,— ди Юксерн, табышын һаман кулында әйләндереп.— Әллә дусларга бүләккә җыябызмы соң?

Без, «пепельница»лар җыя-җыя, яр буйлап киттек. Диңгез комы тыгыз, басканда аяк эзе дә калмый. Дулкыннар чыгарып ыргыткан тасма-тасма диңгез кәбестәләреннән дә күп нәрсә юк.

Океан киңлегенә карасам, миңа ни өчендер ямансу була. Кинәт ямьяшел урамнары белән Әлмәт күз алдыма килде. Кечкенә генә коену бассейны... Яшәгән, торган як, диңгезе булмаса да, шул тагарактай бассейны белән дә үзенә тарта. Безне унбер мең чакрым ара аерып тора. Шул ара ераклыгы, ахры, хисләрне нечкәртә. Туган илләреннән читтә, ят дөньяда адашып йөрүчеләр моны ничек кичерә икән?

Асфальт шикелле тигез, каты ком өстеннән «вездеход» томырылып кына бара. Тәгәрмәчләр тигән җиргә тия, тимәгән җиргә — юк. Прилив башланганын сиздереп, дулкыннар агымы һаман көчәя, машинаны текә яр арасына кысрыклый. «Чаптырып уза» алмасаң — «вездеход»ыңны калдыр да кыяларга үрмәлә. Шутовка мондый тизлек оший, күрәсең, күңеле шат. Шоферның сизелерлек борчылуын ул уен-көлкегә бора:

— Әйдә, бөтен компаниябезне бер коендырып ал әле, егет...

Ул инде чумасын чумган, аңа океан да тубыктан...

Диңгез уртасында басып торган кыяларга якынлашабыз. Гаҗәеп матур күренеш. Алар үзенчәлекле бер архитектура белән салынган корылмаларга охшаганнар. Арада мәчет манарасы кебеге дә бар. Аның биеклеге йөз метр чамасы булыр.— «Шайтан бармагы»,— диде шофер, шул якка күрсәтеп. Чыннан да, күзне чекерәйтебрәк карасаң, хәтта тырнагы да бар сыман. Океанда явызлыклар кылып йөргән бик зур шайтанны, җилкәсенә басып, тирән чоңгылга бастырганнар диярсең. Ә ул һаман үзенекен итә, су астыннан бармагын күрсәтеп булса да янавын белә...

Машина уңга борылды, калкулыкка күтәрелә башлады. Пограничниклар будкасы, шлагбаум янында, мотор тавышын күмәрдәй булып, звонок шалтыраганы гына ишетелде.

Погранзастава сопкалар арасында, яшеллек эчендә урнашкан. Диңгезгә чыга торган коридордан бөтен тирә-як күренеп тора. Артык зур булмаган мәйданда застава, клуб, ашханә, спорт мәйданы, тагын нинди-дер корылмалар. Ә казармалары моннан күренми. Түбәндә шарлавык елга агып ята. Өстеннән сыек пар күтәрелә. Аңа төрле урыннан вак кына чишмәләр килеп кушыла.

— Башта менә чишмәләр белән танышыйк, кадерле кунаклар,— диде кыемнарендә һәм хәрәкәтендә төгәллек, пөхтәлек сизелеп торган урта яшьләрдәге майор.— Мондый чишмәләр Камчаткада һәм Кунашир атавында гына очрый.

Юксерн беренче очраган чишмә белән «күрешергә» теләгән иде дә кулын тиз генә тартып алды.

— Биредә үрдәк пешекләргә була ич!

— Кызганычка каршы, Кунаширда йорт үрдәкләре дә, казлар да үрчеми,— диде майор, тыйнак кына елмаеп.— «Дальний» совхозында үрдәк фермасы оештырып караган иделәр дә, барып чыкмады.

— Ә сәбәбе?

— Үрдәкләр кырылып бетте. Кешеләр өчен шифалы булган сулар каз-үрдәкләргә ярамый, күрәсең.

Чишмәнең кайнарлыгы туксан биш градус икән. Аның составында күп төрле тозлар, тимер, күкерт, мышьяк матдәләре бар. Түбәндә, яр астында, дәвалану корпусы урнашкан. Ике пограничник егет, трусиктан гына калып, аякларын бассейндагы суга тыгып утырганнар. Монда хәрби булмаган кешеләр дә күренгәли.

— Застава мәйданында әллә шифаханә ачып җибәрдегезме? — дип сорады Петр Иванович, бераз гаҗәпкә калган тон белән.

— Вакытлыча бу,— дип аңлатты майор.— Үз белдегебез белән үзебез генә дәваланып карамакчы булган идек тә, даныбыз еракка китте. Мондагы минераль суларның шифасы Мацеста курортларыныкыннан бер дә ким түгел, диләр. Тире авыруларын ялап кына ала. Радикулиттан, ревматизмнан иза чигеп, таякка таянып килүчеләр берәр айдан таякларын онытып кайтып китәләр. Саф су белән кушып эчсәң, ашказаны өчен дә әйбәт. Кеньяк Куриль балыкчыларын да дәвалыйбыз. Хәтта Владивосток, Хабаровск кебек шәһәрләрдән путевка сорап яза башладылар.

Бирәдә берничә җирдә эзләнү, бораулау эшләре үткәрелде, яңа чыганаклар таптылар. Кунаширда киләчәктә зур курорт базасы булдырылачак.

Утрау халкы белән пограничниклар чиксез дус һәм бердәм яшиләр. Монда һәр балыкчы — пограничник. Ә пограничниклар исә, диңгездә «урак өсте» житсә, үз чиратларында балыкчыларга ярдәмгә киләләр. Монда һәрнәрсә сакта: диңгездәге эреле-ваклы кыялар, урмандагы тез наратлар... Куе камышлар да чит авазны бик тиз тотып алалар. Житмеш чакрымнан өскә авардай булып күренгән «Тэтэ-яма» вулканы да гүя алмашсыз каравылга баскан. Сизгер колаклы радиолокаторлар океанның кайсы квадраты өстендә нинди ил самолетлары тыкшынып йөргәнен минуты-секунды белән хәбәр итеп торалар.

Погранзаставаның хәрби батырлык музеенда сатлык шпионнардан, диверсантлардан салдырып алган трофейлар аз түгел. Хәзерге техниканың соңгы ачышлары, төрле маркадагы электрон аппаратлар, микрорадиоалгычлар, тавышсыз ата торган пистолетлар куелган. Райком секретаренең «ярым сугыш, ярым тынычлык» дигән сүзләренә бик ачык дәлил болар. Майор безгә «амфибия» коралларын күрсәтте. Бер диверсант су астыннан Кунашир бугазы аша йөзеп чыгарга уйлаган. Теләгенә ирешкән, ләкин ул безнең пограничниклар кулына килеп капкан.

Отрядның үз тарихы, сугышчан традицияләре бар. Ул, Украинаның башкаласы немец фашистларыннан коткарылгач та, 1943 елда Киев шәһәрендә оештырылган, һөҗүм итүче совет гаскәрләре составында сугышып, Румыния, Болгария җирләрен азат итүдә катнашкан, Богдан Хмельницкий ордены белән бүләкләнгән. Пулялардан челтәрләнгән, сугышчан орден беркетелгән байрак Кунашир атавына күчеп килгән. Автоматлар белән коралланган пограничниклар, очрашу вакытында шул байракны клуб сәхнәсенә чыгардылар. Зал, аягүрә басып, тын калды...

Безнең каршыбызда яшел гимнастерка кигән, чәчләре төптән алынган житди карашлы егетләр утыра. Һәркайсының күкрәгендә — ВЛКСМ значогы. Дүртәр-бишәр төрле значок тагып куйганнары да күренә. Майорның әйтүенә караганда, күбесе урта мәктәп тәмамлаган егетләр. Ә офицерлар — вуз белеме белән. Арада фән кандидаты да бар икән.

— Бигрәк яшь күренәләр,— ди Юксерн, залда утыручыларга ихлас ярату, көнләшү тойгысы белән күз йөртеп.— Алар яшендә без дә шундый «сары томшыклар» булдык микән?

Миңа да шулай күренәләр. Мөгаен, оныткапбыздыр: унсигез яшьтә кулга мылтык тотып, ике дөнья сызыгына, Амур буена ил сагына басканда, мин дә алардан «солидныйрак» күренмәгәнмендер, әлбәттә. Егерме яшендә ВЛКСМның Мари өлкә комитеты секретаре булып эшләгән Юксерн, Кызыл Армия сафына алынгач, артиллерия дивизионы комиссары итеп билгеләнә. Егерме яшьлек комиссарны күз алдына китерик инде? Онытканбыз гына. Ил язмышын үз инебезгә алганда, без дә шундый малайлар гына булганбыз...

Еракта калган, кире кайтмас яшьлегебез утыра залда. Без бүген гүя үз гаиләбездә. Ни сөйләшсәк тә буладыр шикелле. Ләкин күңелдә туган тойгыларны гади генә итеп аңлатып кара син! Кырык ел гомерен солдат язмышы белән уртаклашкан Петр Иванович Шутовка күз салам мин. Аның йөзе тантаналы, кара күзләре очкынланып балкый. Ул, озын гәүдәсе белән чайкалып, автоматлы пограничниклар янына атлады, каршыларында тукталып, бераз уйланып торды. Аннары берәм-берәм аларның маңгайларыннан үбеп чыкты. Шутов истәлекле байрак янына килде, бер аягы белән идәнгә тезләнеп, кояшта, җилдә унган, сугыш сөреме сеңгән байракка иреннәрен тидерде. Залда үлем тынлыгы урнашты. Бу егетләрне хәзер тиңдәшсез батырлыкка күтәрү өчен

шутовның, мөгаен, бер сүзе дә житәр иде. Ул бик гади генә итеп болай диде:

— Туган ил традициясенә турылыклы булыгыз, иптәшләр!

«Сары томшыклы»лар ирләрчә калын, житди тавыш белән җавап бирделәр:

— Совет халкына хезмәт итәбез!

Кунашир — айну телендә «яхшы жир» дигән сүз. Элек-электән айнулар торган бу жирдә. Японнар аларны кысрыклап, нәселләре белән кырып бетергәннәр. Үзләре булмаса да, сүзләре калган: «Тэтэ-яма», «Кунашир»...

Кунашир белән саубуллашканда көн кояшлы, хәтта изүләрне чишеп кибәрердәй эссе иде.

Менделеевск вулканы сизелер-сизелмәс кенә көйрәп, төтен бөркеп утыра. Түбәсе шыр ялан, ә итәкләре ара-тирә урман белән капланган. Без самолетка кереп утыруга, кинәт «четеррр...» иткән тавыш ишетелә башлады. Барыбыз да берьюлы артка борылып карадык.

— Пикадо! — диде ишек тирәсендә утыручылардан берәү. Япон чебене очып кергән икән. Озынлыгы бармак буе булыр, канатлары, сөял төшле торган зур чикерткәнеке шикелле, яшел. Бер абзый аны эшләпәсе белән бәреп төшерде дә пыяла банка эченә салып куйды.

Самолет Камчатка ягына юнәлеш алды.

— Сау бул, Кунашир — Яхшы жир!

...Түбәндә иксез-чиксез зәңгәр киңлектә, ереле-вaклы атаулар, ялгыз кыялар күренеп кала. Куриль утраулары «чылбыры» Камчаткадан алып Япония Хоккайдосына кадәр — мең дә ике йөз километрга сузылган. Ул Охот диңгезен Бөек Тын океаннан аерып тора.

Япония узган гасырның урталарында, Россиянең Кырым сугышында көчсезләнеп калуыннан файдаланып, Куриль утрауларын үз кулына төшерә. Шулай итеп, Тын океан киңлекләренә богау салына. Россия флагы астында йөзгән корабларга иркенлек бетә. Фәкать 1945 елның август—сентябрь айларында гына бу тарихи гаделсезлеккә чик куелды...

Репродуктордан, гадәттәгечә, бик ягымлы хатын-кыз тавышы ишетелде:

— Кадерле пассажирлар! Тиздән Утуруп атавы. Безнең белән бергә, шушы самолетта Куриль утрауларының почетлы гражданины, Советлар Союзы Герое Петр Иванович Шутов оча...

Шутов үз фамилиясен ишетүгә, кинәт йокысыннан айнып, минем якка борылды:

— Нәрсә, нәрсә? Миңа бер кыз дәште түгелме? Әллә төшемдә генә күрдемме ул кызны?..

Шулай сөйләнә-сөйләнә, ул колагындагы ак «бөке»ләрне тартып чыгарды. Игътибар белән күпме тыңлап караса да, андый ягымлы тавыш башка ишетелмәде.

Утуруп аэродромына туктагач, без, такси алып, Касатка култыгына бардык. Шушы урыннан, биек кыялар арасыннан яктәшыбыз Әсгат Жиһаншин командасындагы каһарманнарны океан давылы «урлап» китә. Дәһшәтле стихия көчләре белән кырык тугыз көн буе дәвам иткән тиңдәшсез алышта алар жиңүче булып чыгалар. Үз гомереңдә аз күргәнмени син, Тын океан, андый батырлыкларны! Сугыш каһарманнары-ның берсе менә безнең арабызда. Ул океан култыгы ярына баскан да бизәкле кечкенә кульяулыгы белән маңгай тирен сөртеп тора. Аның уйчан, еракка төбәлгән карашында канәгатьләнү билгесе: Совет флагы өчен Бөек Тын океан капкасы мәңгегә ачык!

Александр Малов

# ТӘВӘККӘЛЛЕК



"Кирәк тирәкне ега», дигәннәр. «Иркеннефть» идарәсе дә «Машиноимпорт» Бөтенсоюз берләшмәсе аша Австриянең «Даагнер Зиро» фирмасыннан ике завод сатып алырга тиеш булды. Бездә аларны тыйнак кына итеп «установка» дип атадылар.

Нефть идарәсе мондый адымны мәйданында нефть суланганга шулай эшләде. Катлам сулары белән бергә «җир мае»на тозлар да эләгә. Шул рәвешле, «кара алтын»ның сыйфаты түбәнәя. Бу нефтьнең экспортка да китүен искә алсак, хәлнең тагын да четрекләнә төшүен аңлау читен түгел. Алучы яхшыны сорый, чөнки арзанның күбеннән асылның азы артык.

Контрактта каралган шартлар буенча, фирма җиһазларның техник характеристикасын гарантияләде һәм моны тәэмин итү өчен монтажга, җибәреп карауга һәм соңгы сынауга җитәкчелекне үз өстенә алды. Моның өчен «Иркеннефть» промыселлары идарәсенә үзенең белгечләрен, аларча әйткәндә, шеф-инженерларын җибәрде.

Җиһазларның соңгы партиясе алынганнан соң, фирма утыз ай дәвамында җиһазларның югары сыйфатлы булуын гарантияли иде. Гадирәк әйтсәң, болай дигән сүз: яхшы товар алырга ниятләгән булсаң, монтаж эшләрен кыска тот, фирма работникларына установканың эшләү сәләтен исбатлар өчен ким дигәндә өч ай вакыт калырлык булсын.

Заказчы идарәнең исәбе буенча, установка май аенда эшли башларга тиеш иде. Ә «Даагнер Зиро» белгечләре бу срокка ышанмыйча карадылар, янәсе, установканың контурларын да чамалап булмый әле, срок хакында сүз алып бару — үзе сәер. Кая карама — казып, актарылып ташланган балчык та таш...

Әмма безнең төзүчеләр эшне шундый көйләп җибәрделәр, фирма инженерлары, әгәр болай барса, май ае реаль срок булуы бик ихтимал, дигән фикергә килделәр.

Тик шул чакта ике якның да исәпләрен чәлпәрәмә китергән хәлләр килеп чыкты.

«Иркеннефть» промыселлар идарәсе начальнигының урынбасары Константин Георгиевич Тамадеев[1] һәр нәрсәнең төбенә тоз коярга яратучан инженер. Кеше бавы белән коега төшә торганнардан түгел, һәммәсен үз күзеннән үткәзә, үз кулыннан үздыра. Һәр узелны, һәр агрегатны тикшерми калмый. Шуңа аның холкыннан дустанә көлеп: «Эшкә килгәндә бу осетин — койган да куйган татар безнең. Тотып карамыйча ышанмый».

Шундый булу да бик кирәк икән шул! Нефть стабилизацияләү колоннасын тикшергәндә (бу шактый авыр һәм күләмле корылма) «татар» Тамадеев колонналың эченә

---

[1] Кайбер фамилияләр үзгәртеп бирелә. (Ред.)

колонна эченә төкәлде. Шуннан соң монтаж буенча шеф-инженерны чакырды:

— Шварц әфәнде, колонналарның эче дөрес ясалмаган.

Югары квалификацияле инженер, төзелеш мәйданында һәр нәрсәнең проект буенча төгәл монтажлануы өчен җавап бирүче тәҗрибәле белгеч Макс Шварц аптырый калды. Рус коллегасы кайда ялгыш таба алды икән?

— Һиер аллес рихтиг, все правиль-но, һерр Тамадеев,— диде ул, икеләнергә җай калдырмый торган итеп.

Константин Георгиевич бер мизгелгә генә күзләрен йомды һәм газ-бензин, нефть куу заводларындагы колонналарның тарелкалары ничек урнаштырылуын хәтеренә китерде. Шулай ук ялгышамыни соң ул?! Юк ла, юк, тарелкалар туксан градуслы почмак ясап борып куелган булырга тиешләр.

— Юк, Шварц әфәнде,— диде ул, кырт кисеп.— Сез эшләгәнчә түгел...

— Боларның сызымнарын,— дип карулашты Макс Шварц,— безнең фирма Америка белгечләреннән эшләтте, о-о-о! — Шварц, үз сүзенә куәт өстәп, уң кулының баш бармагын тырпайтып күрсәтте: — Високий класс шпециалист!..

— Мин аларны яманларга җыенмыйм,— дип каршы төште Тамадеев, ә эченнән: «Ник шунда теләсә кай җирләрен үпмисең, анысы үз эшең, безнең дә бит ике җилкәбездә бер баш бар! дип куйды»,— тик монда хата киткән. Тарелкалар, әлбәттә, агымга туры почмак ясап торырга тиешләр...

Шварц килешергә мәҗбүр булды. Шулай да, бу эшнең үзенә турыдан-туры кагылмавына сөенде. Үзгәртеп ясау котылгысыз, әмма ул аның счетына һәр көнне керәп бара торган егерме сигез доллар хезмәт хакына зыян салмый ич! Әнә шеф-инженер Эдуард Розенкранц тынгысызлансын.

Розенкранц фирма белгечләре арасында иң зирәге, алдан күрә белүчесе. Ул Югославиядә шундый ук установканы монтажлауда һәм эшкә җибәрүдә тәҗрибә туплаган кеше. Колоннадагы хатаның ни дәрәҗәдә житди икәнен бик тиз бәяләде. Яңадан сүтү, установканы эшләтә башлауны кичектерү, «Иркеннефть» житәкчеләренә аңлату газабы, һәм, ниһаять, фирма өчен көтелмәгән чыгымнар дигән сүз бу. Менә сиңа авторитетлы проектантлар! Акт төзеп, аның копиясен бүген үк Америка фирмасына җибәрәчәк. Руслар бирәчәк счетны аннары юллар. Тегеләр тартыга тибә башласалар,— ул затсызлардан теләсә нинди этлек булыр,— халыкара арбитражга мөрәҗәгать итәчәк. Шулай итмәсәң, кесәңнән җиллә исәсен көт тә тор. Аның семьясы, бала-чагасы бар. Үзе бар, килер көне алда.

Демонтажда һәм колонналарны сүтеп җыюда «Даагнер Зиро»ның барлык белгечләре дә эшләде. Моның белән алар колонналарны үзгәртеп эшләү өчен руслар сораячак хакны киметергә өметләнделәр, фирмага мәгълүм җиңеллек эзләделәр. Ләкин «Машиноимпорт» вәкиле Герасимов аларга бик мөлаем гына болай дип төшендерде:

— Демонтажда үзегез эшләгәнсез икән, әфәнделәр, димәк, сез турыдан-туры үз эшегез белән шөгыльләнә алмагансыз. Килештегезме? Без, әлбәттә, счетны яңадан яза алабыз. Ул чагында сезгә монтажчы эшчеләрнең тулы хезмәт хакын түлибез, ә шефлар буларак бер цент та алмаячаксыз...

Розенкранц артык бәхәсләшмәде. Инженер-шеф буларак, ул түләгенә ун сум чыгымнарына ала. Һәм моның өстенә аңа көн саен утыз доллар түлиләр иде. Ә монтажчы буларак... Юк, юк! Андый данның мәгънәсе сукыр бер тиен!

Сыкрап-сыкрап булса да ул алты мең долларлык актка һәм счетка кул куйды. Тик коммерсант акылы җәһәт исәпләп алды: шул суммага русларга запас частьлар һәм җиһаз сатып булмасмы? Шул кадәресе насыйп булса, кесәдән акча чыгарып бирәсе түгел ич!

Колонналарны рәтләдек дигәндә генә тагын бер күңелсезлек килеп чыкты: бу хәлендә отстойникларның производство технологиясен тәэмин итә алмаячагы мәгълүм булды. Һәр отстойникның бүлгечләрендә өчәр мең тишек бораулап тишәргә кирәк иде. Ә отстойниклар утызау! Эшне тизләтү өчен аларны, демонтажлап, якындагы механика заводына алып киттеләр. Шеф-инженер әфәнде исә бу юлы бер кая да, беркемгә дә иза алмады, чөнки отстойниклар фирманың үз сызымнары буенча төп-төгәл эшләнгән иде.

вакытны җилгә очырды. Күпне күргән эш кешесе Эдуард Розенкранц иллюзиягә бирел мәде. Гәрчә ул «вакыт-акча» дигәнне бөтен тирәнлеге белән аңласа да, сәгатенд тота алмасаң, көнендә тота алмассың дигәнне дә яхшы белә иде. Бу сезонда вакытны кулдан ычкындырдылар булып чыкты!..

Иртәгесен ул нефть промыселлары идарәсе начальнигы янына килде. Курешкәч ү сүзгә кереште.

— Һерр Колесин, сездә ничек диләр әле, мин личный бер мәсьәлә белән...

Колесинның вакыты бар иде. Кәефе дә әйбәт. Шунлыктан шаяртып җавап кай тарды:

— Өйләнергә җыенасызмы әллә, Эдуард Эдуардович?

Розенкранц сүзне бик тиз борып алырга исәп итте:

— О-о, мондый ахмаклыкны мин күптән эшләп өлгердем шул инде. Алты балам бар. Гафу итегез, сезнекеләр ничәү, Виктор Михайлович?

— Мин сездән күпкә калышканмын. Беләсез бит, әүвәле — сугыш, аннары уку...

Розенкранц та сугышта булган. Ихлас күңелдән дөрес әйтүе булса, танкист икән һәм сугыш азагында гына Балтик буенда өч ай чамасы сугышкан. Яшьлегенең иң матур елларын Франциядә, оккупацион гаскәрләр сафында үткәргән. Ходай теләгән кабул иткән (ул аллага ышана), сугыштан соң белгечлеге буенча хезмәткә урнашкан. Әйбәт һөнәр! Соңгы елларда нефтехимия бик киң колач җәя, аның гомеренә эш җитәчәк... Эше шәп, дөнья күрә торган. Акчасы да ишәя тора. Фирмадагы хезмәтеннән тыш, Эдуард Розенкранц үзенең акцияләреннән дә мая туплый. Ул бит «Даагнер Зиро» фирмасының акцияләр тотучысы. Фирманың эшләре җайлы икән, Розенкранцның да кереме арта дигән сүз. Олыгайгач, картая башлагач, Эдуард үз иленә кайтып, Остеррайхта төпләнер һәм мал-мөлкәт белән имин гомер кичерер. Әмма фани дөньяның иртәгә калдырмавың хәерлерәк булган мәшәкатьләре дә бар. Ошбу гүзәл замандагы керемнәре Розенкранцка җанын һәм тәнен ял иттерергә зур мөмкинлек бирәләр. Кыскасы шул: Виктор Михайлович каршы килмәсә, ул бер-ике атнага Кавказга, Кара диңгез ярына барып кайтмак була. Аның француз Ривьерасында да, Рига яр буенда да булганы бар. Тик сугыш елларында иде бу. Адриатика ярларында күптән түгел генә, заводны монтажлагачда булды. Командировкада чакны файдаланып калмасаң, Кавказга махсус килү, ай-һай, булырмы?

— Виктор Михайлович,— диде Розенкранц сүзен түгәрәкләп,— без — бер буын кешеләре, икебез дә солдатлар, сугыш аркасында күп нәрсәдән мәхрүм калдык, бәйтакны кулдан ычкындырдык. Мине аңларсыз һәм ялга китүемә тоткарлык ясамассыз, дип уйлыйм...

«Күп нәрсәдән мәхрүм калдык, имеш... Ә соң сез, акционер җәмгыятендә член булып торучы әфәнде, нәрсәдән мәхрүм булдыгыз икән?» — дип уйлап алды Колесин.— Ә үзе эш кызу барган вакытта приборлар белгече Джеймс Вартумны өтисен күмәргә дә җибәрмәскә теләгән иде. Үзенә кирәккәч, тоткарлык ясамассыз дип сайрый...»

Шулай да Виктор Михайлович Эдуард Розенкранцка ял бирергә ризалашты.

Сентябрь урталарында Колесин Әлмәттә «Татнефть» берләшмәсенең баш инженеры Грайдов яныннан кайтып килә иде. Тирә-юньдәге көз сулышын әле генә тойгандай, ул авыр сулап куйды. Көз, җиз-сары буяулар, әбиләр чуагында очкан челтәр-пәрәвезләр, шаулап яфрак коелуы — һәммәсе тиздән җитәчәк кышның хәбәрче-чапкыннары. Ә установканы язын, әйтик, май аенда җибәрү ничек яхшы булыр иде дә бит, никал итәсең?! Яңадан төзәтеп ясаулар аркасында монтаж күпмегә сузылды, хәзер инде менә шеф әфәнделәр ходка җибәрүне сузалар. Һава җибәргечләргә краннар ясарга кирәк, отстойникларның капкачларын җылылык изоляцияләү белән тәэмин итү зарур... Болар проектта каралмаган, әмма шеф әфәнделәрнең җавабы бер: «Сездә кырык градуска җиткән суыклар була. Безнең фирма, моны белә торып, андый тәвәккәллек эшли алмый.»

Баштарак чит ил белгечләренең үз эшләренә искиткеч төгәллек белән караулары һәркемгә ошый иде. Ләкин төгәллеккә һәм пөхтәлеккә мәхәббәт мәгънәсез педантизмга әйләнә башлагач, бу хәл ачу китергечкә әверелде. Көннәр, атналар үтә тора, ә промы-

кире кага торалар.

«Установканы эшләтеп карау, житештерүчәнлекне, товарлыклы нефтьтә су һәм тозлар юклыгын исбатлау,— дип язылган контрактта,— «Даагнер Зиро» фирмасы белгечләре житәкчелегендә үткәреләчәк». Шуңа таянып булса кирәк, фирма белгечләре установканы язга кадәр консервацияләргә исәплиләр. Сентябрь азагы житкәч, әйтәчәкләр: «Установканы режимга куяр өчен 72 көн кирәк. Ә суыклар житәргә ике айдан да кимрәк вакыт калды,— диячәкләр. Эшләтеп карауны көннәр ныклап жылыткачны кичектерергә тәкъдим итәчәкләр.

— Ю-ук! — диде Виктор Михайлович үз-үзенә.— Болай барып чыкмый, әфәнделәр. Димәк, установканы җибәрү мәсьәләсен шушы атнада хәл кылырга кирәк. Иртәгә үк!

Киңәшмәдә шеф-инженерны установканы тизрәк җибәрүгә күндерә алмадылар. Розенкранц, ниһаять, отстойникларның люкларын жылыту чарасын күрүгә керешә. Виктор Михайлович аңа текәлеп:

— Ышаныгыз, Розенкранц әфәнде, ул кирәкмәячәк. Безнең илдә люкларны бер кайда да жылытмыйлар, томаламыйлар. Әйдәгез шуларсыз гына килешик,— диде.

Эдуард Розенкранц мөгезен җиргә терәгән үҗәт үгездәй иде.

— Теләктәшлегем бик зур булса да, килешә алмыйм, һерр Колесин,— диде ул, сабыр гына.— Безнең фирма моңа бара алмый. Проект заданиесендә кырык градуска кадәр суыклар булу күздә тотылмаган...

Идарәнең баш инженеры Борис Федорович Зубанов Колесинга үз карашын сөйләде.

— Розенкранц ризалашмаячак,— диде ул, кырт кисеп. Чөнки шеф-инженерның холкын-фигылен шактый нечкәләп өйрәнергә өлгергән иде инде ул.— Аның минус температурада установка җибәрү тәҗрибәсе бөтенләй юк. Тиешле срокта режимга чыгара алмавыннан курка, әйтик, мичләрнең куәте житмәде, ди... Ә бит контрактта техник мәгълүматлар тиешенчә булмаса, безнең бәяне киметүне таләп итүебез ихтималы да каралган. Ун процент исә безнең кулда әле...

Бераз тын утырдылар. Аннары Виктор Михайлович Зубановны икенче төрле үгетли башлады:

— Дусларча сөйләшеп кара әле син аның белән, Борис Федорович. Джентельменнарча сүз бир, установканы җибәреп карау уңышсыз чыкса да, сезне чишендермәбез, дигән. Бәлки килешер?

Борис Федорович начальнигына сәерсенебрәк карады.

— Килешер дисеңме? Капиталистмы? Хосусый милекчеме? Булмас нәрсә белән баш катырасы да юк. Үзенең җылы урыны белән, фирманың мал-мөлкәте белән санашмыйча килешәме соң? Һич юк! Бер домкрат аркасында ни булганын гына хәтерлә. Тау-тау җиһазлар арасыннан ярты ел эзләсә эзләде, ялгыш кайткан домкратны безнең хисаптан кире Австриягә җибәрде ләбаса! Фирма рөхсәтеннән башка безнең белән килешмәячәк ул...

Шул көнне кичен үк Австриядәге «Даагнер Зиро» фирмасының генеральный директорына халыкара телеграмма суктылар.

Фирма башлыгы белән сөйләшүләрне рәсми сөйләшү белән иптәшләрчә чәй эчү арасындарак уздырасы иттеләр. «Даагнер Зиро» фирмасы директоры Ульрих Лютер әфәндене шәһәр читендәге кечкенә гостиницага кичке ашка чакырдылар. Директор монтажлау мәйданындагы эшләр белән ике көн буена танышырга өлгергән иде инде.

Кунакны бүлмәгә җыелган кешеләр белән таныштырганнан соң, мәҗлес башлыгы буларак, Виктор Михайлович һәммәсен өстәл янына чакырды. Ә «Татнефть» берләшмәсенең баш инженеры Валерий Исакович, алдан килешенгәнчә, хөрмәтле кунак хакына беренче тостны тәкъдим итте, аның фирмасының эше уңышлы булуын теләде һәм директор әфәндене килүе фирма белән «Иркеннефть» промыселлар идарәсе арасындагы үзара мөнәсәбәтләрнең тагын да яхшыруына китерер, дигән ышаныч әйтте.

Лютер әфәнде моның белән килеште һәм рюмкасын күтәреп иренен чылатып куйды. Аның сак кыланышыннан үк иптәшләрчә сөйләшүнең бик үк барып чыкмасын

юк, сәламдә бурычлык юк тәслерәк килеп чыкты. Лютер әфәнде безнекеләрнең хәлен бик аңлаган тәсле сөйләсә дә, азактан:

— Әфәнделәр, сез бит установканы җибәрүгә әзер түгелсез.

Безнең иптәшләрнең үз фикерләрен кыю дәлилләүләре фирма директорын гаҗәпләндерде, хәтта ачуын да чыгарды, чөнки ул үзләрендә башлыкның «әйттем — беттел» дип эш итүенә күнеккән. Шуңадыр, сөмсере коелып:

— Сез мине кем дип беләсез, әфәнделәр! — дип рәнҗи башлады.

Барысы да көн кебек ачык иде: директор әфәнде үз белгечләренә установкаңны кышка каршы эшкә җибәрергә рөхсәт итмәячәк.

Шуннан соң Грайдов бик нәзакәтле, әмма суык кына:

— Нихәл итмәк кирәк, директор әфәнде. Теләмисез икән, без ходка җибәрербез,— дип җавап бирде.

Шеф-директор тиз-тиз кисәтеп калырга ашыкты.

— Бөтен җаваплылык сезнең өстә булачак.

— Әлбәттә, директор әфәнде.

— Шуны истә тотуыгызны үтенәм, без установканы җибәрүдә катнашмаячакбыз.

— Сезнең ярдәмнән башка да ерып чыгарбыз.

Фирма башлыгының миссиясе тәмамланды. Ульрих Лютер әфәнде иртәгесен Венага китте. Ул бик гарьләнгән иде һәм Бөгелмә аэропортында саубуллашканда, мондый вәгъдә бирде:

— Сезгә кинокамера җибәрермен. Хуҗаларның акылсыз хәрәкәтләре нәтиҗәсендә завод җимерекләр, хәрабәләр өеменә әйләнгәч, минем бүләгемнән дә файдаланырсыз.

Розенкранц әфәнде моны бик теләп эшләячәген әйтеп, биленә кадәр бөгелеп, баш иде.

Ә аэропорттан кайткач, үзенең язу машинкасында өч экземпляр итеп хат язды. Ул үзенең хатында безнең белгечләрнең установканы җибәрү өчен билгеләгән срокларын нигезсез дип күрсәтте һәм ихтимал булган күңелсезлекләр өчен үзләренең җавап бирмәүләрен әйтте, дефектларны бетерү чыгымнарын «Даагнер Зиро»ның үз өстенә алмавын белдерде. Хатның бер экземплярын «Мәскәү, Неглинная, «Машиноимпорт»ның Бөтенсоюз берләшмәсенә» дип, икенчесен «ТАССР, «Иркеннефть» НПУсына» дип адреслады. Өченче экземплярын исә, немецларга хас пөхтәлек белән, үзенең эш кәгазьләре папкасына теркәп куйды.

— О-о-о! — диде ул,— бу досьеның бик кирәк булуы бар әле!

Фирма директоры киткәч, «Иркеннефть» идарәсе парткомының киңәйтелгән утырышы булды. Аны секретарь Әнвәр Мусин ачты.

Виктор Михайлович Колесин җитди борчылу белдерде.

— Фирма белән төзелгән контрактка Идарә дә, Берләшмә дә кул куймаган бит,— диде ул.— Димәк, алар килешү шартларын боза алмыйлар. Лютер әфәнде, «Машиноимпорт»та сөйләшеп, безнекеләрне консервациягә күндермәгәе...

Валерий Исакович аның сүзен куәтләде.

— Виктор Михайлович хаклы. Аңлатып хат язарга кирәк. Ни өчен консервациягә бара алмавыбызны дәлилләргә. Һәр пунктны аерым нигезләп, бүген үк язарга кирәк. Мин кул куярмын.

Ул дәлилләр, башлыча, түбәндәгеләргә кайтып кала иде:

Нефтьнең сулану масштабы арта.

Казан органик синтез заводында дүртенче кварталда яңа производство эшкә башлый. Стабилизация продукты кирәк. Установка куәтенә исәпләп план да бирелде.

Әзер установканы консервацияләү алтын йомырка салучы тавыкны сую белән бер булыр иде. Кыш буена ул өч миллион тонна нефть бирәчәк.

Установканы җибәрмәсәк, мөгаен, кышын аңа суык зыян китерер.

Чигенү юллары киселгән. Котылу чарасы — кыю алга бару. Фирма белгечләреннән башка җибәрүгә әзербез, бөтен җаваплылыкны үз өстебезгә алабыз.

өчен тәҗрибәле белгечләр генә җитми җитүен, шефларга ышанган идек бит. Алар установканы җибәрүдә катнашудан баш тарткач, безгә ярдәмгә тәҗрибәле инструкторлар группасы җибәрүне үтенәбез.

Октябрь кердe.

Мәскәүдән Галина Ивановна Краматорова җитәкчелегендә «Оргнефтезавод»тан белгечләр группасы килде. Ул иптәшләр дә, «Иркеннефть» кешеләре дә установканы җибәреп карау көнне дулкынлануларын яшерә алмадылар. Объектның «баш куратор»ы Борис Зубанов аерата дулкынланды.

Менә беренче блокның җылыткыч мичен кабызырга команда бирелде. Краматорова командасын Борис Зубанов белән Константин Тамадеев та кабатладылар.

— Я, Фая,— диде Травцов үзенең шәкерте Вәлиевага,— кабыз!

Ялкын телләре биеште, ут көчәйгәннән-көчәя барды, мич үкереп яна башлады һәм көмеш төсенә буялган морҗа өстендә сизелер-сизелмәс рәшә тетрәнде.

Травцов, мич режимын күзәтеп торды да:

— Молодец, Фая, булдырдың! Шулай дәвам ит,— диде.

Кыз үзенә төшкән зур җаваплылык хисеннән айнырга да өлгермәде, каяндыр фирманың мичләр белгече Петер Минш килеп чыкты һәм кулларын селки-селки кычкыра башлады.

— Останови-ит! Ауслешен! Капут!

Аның бүтәннәргә мөрәҗәгать итеп тә тормыйча турыдан-туры операторга ярсынып кычкыруыннан ниндидер җитди эш килеп туганлыгы аңлашыла иде. Ләкин нәрсә булган? Аңлар хәл юк. Вәлиева аның сүзенә карап мичне сүндерә алмый иде, ул Травцовны чакырды.

Рус һәм немец сүзләрен бергә бутап, Петер мич змеевикларындагы су тамчыларын күрсәтте.

— Вассер, капут, пиечка, вода!

— Кайда капут күрәсез? Металл тирли. Конденсирен, аңладыгызмы? Беләсезме, камрад, аяк астында буталмагыз әле,— диде Травцов, ачуы кузгалып.

Агрегатларның режимын һәм нагрузкасын үзгәртә торып, берничә тәүлек тоташтан установкага обкатка ясадылар. Бу көннәрдә Константин Тамадеев, технолог Әгъләм Сәлимов, өлкән инженер Анатолий Богомаз, механиклар Рәшит Дәүләтхуҗин, Михаил Травцов һәм Владимир Большагин, вахта автобусында өйләренә ярты сәгатьтә кайтып җитәрлек булса да, установкадан китмичә яшәделәр. Ходка җибәреләторган химик производствода дежур тору бала табучы ана янында булу белән бер. Монда төзәтеп булмаслык хәлнең минут эчендә килеп чыгуы бар...

Системага нефть кабул итү шимбә көнгә билгеләнде. Җылы алыштыргычлар майданчыгыннан тулы әзерлек турында хәбәр иттеләр.

Борис Федорович дистәләгән җиргә шалтыратты һәм, идарә итүне Галина Ивановнага тапшыргач, соңгы боерыкларны бирде:

— Янгын сүндерү машиналарын якын китерегез һәм мичләр белән электрогидраторлар арасына куегыз!

— Насосларны чимал кабул итүгә хәзерләгез!

Борис Федорович товар паркы белән элемтәгә керде һәм андагы начальник Владимир Мәрдәновка дустанә эндәште.

— Көткән минут килеп җитте, Володя. Тарихи задвижканы ач. Хәерле сәгатьтә!

Җибәрүгә хәзерлек чорында Борис Федорович Зубанов катгый кисәтеп куйган иде. Бу задвижканы аның рөхсәтеннән башка бернинди шартта да (хәтта министр Валентин Дмитриевич Шашин үзе таләп итсә дә) ачмаска.

Мәрдәнов, зарыгып көткән минут җитүенә куанып, җавап бирде.

— Есть! Чимал бирергә! — Ул, цехның комсомол бюросы секретаре Петр Давыдов белән бергә, приказны үтәргә юнәлде.

Идарә пультына нефтьнең тозсызландыру схемасы буенча үзып җылы алыштыргычлар, отстойниклар аша үтүен, аралыктагы насосларга, дегидраторларга җитүен хәбәр иттеләр. Хәзер ул термохимик мичкә керәчәк. Хезмәт күрсәтүче персонал битка плек-

мөмкин.

Кәтәләр. Ни булып бетәр? Нералар соң чиккә җитеп киерелгән. Прибор стрелкалары ярсынып сикеренмәсме, авария сигнализациясенең кыңгыравы чыңлый башламасмы? Вакыт дигәнең ничаклы озак үтә. Бер минут, ике, өч...

Сәгать кичке сигезенчегә киткәч, мичтә җылынган нефтьнең, бөтен инстанцияләрне узып, җылы алыштыргычлар мәйданчыгына әйләнеп кайтканлыгын хәбәр иттеләр. Шулай итеп, әйләнә йомылды.

Һәммә нәрсә үз чираты белән барды, барысы да җайда иде кебек, бары тик икенче блокны җибәргәндә кечкенә күңелсезлек килеп чыкты. Бер урында җылы алыштыргычның изоляциясе пычранды. Хикмәт шунда иде — блок инструкция таләп иткәнчә 26 атмосферага түгел, бәлки, 6 атмосферага гына прессланган иде. «Иркеннефть» кешеләре монтажчыларның сәләтен артыграк бәяләп, күбрәк ышанганнар. Насослар эш басымын бирә башлагач, трубопроводның бер ялганмасы чималны тышка чыгара башлады. Дефект тиз бетерелде, ә эзе калды. Бүтән производствода булса, аны искәрмәсләр дә иде, ә монда, һәр нәрсә ялт итеп торган җирдә, кешелеккә кия торган костюмыңа төшкән тап сыман, әллә кайдан кычкырып тора. «Даагнер Зиро» әфәнделәрен борчымады ул. Әллә инде алар моны күреп сөенделәр — белмәссең — өгерме тапкыр фотога төшергәннәрдер.

Бу факт — зур бәла түгел. Сынауның дәве алда иде, чөнки әле электрогидраторлар тоташтырылмады, циркуляцияләнүче нефтькә химик реагент бирелмәде. Башкарылган кадәр эш, гаять мөһим булса да, асылда башлангыч адым иде. Бары тик мичләр һәм циркуляцион насослар гына тикшерелде. Үзе аша 22 мең вольт көчәнешле ток узганда «кара алтын» ниләр күрсәтер?

Махсус микроавтобуста килеп төшкән чит ил белгечләрен установка территориясенә кертмәделәр. Ябык капка буенда басып торган санаулы минутларда Эдуард Эдуардович каршылыклы уйлар кичерде. Бер мәлгә ул русларны хаксызга исәпләде, аннары килеште. «Алар нишләргә тиешләр соң? Әлбәттә, үз интересларын яклыйлар»,— диде ул үз-үзенә. Аңа фирмасы өчен оят булып китте. Ул исәп-хисапны өзәр вакыт җиткәч, «Машиноимпорт» кассасының установка территориясенең металл капкасы шикелле ябык булуы мөмкинлекне дә күз алдына китерде. Шуннан соң үзенең тәкәбберлеген җиңеп, «Иркеннефть» җитәкчеләре Колесин, Зубанов һәм Тамадеев янына китте.

— Безгә күзәтүчеләр буларак калырга рөхсәт итегез...

Идарә җитәкчеләре горур табигатьле шеф-инженерның болай ялваруына төп сәбәпнең алынып бетмәгән ун процентны югалтудан курку икәнен яхшы аңладылар.

— Күзәтегез! — диделәр алар, киң күңеллелек күрсәтеп.

Фирма белгечләре көйләү-җибәрү эшләрендә бөтенләй катнашмадылар, ләкин һәр көнне приборлар күрсәткән нәтиҗәләрне үз журналларына терки бардылар.

— Бер литр нефтьтә су — 0,1 процент, тоз — 30 миллиграмм! — Октябрь бәйрәменә каршы төнне лаборатория инженеры Галиуллина шулай дип хәбәр итте.

Бу җиңү иде инде! Галина Ивановна Краматорова ул вакыйганы вахта журналына эре-эре басма хәрефләр белән язып куйды. Һәм сөенеченнән Галиуллинаны үбеп алды. Аннары, ирләрнең кулларын кысып:

— Уңыш белән котлыйм, егетләр! — диде.

Вахтадагылар бүрекләрен һавага чөеп, «Ура!» кычкырдылар. Яңа хәбәрне телефоннан белешкән кешеләрнең дә куанычы эчләренә сыймый иде.

Вакыт соң булуга да карамастан, Борис Федорович идарә пультындагыларга тәбрик сүзе белән мөрәҗәгать итте...

Октябрь тантанасы үтеп китте. Установкада эш җайга төшеп гадәти эзеннән ага башлады. Тулы нагрузка белән ун көн эшләделәр. Кинәт көннәрнең берендә, күңелләрне яшенле давылдай айкап, дәһшәтле хәбәр таралды:

— Авария!

Операторлар Әсхәт Гиниятуллин һәм Фәйзелбари Сөетгәрәев авария хакында җитәкчеләргә хәбәр итәргә ашыктылар. Тиз арада слесарьлар белән бергә механик

алыштырырга булдылар. Янгын сүндерү машиналары килде. Ремонтчылар таләбе буенча, аккан нефтьне суыртып җыю агрегаты һәм автокран китерелде.

Флянцларны бик тиз бордылар, задвижканы трослар белән элэктерделәр һәм, кранчы лебедканы эшләтә башлады. Әмма задвижка кыймылдамады да. Ике машина белән тарттыра башлагач кына ул өскәрәк күчте. Ачык трубадан исә «кое»га нефть ургып ага башлады. Бу күренеш, гомумән алганда, табигый. Тере организмның артериясен кан чыгармый кисеп булмаган кебек, «нефть артериясе»н дә «җир мае»н агызмый гына рәтләп булмый. Ләкин аркылысы ярты метрлы трубадан нефтьнең ярсыптышып агуы һич тә нормаль түгел иде.

Владимир Мәрдәнов моторларны сүндерергә әмер бирде.

Борис Бегов, Павел Смирнов, Николай Васильев, штурвалга чытырдап ябышкан хәлдә, тирләп-пешеп задвижканы шыплатып япканчы сәгатькә якын вакыт узды. Шул арада зур басым астында резервуарлардан йөзләрчә тонна сыеклык акты. Аның янгын куркынычы турында сөйләп тә торасы юк.

Нефть, «кое»дан тәшып чыгып, контроль-пропуск будкасына таба акты һәм пропуск сорап тормый гына капка арьягына җәелде.

Товар паркындагы авария турында Колесин ярты сәгатьтән соң белде. «Шул гына җитми иде,— дип уйлап барды ул юлда, нык әрнеп, уртәлеп.— Чит ил белгечләре белсәләр, үзләренең «хаклыклары»н исбатлау өчен факт итәчәкләр».

Карабаш борылышында күргәне исә аның чәчләрен үрә торгызды. Ак кар өстенә бинһая зур тап булып нефть җәелгән иде. Бу тап минут саен зурая бара. Шоссе юл буена килеп җитә калса, теләсә кайсы узгынчы машина очкыныннан янгын күтәреләчәк. Ул чагында ялкын товар паркына таба үрмәләячәк...

Балчык өемнәре белән нефть юлын кисүне оештыргач, Виктор Михайлович товар паркына ашыкты.

Аварияның сәбәбе ачык иде: задвижка, трубаларның үзәкләре туры килмәүдән, агым басымы нәтиҗәсендә шартлаган. Суыкның катнашы юк монда. Тик «Даагнер Зиро» кешеләренә сәбәпнең асылы кирәкмени?! Алар хәзер кагыйдәдән читкә китүләрне, бозуларны мөмкин кадәр күбрәк теркәргә тырышалар һәм, ул мәгълүматларны «Машиноимпорт»ның Бөтенсоюз берләшмәсенә җиткереп, үз файдаларын күзәтмәк булалар. Авария аркасында агып җәелгән нефть «күлен» фотога төшерәчәкләр инде алар.

Әгәр установка ахыр чиктә контрактта әйтелгән сыйфаттагы продукцияне бирмәсә, Лютер әфәнде, фирмасының абруен сакларга тырышып, Көнбатыш матбугатында шау-шу куптарырга да тартынмас. Шул чагында аның мондагы белгечләр төшереп алган фотосурәте дә эшкә җигелер...

Моңа юл куярга ярамый, юк ярамый! «Бичарадан ни чара?» дип торыр чак түгел. Виктор Михайлович гражданская оборона штабы начальнигы Борис Петрович Семечкинга шалтыратты. Егерме өч сәгатькә авария-техник коткару отрядларының командирларын җыярга дип килештеләр. Запастагы подполковник Борис Петрович эшне тиз тотты.

Виктор Михайлович шат һәм горур иде бу минутларда. Бөтен коллективны һәм җәмәгать оешмаларының иң кискен көннәрдә бер җан, бер тән булып берләшә алуына шатланды һәм горурланды ул. «Ике йөз туксан кеше килгән. Кирәге калса, меңнәр киләчәк!» — дип сөенде. «Күрегез совет кешеләрен!» Шулай дип кычкырасы килде аның.

Отрядлар бердәм ябырылып эшкә керештеләр.

Ул көнне «Даагнер Зиро» белгечләрен алырга автобус килмәде, «техник тикшерүгә» калган иде. Чит ил әфәнделәренә бу көнге хезмәт хакы өчен борчылмаска киңәш бирелде. Хакы тулысынча түләнәчәк...

Шулай да Карабаш установкасындагы авария хәбәре аларга да барып ирешә. Иртәгесен алар бик ашыгып килеп җиттеләр, әмма территориядә күңелгә шик салырлык бер нәрсә дә абайламадылар. Бары установка белән товар паркы арасындагы мәйданда гына кар тапталган һәм анда ком, чуерташ һәм балчык түшәлгән булып чыкты. Һәрхәлдә, әфәнделәрнең фотообъективларына «җим» юк иде. Чит ил белгечләре, җилкәләрен биетеп!

Алгарак узып булса да әйтик, борчулы кыш үтеп, җәй җиткәч, Татарстанның «кара алтын» төбәгенә, гражданский оборонаның торышын тикшерү өчен, илебезнең Гражданский оборона начальнигы Советлар Союзы Маршалы Василий Иванович Чуйков килде.

«Иркеннефть» промыселлар идарәсе объектларының һәм кешеләренең гражданский оборонага бик әйбәт әзер булуларын күрсәтеп, Виктор Михайлович Колесинга «СССР гражданский оборонасы отличнигы» значогын тапшырганда, маршал:

— Служба исеменнән сезгә рәхмәт белдерәм! — диде һәм Колесинның кулын кысты.

Хәрби хезмәттә узган елларын хәтерләгән Виктор Михайлович дулкынланып җавап кайтарды:

— Советлар Союзына хезмәт итәм!

Установкаларның чунып сафтан чыгу куркынычы артта калды һәм иркенлеләр шеф-инженердан башка да эшли алуларын кире каккысыз итеп расладылар. Эдуард Розенкранц, барысын кат-кат үлчәп карагач, Колесин янына килде һәм установканы ходка җибәрүдә катнашырга карар кылганлыкларын әйтте. Әгәр безнекеләр ризалашсалар, шат буласын белдерде. «Иркеннефть» кешеләре ризалык бирделәр.

Барлык кичерешләр узгач, дәүләт комиссиясе актына кул куелгач (ә ул актта фирмага карата бер дәгъва да булмау Розенкранцка канат үстерә иде!), Эдуард Эдуардович безнекеләрне сыйларга бер әрҗә шәраб китертте. Аны авыз итеп куйгач, ул чын күңелдән болай диде:

— Рәхмәт сезгә! Әйбәт эшләдегез! — Аннары йөрәк түрендәгесен яшерә алмыйча дәвам итте.— Безнең Австриядә фәкать бер генә мондый установка бар. Әмма миңа анда тагын бер установканы эшкә җибәрергә туры килсә, бу эшкә мин бары сезне генә чакырыр идем!..

Габдрахман нефть мәйданындагы Карабаш установкасы алтынчы ел инде «кара алтын»нан суны һәм тозларны, шулай ук җиңел фракцияләрне аера. Хезмәтче персонал, технологияне оста кулланып, беренче елны ук проект куәтендә каралганнан тыш продукция алуга иреште.

## Валентина Гудкова

# ЭЗЛӘНҮ АЗИМУТЫ

ОЧЕРК

Фән үз-үзеннән канәгать булып, бер урында туктап калган кешеләрне яратмый. Ул бары тик үзен аңа бөтенләйгә багышлаган ачык максатлы, зур ихтыяр көченә ия булган тынгысыз кешеләргә генә буйсына һәм шуның бәрабәренә аның бөтен тормышын таләп итә. Бу язмаларда сүз нәкъ әнә шундый кешеләрнең берсе турында барачак.

...Бу вакыйга моннан егерме ел элек булды. Республикабызда ТАССР Верховный Советына сайлауларга хәзерлек барган көннәр иде. Казан университеты профессоры Гомәр Тумашевны мин беренче тапкыр әнә шул көннәрдә, сайлау алды җыелышларының берсендә очраттым. Әле дә хәтеремдә: җыелышта кандидатны яклап чыгыш ясаучы — доверенный сайлаучыларга республиканың югары органына депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелгән профессорның тормыш һәм хезмәт юлы турында сөйли. Ә президиум өстәле артында кара чәчләре артка таба сыпырып куелган киң маңгайлы, мөлаем йөзле профессор үзе утыра. Читтән караганда, ул бик тыныч кебек күренә. Ләкин ныклабрак күзәтсәң, аның дулкынлануын сизәсең. Үзенең эмоцияләрен яшерергә тырышуын абайлыйсың. Эшләгән эшләре, күрсәткән хезмәтләре турында башкалар сөйләвен тыңлаганда кеше үзен һәрвакыт шулай уңайсыз хәлдә итеп тоя.

— Кырык яшьлек галим инде биш елдан бирле физика-математика фәннәре докторы. Аның үз мәктәбе, үз шәкертләре бар. Ул яхшы оештыручы, университеттагы иң зур факультетның деканы. Принципиаль коммунист...

Доверенныйның чыгышы сүзләргә саран. Хәер, Тумашев кебек кешеләр турында сүзләр түгел, аларның биографияләренә хас булган фактлар бөтенесенә караганда да ачыграк итеп сөйли.

Соңыннан миңа профессор Тумашев белән күп тапкырлар очрашырга туры килде. Һәрвакыт тыныч холыклы, тавышын күтәрми генә сөйләшә торган һәм бик үк җиңел булмаган хәрәкәтле бу кеше бер күрү белән һәркемнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Аның күзләрендә уй-фикерләре бер мизгелгә туктап калганда үз эченә бикләнүчән кешеләргә хас булган ниндидер моңсулык чагыла. Ләкин шуның белән бергә бу түгәрәк зәңгәр күзләр профессорның әңгәмәдәшен бер генә секундка да игътибарсыз калдырмый. Гомәр Тумашев кешеләргә карата гомумән ифрат дәрәҗәдә игътибарлы.

Менә аның кабинетына, машинкада басылган кулъязма тотып, урта яшьләрдәге бер ханым килеп керде. Гомәр ага үзенең монографиясен матбугатта яңадан бастырып чыгарырга әзерли икән.

Ике арада кыска, әмма эшлекле әңгәмә булып алды һәм сүз, һич көтмәгәндә, чаңгылар турында сөйләшүгә күчте. Бу хакта сүз башлаганда профессор балаларча елмаеп куйды. Күрәсең, ул узган якшәмбедә чаңгылар киеп прогулкага чыгуын исенә төшерде. Ә чаңгыда йөрү — аның күптәнге һәм яраткан шөгыле. Бу минутта аңа әйтерсең лә алтмыш яшь түгел, әйтерсең лә ул политехникумга укырга керү өчен беренче тапкыр Казанга килгән унҗиде яшьлек егет чагына яңадан әйләнеп кайтты.



аның мәктәпне тәмамлау турындагы таныклыгы белән танышалар. Математикадан, физикадан, химия һәм немец теленнән куелган билгеләрнең бөтенесе өйбәт. Ләкин Гомәргә бит инде унҗиде яшь, бу таныклык исә аның нибары җиде класс кына тәмамлавын раслап бирелгән. Ә башкалар аның яшендә көсәләрендә техникум тәмамлаучылар дипломын йөртәләр.

Болай да аз сүзле Гомәр эндәшми. Күп сөйләшеп торуның файдасыз икәнлеген ул бик яхшы аңлый.

1918 елда Гомәр, башка балалар шикелле үк, җиде яшендә укырга керә. Ләкин ике елдан соң укуын ташларга мәҗбүр була. Бөтен ил буйлап кара канатын җәйгән ачлык Гомәрләр гаиләсе яшәгән Чистайны да читләтеп узмый. Кечкенә шәһәрчек үлем тынлыгы хөкем сөргән каберлеккә охшап кала. Аның урамнарында балаларның гамьсез көлү тавышлары ишетелмәс була. Җәй һәм көз көннәрендә алар төрле үләннәр, җиләк-җимешләр ише ризыклар белән тукланалар, ә мәрхәмәтсез кыш аларны табигать биргән әлеге ризыклардан да мәхрүм итә.

Менә шундый авыр шартларда яшәргә мәҗбүр булган зирәк һәм сәләтле малайга җидееллыкны бары тик унҗиде яшендә генә тәмамларга туры килә. Аның Казанга укырга китәргә җыенуын белгән укытучылары ихлас күңелдән куаналар. «Әйе, мондый зиһенле егеткә,— диләр алар,— һичшиксез, укуын дәвам иттерергә кирәк».

Гомәр индустриаль техникумда да кешегә һәрвакыт яхшылык кылырга әзер торучы укытучылар кул астына эләгә. Математика укытучысы Иван Иванович Пауткин аның күпне белергә, күп нәрсәләрне төшенергә омтылуын шунда ук сизеп ала. Дәрестән соң ул еш кына Гомәр янына килеп, аның белән дусларча сүз башлый:

— Кичен менә бу мәсьәләгә күз йөртеп чык әле, Гомәр.

Егет башта югары уку йортларында үтелә торган математика дәреслегенең тышына карый, аны беразга икеләнү хисе биләп ала: моны җиңеп чыгарга көче җитәрме аның, яисә ул укытучысы алдында уңайсыз хәлдә калырмы? Ләкин уйлап карау зыян итмәс. Яхшылыктан башканы теләми ич аңа Иван Иванович.

— Эх, университетта укытырга иде бу егетне,— дип көрсенә Пауткин һәм алдагы дәрескә чишеп килү өчен аңа катлаулырак мәсьәләләр биреп җибәрә.

— Юк, Иван Иванович,— ди Гомәр остазына,— укуга караганда эшләвем артыграк булыр минем.

— Тукта әле, Гомәр,— дип каршы төшә Иван Иванович,— нәрсәгә кирәк булды сиңа тире-күн эшкәртү мастеры дипломы? Син бит тумыштан ук менә дигән математик.

Басынкы, оялчан Тумашев тыштан гына карышмаучан, буйсынучан егет булып күренә. Үз сүзен сүз итү ягына килгәндә, ул башкалардан һич тә калышмый. Пауткин

[illegible] булдыра алмый. Вакыты килер, бу егет киләчәктә үзенең төп профессиясен дөрес сайлап алмыйча калмас дип уйлый ул.

Тумашевны куркусыз гладиатор Спартак исемен йөрткән комбинатның химия лабораториясенә билгелиләр. Ләкин Пауткин үзенең шәкертен онытып бетерми. Җае чыккан саен кичләрен аның янына килә, университет турында әңгәмә алып баруын туктатмый.

— Котлагыз, Иван Иванович,— ди Гомәр аңа бер килүендә,— мине үз һөнәрем буенча цехка күчерделәр...

Смена мастеры эштән арып-алҗып кайта. Әмма шуңа да карамастан, ашын-йокысын онытып, бер генә минут вакытын да әрәм итмичә, кулына математика дәреслеге алып утыра.

Көннәрдән беркөнне Гомәрнең күзенә университетка керергә теләүчеләрне имтиханнарга хәзерләү буенча оештырылган махсус түгәрәккә йөрергә чакырган белдерү чалына.

— Әллә миңа да көчне сынап, бер талпынып карарга микән? — дип уйлый Тумашев.— Бу хакта әнә Иван Иванович та ни гомердән бирле үгетләп килә.

Цех белән, иптәшләре белән бик авыр аерылыша ул. Эш монда цехка, андагы дусларына иялəнеп, үз булып бетүдә генә түгел. Заманы шундый кайнар сулышлы заман була: беренче бишьеллыкның соңгы квартал планын срогыннан элек үтәп чыгу өчен бөтен ил буенча удар айлыклар игълан ителә. Бөек җиңешкә үзләреннән мөмкин кадәр күбрәк өлеш кертү теләге белән янган яшь энтузиастлар ул көннәрдә бер-берләреннән аерылуны хәтта күз алларына да китерә алмыйлар.

Аннан соң инде кырык елга якын вакыт үтте. Ләкин профессор комсомолларның шәһәр читенә — Казанда беренче булып сафка баскан һәм җылылык бирә башлаган Казгрэс төзелешенә көчле җырлар яңгыратып килүләрен әле һаман хәтерендә саклый. Бу өмәләр — аның комсомолда үткәргән елларының иң якты хатирәләре. Юк, истәлек-хатирәләр генә түгел алар. Кулына лом һәм көрәк тотып төзелештә эшләгәндә Тумашев уку турында, белемнең кирәклеге турында кат-кат уйлана, илнең югары квалификацияле белгечләргә әле мохтаҗ булуын үзе күзләре белән күрә.

...Университетка кабул итү имтиханнарын Тумашев уңышлы тапшыра. Менә ул — физика-математика факультетының беренче курс студенты. Ә бер айдан соң доцент Борис Леонидович Крылов, аны үз янына чакырып, болай ди:

— Сезгә, Тумашев, беренче курста укып торуның артык кирәге булмас. Укуыгызны турыдан-туры икенче курстан башларга киңәш итәм.

Гомәрнең шатлыгы эченә сыймый. Аның белән бергә укытучысы Иван Иванович Пауткин да шатлана. Югары математика дәреслекләре өстендә төн йокыларын калдырып утыруларның матур нәтиҗәсе аларның һәр икесенең уртак куанычына әверелә. Университетта студент Тумашев башкалардан үзенең киң эрудицияле, математиканы тирәнтен үзләштерергә сәләтле булуы белән аерылып тора. Аның белән сөйләшкән яки аны тыңлаган һәр кеше бу егеткә фән дөньясына үтеп керү өчен юлның киң ачылачагын бик яхшы аңлый. Соңыннан атаклы парамагнит резонансы теориясе авторы буларак танылган Евгений Константинович Завойский да Тумашевның сәләтенә югары бәя бирә.

Һәм менә, һич көтмәгәндә, Гомәр Тумашев деканатка үзен авиация институтына күчерүләрен сорап язылган гариза белән керә. Киләчәккә зур өметләр баглаган студенттан аерыласылары килми. Тик шулай да, озаклап фикер алышканнан соң, аның теләгенә каршы килмаскә дигән фикергә киләләр. Профессор Четаев укыган аэродинамика курсы Гомәрнең иң яраткан, аерылмас фәне булып әверелә һәм ул үзенең бөтен фәнни эшчәнлеге дәверендә шуңа тугрылыклы булып кала. Студент Тумашев авиация институтында укыганда очу аппаратлары конструкцияләрен өйрәнеп, төннәр буена сызымнар өстендә утыра. Фәннең үз серләрен бары тик тырыш, юлында чигенүне белмәүче, хезмәт сөючән кешеләргә генә ачканлыгын ул бик яхшы аңлый.

1937 елда Тумашев самолетлар төзү буенча инженер-механик дипломы ала һәм профессор Георгий Владимирович Каменков аңа аэродинамика кафедрасы аспирантурасына керергә тәкъдим итә. Аның аспирантура еллары, башкаларныкы шикелле үк, кичекмәстән башкарылырга тиешле җитди эшләр белән, имтиханнарга һәм диссертация яклауга хәзерлек белән үтә. Тумашевның тынгысызлыгын, үз-үзенә карата

ифрат дәрәҗәдә таләпчән булуын искә алсаң, аның күптәнге максатына ирешүенә — диссертациясен билгеләнгән вакытта һәм уңышлы яклавына һич тә гаҗәпләнерлек түгел.

Кырык беренче ел Гомәр Тумашев өчен матур яңалыклар китерә: январь аенда аңа физика-математика фәннәре кандидаты дигән исем бирелә. Мактау сүзләренә артык юмартлардан саналмаган профессор Николай Николаевич Парфентьев яшь галимнең хезмәтен әйбәт бәяли. Профессорны, Тумашев язган диссертациянең нигезле, тирән фикерле булуы белән бергә, аның фәнни эзләнүләрендәге кыюлык һәм эзлеклелек сокландыра.

Өч ел буена аспирантура тормышы белән яшәгән, әллә нигә бер әләгә торган ял вакытларында язылачак диссертациясе турында уйланып уздырган Тумашев җәйне күркәм табигатьле Идел буенда ял итеп уздырырга дигән теләк белән каршы ала. Ләкин кинәт башланып киткән сугыш кешеләрнең иң-иң матур исттәлекләрен юкка чыгара. Ватанны саклап калу, халкыбызның азат тормышына кул сузган мәкерле дошманны тар-мар итү — авыр сугыш елларында фронтның алгы сызыгында торып көрәшкән сугышчыдан алып, заводлардан һәм колхоз кырларыннан изге яу кырына китүче әтиләренең эш урынына баскан үсмерләргә кадәр әнә шундый уй-теләк белән яшиләр.

Тумашевны — сугышның беренче көннәрендә үк Казанга эвакуацияләнгән Үзәк авиация дәүләт институтының (ЦАГИ) аэродинамика лабораториясенә алалар. Казарма шартларында яшәмәсәләр дә, институт хезмәткәрләре өйләренә бик сирәк кайталар. Алар сәгатьләп түгел, тәүлекләр буена эшлиләр. Фронтка яңа төрдәге тиз очышлы, җитез, оста маневрлар ясый ала торган самолетлар соралганлыгын, гитлерчы этләргә каршы сугышның безнең җиңүебез белән тәмамлануы өчен үзләреннән мөмкин кадәр күбрәк өлеш кертергә кирәклеген институт инженерлары һәм хезмәткәрләре бер генә минутка да исләреннән чыгармыйлар.

Менә шундый әйтеп бетергесез авыр шартларда да доцент Тумашев докторлык диссертациясе өстендә эшләү өчен көч һәм вакыт таба. Яңа хезмәтен ул искиткеч кыска вакыт эчендә — өч елда язып бетерә. Диссертациясен якларга да өлгерми, аны университетка теоретик механика кафедрасы мөдире итеп чакыралар. Никогай Николаевич Парфентьев үлгәннән соң, елдан артык җитәкчесез торган кафедра аның карамагына тапшырыла.

Докторлык дәрәҗәсен алу алдында торса да, Тумашевның югары уку йортында эшләү стажы әле бик аз була. Аспирантурада укуын да кертеп исәпләгәндә — нибары алты ел! Шуңа да карамастан, аны үзенең традицияләре белән дан тоткан иң зур факультетның кафедра җитәкчесе булырга лаек саныйлар.

Кафедраны кабул итеп алгач, Тумашев иң беренче мөһим бурыч итеп кадрлар хәзерләү мәсьәләсен куя. Бары тик шул чагында гына яңа махсус курслар укырга мөмкин булачак, дип уйлый ул. Ә аңарчы студентларга теоретик механика буенча гомуми курс кына укыла. Кафедра мөдире авиация институтыннан бирегә үзе белән яңа фәнни теория — кире кайтармалы мәсьәләләр (обратные краевые задачи) теориясен алып килә. Аның кандидатлык диссертациясе докторлык диссертациясе язганда бай материал булып хезмәт итә. Фәндә ул сайлап алган юнәлеш теоретик яктан гына түгел, практик яктан да зур әһәмияткә ия булганлыгын раслый.

Университетка Тумашев ифрат авыр вакытта кайта. Бу югары уку йорты аны ягылмаган аудиторияләре, студентларның аз санлы группалары белән каршылый. Ләкин берninди кыенлык та аның ихтыяр көчен җиңә алмый. Хезмәткә булган тирән мәхәббәт һәм тумыштан килә торган сәләт икесе бергә кушылса, кеше барлык авырлыкларны җиңеп чыга, тормышта төрле могҗизалар тудыра. Тормышының бу чоры турында сүз чыкканда, Гомәр Галиевич, аңа гомумән хас булганча, бик аз сөйли, эшләгән эшләренең соңгы нәтиҗәсен искә төшереп үтү белән чикләнә:

— Докторлык диссертациясен өч ел эчендә язып бетердем. Әмма аны 1947 елда гына якларга туры килде. Сугыштан соңгы елларның катлаулылыгы безнең эштә дә үзен бик нык сиздерде.

Кире кайтармалы мәсьәләләрнең төп асылы нәрсәдән гыйбарәт соң? Күренекле галим бу катлаулы математик төшенчәне үзе менә болай аңлата:

Механиканың классик мәсьәләләрендә әйбернең формасы алдан ук билгеле булып, шуның буенча аларның үзенчәлекләрен белү таләп ителсә, кире кайтармалы мәсьәләләрдә бөтенләй башка ысул кулланыла. Анда әйбернең формасы аның үзенчәлекләреннән чыгып билгеләнә.

Бу ысулны авиациядә, суднолар төзелешендә, кыскасы, сыеклык эчендә хәрәкәт итүче әйберләрнең формаларын билгеләү таләп ителгән һәр җирдә кулланалар. Кире кайтармалы мәсьәләләр теориясен образлы итеп биологиядә Мичурин кулланган ысул белән чагыштыралар. Бөек селекционер аерым сыйфатларына карап үсемлекләрнең яңа сортларын ничек тудырган булса, Тумашев та, алдан билгеле булган үзенчәлекләреннән чыгып, яңа объектлар төзү мөмкинлеген исбат итә. Аның тарафыннан беренче тапкыр безнең илдә системага салынган бу теория тиз араларда киң таралыш таба, аның белән галимнәр дә кызыксыналар.

Шулай итеп, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан университетында соңыннан профессор Тумашев мәктәбенә әверелгән тагын да бер яңа фәнни юнәлеш барлыкка килә.

Безнең көннәрдә совет галимен кабинет эченә бикләнеп, бернинди хәрәкәтсез, үзгәрешсез формулаларга күмелеп утыручы кеше итеп күз алдына китерүе бик кыен. Аның өчен бүген саф теориядән гыйбарәт булган фәнни ачыш иртәгесен производствога хезмәткә җигелә. Менә шуңа күрә дә фән һәм техника революциясе чорында һәр яңа теориянең җитештерүче көч булып әверелүе бер дә гаҗәп түгел. Яңа ачышларның әнә шул үзенчәлеге безнең чор галимнәренең эш стиленә дә йогынты ясамыйча калмый.

Югары уку йортында укытыла торган фәннәрнең үзләренә хас булган катлаулыклары бар. Ләкин шуның белән бергә аларның академик фәннәргә караганда өстенлекләре барлыгын да истән чыгарырга ярамый. Үзенең коллегаларыннан аермалы буларак, галим Тумашевның бәхете шунда: ул студентлар белән эшләүне мәшәкатькә санамый. Киресенчә, студентларга укыла торган лекцияләр Тумашев өчен аның фәнни эшенең төп нигезен тәшкил итә. Профессор Тумашевның беренче лекциясен тыңлаган кешенең азрак аптырап калуы да ихтимал: анда күзгә бәрелеп торган тышкы бизәкләр юк, ораторларга хас алымнар да сизелми, тавышы колакны ярып керми, ул ашыгып сөйләми, кул хәрәкәтләре дә артык җитез түгел. Әмма студентлар тышкы яктан караганда бераз сәер күренгән бу профессорның һәр сүзен йотлыгып тыңлыйлар. Чөнки алар ул өйрәтә торган курсның тирәнлеген бик тиз абайлап алалар. Ә ул, үзен бик тыныч тоткан хәлдә, сүзгә артык юмартланмыйча, студентларга гаять зур игътибар белән карый. Зачетлар һәм имтиханнар тапшырганда студентлар профессорның кырыслыгыннан шүрләүләрен яшермиләр. Мондый вакытта Тумашев аларның әле берсенә, әле икенчесенә йомшак кына итеп әйтеп куя:

— Безнең кафедра каршында эшли торган түгәрәк занятиеләренә килгәләгез. Кем белә, бәлки, ул сездә дә кызыксыну уятыр.

Һәм студентлар киләләр. Башта түгәрәк күләмендә өйрәнчек рефератлар үткәрелә, аннан соң аларга катлаулырак мәсьәләләр буенча кафедрада студентларның фәнни җәмгыятендә докладлар укуны тапшыралар. Һәм, шуларның барысына йомгак ясау йөзеннән, конференцияләр уздырыла. Нәтиҗәдә студентларның курс эшләре башта диплом эше, соңыннан исә диссертациягә кадәр үстерелә.

Университетта Тумашевның талантларны эзләп табарга, сәләтле яшьләргә һәрвакыт игътибарлы булуын бик тиз күреп алалар. Ул бернича ел буена студентларның фәнни җәмгыяте белән җитәкчелек итә, илленче елларда университетта иң зур факультет исәпләнгән физика-математика факультетының деканы була.

Профессорның студентларга фәнни-теоретик белем бирү турындагы әңгәмәсен рәхәтләнеп тыңлыйсың.

— Университетны тәмамлап чыгучыларның һәркайсы үзен фәнни эшкә багышлар дип булмый, әлбәттә. Ләкин аларның бөтенесе дә, хәтта турыдан-туры производствода эшләячәк студентлар да, фәнни-тикшеренү эше алып бару принципларын тирәнтен үзләштерергә тиешләр. Чөнки,— ди ул,— хәзерге заманда эш бер генә производствода да фәнни-тикшеренүләргә нигезләнмичә алып барылмый. Күптән түгел, мәсәлән, безнең кафедрага сал агызу институтыннан килеп керәләр. Бер уйласаң, бу учреж-

дение белән безнең арада берниндн дә уртаклык юк шикелле. Киләләр дә болай диләр:

— Безгә диплом алды практикасына студентлар җибәрә алмассызмы икән? Алар өчен бездә ашыгыч тикшеренү таләп иткән темалар бар...

Аспирантлар сайлап алуда Тумашевның үз ысулы бар. Бирегә студент чагыннан ук фәнни түгәрәкләргә йөргән, семинарларда актив катнашкан кешеләрне генә алалар. Ә семинарлар галимнәр өчен белем арттыру һәм тәҗрибә уртаклашуның иң кулай төре.

Гомәр Галиевич берничә елдан бирле кире кайтармалы мәсьәләләр буенча шәһәр күләмендәге семинар белән җитәкчелек итә. Аның гыйльми мәктәбе үсә, биш шәкерте фән докторы дәрәҗәсен алуга иреште, кандидатлар исә тагын да күбрәк. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, хәзер университетта механика кафедрасы да икәү инде. Тәҗрибәле галим теоретик механика кафедрасын үзенең элекке аспирантларыннан берсенә тапшырды, ә үзе яңа кафедраны — гидроаэромеханика кафедрасын җитәкләргә алынды. Аңа эшне тагын өр-яңадан башлап җибәрергә туры килде.

Республикабызның көнчыгыш районнарында нефть чыгаруның торган саен үсә барган чагы иде бу. Аннан университетка ярдәм сорап мөрәҗәгать иттеләр. Коммунист Тумашев зур нефть проблемаларын тикшерү буенча комплекслы группалар төзегән инициаторларның берсе булды. Шулай итеп, җир асты гидромеханикасы мәсьәләләре аның фәнни эзләнүләрендә төп урынны алды. Бу вакытта Гомәр Галиевич Н. Г. Чеботарев исемендәге математика һәм механика буенча фәнни-тикшеренү институтының директоры иде инде. Аның вазифалары артты, институтның да колачы киңәйде, проблемалы лабораторияләр барлыкка килде. Тумашевның нефть катламында басымны бүлү өлкәсендәге хезмәтләре теоретик яктан гына түгел, практикада да әһәмиятле булып чыкты. Хәзер җир асты гидромеханикасы лабораториясе белән Тумашевның шәкерте Юрий Матвеевич Молокович җитәкчелек итә, аның икенче шәкерте Семен Федорович Сайкин Чуваш дәүләт университеты ректоры булып эшли.

Гомәр Галиевич һәр иртәдә, моннан нәкъ егерме җиде ел элек килгән шикелле үк, университет корпусына өстәп салынган бинаның икенче катына күтәрелә. Кафедрада ике өстәл һәм китап шкафыннан башка күзгә ташланырлык бернәрсә дә юк.


Берничә минуттан лекцияләр башланачак. Профессор өченче курс студентларына «Гидроаэродинамика» фәненнән, дүртенче курстагыларда «Газ динамикасы» буенча лекция укыячак.

Җаен туры китереп, профессордан мин болай дип сорадым: «Сезнең лекцияләрегез артык күп түгелме, Гомәр Галиевич? Сезгә аларның санын бераз киметергә дә мөмкин иде ич. Чөнки сез кафедра мөдире хезмәтен дә башкарасыз бит».

Профессор җиңелчә генә елмаеп куйды. Бу сорау аңа артык тоелды, күрәсең.

Күптән түгел университетта Тумашевның тууына алтмыш яшь тулуны билгеләп үттеләр. Шул уңай белән аның фәнни казанышлары, башкарган олы эшләре турында күп кенә мактау сүзләре әйтелде. Бу вакытта президиумда утырган профессорның чал чәчләре һәркемдә тирән ихтирам һәм чиксез хөрмәт уятты. Ә залда аның бәхете, сөенече — үз фәнни мәктәбенең вәкилләре — әлегә бик яшь һәм урта яшьләрдәге галимнәр утыра иде.

Һәр галим өлешенә дә мондый олы бәхет — беренче ачышлар ясау, фәндә яңа юнәлеш тудыру бәхете туры килми. Профессорның иң изге теләкләреннән берсе үзенең бөтен гомерен, акыл һәм йөрәк көчен багышлаган фәнгә турылыклы булып калудан гыйбарәт.



# ЮЛЛАР ЧАТЫНДА

*Шагыйрь исемендәге шәһәрдән репортаж*

**Бәхетле син, ерак илдәш,**
**Хезмәтеңә мин баш иям.**
**Һәйкәл булып яшьлегеңә**
**Үскән монда бер карт имән.**

Йөрәккә якын, таныш юллар. Әйтерсең лә Муса Җәлил аларны нәкъ шушында яшәүчеләргә багышлаган. Биредә алар аеруча мәгънә белән, үлемсезлекнең тантанасы булып яңгырыйлар. Вакыт сынауларын, бормалы тормыш юлларын үтеп, менә кайда җыр яшьлек белән очрашa!..

Алар да шушы чатта очраштылар. Барысын да баштан башларга, кыенлыкларны җиңәргә, җил-бураннарны кичерергә туры килде аларга.

Менә шушы урында шәһәр төзелергә тиеш, диделәр. Бу фикерне иң башлап ул вакыттагы «Әлкәйнефть» промыселлар идарәсе коллективы яклап чыкты. Экономистлар исә аны үзләренчә, хуҗалык исәпләреннән чыгып раcладылар. Эшчеләрнең вахта юлларында әрәмгә үткән вакытларын, артык транспорт чыгымнарын, тонна-километрларны һәм сумнарны исәпләделәр алар. Барыннан да бигрәк тирә-як авылларда таркау яшәүче нефтьчеләрче шәһәрчә төзекләндерелгән бер урынга җыйнап, анда аларга нормаль көнкүреш шартлары тудыру күздә тотылды. Бу исә, үз чиратында, нефть чыгару производствосын тагын да үстерүгә уңай мөмкинлекләр бирергә тиеш иде. Ниһаять, ГИПРОГОР өстәлләрендәге ак кәгазьләргә булачак шәһәрнең контурлары төшә башлады. Ә төзүче мастер Тимергалиев җитәкчелегендәге эшчеләр, Әлмәттән килеп, салыначак йортларның нигезләрен корырга керештеләр.

Һәр яңа башлангыч каршылыклар белән көрәшүне таләп итә. Биредә дә тормышның бу законын читләтеп үтәргә мөмкин булмады. Көне җиткәч, аерым семьяларның эчендә дә җил-бураннар күтәрелде. Шәһәрдәге менә дигән квартираларын яки авылдагы йорт-җирләрен, мал-туарларын калдырып китәргә кызганучылар да булды. Әмма бик күпләр яңа поселокка күчү көнен, зур бер бәйрәмне каршылаган шикелле, атлыгып көтеп алдылар.

Ул көн килде. Тик анда да, юри ачу иткән кебек, буран бик әшәке котырды. Төялеп чыккан машиналар карлы юлларда югалып калдылар. Ярый әле — бульдозерлар. Ул көннәрнең геройлары Филиппов Борис, Суфиянов Салихлар тәүлек буена юлларны эрчеп буран эчендә кайнадылар. Стихия чигенде. 11 январь таңында квартираларда беренче утлар кабынды.

1964 елның бу кышын бирегә яшәү җиңел булмады. ... тең-
кәгә тиделәр. Инде бетте, рәт калмады, дип китәргә җыенган чәклар да булмады тү-
гел. Ләкин яшәү көче җиңде. Мөхәммәтҗанов Әкълим һәм аның иптәшләре кебек
арысландай батыр егетләр тормышны башлап җибәрүче инициаторлар булдылар.
Авырлыкларны җиңел итеп кичерергә тырыштылар алар. Карт әбиләр дә аптырап
тормады, чокырлар аша сикереп үтәргә күнектеләр. Әлмәт юлында автобуста бала
тудырулар да гаҗәпкә саналмады. Тышкы ишекләрне кар күмеп китсә, тәрәзәдән чы-
гып, көрәп ачтылар. Ул йорт котлау туйларын әйтәсе дә юк: дүрт-биш катлы булып,
шаулап уздылар. Яшьләр бит! Нәкъ Муса Җәлил язганча, буран булса да күңелле иде:

**Туңдырса да тәнне, кыздырса да**
**Адаштырып кырда, урамда —**
**Тын тормыштан, дуслар, мең мәртәбә**
**Күңеллерәк икән буранда.**

Шулай итеп, зур Татарстан нефте өчен көрәш юлында мөһим бер терәк пункты — Җәлил эшчеләр поселогы барлыкка килде. Ул көрәш инде 1951 елда ук, Сөләй мәйданындагы беренче скважиналардан башланган иде. Тора-бара промыселлар хуҗалыгы киңәйде, Әлкәй, Чишмә һәм Ташлыяр мәйданнарына җәелде. Якында гына цехлары һәм мастерскойлары белән промбаза шәһәрчеге үсеп чыкты. Яңа Сөләйдә, соңрак Якыйда һәм Чишмәдә нефть эшкәртү корылмалары тәзелде.

Нефть өчен көрәш барышында кешеләр үзләре дә үстеләр, күтәрелделәр. Нефтьче мастерлардан дан казанган геройлар чыкты. Социалистик Хезмәт Геройлары Корбан Вәлиев белән Павел Савельевның исемнәре бөтен илгә билгеле булды. Йөздән артык кеше хөкүмәтебезнең орденнары һәм медальләре белән бүләкләнде. Нефтьчеләрнең иң алдынгы вәкилләреннән: «Татнефть» производство берләшмәсе начальнигы Әгъзам Вәлиханов, «Татнефтестрой» начальнигы Л. А. Гагалашвили, Социалистик Хезмәт Герое Әхәт Гобәйдуллин, «Әлмәтнефть» идарәсенең партком секретаре Наилә Закирова, нефтеавтоматика заводы эшчесе Т. И. Саблина, «Лениногорскнефть» идарәсе операторы А. Г. Соловьев партиябезнең XXIV съездына делегат булып катнаштылар. Алар Җәлил коммунистларының да вәкилләре иде.

Хәзер Җәлил пөселогыннан тугандаш ике предприятиенең — «Җәлилнефть» һәм «Сөләйнефть» идарәләренең эшчеләре һәм инженер-техник работниклары вахтага йөриләр. Бергә-бергә юллар да күңелле була. Алар кулга-кул тотынып, олы юлга — үзара ярышка чыктылар.

**Ә юллары нинди!**
**Сезне, юллар, аяк эзе түгел,**
**Йөрәк хисе салган бу җиргә.**

Чыннан да, Муса Җәлил мең мәртәбә хаклы. Чиксез йәрәк хисе, фантазия аларда! Бер карасаң, алар, һич тә исәпләшеп тормастан, суларны, текә тауларны һәм урманнарны кисеп үтәләр. Дөресрәге, алар кисмиләр, ә тоташтыралар, шәһәрләрне бәйлиләр, дусларны кавыштыралар. Шушы чатта аерылышалар да, кушылалар да алар. Очлары Әлмәт, Бөгелмә, Азнакай урамнарына барып керә, Чаллы, Сарман якларына китеп, күздән югала. Авыр йөк машиналары үкереп узалар. Купшы автобуслар чираттагы вахтага ашыга. Төрле типтагы махсус машиналар, үзйөрешле агрегатлар буровойларга, скважиналарга юл тоталар. Бу хәрәкәтнең үзенә күрә тәртибе, закончалыклары бар. Һәр машинаның үз путевкасы, үз маршруты. Диспетчер кызлар йөзләрчә машинаны юлга озаталар. Отличник шофер Борһанов Нигъмәт тә юлга чыга. Аның кайчандыр Ромашкинодан ук башланган тормыш маршруты уңышлы дәвам итә. Куәтле «татр»ы юл чатларында, койрыклы йолдыз шикелле, күзгә чалынып кына кала. Әле генә Бөгелмә базасында була, икенче карауга инде йөз километрларны артта калдырып, скважиналар арасында йөри. Әйе, ару-талуны һич белмәүче шоферлар күп бирегә. Агрегат машинисты Вәлиев, бульдозерчы Җамалиев, автобус йөртүче Саттаров һәм Кандалинцев кебек танылган механизаторлар, маяк булып, колонналарның алдыннан баралар. Бу юлларда үтелгән сәгатьләр дә, тонна-километрлар да — барысы да нефть чыгаручыларга хезмәткә куелган. Хәерле юл аларга!

Бу якларга беренче тапкыр килеп чыккан юлчы, гадәттә, плакатларга бизәп тәшерелә торган индустриаль картинаны эзли. Кая алар, гигант корылмалар, төтеннәрен бөркеп торган биек торбалар? Юл буйларындагы скважиналар да, баганалар да артык зур тәэсирле булып тоелмыйлар. Ләкин әнә шул баганаларга сузылган чыбыклар буйлап зур-зур елгаларның көче ташып ага түгелме соң! Юкка гына шауламыйлар, меңнәрчә ат көче белән экономик районнарның производство механизмын хәрәкәткә китерәләр алар. Юкка гына шауламыйлар, гүя нәрә җепләрәдәй, бередәге промыселлар хуҗалыгын илебезнең йөрәк тибеше белән бәйлиләр алар. Диспетчерлар үз урыннарында, мастердан министрлыкка кадәр оператив сводкалар агылып тора.

Җәлил тирәсендәге мәйданнарда — меңнәрчә скважиналар. Операторлар аларны үз савым сыерларыдай яхшы беләләр. Арада төрлесе, нефтьне бик күпләп бирганнәре дә бар. Юлларның иң олысы менә шулардан башлана да инде. Җир астыннан үткән торбалар буйлап җыю пунктларына, ә аннан товар паркларына нефть туктаусыз агып тора.

Якый товар паркы һәм андагы стабильләштерү корылмалары — нефть юлындагы узәк станцияләрнең берсе. Техниканың соңгы сүзе буенча җиһазландырылган махсус узелларда нефть иң беренче башлап эшкәртелә — бензин парларыннан, су һәм тоз кушымталарыннан арындырыла. Бередәге катлаулы агрегатлар һәм технология процесслары белән югары квалификацияле операторлар идарә итә. Шәүкәт, Әхәт, Рәнас, Садит һәм башкалар — барысы да шушы Җәлилдә яшәүче егетләр. Инженер-диспетчер Лариса Каржилова операцияләрнең барышына контрольлек итә. Көннәр, айлар, еллар буена шулай миллионнарча тонналар, алар кулыннан үтеп, «Дуслык» магистраленә — олы юлга — чыга.

Озатылган тонналар сумнар булып кайталар. Яңа экономик система белән эшләүче предприятиенең хуҗалык күрсәткечләре әнә шулардан чыгып билгеләнә. Илгә күбрәк нефть — кара алтын бирергә! Коллектив алдында торган төп бурыч әнә шундый. Бу мөһим мәсьәлә җыелышларда әледән-әле көн тәртибенә куеп тикшерелә.

Бу җыелышларда идарә начальнигы Әхмәдиев Галимҗан доклад белән чыга. Аның докладында да юллар — акка кара белән сызылган юллар, узган хуҗалык чорының йомгакларын характерлаучы саннар һәм фактлар. Кичкенә клубның залында зур мәсьәләләр күтәрелә. Фикер алышулар уйларны еракларга, алдынгы операторлар Әхмәдуллин Хәмзә, Рәкаев Җәмилләрнең эзләре белән, скважиналарга алып китә. Нефтьне күбрәк чыгару өчен барысы да эшләнгәнме! Тагын нинди резервлар, нинди юллар бар? Шушы идея кызыл җеп булып сузыла. Гади эшчеләр, инженерлар һәм геологлар белән бергәләп, җир асты катлауларының торышы, мөһим техник проблемалар турында фәнни яктан тирәнтен фикер уртаклашалар.

Әйе, техника прогрессы өлкәсендә эшлисе эшләр күп әле. Нефть чыгару, аны башлап эшкәртү һәм озату технологиясен тагын да камилләштерү һәм автоматлаштыру бурычы даими кайгыртучанлыкны һәм эзләнүләрне таләп итә. Бередә моның өчен тулы мөмкинлекләр һәм сәләтле көчләр бар. Промыселларда, цехларда рационализатор һәм уйлап табучыларның иҗади эшчәнлеге кайнап тора. Алар тарафыннан бертуктаусыз яңа, файдалы җайланмалар һәм камилләштерү тәкъдимнәре производствога кертелеп тора. А. Ртищев, Р. Минһаҗов, А. Ульбаев һәм В. Гариповларның тәкъдимнәре зур файдалы булды. Инженер Шагалеев Файразның нефтьне судан арындыру һәм суны тагын да файдалану буенча тәкъдим иткән җайланмалары да уңышлы булды.

Коллектив үз вәкилләренең уңышлары белән горурлана һәм ил каршына чыга. Бөтенсоюз ярышында җәлилчеләр әледән-әле алдынгылар рәтендә призлы урыннарны алып киләләр. Мәскәүдә һәм Казанда Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәләрендә Җәлилдән китерелгән экспонатлар бар. Украинаның «Долиннефть» промыселлар идарәсе һәм башка шундый илебезнең 26 предприятиесе белән дусларча, эшлекле элемтәләр тотыла. Җәлилчеләр, үз Җәлилләре белән бергә, бер тавыштан кабатлыйлар шикелле:

Бер ананың туган балалары —
Ташкын булып бергә кузгалдык.
Һичкайчан да, һичбер көч алдында
Җиңелмәс бу изге туганлык.

Бу ташкыннар кочәя бәралар. Алдынгылар сафына яңа коллективлар, куплаган ударниклар өстәлә. Бүген йөзгә якын участок һәм бригада, ике мең чамасы кеше коммунистик хезмәт ударнигы исеме алу өчен көрәшәләр. Вахтадан-вахтага, вакыт алга барган саен, график һәм план үтәлешен күрсәткән контроль сызык та күтәрелә бара.

«Якын арада тагын бер әһәмиятле үр яуланачак — безнең ятмаларда беренче миллиард тонна нефтьне чыгару тәгәлләнә,— диде КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Ф. Табеев партиябезнең XXIV съездында сөйләгән речендә.— Нефть чыгаруның шундый күләменә нибары 20 ел эчендә ирешеләчәк. Ватаныбыз нефть индустриясендәге бу тиңдәшсез тәҗрибә безгә ятмаларның нәтиҗәлелеген күтәрү юлларын эзләү өчен тагын да зуррак стимул булып хезмәт итәчәк».

Алда тагын яңа үрләр һәм бәйрәмнәр. Башкача мөмкинме соң! Аларның легендар якташлары, Моабит төрмәсендә үлем көткәндә дә, үзенең партиябезгә, илебезгә карата булган мәхәббәт хисләрен менә ничек җырлаган иде:

Кайгырма, җир, йөрәк калтырамас
Синең өстә чакта аяклар.
Аның исеме белән ачылган тел,
Үлгәндә дә аны кабатлар.

Бу чатка килеп чыккан юлчы, бәлки, өлеге карт имәнне эзләр. Ләкин әкияттәге кебек башка картинаны күреп гаҗәпкә калыр. Юк, әкият тә, гаҗәп тә түгел. Генпланда каралган масштабларда Җәлил эшчеләр поселогы үсүендә дәвам итә. Торак йортлар белән беррәттән культура-көнкүреш объектлары да үсеп чыгалар. Әле менә яңа уку елына 960 урынлы яңа мәктәпнең ишекләре ачылды. Биш катлы тулай торак, 140 урынлы балалар бакчасы файдалануга кабул ителде. Культура сарае һәм больница шәһәрчеген төзү мәйданнарында киеренке эш бара. Бер үк вакытта поселокны тезекләндерү һәм яшелләндерү чаралары күрелә. Үзәк бульвар буйлап тезелеп киткән сәүдә һәм башка көнкүреш биналары хәзерге заман культурасы ямен күрсәтеп торалар. Поселокның символик эмблемасы булып мәйдан уртасында Муса Җәлил һәйкәле тора. Ул мәһабәт, горур карашы белән көн саен якташларын вахтага озата, каршылый һәм гүя үзе дә алар белән бергә яши. Аның тирәсендә чәчәкләр клумбасы. Бик яраткан бит ул чәчәкләрне.

Чәчәкләр, үсегез, чәчәкләр,
Дәрт биреп безнең шат күңелгә.
Сезгә бу шатлыклар, рәхәтләр
Бит җиңеп алынган гомергә.

Әйе, ул шатлыклар һәм рәхәтләр... Үзеңне үз җиреңдә хуҗаларча тоеп яшәү нинди зур бәхет! Шуларны уйлыйсың да, бүгенге тормышны күрәсең дә, мәрхүм шагыйрьнең үз хәле турында «Соңгы үпкә» дигән әсәрендәге түбәндәге юлларын укыгач, күздән яшьләр килә:

Туган илем, үксез улың булып,
Үләм инде читтә тилмереп.
Яшем барсын сиңа елга булып,
Каным шытсын кызыл гөл булып.

Яшәүнең кадерен беләләр җәлилчеләр. Аларның яңа бичаларны, объектларны тизрәк һәм биегрәк итеп үстерәселәре, үз поселокларын мактаулы шәһәрләргә тиң итеп күрәселәре килә. Җәлилнең һәм шәһәрнең легендар исеме белән горурланалар алар.

Алар шушы чатта очраштылар. Тормыш төрле яклардан китерде аларны. Болай карауга күбесе яшьләр, кордашлар. Ләкин һәрберсенең үз биографиясе, үткән тормыш юлы бар. һәрберсенең үзенә хас характеры һәм тормышта тоткан урыны бар. Берәүләре — тормыш юлын беренче скважиналардан башлаган шушы як кешеләре. Илебезнең башка районнарында инде нефть исе сеңдереп яки махсус уку йортларын тәмамлап килүчеләр дә байтак. Хәзер инде алар барысы да үз кешеләр.

Әйтик, менә баш инженер Зиятдиновның эш бүлмәсенә килүчеләр гел өзелеп тормый. Юныс Ибраһимович дип, якын итеп, аңа эш белән дә, үз тормыш хәлләре

турында киңәш сорап та керәләр. Файдалы җавап алачакларына ышанып керәләр алар. Хәбибуллин Фәһим һәм Бәдрунов Хәләфләр — эштә алтын куллы мастерлар, гаиләдә киң күңелле әтиләр. Парикмахер Шура һәм икмәк сатучы Нисә апаны, игелекле һәм ягымлы булганнары өчен, фамилияләрен атап әйтмичә дә, бөтен кешә белә һәм ихтирам итә. Пенсионер Аксенов Михаилның узган еллар тарихыннан сөйләгән истәлекләрен яшьләр зур кызыксыну белән тыңлыйлар. Өстәвенә, ул бакчачылык буенча да бик файдалы киңәшләр бирә. Фатыйма апаларына ерактан ук олылап сәлам бирәләр. Шәфкатьле сүзе генә дә аның авырулар өчен шифалы булып тоела. Башта бөтен поселокка бер үзе иде. Хәзер врач Әхмәдиева поликлиниканың медработниклар коллективына җитәкчелек итә. Урамны иңләп комендант йөри. Аптырыйлар аңа: ничек өлгерә бу Оркыя, һич җитешмәгәне юк, диләр. Чыннан да, әйтергә генә ансат, тулай торакта берничә йөз кеше яши. Аларга нормаль шартлар тәэмин итәргә кирәк. Өстәвенә Әхметова җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша, яшьләргә тормыш кору буенча киңәшләр бирә. Олы яшьтә дип тормый, Шакирова Зәйтүнә бик дәртләнеп, драмтүгәрәк эшләрен оештырып йөри. Роберт Хәлиуллин җитәкчелегендә укытучылар коллективының концерт чыгышларын тамашачылар алкышлап каршылыйлар. Көндәлек эшләр һәм мәшәкатьләр белән шулай кайнашып яшәү дәверендә, барысы өчен дә уртак булган яңа гадәтләр һәм нормалар барлыкка килә, традицияләр формалаша.

Шунысы характерлы, бирердәге тормышның пульсендә яшьлек ритмы аеруча сизелеп тора. Муса Җәлилнең яшьләргә карата әйтелгән сүзләре девиз булып яңгырыйлар:

**Яшьлек дисез, әскә үрләр өчен**
**Бирелгән бит аңа канатлар.**

Шундый ялкынлы лозунглар белән яшь коммунистик хезмәт ударникларының эшләре булып үтә. Комсомол рейдлары, прожекторлары, спорт ярышлары һәм башка шундый масса чаралары практикага кереп баралар. Пенсионер Семен Михайлович җитәкчелегендәге 80 кешедән торган оркестрның тавышы юллар чатыннан еракларга яңгырый. Бәйрәм тантаналарын да шушы музыка бизи. Мәктәптә Муса Җәлил истәлегенә багышлап музей бүлмәсе ачылды. Ана «Ал канәфер» түгәрәге членнары шефлык итә. Яшь җәлилчеләр үлемсезлек һәм дуслык турындагы шигырьләрне телдән телгә күчереп кабатлыйлар, ташларга язалар:

**Үзем үлсәм, исемем, җырым үлмәс,**
**Ул яңгырар илнең кырында.**
**Сөйләп илгә тоткын күңелләрдә**
**Чәчәк аткан дуслык турында.**

Шул җырлар һәм хезмәт маршы астында тормыш алга бара. Бу поселокка җиде генә яшь дип һич уйламассың. Күп катлы йортлар, тарих тирәнлегенә тамыр җәйгәндәй, нык утыралар. Менә күңелләргә сафлык, йөрәкләргә дәрт биреп, җилләс җил исә. Түбәләр өстендә кызыл флаг җилфердн. Юкка гына җилфердәми ул: шул бинаның утырышлар залында поселок советының чираттагы сессиясе бара. Депутатлар, сайлаучыларның наказларыннан чыгып, хуҗалык һәм культура төзелеше өлкәсендәге мөһим чараларны билгелиләр.

Юлларда бертуктаусыз хәрәкәт. Йөз миллион тонналы Татарстан нефте өчен көрәшнең алгы сызыгы менә шушы яклардан үтә. Быел бу тирәдәге мәйданнардан 20 миллион тонна чамасы кара алтын алу күздә тотыла. Сарман буйларына таба киң фронт белән һөҗүм җәелдерелә. Яңа скважиналар борауланә. Электр һәм элемтә линияләре сузыла. Әлбәттә, асфальт юллар салына. Шушы юллар чатында форпост булып, үлемсезлеккә һәйкәл булып, нефтьле ҖӘЛИЛ поселогы күтәрелә.

**КӘШИФ ЗАРИПОВ,**
Әлмәт районы, Җәлил эшчеләр поселогы советы председателе.

**Асия Хәсәнова**

«Азат хатын» журналының баш редакторы.

# «АЗАТ ХАТЫН» ЖУРНАЛЫ ЧЫГА БАШЛАУГА 45 ЕЛ

«Гомер — аккан су белән бер», ди торган булган безнең бабайлар. Ә бүгенге, вакыйгаларга, могҗизаларга бай, киеренке хезмәт белән узучы көннәребезне нәрсә белән чагыштырырга? Замандашларыбыз әйткәнчә, әллә космик тизлекләргәме?

«Азат хатын» журналының, 17 еллык тәнәфестән соң, беренче саны чыгуга әле генә кебек. Баксаң, аңа да инде 13 ел узып киткән. Тормышыбыздагы үзгәрешләр, кешеләрнең аңы, белеме, культурасындагы үсешләр белән үлчәсәң, ул елларның һәрберсе бөтен бер чорга тигез. Без журналда шул үсешне күрсәтергә, замандашларыбыз — совет хатын-кызлары турында сөйләргә, укучыларыбызны илебездә бара торган гаҗәеп зур үзгәрешләр белән таныштырырга тырышабыз. Ләкин журналист блокнотында журналга кермәгән бик күп материал кала. Шул җөмләдән Союз буенча зур (300 000) тираж белән тарала торган журналның аякка басуы турында да укучыларыбыз күп нәрсәләрне белмиләр. Мин сүзне журналның беренче сәхифәләрен ачкан 1926 елдан түгел, ә сугыштан соң яңадан чыга башлаган һәм инде тарих булып бара торган 1958 елдан башлыйм, бүген безне борчый торган кайбер мәсьәләләр турында сөйләргә телим.

## «Яши безнең белән Сәхипҗамал диган Онытылмый торган легенда».

«Азат хатын» яңадан чыга башлый икән»,— дигән хәбәр гөр килеп алды. Матбугат киштәсенә тагын бер әдәби журнал өстәлү язучыларыбызны аеруча сөендерде. Редакциядән кеше өзелми, әле бер язучы, әле икенчесе кереп хәлләребез белән кызыксына, киңәш бирә, әсәрләрен тәкъдим итә һәм менә журналга яңадан җан керә һәм 1958 елның январь саны чыга.

Журналның беренче саны укучыларыбызның күңеленә хуш килүе белән без, һичшиксез, күренекле шагыйрьләребез һәм язучыларыбыз Хәсән Туфанга, Әхмәт Фәйзигә, Шәйхи Маннурга, Габдрахман Әпсәләмовка, Шәраф Мөдәррискә аеруча бурычлыбыз, чөнки беренче санга алар үзләренең иң әйбәт әсәрләрен тәкъдим иттеләр. Ничә еллар узса да, шагыйрь Шәраф Мөдәрриснең шул ук беренче санда басылган «Алжир кызы Җәмилә» исемле талантлы, ялкынлы публицистик мәкаләсен укучылар әле булса онытмыйлар, «Җәмиләнең язмышы турында язмассыз микән», дип әледән-әле редакциягә мөрәҗәгать итәләр.

Шагыйрь Әхмәт Фәйзи турында аерым сөйлисе килә. Ул елларда Әхмәт Фәйзи инде танылган зур шагыйрь иде. Аның «Тукай» романы да басылып чыккан

иде. Журналыбызның яңадан чыга башлавы аны да куандырды. Ул Мәскәүдән әледән-әле шалтыратып торды, эшнең барышы белән кызыксынды.

Кышкы кичләрнең берсе иде. Шактый соң инде. Өебездә телефон шалтырады. Мәскәүдән Әхмәт Фәйзи икән.

— «Азат хатын» өчен Сәхипҗамал турында шигырь яздым. Аны үзем алып барам. Иртәгә юлга чыгам,— ди.

Чыннан да, ике көннән соң редакциягә җиңел гәүдәле, җитез хәрәкәтле Әхмәт Фәйзи килеп керде һәм минем алга «әле генә табадан төшкән» шигырен куйды. Үзе шат. Күренеп тора: бу шигырен ул илһамланып, рухланып язган һәм башкаларның да фикерен беләсе килә, дөресрәге, башкаларны да куандырасы килә.

Заманында Тукайны:

Күр, ничек иртә кояш чыкса, җиһанда нур тула;
Һәр күңелләр нурланадыр, чыкса Гыйззәтуллина.
Бу икәүгә тәңре биргән бертигез зур мәртәбә:
Берсе уйный күк йөзендә, берсе уйный сәхнәдә,—

дигән мәңге онытылмаслык юлларны язарга рухландырган артистка бүген икенче зур шагыйрьне — Әхмәт Фәйзине түбәндәге шигырьне язарга рухландырган:

Уянуны һәм көрәш елларының
Искә алсам данлы билгесен,
Яшь ай булып туа күз алдымда,
Курай булып чыңлый колагымда
Сәхипҗамал дигән бер исем.

Каһәрле төн... Усал тискәре җил...
Юл өстендә ташлар, кыялар...
Артта — шымчы... Алда, кирпеч тотып,
Көтеп тора котсыз феодал...

Кыз боларны белә. Аның саен
Яшьләгән һәм бөтен сәләтен,
Кирәк булса гомерен, көлә-көлә,
Корбан итәр, тик яшәсен генә
Үз халкының якты сәнгате!

Рәссам тема эзләп газап чигә,
Әле йоклый таулар куенында
Киселмәгән таш сын... Ә монда
Яши безнең белән
Сәхипҗамал дигән
Онытылмый торган легенда.

Шигырен укып чыккач ук, типографиягә җибәрдек, чөнки беренче сан җыелып ята иде инде.

— Сәхипҗамал турында зуррак әсәр язу теләге дә бар миндә, мәнә романны гына тәгәллим...— диде Әхмәт Фәйзи.

Шагыйрь исән булса, без, ихтимал, халкыбызның беренче артисткасы Гыйззәтуллина-Волжская турында поэма я роман уку бәхетенә ирешкән булыр идек, әмма, кызганычка каршы, без аны арабыздан югалттык. Ә бит, мәрхүм шагыйрь әйткәнчә, исеме инде легендага әйләнгән Сәхипҗамал апа әле исән, ул безнең арада яши, әмма аның турында Нәкый ага Исәнбәт язган пьесадан башка әсәр күренгәне юк. Уноч ел үтсә дә, Әхмәт Фәйзи әйткән сүзләрне кабатларга туры килә:

Әле йоклый таулар куенында
Киселмәгән таш сын...

Кеше мәңгелек түгел. Язучыларыбыз, журналистларыбыз моны исләреннән чыгармасыннар иде.

Беренче санның корректурасы килгәч, Әхмәт Фәйзи аны кызыксынып карап чыкты һәм, безнең үтенүебез буенча, бер рәсемнең астына алты юллык шигырь дә язып куйды. (17 нче биттә басылган бу шигырь «Актырнагым минем акыллы...» дип башлана.) Шагыйрьнең теләген искә алып, без ул шигырь астына авторның исемен куймадык.

## «Һади Такташ шигыре»

Беренче белен төерле була, диләр. Баштарак без дә төерләнеп алгаладык. Менә шул елларда инде мин: «Барысын да кешеләр, кадрлар хәл итә»,— дигән сүзләрнең мәгънәсен яхшы аңладым. Аңлашылсын өчен сүзне баштан ук алып китик әле.

1957 елның ноябрендә «Азат хатын» журналын яңадан чыгару турында карар да бар, редактор да билгеләнгән, әмма штатта башка берәү дә юк иде. Ул заманда әле бүгенге кебек Казан университетында журналистика факультеты да юк, яшь язучыларның саны да бүгенге кебек йөзләр белән исәпләнми. Башка редакцияләрдәге журналистлар да килабез дип атлыгып тормыйлар. «Рәте булыр микән ул журналның», ди кайсы берсе. «Редакторы да моңа кадәр фәнни әдәбият белән генә шөгыльләнгән кеше. Ай-һай, барып чыгар микән аның эшләре», диючеләр дә бар. Ә мин эшне бик эредән башлаган идем, югыйсә. Журналның художнигы итеп теләсә кемне түгел, Татарстан художниклары союзы председателе Харис Якуповны, әдәби хезмәткәрләр итеп (мөдирләр редакция штатында әле дә юк) «Социалистик Татарстан» газетасының бүлек мөдирләрен чакырдым. Алар елмаештылар гына. Алай иттек, болай иттек, штатны көч-хәл белән туплап, эшкә керештек.

Менә, ниһаять, ун мең тираж белән журналның беренче саны чыкты. Без үзебезне мәйдан тоткан батырлар кебегрәк хис итәбез: бер өзлексез телефон шалтырый. Беренче булып безне язучылар, каләмдәшләребез — журналистлар котлый.

Көлке моментлар да булмады түгел.

Ул елларда Казанда аяк киемнәре тегә торган «Азат хатын» исемле артель бар иде. Менә телефон шалтырый.

— Бу «Азат хатын» әртилеме? Минем хатынга читек кирәк иде. Шуны тегеп бирмәссезме? — ди берәү язучы Абдулла Әхмәт тавышы белән.

Трубканы куярга өлгермим, тагын телефон шалтырый:

— Мәчетме? Намаз бетмәдеме әле? Абыстайлар ничәдә килерләр икән? — ди берәү борчулы тавыш белән.

— Абыстайларның эше күп, кунакка барырга вакытлары юк,— дим ачуланып.

Әмма шаяртып сөйләмәгәннәр икән: мәчет белән редакциянең телефон номерлары охшаш булганга, ялгышып безгә шалтыратканнар.

Беренче санга әллә ни исләре китмәгән галимнәребезнең өченче сан белән кинәт кызыксына башлаулары мине әлек бик куандырды. Без өченче сандагы бер мәкаләдә түбәндәге юлларны баскан идек:

Такташ... «Китикатка» дигән күңелле генә шигырь язды. Анда мондый юллар бар:

> Камиләләр бүген иртән
> Собраниегә киттеләр,
> Анда бүген Камиләне
> Делегатка иттеләр.
>
> Нәрсә булып сайланганын
> Юлга чыккач онытты,
> Юл буена шул исемне
> Хәтерләргә тырышты.

Китикатка микән, ди,
Митикатка микән, ди,
Өйдәгеләремә кайтып
Ни дип әйтим икән? — ди.

Журнал чыгып, бер-ике көн үттеме икән, Казан университетының доценты (хәзер ул профессор инде) язучы Хатип Госман шалтырата:

— Асия ханым, өченче санда Һади Такташның хәзергә кадәр безгә билгеле булмаган шигыре басылган. Кайдан таптыгыз аны? Шуның оригиналын күрергә мөмкин булмасмы? — ди.

Бераздан тәнкыйтьче Хәсән Хәйри шалтырата:

— Һади Такташның матбугатта басылмаган шигырен кайдан алдыгыз?

Тагын берничә кешенең соравына җавап бирергә өлгермәдем, бүлмәгә зур гәүдәле, таза гына берничә хатын килеп кермәсеннәрме.

— Редактор дигәннәре сез буласызмы? — ди арадан берсе.

— Мин,— дим. Һәм: «Менә журналның укучылары да рәхмәт әйтергә килгәннәр» дип эчемнән генә куанып куям.

— Ни өчен сез минем әниемнең шигырен Һади Такташ шигыре дип язасыз?

Хакым минем алдыма «Азат хатын» журналының 1928 нче елда чыккан 2 нче санын куя. Карасам, күзем дөрт булды. Шигырьнең авторы Мамашева. Һади Такташ турында сүз дә юк. Җитмәсә әле, редакция шундый искәрмә биргән: «Мамашева апа безнең иң карт җырчыларыбыздан. Ул хәзер 55 яшендә».

Кунаклардан гафу үтенеп, тиешле чаралар күрелер, дип юатып, җайлап озаткач, бу мәкаләне язган сотрудникны чакырдым.

— Ни өчен Мамашева шигырен Һади Такташ шигыре дип яздыгыз? — дим.

Сотрудникның исе дә китми.

— Язсам соң... Аның нинди әһәмияте бар?

— Бер авторның әсәрен икенче кешенеке дип язарга ярамаганны беләсез ич...

— Әй, Мамашева нинди автор булсын. Аны кем белә? Ә менә Һади Такташны белмәгән кеше юк.

Болай эшләргә ярамаганны аңлата башлагач, сотрудныгымның җен ачулары чыкты:

— Сез кызыклы материалны аңлыйсызмы соң? — диде дә ишекне шартлатып ябып чыгып та китте. Аның белән бәхәсләшеп утыру мәгънәсез бер эш иде. Бу мәкаләнең авторы журналда әдәби бүлекне алып барса да, бар белеме — җиде класс.

Унөч ел узды. Бүген безнең редакциядә югары белемле, исемнәре меңнәрчә укучыларга таныш булган тәҗрибәле журналистлар эшли. Мәдинә Маликова, Диләра Зөбәерова, Кояш Тимбикова һәм Габдулла Шәрәфетдиновларның инде әдәби әсәрләре дә басылып чыкты. Маликова, Зөбәерова һәм Шәрәфетдинов инде язучылар союзы члены. Техник редакторыбыз Эльмира Әднатуллина эштән аерылмыйча Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлады. Венера Кәлимуллина шул бүлекнең соңгы курсын тәмамлау алдында, секретарь-машинисткабыз Фәүзия Гарифуллина культура институтының II курсында укый.

Ил язмышы — халык язмышы, дип әйтәләр. Илебез үсә, ныгый, илебез белән бергә халкыбыз да, шул халыкның бер тамчысы булган хезмәткәрләребезнең дә белеме, культурасы, аңы, осталыгы үсә.

## «Бетсен мода, яшәсен хезмәт!»

Журналның беренче саннарын әзерлибез. Мода бүлегенә күлмәк өлгеләрен аеруча сак сайлыйбыз, фасоннарның гадирәкләрен алырга тырышабыз. Ни әйтсәң дә «мода», «модалы» дигән сүзләрнең дәрәҗәсе зур түгел иде әле. Әмма шул гади генә фасоннар да кайбер укучыларның ачуын китерде. Шундый ярсулы хатлар-

ның беренчесе Актаныш районыннан килеп төште. «Сез безне рестораннан ресторанга йөри торган эшсез хатыннар дип уйлыйсыздыр. Без эш кешеләре. Безгә модалар кирәк түгел. Бетсен мода, яшәсен хезмәт!» дигән бик катгый сүзләр белән тәмамланган иде ул хат.

Еллар узды. Мин Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында утырам. 1200 кеше сыешлы тамашачылар залы шыгрым тулы. Республикабызның колхозчылар съезды бара. Бирелә колхозчылар, механизаторлар, агрономнар, галимнәр, күрше республикалардан килгән кунаклар. Залны игътибар белән күзәтәм. Моннан берничә еллар элек авыл кешесе урамда булсын, театрда булсын, кием-салымы, прическасы белән әллә каян аерылып тора иде.

Ә менә хәзер биредә кемнең агроном, кемнең сыер савучы яки галим икәнен белә алмыйсың: ирләр өстендә заманча тегелгән костюмнар, кершәндәй ак күлмәк, галстук, хатын-кызларның өстендә яхшы күлмәк. Кыш булуга карамастан, аягына киез итек кигән, башына дебет шәл чорнаган хатын-кыз юк хәзер. Башына яулык япкан кайбер хатын-кызларны авыл кешесе икәнен чамаларга мөмкин. Дөрес, әле дә теге яки бу мода белән риза булмауларын белдереп безгә хатлар язалар. Әмма бу хатларда инде: «Бетсен мода!» дигән сүзләрне очратмассың.

## «Хатын-кыз әдәбияты бармы?»

Хәзер бу сорау сәер яңгырый, әмма журнал чыга башлаган елларда бу мәсьәлә безнең канга шактый күп тоз салган иде. Журналның берничә саны чыгуга бер төркем хатын-кыз чат ябышты:

— Журналда ир-ат катнашмасын!

Әмма иң гаҗәбе шул булды: бу сәер тәкъдимне очраклы кешеләр түгел, бәлки матбугатта утыз елга якын эшләп килгән һәм шул чактагы редколлегия члены булып торган иптәш яклады.

— Фатих Хөсни әсәрләрен без башка журналлардан да укый алабыз. «Азат хатын» журналында, йомшаграк язылган булса да, хатын-кызларның әсәрләре генә басылсын! — диде ул.

Каләм тибрәтүче берничә ханым, басарга яраксыз әсәрләрен кайтарып бирсәң:

— «Азат хатын»да хатын-кызга мөнәсәбәт начар,— дип шау итәләр иде.

Безнең хәлләр мөшкелләнде. һәм, дөресен әйтергә кирәк, ул елларны (ул елларны гына микән?) шактый шүрләп, без, әдәбиятка мөнәсәбәте шикле булса да, хатын-кызлар язганы өчен генә, йомшак әсәрләр баса башладык. Бүгенгедәй хәтеремдә, ояла-ояла, журналда:

> Каенлыкка барсаң — исең китәр:
> Анда шундый-шундый матурлык! —

дип башланган шигырь басып чыгардык. Күп тә үтмәде, редакциягә Гомәр ага Бәширов килеп керде, гадәттәгечә, ашыкмыйча һәм көлемсерәп:

— Асия, әдәбиятны, шигъриятны аңлый торган кеше дип уйлый идем мин сине, ә менә шундый нәрсәләргә журналда урын бирә башлавың гаҗәпләндерә,— диде.

Туры сүзгә җавап юк. Гомәр ага хаклы иде. Язучылар җыелышында да безне шуның өчен әсәрләр өчен шактый нык «пешерделәр». Шуннан соң без таләпчәнрәк була башладык. Хатын-кызларның әсәрләренә таләп артык каты булмасын, дигән карашны мин үзем якламый идем. Бервакыт Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим белән шул турыда сөйләшеп торганда, ул да:

— Бездә ирләр һәм хатын-кызлар әдәбияты юк, бездә совет әдәбияты гына бар. Кем язуга карамастан, таләп бер — әсәр, һичшиксез, яхшы булырга тиеш! — диде.

«Все гениальное очень просто» дигән иде Эйнштейн. Без күптән белергә тиешле хакыйкатьне әйтте бит шагыйрь.

Юк юк та безне борчыган проблема тегe яки бу формада әле дә калкып чыкалый. «Сез хатын-кыз язучыларга ярдәм итәргә тиеш!» — диләр.

Һәм бу ярдәмне кайберәүләр автор өчен... хикәя язып бирүдә күрәләр. Автор безгә, итек тегәргә китергән шикелле, чиле-пешле материал китерә дә, безнең сотрудниклар шуннан хикәя язарга тиеш булалар.

Олы әдәбиятка кеше җилкәсенә атланып керү була түгелме соң бу?

## Якын ярдәмчеләребез

Һәр көнне дип әйтерлек эшкә килүгә телефоннан: «Иптәш Рәхмәтуллина килмәдеме әле?», «Рауза Газизова бүген анда булырмы?», «Гасимә апа Мостафина?» дип сорыйлар. Кемнәрне шулай эзлиләр соң? Бу иптәшләр — редакциянең штаттан тыш бүлек сотрудниклары. Илледән артык кеше эшли торган бу бүлекнең эше укучыларга күренми диярлек яки бу эш журналның 24 нче битендәге «Азат хатын» ярдәм итте» дигән баш астында биш-алты юллык кыска информациядә генә чагылып китә. Хәлбуки, зур һәм кирәкле эш эшлиләр бу иптәшләр. Балалар бакчалары һәм ясләләр салынуның барышын тикшереп торалар, мәктәпләрдә, ата-аналар янында булалар. Шәһәр активының бер утырышында «йозләрчә балалар кая барырга белми урамда трай тибеп йөрергә мәҗбүр булган бер вакытта шимбә һәм якшәмбе көннәрдә күп кенә мәктәпләрнең физкультура заллары бикле була», дип сөйләнгән иде. Шуннан соң бүлек эшчеләре Казандагы утызга якын мәктәпнең физкультура залларын тикшерделәр. Табигатьне саклау буенча да шәһәр оешмаларына бик эшлекле тәкъдимнәр керттеләр. Төрле учреждениеләргә йөреп-йөреп тә эшләре чыкмагач, редакциягә мөрәҗәгать иткән күпме иптәшкә ярдәм иттеләр, туганнарын югалткан күпме кешегә булыштылар, журнал өчен күпме әһәмиятле, кызыклы темалар тәкъдим иттеләр.

Без гадәттә активистларның җәмгыятькә китергән файдалы эшләре турында гына сөйлибез. Ләкин иҗтимагый эш кешенең үзе өчен дә файдалы. Җәмәгать эше кешене үстерә, аның тормышына эчке бер яктылык бирә, кызыклырак итә. Мисалга Рауза Газизова иптәшне алыйк. Язучы хатыннарының кайберләре кая да булса бер җиргә кереп эшләми. Ул үзенең тормыш иптәше — язучыга иң беренче ярдәмче. Аның беренче тәнкыйтьчесе, секретаре, китапханәчесе һ. б. Рауза Газизова да — язучы хатыны. Шуның өстенә, әле ул өч бала анасы. Шулай да ул җәмәгать эшендә актив катнашырга вакыт тапты һәм бу эш аңа йорт хуҗасы гына булып калмаска, бәлки үсәргә ярдәм итте. «Азат хатын» журналының штаттан тыш бүлек мөдире булып эшләүче Рауза Газизова хәзер актив журналист та, татар мәктәпләре өчен дәреслекләр төзүче автор да. Бу мактаулы эшләре өчен ул КПССның Татарстан өлкә комитеты һәм Министрлар Советының Почет грамотасы, «Работница» журналы редакциясе, Татарстан тынычлыкны яклау комитеты, «Азат хатын» журналы редакцияләре Почет грамоталары белән бүләкләнде. Мәскәүдә һәм Казанда үткәрелгән семинарларга чакырылды. Редакциянең актив ярдәмчесе булып киткән иптәшләрнең бер өлеше журналист булып үсте. Аларның мәкаләләре «Социалистик Татарстан», «Татарстан яшьләре» газеталарында һәм журналларда басыла.

Газета-журналларның бай эчтәлекле, анда басылган материалларның тәэсирле булуы өчен редакциядә оста журналистлар эшләү генә, хәтта авторлар саны күп булу гына да җитми. Һәр редакциянең Газизова, Хөснетдинов, Мостафина, Рәхмәтуллина, Гафарова, Магизов, Зәйнуллина, Булатова, Садыйкова кебек тырыш ярдәмчеләре дә булырга тиеш.

# Алда торган бурычлар

Укучылар хәтерлидер, узган унөч ел эчендә журнал хатын-кызлар тормышына кагылышлы күп кенә әһәмиятле мәсьәләләрне күтәрде. Мәсәлән, моннан егерме еллар элек Татарстан үзенең механизатор хатын-кызлары белән дан тота иде. Соңгы елларны аларның күбесе башка эшкә күчкән, кызлар бу эштән читләшә башлаганнар. Элек механизатор булып эшләгән кайсы гына хатын-кыз белән сөйләшсәң дә, сыер саву, дуңгыз фермасында яки кырчылык бригадаларында эшләү трактор я комбайнда эшләүдән җиңел түгел дип әйтәләр. «Механизатор булсаң, ичмаса, сине төрле эшкә куып йөртмиләр, кулыңда менә дигән профессияң була, эш хакың да, пенсиягә чыккач пенсияң дә югары, почетың да зур була», диләр. Шуларны истә тотып, без дүрт ел буена кызларны механизаторлык эшенә чакырып язылган күп кенә мәкаләләр, хатын-кызлардан механизатор ветераннарыбызның мөрәҗәгатьләрен урнаштырып киллдек. Әлеге мәкаләләрдән соң механизатор булырга теләкләрен белдереп йөзләрчә кызлардан хатлар килде. Без механизаторлар әзерли торган уку йортлары белән элемтәгә кердек, кызларны күбрәк алуларын һәм аларга тиешле шартлар тудырылуын үтендек. Бу чаралар нәтиҗәсез калмады. Ләкин бу өлкәдә әле бик күп эшлисе, тырышлык куясы бар, чөнки гомумән алганда, авыл җирләрендә механизатор булып эшләүче хатын-кызларыбыз аз әле.

Хатын-кыз — җәмгыятебезнең актив члены гына түгел, ул әле безгә алмашка килүче буынны тәрбияләп үстерүче дә. «Ана — бөек исем!» ди шагыйрь Һади Такташ. Бөек һәм җаваплы исем! Безнең чор балаларын тәрбияләп үстерү, мәктәпләрдә элеккеләреннән катлаулырак программалар буенча укучы балаларга ярдәм итү өчен эни кешегә 7—8 класс белем һич тә җитмәячәк. Анның ким дигәндә урта белеме булырга тиеш. Хатын-кызларның белемен арттыру, аларны җитәкче эшләргә күтәрү, яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләү, хатын-кызларның хезмәтен җиңеләйтү кебек мәсьәләләр журналның һәрвакыт игътибар үзәгендә.

Партиябезнең XXIV съезды совет халкының тормыш-көнкүреш шартларын яхшыртуга юнәлдерелгән гаять зур чаралар билгеләде. Журнал хәзер үзенең төп бурычы итеп әнә шул чараларны тормышка ашыруга хезмәт иялярен туплауда партия һәм совет оешмаларына якыннан торып булышуны саный.

**Мөнир Юсупов**

# СҮРИЯДӘ ОЧРАШУЛАР[1]



Сүриядә ике еллап эшләү дәверендә минем өчен иң хатирәле вакыйгалар — Пальмирада булу көннәре иде.

Пальмира — ком даласы үзәгенә урнашкан борынгы шәһәр. Легендаларга караганда, ул Соломон[2] патша хакимлек иткән елларда салынган.

Географик яктан уңайлы урында утыруы аркасында Пальмира тора-бара Рим һәм Персия сәүдәгәрләренең очрашу базары булып китә. Алтын-көмеш төялгән кәрваннар шәһәргә төрле яктан агылып кына тора. Пальмиралылар исә, ком чүлләренә чыгып су сату, кәрваннарны юлбасарлардан саклау кебек эшләрне эшләп, шактый муллык белән көн күрәләр. Шәһәрнең байлыгы Рим вәкилләренең нәфесен уята һәм алар безнең эрага кадәрге 42 нче елларда Марк Антоний җитәкчелегендә Пальмирага һөҗүм оештыралар. Коралллы һөҗүмгә каршы торырлык ныгытмалар белән әйләндерелеп алынмаганлыктан, шәһәр дошманга бирелергә мәҗбүр була һәм бик күп еллар буе Рим императорына ясак түләп торырга тиеш була. Соңрак Пальмира гарәп халифәлеге составына кертелә һәм яңадан үсеш чорын кичерә.

Менә шундый катлаулы вакыйгалардан тора Пальмираның үткән тарихы. Ял көннәренең берсендә шул шәһәрнең ярым хәрабә хәлендәге урынын карарга бардык. Хәрабәләр шактый киң мәйданны биләп тора. Аларны истәлек өчен фотога төшерү нияте белән, без шәһәр читендәге артык биек булмаган тау итәгенә күтәреләбез. Аннан гасырлар җилена баш ими утырып калган йөзләрчә колонналар бик яхшы күренә. Ә тау түбәсендә дистәләрчә гасырлар буе сәяхәтче һәм туристларны үзенә тартып тора торган замок. Калаат ибн Маан дип аталган бу крепостьның тарихы атаклы друз халкының әмире Фәхр-эд-Дин (1590—1635) патшалык иткән чорлардан башлана дип сөйлиләр. Ливанның һәм өлешчә Сүриянең хуҗасы булып алгач, бу әмир терекләрнең һөҗүменнән саклану өчен бик күп урыннарда текә тау түбәләренә крепостьлар салдыра. Бу да шундый крепостьларның берсе. Борынгы гарәп стилендә эшләнгән зур капка аша эчкә үтәбез. Һәркайда биеклеге 20 шәр метрлы таш баганалар. Моннан өч-дүрт йөз ел элек бу колонналарның өстендә матур йортлар булган, аларда кешеләр яшәгән. Колонналарның башында элек полководецларның һәм колонналар төзүгә зур өлеш керткән гади кешеләрнең сыннары куелган булган.

---

[1] Ахыры. Башы 7 санда.

[2] Соломон — элекке Израил дәүләте патшасы, Давидның улы. (Безнең эрага кадәр 971—972 еллар.) Мөселман легендаларында исә Соломон — Сөләйман, Давид — Дауыт дип йөртелә.

каласың. Экскурсоводның сөйләвенә караганда, колонналарны [illegible] бу мәрмәр ташларны Сүриядә түгел, Мисырда — Асуан тирәсендә чыгарганнар. 20 шәр тонналы ул ташларны диңгез буйлап башта Бейрутка, ә аннан Ливан далалары аша Пальмирага алып кайткан булырга тиешләр. Бу, әлбәттә, коллар көче белән эшләнгән.

Таулар артына бик зур Кояш гыйбадәтханәсе урнашкан. Аның җилләр ашаган стеналары янына килгәч, сокланмый китә алмыйсың. Стеналарның һәркайсы озынлыкка 200, ә биеклеккә 16 метр.

Сүриянең кайсы гына почмагына барып чыкма — һәркайда тарихи вакыйгалар белән бәйләнгән истәлекле урыннар. Мөлаем-кунакчыл гарәп халкы үткән вакыйгаларны легендалар белән бизәп, матурлап килгән. Шундыйларның берсе — Дәмәшкъ шәһәреннән 35 километрларда урнашкан Седнай авылы. Анда 2300 кеше яши, барысы да христианнар. Авылның бер өлеше үзәнлеккә, ә бер өлеше тау башына урнашкан. Соңгысының ерактан ук күренеп торган монастыре да бар. Күңелне җәлеп итеп торган бу монастырьның легендасы кызык кына.

Тарихтан мәгълүм булганча, Рим императоры Юстиниан 547 елны үзенең гаскәрләре белән Сүрия җиреннән уза. Гаскәрләре суга сусагач, Дәмәшкъ шәһәреннән ерак түгел бер урынга туктап хәл алдырырга була. Үзәнлекләрдә чишмә эзләп йөргәндә Юстиниан кыр кәҗәсе күрә һәм, аның матурлыгына сокланып, артыннан куа китә. Ләкин тота алмый, күзеннән югалта. Әмма кич җиткәч, яңадан очрата. Атарга дип җәясен тарткач, кинәт бөтен тирә-якны яктыртып нур балкый һәм кыр кәҗәсе гүзәл кыз кыяфәтенә кереп, телгә килә: «Син мине үтерә алмассың, Юстиниан. Угыңны кынысына салып куй да мин басып торган урынга монастырь салдыр»,— ди. Шунда ук нур сүнә һәм кыз да югала. Кызга гашыйк булган Юстиниан, аның сүзен үтәп, шул урында монастырь салдырган, имеш.

Бер көнне эштән кайтып, гарәп телендә кызыклы гына китап укырга дип утырган идем, номерыма Галә-эд-Дин (безнеңчә Галәветдин була) йөгереп керде.

— Әйдә, җыен тизрәк, туйга барабыз, икенче энем өйләнә. Сезнең як кешеләре туенда буласым килә дигән иде бит,— диде.

Озак уйланып тормыйча, шефка кердем һәм, бераз соңлап кайту ихтималымны әйтеп, урамга чыктым.

Без килгәндә туйның кызган чагы иде. Киң һәм якты бүлмә. Өстәл-фәлән юк. Стена буйлап урындыклар тезелгән. Аларга шәһәрнең аксакаллары һәм башка кунаклары утырган. Уртада музыкант. Авызына курайга охшаш нәрсә капкан да моңлы гарәп көйләрен сыздыра. Алар аерым бүлмәгә җыелганнар. Безгә аш-суны да ирләр ташыды. Аннары берничә ир бергәләп «Корьән» сүрәләрен көйләп укыдылар. Аннары уен-көлке, җыр-бию башланды. Болар барысы да кияү белән килен очрашканчы эшләнә икән. Килен бу вакытта әти-әнисе, туганнары белән бергә кияүнең килүен көтеп утырырга тиеш. Бераздан егетне ата-анасы, туган-тумачалары әйләндереп алдылар да шәп-шәрә калганчы чишендерделәр һәм одеколон сиптереп өр-яңа күлмәк, чалбар кидерделәр. Бу исә аны кыз янына барырга хәзерләүләре иде. Шуннан соң туганнары, якын танышлары егетне уртага алып, кыз өенә юнәлделәр. Галә-эд-Дин мине дә калдырырга теләмәде. Юл буе кызның чыгуын сорап җырлар җырладылар. Ләкин кыз чыкмады. Килен янына кияүдән башка берәүнең дә керергә хакы юк. Урамда калып без кияү белән килennең чыкканын көтәбез. Алар чыгып баскач, барыбыз да киленне котлыйбыз һәм, исәнлек-саулык, бәхетле тормыш теләп, яңадан кияүнең йортына әйләнеп кайтабыз. Һәркайсыбызга аерым тәлинкәләрдә татлы азыклар өләшеп чыгалар. Ашыйсың килсә ашыйсың, үзең белән алу да гаепкә саналмый.

Өйләнешү вакытында иң әһәмиятлесе — калым җыю. Әгәр ярлырак егет өйләнергә теләсә, кызны күрми торып, ул калым өчен акча эшли башлый. Сумма 5 мең сирия фунтыннан да ким булырга тиеш түгел. Артыграк булса — тагын да шәбрәк.

Калым гарәп яшьләренең алдагы көне өчен кирәк. Әгәр, мәсәлән, килен иреннән аерылырга теләсә икән, ул бөтен административ расходларны үзенә ала. Яшь гаиләләрнең аерылышу очракларын егет белән кызның өйләнешкәнче бер-берләрен күрмәүләре белән аңлатырга кирәк. Шуның өстенә, ирләр, семья бюджетларын истән чыгарып,

була.

Калым дигәннең башка яклары да бар әле. Әгәр егет фәкыйрь икән, ул кызның атасына эшләргә тиеш һәм ата хезмәт хакы урынына аңа үзенең кызын тәкъдим итә. Һәр ике якның да калым бирерлек рәте юк икән, кияү гаиләсеннән бер кыз килен гаиләсенә килен булып төшәргә тиеш.

Хомс шәһәрендә Габдел-Кәрим Төркмәни атлы бер сатучы белән танышкан идем. Аның бабасы кайчандыр Төркмәнстан республикасында яшәгән булган. Габдел-Кәрим магнитофон, транзистор кебек әйберләр ремонтлап көн күрә. Өйләнмәгән. Бик кыстагач, мин аның өенә барырга булдым. Тар гына иске караңгы бүлмә. Идәне балчык. Су түгелсә, шунда ук җебеп аякка ябыша.

— Менә минем бөтен байлыгым,— диде ул, почмакта торган китап шүрлегенә күрсәтеп. Инглизчә, гарәпчә китаплар арасында Советлар Союзы турында язылганнары да бар иде.

Бераздан җырлап утырган самовар янына хуҗа йомырка тәбәсе, ипи һәм май куйды. Өстәл янына утырышкач, ул үзенең өйләнергә ниятләвен һәм бераз акча да туплавын, ләкин калымга җитәргә бик күп кирәклеген әйтте. Калым җыю өчен яхшы һөнәрче булу гына җитми, ди. Ул, хәллерәк иптәш табып, хуҗалык әйберләрен ремонтлау мастерское ачарга хыяллана.

Кая гына барсам да, кем белән генә сөйләшсәм дә, мине, барыннан да бигрәк, гади гарәп халкының, хезмәт ияләренең тормыш-көнкүреш хәле кызыксындыра иде. Шуңа күрә буш вакытларымда күбрәк йөрергә, күбрәк күрергә тырышам. Бу исә, берьяктан, миңа Сүрия диалектын тирәнрәк аңларга ярдәм итсә, икенчедән, Якын Көнчыгыш гарәп дөньясының бүгенге культура һәм экономикасын танып белергә булыша. Шул максат белән көннәрнең берендә Ливанның башкаласы Бейрутка барырга булдым. Ливан мине Әмин-әр-Рәйхани, Җәбрән Хәлил Җәбран, Михаил Нуайме кебек галимнәрнең ватаны буларак кына түгел, үзенчәлекле, тарихи ил буларак та кызыксындыра иде.

Автомоторицаның беренче класслы салоны. Пассажирлар күп түгел. Янәшәмдә берничә егет утыра. Каршымда ирле-хатынлы ливанлылар да бар. Ире 45 ләрдә булыр,еска-биткә чибәр, төз гәүдәле. Хатыны исә кайгылы — чәчләре ап-ак. Алка, браслет, балдак кебек бизәнү әйберләре — бар да алтыннан. Өсләренә кигән киемнәре дә бай гемьядан икәнлекләрен әйтеп тора. Кулымдагы газеталарны күреп, минем гарәпчә белүемне аңлады булса кирәк, ире сорау бирде:

— Сез кайдан буласыз?

— Советлар Союзыннан,— дидем мин, ниндидер эчке горурлык белән һәм җавабымнан соң сорауларның күпләп явачагын тоеп. Һәм ялгышмадым.

— Ә гарәпчәгә кайда өйрәндегез? Әллә Советлар илендә гарәпчә укыталармы? — диде ул, сорауларны бер-бер артлы тезеп.

Бездә күп кенә университетларда көнчыгыш телләрен өйрәнү факультетлары, Мәскәүдә хәтта берничә махсус институт та барлыгын әйткәч, әңгәмәдәшемнең гаҗәпләнүдән кашлары маңгаена менде.

Аның исеме Рәшит Битан икән. Бейрутта кечкенә ресторан ачып җибәргән. Бейруттагы Америка университетын тәмамласа да, Советлар Союзы турындагы мәгълүматлары бик чикле булып чыкты. Русчага гарәп авторларының әсәрләре тәрҗемә ителүен һәм бездә дин тотуның ирекле икәнен ишеткәч, сүз әйтә алмый аптырап калды.

Бейруттан кайтышлый, эш белән Сүриянең икенче бер тарихи шәһәре Һамага кагылырга булдым. Бу борынгы шәһәр Нәхер-әл-Асы елгасының яшел үзәнлегенә урнашкан. Археологларның язуына карaганда, якын тирәдәге калкулыклардан унике дәвер катламы табылган. Бу хәл исә әлеге үзәнлектә безнең эрага кадәр биш мең ел элек кешеләр яшәгәнлеген дәлилли. Шәһәрнең искиткеч бай музеена кергәч, археологлар сүзенә ышанмый кала алмыйсың.

Һама бүген дә үзенең патриархальлеге белән аерылып тора. Табигать шартларының яхшы, уңдырышлы мәйданнарның күп булуы шәһәр халкына кырчылык, яшелчәчелек һәм җиләк-җимеш үстерү белән көн күрергә мөмкинлекләр тудыра. Шуңа күрә күп кенә хөкүмәт чиновникларының Һама белән тыгыз элемтәдә торуы бер дә гаҗәп түгел.

эшли. Шәһәрнең бер читендәрәк металл әйберләр заводы төзелеп килә. Ләкин һа һәм аның тирә-яклары, минемчә, туристлар күңелендә борынгы җир сугару корылм ларының күплеге һәм оригинальлеге белән калырга хаклыдыр шикелле. Без яр буе дагы искиткеч зур наур янына килеп туктыйбыз. Наур — су агымы белән хәрәкәт китерелә торган, диаметры 20—25 метрлы агач тәгәрмәч. Аның әйләнәсенә тагар кебек итеп калаклар беркетелгән. Елга агымы белән әйләнгән тәгәрмәчнең әле калаклары өскә күтәрелгәч, су анда торган ялгашларга агып төшә һәм, махсус ары лар буйлап, кирәкле урыннарга китә. Наурда бер генә тимер болт, тимер кадак очра массың, барысы да агачтан. Хәер, шулай булмаса, алар күптән инде суда тутыгып һә череп эштән чыккан булырлар иде. Шундый зур тәгәрмәч ничә гасырлар инде ышкы лу, шыгырдау тавышы чыгарып, салмак кына үз көенә әйләнә дә әйләнә.

Мондый җир сугаргыч корылмаларның саны Һама оазисларында 80 нән арта. Ка бер белгечләрнең исәпләвенчә, аларның күбесе Рим империясе Сүрияне басы алганчы ук эшләнгән булырга тиеш, ләкин иң куәтлеләре соңрак ясалган. Мәсәлә Нәхер-әл-Асы елгасының сул як ярындагы Әл-Мөхәммәдия науры якындагы мәчетне с белән тәэмин итәр өчен XIV гасырда гына эшләнгән.

Сүрия халкы — хезмәт сөючән, тәләпчән халык. Гасырларны таң калдырып килга тарихи һәйкәлләр моны ачык күрсәтә. Ләкин империалистик дөнья Сүрия халкыны эчкерсез күңелендә генә түгел, политик һәм экономик тормышында да озак вакытла төзәлә алмаслык җәрәхәтләр калдырган.

Хәзер илнең кайсы гына почмагына барып чыкма — һәркайда гигант төзелешлә бара. Халык рухланып яңа, бәхетле тормыш кора. Ләкин хәзерге заман техникасы яхшы үзләштергән югары квалификацияле белгечләр җитми. Вакытлыча контракт белә Советлар Союзыннан һәм социалистик илләрдән килгән белгечләре генә бөтен и күләмендәге төзелешне тәэмин итеп бетерә алмыйлар, әлбәттә...

Туган илдән тагын бер группа белгечләр килү сәбәпле, миңа яңа төзелеш объек ты — Тартус шәһәренә кучәргә туры килде. Тартус — Урта диңгез буена урнашка кечкенә шәһәрчек. «Даниял» гостиницасының бишенче катыннан тар урамнар, кукка калкып торган мәчет һәм чиркәү манаралары күренә. Тәрәзәләре диңгезгә караган бүлмәгә урнашкан идем. Дулкыннар шавының йөрәккә сихәтле булуын шунда тойдым

Газиз-эд-Дин исемле бер егетне безгә аш пешерүче итеп билгеләделәр. Бирерә чит җирдә, үз милли ашың бик сагындыра. Шуңа күрә үзебез яраткан ашларны пеше рергә Газиз-эд-Дингә чиратлап булышабыз.

Газиз-эд-Диннар семьясы кайчандыр Палестинада яшәгән. Израил оккупантлары басып кергәч, торыр урыннары калмаган һәм алар качып китәргә мәҗбүр булганнар. Эшсезләр дөньясына эш эзләп килгән кешенең хәлен аңлау кыен түгел, әлбәттә.

Сүрия хөкүмәте качакларны эшкә урнаштыру өчен бөтен мөмкинлекләрдән фай даланырга тырыша. Аларның торыр урыннары да юк, палаткалар төзеп аерым лагерь ларда яшиләр. Санитария-гигиена шартлары булмау сәбәпле, еш кына авырулар тарала.

Нәрсә, ни өчен соң бу гарәпләр мондый көнгә калганнар? Палестина мәсьәләсе — бүгенге көндә ашыктыргыч хәл ителәсе халыкара проблемаларның берсе. Иордан ел гасы белән Иерусалим шәһәре ничәмә-ничә еллар инде гарәпләр белән Израил ара сындагы конфликтның төп чыганагы булып килә. Көнбатышның империалистик даирәләренең бу каршылыкларны үз максатларын тормышка ашыруда файдаланырга тырышулары һәркемгә мәгълүм. Гарәп илләренең мөстәкыйль юлга басуына аяк чалып маташуларын фәкать Якын Көнчыгышның табигый байлыкларына монополия оешмалары белән генә аңлатырга мөмкин.

Мин повар Газиз-эд-Дингә тиздән совет белгечләре һәм яңа машиналар киләчәген һәм шуннан соң күпләргә эш булачагын әйтәм. Аның коңгырт-кара күзләре җанланып китә, кайгылы йөзендә шатлык нурлары балкый.

— Ктир Квейс, руси машина[1],— ди ул, үзенең совет машиналарын күргәнлеген белдереп.

---

[1] Рус машиналары бик яхшылар (Сүрия диалекты).

запас частьлар эзләшеп кайтуымны үтенде. Мин риза булдым.

Сатучыдан үзебезгә кирәкле әйберләрне сорауга, кибет хуҗасы гаҗәеп тиз өлгерлек белән безнең янга йөгереп чыкты. Ул безне шәхси милек хуҗалары дип уйлады, ахры, сәүдә фирмасына кампаньон булып керергә кыстый башлады. Бөтенләй көтелмәгән һәм безнең колакка сәер яңгырый торган мондый тәкъдим мине ирексездән елмаерга мәҗбүр итте. Мин аңа үзебезнең Совет белгечләре булуыбызны һәм Сүрия халкына техник ярдәм күрсәтергә килүебезне әйткәч, ул тагын да ачыла төште. Кибетенең безнең өчен һәрвакыт ачык булуын әйтеп, ул альбом-каталог чыгарды. Анда безгә кирәкле совет подшипниклары да бар иде.

Үз хезмәте белән көн күргән гади кешеләр арасында мин ышанычлы дуслар очраттым. Хомс шәһәрендә яшәүче Мөхәммәт шундыйларның берсе иде. Бер ял көнендә без аның белән җәяүләп олы юлдан килә идек. Шул чак, шоферларның саксызлыгы аркасында, бер автокран яны белән ауды да дөрләп яна башлады. Кешеләр куркышып читкә тайпылыштылар. Автокранның шоферы, тончыга-тончыга кабина ишеген ачып, ялкын эченнән чыгарга тырышты. Бензобакның менә-менә шартларга торуына карамастан, Мөхәммәт ярдәмгә ташланды һәм һушын югалткан шоферны үлемнән коткарып калды.

Ул үзе Тартус шәһәреннән ерак түгел — Хәсәен-әл-Бәхер авылыннан иде. Соңрак миңа ул авылга кунакка да барып кайтырга туры килде. Табигатьнең иң матур урыннарыннан берсенә урнашкан «Шавати-эл-Азрак» пляжы да шуннан ерак түгел. Аның татарчасы зәңгәрсу ярлар дигән сүз. Чыннан да, диңгездән килгәндә зәңгәр күк төсен хәтерләткән сөзәк ком ярлары ерактан ук күңелне җәлеп итеп торалар.

Мөхәммәтнең өе авыл читендәрәк булып, дүрт казык башына эленгән брезенттан гыйбарәт иде. Берничә хатын-кыз һәм бала-чагаларның ишек алдында савыт-сабалар юып маташкан чагына туры килдек. Мөхәммәт минем Россиядән, Юрий Гагарин иленнән булуымны әйткәч, бала-чагалар мине сырып алдылар һәм төрлесе-төрле сораулар яудыра башлады. Мөхәммәт исә горур кыяфәт белән йөри: менә, имеш, аңа нинди зур илдән кунак килгән. Ашарга әзерләргә кушып, хатыннарын ашыктыра, мине кунак итәргә бөтен семьясын аякка бастыра.

Кичен Халеб шәһәрендәге тимер юллар төзелеше идарәсе белән телефоннан сөйләшкәннән соң, без баш механик белән Латакия йортына китәргә тиеш булдык, чөнки анда туган илдән кораблар килгән һәм төяп алып килгән машиналарны бушатуны тизләтергә кирәк иде.

Рейдта торган совет корабларын мин ерактан ук күрдем. Алар күп: «Сихотэ Алинь», «Чернигов», «Сергей Боткин» һ. б.

Машиналарны бушатырга тотынганда бирелгеге таможникларның катгый кагыйдәсенә тап булдык. Порт территориясеннән бернәрсә дә алып чыгарга ярамаган кебек, бирегә дә берни дә алып керергә ярамый икән. Ә бит килгән машиналарның төзеклеген тикшерү өчен инструментлардан тыш, ягулык кебек нәрсәләр дә кирәк әле.

Ә рөхсәт кәгазе артыннан йөри башлагач, көн, көн ярым вакытың уза да китә. Рөхсәт кәгазендә, гадәттә, берничә җаваплы чиновникның имзасы кирәк. Ә чиновникка керү өчен син аның туган илен, семьясын, сәламәтлеген, кыскасы, тәрҗемәи хәлен белергә тиешсең. Сәламләшүдән соң ук эш турында сүз башларга ярамый. Бу исә синең культурасызлыгыңны, әдәпсезлегеңне күрсәтә. Хуҗа кеше якындагы йомшак урындыкның берсенә утырырга тәкъдим иткәч, кечкенә чәшкәләрдә кофе кертәләр. Менә шунда инде беренче чиратта кабинет хуҗасының сәламәтлеген, аннары гаилә членнарының хәл-әхвәлләрен сораштырырга тиеш буласың. Әгәр шул тәртипне бозсаң, килүеңнең мәгънәсен югалтасың. Кырык эшең кырылып ятса да, әңгәмә бик акрын бара һәм әчтән генә һаман имза турында уйлыйсың.

Гарәп дуслар белән миңа бу хакта бәхәсләшергә дә туры килде. Ләкин аларның бер дә исе китми, имеш, дөньяның бөтен тәме дә ашыкмыйча яшәүдә, һәркайда ашкыар булып кылану — үзе сәламәтлек өчен зыянлы.

Мондый фәлсәфә белән килешеп булмый, әлбәттә. Файдалы мөһим эшне вакытында җиренә җиткереп үтәү үзе кешегә рухи канәгатьлек бирә.

Караңгы төшәр-төшмәстә без баш механик белән катерга утырып рейдтагы «Чернигов» теплоходына ватандашларыбыз янына юл тоттык. Койрыктагы Совет флагы, без-

тагын да зуррак, горуррак булып күренә кебек.

— Рәхим итегез, сез үз илегездә,— дигән ягымлы тавыш ишетелде. Палубага аяк басканда мин нинди генә хисләр кичермәдем. Бу бит Совет җиренең бер кечкенә кисәге! Саумы, Ватан! Саумы, туган җир! Өзелеп сагындым бит мин сине. Йөк теплоходында булганым юк иде. Капитан, безне үз каютасына алып кереп, таныш аракы һәм селедка белән сыйлый. Сүриядә аларның берсе дә юк. Без туган ил, юбилейга әзерләнүнең барышы, Одесса-Севастополь шәһәрләре турында сорашабыз, безне бары да кызыксындыра.

Бераздан китәргә җыендык, аерылышу бик тә авыр тоелды. Безнең милли татар җыры мондый минутларны ничек дөрес бирә алган:

Бергә булулары бик күңелле,
Аерылышулары бик яман.

Вакыт инде соң иде һәм без туганнарча кул кысышып аерылышабыз.

Советлар Союзыннан китерелгән экскаваторлар өлешчә сүтелгән хәлдә булалар. Безгә исә аларны җыярга һәм тиешле урыннарга алып барып, гарәп дусларны шулар белән эш итәргә өйрәтү йөкләнгән. Ләкин бу без уйлаганча җиңел булып чыкмады. Чөнки экскаваторларны җыю өчен краннар кирәк. Безгә билгеләнгәне күптән инде ватылып, хәрәкәтсез тора. Эш кешесенең эштә булуы хәерле дигәндәй, вакытны әрәм итмичә, якында гына торган 100 тонна күтәрешле йөзмә кранга мөрәҗәгать итәргә булдык. Кранда берничә кеше эшли. Кофе эчә-эчә без кранның бригадиры белән сөйләшәбез. Безнең үтенечне үзе генә хәл итә алмасын белдереп, ул башын селки һәм үзеннән җаваплырак кешедән сорарга куша. Берничә кешегә күрсәткәннән соң, без, ниһаять, йөк төяү һәм йөк бушату конторасы мөдире янына керүгә ирештек. Зур өстәл артыннан күтәрелеп, ул безнең белән әдәпле генә исәнләште, утырырга тәкъдим итеп, урындыклар күрсәтте.

Мин, татар мәкалендә әйтелгәнчә, бауның озыны, сүзнең кыскасы яхшы дигән принцип белән эшнең асылын аңлатырга теләп авызны гына ачарга җыенган идем, хуҗа әфәнде, кунакчыл кыяфәт күрсәтеп, күп җирләрдә колакка сеңгән гарәп мәкален әйтеп, мине шундук бүлдерде:

«Ассабру мифтахул — фараджь»[1].

Ул бик җитди төс белән безнең эшләрнең нәтиҗәсен сорашты, аннары совет халкы, аның тарихы белән кызыксына башлады.

Советлар Союзын ул дөньядагы иң көчле илләрдән күрә, империализмга каршы көрәштә гарәпләрнең Россиягә ышаныч баглауларын әйтте.

Вакыт үтә тора. Җитмәсә, зур-зур папкалар тотып, төрле чиновниклар керә һәм безнең сөйләшүне бүлдерәләр. Тиешле күрсәтмәләр алганнан соң алар «оля рааси»[2] дип ишеккә юнәләләр.

Мин ул арада «бюрократ» сүзенең төшенчәсен тирәнрәк аңларга тырышам. Бу сүз гарәпчә дә шулай яңгырый, югыйсә. Күрәсең, алар аны бик үк тиешле урында кулланмыйлар. Хәер, искелек тиз генә үтеп китми шул. Болар бар да җитәкче урыннарда иске кадрлар утыру белән аңлатылырга тиеш. Сүрия халкы яңа тормыш төзи. Яңалык юлында искелекнең каршы килүе табигый нәрсә. Ләкин искелек кайчан да булса җиңелергә һәм яңалык өстенлек алырга тиеш.

Сүрия тимер юллары дирекциясенең вәкиле Фуад Саббах килгәч, безнең хәлләр яхшыра төште. Ул үзе шушы якларда туган, җирле шартларны яхшы белә. Кайбер җирле чиновниклар белән таныш та булуы иске кадрлар яраткан бюрократик ысулларны тизрәк һәм эшлекле хәл итүгә китерде.

Тимер юл салыначак урыннарны карап чыкканнан соң Фуад Саббах безне үзенә кунакка чакырды.

---

[1] Түземлек — шатлык ачкычы.
[2] Төгәл тәрҗемәсе «баш өсте» дигән мәгънәгә туры килә. Безнеңчә «ярар, үтәлер» дип аңларга кирәк.

туристлар өчен кафе, ашханәләр ачылган. Фуад Саббахларга барышлый кафеларның берсе яныннан узганда мин урманга кереп чыгарга тәкъдим ясаган идем. Фуад үзләре яшәгән урында да урман бар икәнен әйткәч, машинаны туктатып тормадык.

Юл өстендә кечкенә-кечкенә генә авыллар очрый. Йортлар тәбәнәк һәм бер-берләренә охшаш. Очлы түбәләре салам өемнәрен хәтерләтә. (XX йөз башында Мәккәгә хаҗга барган татар сәяхәтчесе Сакмариннның Сүрия авылларын печән эскертләренә охшатуы юкка гына түгел икән.)

Фуадларның өйләре зур яшел бакча эчендә иде. Газоннарда гөлләр, чәчәкләр. Уртада цементтан эшләнгән бассейн, аңардан фонтан атылып тора.

Без өйгә узабыз. Киң якты бүлмәләр милли колорит белән бизәлеп җыештырылган. Стеналарда бизәкле коверлар, кроватьларда ап-ак җәймәләр һәм күпертеп куелган мендәрләр.

Безгә утырырга урын күрсәтәләр. Ләкин бездәгечә урындыкка түгел, ә аякны төрекләрчә бөкләп идәнгә утырырга... Безнең өчен гадәти булмаган бу күренештән бераз уңайсызланыбрак калуыбызны сизепме, Фуад барыбызны да икенче бүлмәгә чакырды. Бусы аш бүлмәсе иде. Сүз уңаенда әйтергә кирәк, гарәпләрдә ашамлыкларны бездәгечә берәмләп китермиләр. Бөтенесен бергә тезеп куялар. Бу исә, кунаклар беренче ашны ашап туйганнан соң, калганнарын ашамый калмасын өчен шулай эшләнә. Өстәлдә утыз төрле аш тора. Һәммәсеннән авыз итеп чыгарга тиешсең. Туйганлыкны белдерергә ярамый, үпкәлиләр. Иптәшләр аларны хәзерләү ысуллары белән кызыксыналар. Фуад Саббах тапкыр сүзле кеше генә түгел, яхшы кулинар да икән әле. Ул барысын да иркенләп сөйләп чыга. Тәрҗемә итеп кенә өлгер.

Безнең янда Фуадның ике сеңелесе дә утырды. Зурысы Пальмирада балалар укыта. Кечкенәсе инглиз мәктәбендә укый. Аларны барысы да кызыксындыра. Сүрия халкы безгә ошыймы? Советлар илендә кызлар твист биилəрме? Алар нәрсә укыйлар, нәрсә белән кызыксыналар? Гарәп язучыларын тәрҗемә итәләрме?

Ул арада Анатолий Васильевич сүзгә кушылып, кызга инглизчә сораулар яудыра башлый.

— Пәрәнҗә ябынмый йөргән кызлар иргә чыккач еш кына ни өчен йөзләрен каплыйлар? Сез дә шулай булырсызмы?

Кызлар бу сорауга төгәл генә җавап бирмиләр. Чөнки кем нинди шартларга, нинди гаиләгә туры киләчәк — анысы берәүгә дә мәгълүм түгел.

Аштан соң без кунак бүлмәсенә чыгып утырдык. Фуадның кече сеңелесе һәркайсыбызга конфетлар өләште. Абыйсының кушуы буенча, ул безгә рояльдә берничә рус совет көен уйнады.

Нәкъ шул чакта безнең янга аларның әтиләре Әбү-Шөкри керде. Ул күрше бүлмәдә намаз укыган булса кирәк, кулындагы дисбесен дә куймаган иде. Төскә-биткә шактый карт күренсә дә, ул әле җиңел йөри, сөйләшүе дә бик аңлаешлы. Барыбыз белән дә кул биреп исәнләшкәннән соң, келәмгә аякларын бөкләп утырды. Минем гарәпчә сөйләшүемне ишеткәч, карт аптырау катыш гаҗәпләнеп калды. Ул гына да түгел, Фуад минем «Коръән»не дә укый белүемне әйткән иде, Әбү-Шөкри дулкынланып урыныннан торды һәм кызларына изге китапны алып чыгарга кушты.

«Коръән»не ачып, берничә сурәне укый башлауга барысының да игътибары мең кучте. Әбү-Шөкри, үз колакларына үзе ышанмаган кебек, сорау арты сорау бирә. Сөйләшә торгач, сүз үзеннән-үзе сәясәткә кагылды. Сүрияләләр сөйләшергә, бәхәсләшергә бик яраталар. Һәркайсының телендә Израил агрессиясе. Сүз белән әйтелмәгән ачу, нәфрәт йөзләрендә чагыла.

— Гомер-гомергә еврейләр гарәпләр белән тату яшәделәр,— ди Әбү-Шөкри.— Гомер-гомергә,— дип дәвам итә ул.— Ә менә Көнбатыш Европа һәм Америка империалистларына буйсынган капиталистлар бөтен эшне бутап ташладылар.

— Сездә милли мәсьәләләр ничек хәл ителә? — дип сорый карт.

— Бездә алтмыштан артык милләт яши,— дим мин аңа.— Хәтта сезнең илегездә дә Советлар Союзыннан килгән унлап милләтнең вәкилләре эшли. Бирегә ничек булса, без илебездә дә шулай ук дус, кулга-кул тотынып яшибез.

Апрель ахырларында без барлык техниканы Тартус шәһәренә китереп бетердек.

гарәпләрне кире борып җибәрмәскә тырыштык.

Техника һәм эшче көчләр арткач, төзү эшләрен берничә участокта алып барырга мөмкинлекләр туды. Мине әле генә килгән совет белгечләре белән Халеб шәһәренә күчерделәр. Биреде Ташкентта бергә укыган иптәшем Гомәр Әргәшевны очраттым, ул миңа туган ил хәбәрләрен сөйләде. Шул ук кичне Халебтагы совет консульствосы хезмәткәрләре үзешчән концерт күрсәттеләр. Һәр күрсәтелгән номерны тамашачылар көчле кул чабулар белән каршылады, чөнки алар безгә туган-үскән илдәге кичәләрне хәтерләтеп, сагыну хисләрен яңартты.

Без Халеб белән Евфрат плотинасы арасында проектлаштырылган юлны сузарга тиешбез. Аның гомуми озынлыгы — 750 километр чамасы. Әгәр моңарчы Сүриядә барлык тимер юлларның озынлыгы нибары 844 километр гына булуын күз алдына китерсәң, Сүрия халкына Советлар Союзы күрсәткән ярдәмнең нинди зур әһәмияткә ия булуын аңлау кыен булмас. Сүриянең элекке тимер юллары колониаль дәвердә, халыкның экономик көнкүреш ихтыяҗларын исәпкә алмыйча, империалистларның хәрби стратегик максатларыннан чыгып төзелгән. Нәтиҗәдә илнең Үзәк районнары Урта диңгез ярлары белән тоташтырылмый калынган, экспортка куелган товарларны гарәпләр йөк машиналары белән ташырга мәҗбүрләр. Бу исә сатучы өчен генә түгел, сатып алучы өчен дә ифрат дәрәҗәдә кыйммәткә төшә.

Мин килгәндә участокларда эшнең кайнаган чагы иде. Көн саен 30—40 километрга йөреп эшлибез. Эшнең сыйфатын тикшерергә Сүрия тимер юлларының генеральный директоры Габдел-Кәрим Шәми дә килеп киткәли. Ул совет машиналарына карап, мондый зур бульдозер, дозаторларны Көнбатыш Германия, Франция, Италиядә дә күргәнлеген әйтә. Ләкин безнең техниканың куәте һәм ныклыгы ягыннан алар белән тиңдәшсез булуын билгеләп үтә.

Чыннан да, безнең машиналар гарәпләрне таңга калдыра. Аларны күзләре белән күреп китү өчен, якын тирәдәге авыл, шәһәрләрдән ирләр, хатын-кыз, бала-чагалар килә. Безнең өлкән һәм тәҗрибәле белгечләр белән бергә гарәп белгечләре практика үтәләр.

Дөрес, алар белән эшләү безнең кешеләр өчен шактый кыенлыклар тудыра. Мәсәлән, безнең өлкән инженер бер гарәп эшчесенә күрсәтмә яки киңәш бирергә теләсә икән, ул аны үзе генә башкара алмый, фәкать гарәп чавишы (бригадир) аша гына җиткерә ала. Бу исә вакытны сузу дигән сүз.

Гарәп эшчеләре арасында укый-яза белмәүчеләр күп әле.

Күптән түгел шәһәрнең истәлекле урыннары белән танышырга уйлап йөри идем. Ниһаять, уңайлы көн туры китереп, якын-тирәдән әйләнеп кайтырга булдык.

Халеб — безнеңчә сөт дигән мәгънәгә туры килә.

Халык телендә бу исемгә кагылышлы легенда сакланган. Имеш, Ибраһим пәйгамбәр (Аврам) Палестинадан кайтышлый биредә тукталып ял иткәндә һәр көн саен сыер савып ярлыларны сөт белән сыйлый торган булган. Шуннан инде Халеб Ибраһим (Сөтче Ибраһим) дигән кушамат киткән дип сөйлиләр.

Халеб — мөхәфәзәтнең баш шәһәре. Борын-борын заманнардан сәүдә үзәге булып, аның базарларын Европа илләре белән Кытай, Һиндстан товарлары бизәп килгән.

Биреде кайчандыр Квик елгасы аккан. Ләкин ул инде күптән кипкән. Яшеллек белән аз, танылган Халеб чикләвеге куаклыкларын исәпкә алмаганда, бөтенләй юк дияргә мөмкин. Алма, чия, яшелчә бакчаларында су җитешмәве сизелә. Шәһәрне су белән тәэмин итү өчен күп көч куелган. Зур-зур торбалар буйлап 95 километрга Евфрат елгасыннан су кудырыла. Ясалма сугару системаларының гомуми биеклеге 170 метрга җитә. Бу үзе генә дә суның никадәр кыйммәткә төшүен раслый булса кирәк.

Әйтергә кирәк, Халебта йортлар бер-берләреннән архитектуралары белән генә түгел, хәтта буяулары белән дә аерылып тора. Алар яңача стильдә булып, ерактан ук күңелне җәлеп итә. Һәр урамда дип әйтерлек ирләр өчен махсус кафе-клублар очрый. Аларда чәй, кофе, лимонад кебек эчемлекләр сайлап эчә аласың. Ләкин аракы катгый тыелган. Эчкә узсаң, тәмәке тартып, домино сугучы, карта уйнаучыларны күрәсең. Алар үзләренең көндәлек эшләре турында ашыкмый гына әңгәмә алып баралар.

Халебтан Хомска барышлый Маарат-ән-науман авылының зиратына кергәч бер кабер алдына сокланып баш иясең. Анда мең еллар элек яшәгән бөек акыл иясе

кеше сирәктер. Гарәп интеллигенциясе генә түгел, бөтен прогрессив мөселман дөньясы вәкилләре бу урынны юкка гына Мәккәгә тиңләп язмый. Бирелә 973 елны бер малай дөньяга килә һәм аңа Әхмәт дип исем кушалар. Ләкин ул кешелек тарихында Әбү-ль-Аля Әль-Маари исеме белән калган. Әхмәт өч яшь тулар-тулмастан кызамык авыруы белән авырый һәм гомере буена сукыр һәм шадра булып кала. Малай тиздән олы җанлы, тирән хисле, тапкыр сүзле шагыйрь булып үсеп җитә. Ул иҗат иткән поэтик җәүһәрләр бүген дә гарәп укучыларын таңга калдыра. Тынычлыкка өндәп язган шигырьләре, моннан мең ел элек язылуларына карамастан, халыклар күңелендә мәңге саклана.

Бу зур философ шагыйрьнең татар иҗтимагый агымына да йогынтысы зур булган. Бу турыда, мәсәлән, Шиһабетдин Мәрҗани, Фатих Әмирхан әсәрләрендә телгә алына.

1907 елны дини реформатор Муса Бигиев Төркия, Мисыр, Сүрия җирләрендә биш еллык сәяхәттә булып кайтканнан соң, шагыйрьнең «Әл-Лузимият» әсәрен татарчага тәрҗемә итеп чыгара.

Хезмәтемне тәмамлап, туган илгә кайтырга өч-дүрт ай кала, Гарәп илләре күгендә кара болытлар куерды. Пакь намуслы, кыю йөрәкле гарәп дусларның гына түгел, безнең дә күңелләр тынычсызлана башлады, чөнки гарәп Көнчыгышында нинди генә вакыйга булмасын, ул һәрвакыт нефть белән бәйләнгән. Бу бик табигый, чөнки Якын Көнчыгыш нефте империалистик дөнья даирәләре өчен XX гасырның иң арзанлы табышы булып хисаплана. Капиталистик дөньяның 60 процент нефтен Гарәп илләрендә чыгарылган сыек ягулык тәшкил итә. АКШ һәм Көнбатыш Европа илләренең 1966 елда нефтьтән алган кереме 2,5 млд. доллар булуы моны ачык дәлилли.

Израил агрессиясе көннәрен мин язып тормыйм. Бу турыда Совет матбугаты күп язды. Без, Сүрия халкы белән кулга-кул тотышып эшләүче Совет белгечләре, барыбыз да Совет хөкүмәтенең Израил хөкүмәтенә җибәргән нотасы белән рухланып һәм аннардан көч алып яшәдек. Хезмәтчел Сүрия халкы ул көннәрдә фәкать тугандаш Совет халкының материаль һәм мораль ярдәме белән көн күрде. Без китәргә җыенгач, алар безгә өмет баглап, гүя безнең һәркайчан аларга ярдәмгә килеребезне белеп, озак итеп кул селтәп калдылар. Теплоход сузып-сузып кычкыртты да Кара диңгезгә, Совет ярларына юл тотты.

— Хушыгыз, дуслар! Сезнең көрәш изге! Сез җиңәрсез! Без һәрвакыт сезнең белән!

Ул минутлар бервакытта да минем хәтердән чыкмас.

Энгель Нигъмәтуллин

# ТӘҖРИБӘ ҺӘМ БЕЛЕМ АЛМАШЫП...

*(XX йөз башы татар әдәбиятының Европа язучыларына һәм андагы эстетик карашларга мөнәсәбәте)*

Татар әдәбияты гомуми әдәби процесска, бигрәк тә Көнбатыш Европа әдәбиятларына, күбрәк рус мәдәнияте аша якынайган. Шуңа күрә, үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, татар һәм рус әдәбиятларының бер-берсенә йогынтысы никадәр киңрәк һәм тирәнрәк өйрәнелсә, безнең әдәбиятның Көнбатыш Европа әдәбиятлары белән элемтәсен тикшерүнең зарурлыгы да көн тәртибенә шулкадәр ачыграк булып килеп басачак. Әлеге мәсьәләнең беренче өлеше, ягъни татар һәм рус әдәбиятларының үзара мөнәсәбәте, бездә беркадәр өйрәнелгән. Ә менә татар әдәбиятының Көнбатыш Европа белән бәйләнешләрен тикшерүгә багышланган махсус тикшеренүләр хәзергә күренми. Хәлбуки, бу бик тә әһәмиятле булган өлкә. Рус совет әдәбияты фәне бу эшкә аерым игътибар бирә. Без шуны истән чыгармаска тиешбез: «әдәби процессның гомуми, уртак закончалыкларын өйрәнмәү, аларны өйрәнүдән баш тарту аерым милли әдәбиятларның үсеш закончалыкларын ачуны да кыенлаштырачак»[1]. Һәм, киресенчә, дөньякүләм гомуми әдәби процесс белән контекста каралганда, милли әдәбиятларның еш кына күтелмәгән үзенчәлекләре, бөтенләй уйламаган яклары ачылып китәргә мөмкин.

Күп гасырлык татар әдәбияты, безнең әдәбият туплаган бай тәҗрибә үзен әнә шулай бөтен дөнья масштабындагы әдәби бәйләнешләр планына куеп аңлатуга, милли әдәби процессның яңа закончалыкларын ачыклауга мохтаҗ. Әйтик, татар әдәбияты һәм бездәге эстетик фикер Көнбатыш Европага ни өчен нәкъ менә XX гасыр башында йөз белән борыла! Бу бик кызыклы һәм шул ук вакытта җитди мәсьәлә. Аңа бер сүз белән генә җавап табуы да читен. Шулай да мәсьәләгә күпмедер ачыклык кертерлек ике моментны күрсәтеп була. Беренчедән, бу хәл демократик массаларның дини фанатизмга, милли буржуазиягә һәм самодержавиегә каршы социаль көрәше көчәю белән бәйләнгән. Көнбатыштагы алдынгы карашлар белән танышу укучы массаларның аңын үстерә, дөньяга карашын киңәйтә, нәтиҗәдә милли буржуазиянең һәм ислам диненең хакимлеге какшый.

Икенчедән, егерменче йөз башы татар әдәбиятының тизләтелгән үсеше күпьяклы талантка ия булган, синтетик типтагы язучылар тууга китерә. К. Насыйри, Г. Тукай, Г. Ибраһимовлар нәкъ шундый язучылар була. Талантлары мул, фәлсәфи карашлары

---

[1] Современные буржуазные концепции истории всемирной литературы. Рус теленд. Мәскәү. 1967 ел. 40 бит.

[illegible] демократик юнәлештә булганга, бу язучылар укучы массаларның эстетик зәвыгын күбрәк, тулырак канәгатьләндергән. Үз чиратларында Г. Тукай, Г. Ибраһимов кебек укытучылары булган татар язучылары да Көнбатыштан (шулай ук Россиядән һәм Көнчыгыштан), барыннан да элек, нәкъ менә шундый — синтезлауга сәләтле язучыларны: Гете, Данте, Шекспирны (Россиядә Пушкин, Толстой, Белинскийны; Көнчыгышта Сәгъди, Фирдәүси, Фозули, Нәвоины) сайлаганнар.

Нибары егерме еллап вакыт эчендә безнең әдәбият Европа әдәбиятлары гасыр буе диярлек узган үсеш юлы үтә. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, шундый тизлекне тәэмин итәрлек ниндидер алшартлар булган, дигән сүз. Шулар арасыннан икесен аерым билгеләп үтәргә мөмкин. Беренчесе — халыкның формалашкан идеалы булу, икенчесе — Көнчыгышның (бигрәк тә Шәрык ренессансының) этик-эстетик традицияләре. Шушы алшартлар Көнбатыш мәдәнияте материалын, әйтерсең, «контроль аша» уздыралар: ярардаен кабул итә, туры килмәстәен читкә тибәреп торалар. Мисалга татар халкына яхшы таныш булган Фозулины алырга мөмкин. Аның белән бер үк вакытта, ягъни 1905 елларда ук, татар әдәбиятына Гете идеяләре үтеп керә башлый. Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов кебек әдипләр Гете иҗатын, аеруча аның «Фауст» исемле мәшһүр әсәрен яхшы белгәннәр. Фозулидан Гетега таба сузылган ассоциацияләр чылбырын күздән кичерик.

«Ләйлә белән Мәҗнүн» поэмасының нигезендә гашыйклар күзенә һәрнәрсә матур булып күренә, дигән фәлсәфи фикер ята. Автор үзенең фәлсәфи карашларын распарлык идеал эзли. Мәҗнүн — шундый эзләнүләр нәтиҗәсендә туган образ. Ул үзенең бөтен табигате белән үгет-нәсихәткә, коры акыл сатуларга дошман кеше. Ул хисләр кешесе, ул табигатькә, тормышка гашыйк. Мәҗнүннең әнисе үзенең улын чибәрләрдән ерак йөр, шәраб эчмә, шигырьләр тыңлама, ялкау һәм җилкуар булма, белем алырга тырыш, дип үгетли. Болай караганда, аларның һәммәсе әйбәт нәрсә. Тик менә алар Мәҗнүн күңелен генә кузгата алмыйлар, ул ашкынып үзенең идеалын эзли...

Кешенең шулай бертуктаусыз, мәңге камиллеккә омтылышы белән безнең халык Гетеның «Фауст» трагедиясендә кабат очраша. Бу күпләгән мисалларның берсе генә...

Бу мәкаләдә татар-Европа әдәби бәйләнешләренә караган зур теманың өч аспекты гына күздән кичерелә: иң әүвәл, татар әдәбиятындагы прогрессив һәм консерватив романтизмның үзара мөнәсәбәте; аннары Көнбатыштагы тарихчанлык һәм психологизм идеяләренең татар әдәбиятына тәэсире мәсьәләсе һәм, ниһаять, Шекспир белән Гете иҗаты.

Сүзне беренче мәсьәләдән башлыйк. Киредә безне гомумән татар әдәбиятында, о еш кына теге яки бу аерым язучы иҗатында романтизм белән реализмның бергә үрелеп үсүе кызыксындыра. Бездәге романтизм, бигрәк тә аның консерватив төре, немец философиясенең эстетик принципларына нигезләнә. «Яшь әдәбиятыбызда «Яшь йөрәкләр» дигән мәкаләсендә Г. Газиз, мәсәлән, романтизмның әлеге эстетик чыганакларына тукталып, болай ди: «Бездә ник романтизм булмасын! Гарептә, мәсәлән, Германиядә дә шундый бер заман да булган иде бит» [1]. Н. Думави исә тагын да ачыграк яза: «Ул вакытларда мин немецларның натурфилософиясен өйрәнү илә мәшгуль идем» [2]. Киредәге «натурфилософия» сүзен идеалист немец философы Ф. Шеллингның философиясе дип аңларга кирәк.

Француз буржуаз революциясе уңышсыз тәмамланганга күңелләре тошкән немец романтиклары төрле реакцион теорияләр белән мавыгырга керешәләр, алар сәнгатьне акыл көченә һәм фәнгә каршы куя башлыйлар. Ф. Шеллинг өчен сәнгать әсәре — аң катнашыннан тыш иҗат ителә торган продукт. «Шагыйрь,— дип яза немец романтигы Новалис,— чынлап та үз-үзен белештермичә иҗат итә. Художник аңсыз коралга, югары көчнең аңсыз кисәгенә әйләнә» [3]. «Практик акылга тәнкыйть» дигән хезмәтендә Кант та сәнгатьнең реаль дөнья белән «кызыксынмавы» турында яза. «Татар шагыйрьләре» исемле китабында Г. Ибраһимов шундый «хөр» шагыйрьнең өлгесе

---

[1] «Аң» журналы. 1913 ел. 11 сан. 192 бит.

[2] «Йолдыз» газетасы. 1915 ел. 1535 сан.

[3] Литературная теория немецкого романтизма. Мәкаләләр җыентыгы. Рус теленда. Ленинград. 1934 ел. 122—123 битләр.

итеп С. Рәмиевне саный: «Шагыйрь, әгәр дә ул чын мәгънәсе илә шагыйрь булса, шөбһәсез, хиссият колы. Аның шагыйрьлеге ягыннан караганда, салкын гакыл, коры мантыйк белән күп эше булмый»[1]. «Сәгыйт Рәмиев шигырьләре турында» исемле хезмәтендә Г. Газиз шулай ук С. Рәмиев әсәрләрендә идеал белән чынбарлык арасында каршылык булуын күрсәтә. «Менә шуның соңында идеал, хыяллар белән чын тормышта икесенең арасында никадәр зур фәрекъ[2] барлыгы, бу караңгы дөньяны яратмау хисләренә китергән булыр»[3]. С. Рәмиев «чын хисен бер вакытта да дөньяга кол иттерми», ул «җүләр, тиле Сәгыйть», «аллалык дәгъва итүче Сәгыйть»[4] булып күренә генә.

Әгәр романтиклар, шул рәвешчә, сәнгатьне чынбарлыкка каршы куялар икән, моның, социаль сәбәпләрдән тыш, образлы фикерләүнең характеры һәм эчтәлеге белән бәйле яклары да бар, билгеле. Образлы фикерләүгә объектив эчтәлек хас, һәм ул эчтәлек еш кына художникның субъектив теләкләреннән өстен була.

Ф. Энгельсның Бальзак иҗатына биргән бәясен генә хәтерләгез. Әдәби образның объектив, реалистик характеры турында Энгельс болай ди: «Әгәр Бальзак үзенең сыйнфый симпатияләренә һәм сәяси ышануларына каршы барырга мәҗбүр булган икән, әгәр ул үзе яраткан аристократларның котылгысыз үләргә тиешлеген күргән һәм аларны шуннан да яхшырак язмышка лаек булмаган кешеләр итеп тасвирлаган икән һәм әгәр ул, шул вакыттагы тормышта аз очрауларына карамастан, киләчәкнең чын кешеләрен дөрес күрә алган икән — моны мин реализмның иң зур казанышы һәм Бальзак картка хас иң матур сыйфатларның берсе дип саныйм».

Ф. Энгельс кебек материалистлардан аермалы буларак, романтиклар әдәби образның мондый үзенчәлеген субъектив планда гына карыйлар, аны сәнгатьчә фикерләү тибының фәнни фикерләүдән, сәнгатьнең фәннән өстен булуы белән аңлаталар. Шеллинг фикеренчә, табигать ихтыяры белән иҗат ителгән сәнгать әсәре һәрвакыт художник әйтергә теләгәннән күбрәкне белдерә. Н. Думави немец натурфилософиясенең бу тезисын суфи шагыйрьләрнең дөньяга карашы белән янәшә куеп карый. Шеллинг та, Думави да сәнгатьне фәнгә каршы куялар. Шеллинг материаль җитештерү һәм экономик яктан файдалы уйлап табулар хакында җирәнү белән генә сөйли. Н. Думави фикеренчә, «вакыйган, иман, гыйшык, хыял — һич кайсы фәнгә сыймыйлар, алар фәннән качалар», «Адәмнәр шул салкын гакыл, тупас фән багажы булудан туялар»[5].

Шулай да татар романтиклары немец эстетикасының идеяләрен берсүзсез кабул итәләр дисәк, хата булыр иде. Өлкәнәйгән Шиллерның фикеренчә, эстетик идеаллар һәртөрле сәяси һәм мораль тенденцияләрдән азат булырга тиеш. Аның бу карашларын С. Рәмиев тә уртаклаша. Ләкин шул ук Шиллерның «Перчатка»сын татар теленә тәрҗемә иткәндә, балладага ул милли аңга хас куәтле фикер ташкынын кертә:

Ташлап китә шунда егет мәгърурәне,
Торырмын батыр (курсив безнеке — Э. Н.) булгач үзем дә,—

ди[6].

Күрәсез, бу юлларны инде фани дөнья белән бөтенләй бәйләнеше булмаган әсәрләр рәтенә кертеп булмый. «Шиллердан» шигырендә Тукай исә Шиллерны бөтенләй реалистик алымга ук җайлый:

Син исә: «Эстәр исәң, җанымны бирермен»,— дисең;
Нәрсәгә җаның миңа, нишлим синең җаның белән![7]

Шул рәвешчә, романтиклар, үз настроениеләренә карата укучыларда теләктәшлек уяту өчен, немец эстетикасында «рациональ орлык» (образның эмоциональ характеры, кеше күңеле турындагы тәгълимат) барлыгын табалар. Шулай да Гейне, Гюго,

---

[1] Г. Ибраһимов. Татар шагыйрьләре. 1913 ел. 16 бит.
[2] Фәрекъ — аерма, башкалык.
[3] «Аң» журналы. 1913 ел. 12 сан. 215 бит.
[4] Шунда ук.
[5] «Йолдыз» газетасы. 1915 ел. 1535 сан.
[6] С. Рәмиев. Сайланма әсәрләр. Казан. 1962 ел. 52 бит.
[7] Г. Тукай. Әсәрләр. I том. 116 бит.

ләү моментын, гражданлык хисләрен һәм социаль пафос та алып киләләр.

«Немец халкының хөррият өчен кузгалулары» исемле мәкаләдә В. Тәрҗеман революциягә мөнәсәбәтнең реалистик һәм романтик алымнарына туктала. Аныңча, 1848 ел вакыйгаларына иң дөрес, реалистик бәяне К. Маркс бирә: «Демократлар, үзләренең олугъ эшләр кылачакларын мактанып сөйләп, халыкны кузгалырга... дәгъвәт [1] иттеләр. Бу кузгалу, корал истигъмале [2] дәрәҗәсенә җиткәч, демократлар, кузгалырга өндәшкәнлекләре өчен халыктан курыктылар кебек, иттифак куллары астына кергән хөкүмәт илә үзләре нәтиҗә хәлләреннән курка башладылар» [3].

Гейненың исә революциягә мөнәсәбәте бераз башкачарак, романтиграк. Әмма мондый караш та кирәк, чөнки ул да чын күңелдән әйтелгән: «Гейне, Париждагы ихтиляльне ишетү илә, сискәнеп китте. «Миңа истирахәт» [4] кирәк түгел, миңа хәзердә ни белән шөгыльләнергә кирәк икәнен минем вөҗданым әйтәдер. Мин — ихтиляль улы. Мин — ихтиляль җырларын җырлый башлыймын» [5]. Биредә шунысы мөһим, романтик Гейне К. Маркның фикердәше итеп, ә сыйнфый көрәшне халык массалары интересыннан чыгып тасвирлау әдәби иҗатының мәҗбүри шарты итеп карала. Гадиләштереп әйткәндә, бу инде — реализмга аяк атлау дигән сүз. С. Сүнчәләйнең «Әҗәлгә хитап» шигырендә дә җәмгыятькә хезмәт итү идеясе уздырыла, әсәргә эпиграф итеп Гейненың:

Күпме генә яктырса да хак тәгалә кояшы,
Кай вакыт булса бәрабәр булыр аның баешы,—

дигән юллары алынган. Шигырьнең ахырын китерәбез:

Менә килер бер вакыт көн, күкрәгем тормыш өчен
Ерткаланган, яргаланган булыр һәм бетәр көчем.
Шул вакыт тик син килерсең — каршы булмас һич сүзем,
Җанымны алып китәрсең мәңгегә, ике күзем [6].

С. Сүнчәләй Гейненың «Әльмансур» трагедиясен тәрҗемә итә. Ул исә дин сөременә, динчеләргә каршы язылган әсәр.

Гейне кебек үк Гюго да романтизмны политика белән бер нәрсә итеп карый, аның политик асылыннан чыгып эш итә, «һәм романтизм, һәм социализм бер үк юнәлешләрдән» дип исәпли [7]. В. Гюгодан, С. Сүнчәләй тәрҗемәсендә, характерлы бер өзек китерәбез:

Кайда кан, кайгы, матәм — шунда торыйк,
Кайда кәнд, күз яшь — тормыш күрик.
Без чәчик дуслык, туганлык орлыгын,
Тәңредән без халкыбызга тан сорыйк!
Халкыбыз күптән көтә безне, җаным,
Милләтем сагына сине, пакь илһамым! [8]

Моннан тыш, Гюго романтизмның асылын төрле категорияләрнең, әйтик, трагик хәлләрнең һәм көлкенең, үзара чиратлашуында күрә. Бу нәрсәне Ф. Әмирханда да табарга мөмкин. («Хәят», «Габделбасыйр гыйшкы» һ. б.) Татар әдәбиятына Руссоның йогынтысы үзе зур тема, биредә без аңа тукталып тормыйбыз.

Татар әдәбиятындагы этик-эстетик традицияләр Көнбатыштагы тарихчанлык һәм психологик идеяләре белән дә бәйләнешкә керә. Реализмның үсешен аңлау өчен кирәк булган шушы мәсьәләгә кыскача гына тукталыйк. Нәрсә соң ул тарихчанлык! Тормыш, тормыштагы күренешләр мәгълүм бер закончалыклар нигезендә гел үсеп,

---

[1] Дәгъвәт — чакыру, өндәү.
[2] Истигъмаль — куллану.
[3] «Казан мөхбире» газетасы. 1906 ел. 124 сан.
[4] Истирахәт — ял итү.
[5] «Казан мөхбире» газетасы. 1906 ел. 120 сан.
[6] «Йолдыз» газетасы. 1910 ел. 503 сан.
[7] В. Ванслов. Эстетика романтизма. 1966 ел. 40 бит.
[8] С. Сөнчәләй шигырьләре. Казан. 1913 ел.

тарихчанлык идеясенең асылы да шуңа кайтып кала. Бездәге тарихчанлык идеясенең социаль нигезен татар хезмәт ияләренең социалистик җәмгыять төзү өчен алып барган көрәше билгеләде. Марксизм тәгълиматы исә тарихчанлыкның югары казанышы санала. Ләкин аны тирән үзләштерү өчен шул чордагы башка фәнни тәгълиматлардан да хәбәрдар булу соралган. Менә шуңа күрә татар халкының фикер ияләре, К. Маркс, Ф. Энгельс әсәрләрен уку белән бергә, Ч. Дарвинның эволюцион үсеш турындагы тәгълиматын да, Кондорсэ [1], Вольтер, Гердер [2] кебек буржуаз философларның тарихи концепцияләрен дә өйрәнәләр.

Иң әүвәл Гердерга тукталырга мөмкин, чөнки аның традицияләрен Шиллер һәм Гете кабул итә. Бу соңгыларының исемнәре исә татар матбугатында да еш очрый. Исемнәре саналган фикер ияләре мәдәният күренешләрен аерым хәлдә түгел, ә үзара бәйләнештә, үсә, көчәя барган җанлы процесс буларак карыйлар. Көнчыгыш мәдәниятен алар дөньякүләм гомуми мәдәниятнең аерылмас бер кисәге дип карыйлар.

Татар язучылары гарәпчә тәрҗемәләре буенча ук Вольтерның тарихи әсәрләрен белгәннәр дип уйларга безнең тулы хакыбыз бар. 1841 елда Мөхәммәт Мостафа аның «Карл XII тарихын», ә 1850 елда Әхмәт ибне Мөхәммәт гарәп теленә «Петр патша тарихын» тәрҗемә итә. Татарлар Вольтерның фәлсәфи повестьлары белән дә таныш булганнар. Башка халыкларның тормышы белән кызыксыну барлык татар язучыларына да хас күренеш. Чөнки «бер милләт, үз тарихын укып, үз кавеменең хәлен аңлар, башка җәмгыятьләргә караганда, үзенең мәүкыйг иҗтимагыйсыннан вә хассият миллиясеннән мәгълүматы улмас» [3]. Цивилизациянең бер бөтен булуы турындагы фикер, логик рәвештә, әдәбиятларның бөтенлеге турындагы фикергә этәрә. Г. Ибраһимов болай яза: «Тарихи гомумиядән бөтенләй хәбәрсез калып, фәкать татар тарихы белән генә танышу никадәрле берьяклылык бирсә, гомуми әдәбият тарихының башлыча дәвер вә агымнарыннан хәбәрсезлек тә шундый ук берьяклылык тудырачак» [4]. Г. Ибраһимов татар шагыйрьләрен, шул исәптән Г. Тукайны да, милли тормыш кысалары эчендә генә карамый. Дәрдмәнднең «Кораб» шигыренә анализ мисалында Г. Ибраһимов татар шагыйрьләренең фикер йөртеше тарихи объектив характерда булуын билгеләде. Үзенең чынбарлыкны субъектив тоюы аша шагыйрь милләт яшәмә, аның тарихи перспективалары нинди кебек эпохаль мәсьәләләрне чагылдыра, ди.

Тарихчанлык идеяләре татар язучыларына тема ваклыгыннан котылырга һәм роман, реалистик эпик поэма кебек эре жанрларга мөрәҗәгать итәргә мөмкинлек бирә. Тарихчанлык идеяләре әдәби иҗат өлкәсенә үтеп керә: рус һәм Көнбатыш әдәбиятларындагы тарихи әсәрләр тәрҗемә ителә башлый («Дубровский», «Капитан кызы», «Борис Годунов», «Хаҗи Морат», «Надир шаһ» һ. б.), татар әдәбиятының үзендә тарихи жанрлар барлыкка килә (Ш. Мөхәммәдовның «Хан кызы», Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы», «Безнең көннәр»е һ. б.).

Татарларны психологизм идеяләре [5] тәрбия мәсьәләләре белән бәйләнештә аеруча нык кызыксындыра. Әдәбият галиме Г. Кәрам «Ялкаулык вә аны дәва итү» исеме белән французчадан бер мәкалә тәрҗемә итә. Мәкаләгә язган кереш сүзендә тәрҗемәче иҗтимагый тормышның катлауланы кешенең тирә-юньдәге һәр үзгәрешкә психологик яктан яраклашырга тиешлеген таләп итә ди: «Тормыш өчен көрәш елдан-ел нәселдән-нәселгә читенләшә вә авырлаша бара; иң садә тормыш өчен кеше тән вә җанының бөтен куәтен сарыф итәргә мәҗбүр буладыр» [6]. Алга таба сүз Гете, Золя,

---

[1] Ж. А. Кондорсэ (1743—1794) — француз философы, мәгърифәтче, экономист, политик эшлекле.

[2] И. Г. Гердер (1744—1803) — немец галиме һәм язучы. Сәнгать әсәрләренә тарихи конкрет якын килүне таләп итә, реализм принципларын яклый.

[3] «Шура» журналы. 1910 ел. 1 сан.

[4] «Тормыш» газетасы. 1915 ел. 365 сан.

[5] Кешенең психикасын тышкы шартларга бәйләп һәм, киресенчә, аның тышкы гамәлләрен психик хәле аша аңлату — психологизм әнә шул була.

[6] «Аң» журналы. 1914 ел. 8 сан. 163 бит.

тырлык ысулларны эзләп таба. Шуннан 50 ел вакыт узгач кына чагылыш турындагы совет фәне бу процессның аслын ача: «һәм, әлбәттә, иҗат эше кыюлыкны, һәртөрле шаблоннарга йөз җыерып карауны күздә тота, шунсыз гадәтләнгән алымнардан котылып һәм тагын да тирәнрәк нәрсәләргә ирешеп булмый»[1]. Г. Кәрам бу теорияне психологик планда да сизеп ала. Әгәр гадәтләнгән бәйләнешләрне җимерүнең хәзерге теориясе, берьяктан, фәнни, иҗади уйлау һәм, икенче яктан, психология кебек параллель юлларны белсә, Г. Кәрам иҗади фикерләүне дә, психологияне дә интуиция буенча гына якынлаштыра.

Гадәтләнгән бәйләнешләрне җимерүгә мисал төсендә, Г. Тукайдан бер өзек китерергә була. Анда ул комсызларны, бозыкларны камчылый, шул ук вакытта:

Уйнасын шул бәндә, кемнең акчасы бар, вакты бар,
Әйдә оттырсын бәхетсез, отсын әйдә бәхте бар,—

ди.

Монда инде укучының игътибары отышлы уеннарның үзләренә түгел, ә аларны китереп чыгарган социаль сәбәпләргә юнәлтелгән.

Психологизм идеяләренең, әдәби-эстетик эзләнүләр белән бергә, сәнгать әсәренең тукымасына да үтеп керүен күрсәтү өчен, Ф. Кәриминең «Шәкерт илә студент» повестена мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Повестьның гомуми идеясе — вольтерча, ачык, саф. Тәрбия методларындагы каршылык конструкциясе аша сәнгатьчә тукыма элементларын чамаларга мөмкин. Ул үзе бер генә фраза, ләкин ул инде идеягә түгел, ә к е ш е г ә (аның халык я з м ы ш ы  ө ч е н борчылуына) карый. «Студент — башка милләтләр дөньяда торганлыгы өчен ул гыйлемнәргә мохтаҗ булгач, сез ничек мохтаҗ булмыйсыз! Сез дә бит алар кебек к е ш е (курсив безнеке — Э. Н.)...»[2]

Реалистик образлар иҗат итү юнәлешендә өзлексез эзләнүләр татар язучыларын Шекспир һәм Гете мирасларына мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр итә. Нәкъ менә синтезлаучы язучы буларак Шекспирга якын торган Тукай аның иҗаты белән аеруча нык кызыксына. Реалист Тукай искитмәле герой концепциясен, «гомуми матәм» хисләрен җиңәргә тиеш иде. Герой үз чорының алдынгы идеяләре белән коралланган булырга тиеш. Гамлетны алдынгы карашлы, көчле шәхес итеп аңлату шуннан килә. «Юбилей мөнәсәбәте белән» исемле мәкаләсендә Г. Тукай болай дип яза: «Бәгъзылары: «Яшьләргә барыбер гимназияне бирмәсләр!» — дигән булалар иде. Ләкин яшьләр бу тарихи вакыйганың чын кадерен аңлау белән, милләтнең дә ихтыяҗын сизү белән, аларга Шекспирның зур каһарманнарыннан берсе булган Гамлетның: «Быть или не быть!» — дигән сүзе белән җаваплаганнар иде»[3].

Тукай Шекспирны татар тормышына хас мәсьәләләрне хәл итүдә файдаланмакчы. Аның Шекспирдан тәрҗемәсен алыйк:

Күрәм кайчакта җанкәмнең яңгагына чебен кунган,
Йөри бит шатланып шунда, үзенчә әллә кем булган!

Карыйм да мин, бәхетсез, шул чебеннең бәхтене көнлим;
«Ходаем, ни сәбәптән булмадым соң шул чебен мин!» — дим[4].

Мисал өчен шигырьне образларның Шәрык традицияләрендәгеләре белән — А. А. Фетның немецча «Хафиз» циклыннан тәрҗемәсе белән чагыштырыйк:

О, если бы потоком я был мировым,
А ты былинкой, над ним растущей!
О, если бы розовым был я кустом,
А ты бы розой, на нем цветущей![5]

---

[1] Б. Рунин. Вечный поиск. Рус телендә. Мәскәү. 1964 ел. 48 бит.
[2] Ф. Кәрими. Шәкерт илә студент. Оренбург. 1903 ел. 30 бит.
[3] Г. Тукай. Әсәрләр. 4 том. 182 бит.
[4] Г. Тукай. Әсәрләр. 2 том. 30 бит.
[5] А. Фет. Полное собрание стихотворений. 1959 ел.

(«Чебен»). Аның каравы, абстракт, төссез матурлыкка герой хисләренең бөтен бер гаммасы (өмет һәм шикләнү, юмор хисе, аның артына яшеренгән яралы күңел) каршы куелган. Тукайга Шекспирның катлаулы психологик сурәте якынрак. Шәрыкка хас традицияләрдән, тормышны Шекспирча колач белән кабул итүдән тыш, шигырьдә халыкчан юмор ялтырап ята. Үзенең истәлекләрендә С. Рахманколый Тукайның рәттән ике-өч мәртәбә «Тимон Афинский» трагедиясен укып чыгуы турында яза: «Бу фаҗиганең мәгънәсе Тукаевның үз гомерендәге тәэссоратыннан иң куәтлесе иде кен үз сүзләреннән аңладым» [1]. Белинский исә бу трагедияне чын поэзия җәүһәрләреннән саный.

Афинаның почетлы гражданы Тимон туган шәһәренә күп хезмәтләр күрсәтә. Юмарт, кунакчыл кеше булганга, ахырдан ул бөлгенлеккә төшә, дусларсыз кала. Афина сенатына шулай ук хәтере калган полководец Алкивиад, шәһәрдән үч алу өчен, гаскәр туплый. Ут Тимонны да үзе ягына чакыра. Ләкин Тимон дуамаллана:

Круши их! Бей! Забудь о милосердье,
Надень на уши и глаза броню,
Чтобы сквозь нее не проходили слезы
Грудных младенцев, дев и матерей [2].

Алкивиад Тимонны дөрес аңлый: үзе дуамалланып кыланса да, төбендә ул өзелеп Ватанын ярата икән. Һәм Алкивиад Афинага тынычлык алып килә:

Пускай война рождает мир, а мир,
Войну смирив, отныне будет свят [3].

Алкивиад акчаны һәм җинаятьләрне күрә алмаучы Тимонның тарихи яктан хаклы булуын чагылдыра. Тарихи оптимизм — Шекспир иҗатының төп мотивы.

Тукайның Шекспирга мөнәсәбәте безгә аның буржуаз җәмгыятьне фаш иткән күп кенә шигырьләрен (мәсәлән, «Эштән чыгарылган татар кызына») дөрес аңларга булыша. Биредә Алкивиад ролен лирик герой башкара. Халыкның әхлакый-эстетик идеалы исеменнән ул байбәтчәләр йөзенә нәфрәтле гаепләү ташлый, шуның белән гүзәллекнең тормышчанлыгы хакындагы Шекспир идеясенең дөреслеген раслый, үзе иҗат иткән образларның күпьяклылыгына ирешә.

Гетега мөнәсәбәт әле Шәрыктан ук үзләштергән материалистик тенденцияләр белән бәйләнгән. Күп кенә совет галимнәре беренче дәвер суфичылыкның прогрессив характерда булуын әйтәләр, аның үзендә стихияле халык материализмын һәм борынгы грекларның материалистик тенденцияләрен гәүдәләндерүен билгеләп үтәләр. Шәрык пантеизмы [4] аша Гетеның табигать теориясе эшләнә. Гете, язучы буларак та, гармоник шәхес буларак та, игътибарны үзенә тарта. Татар галимнәренең фикеренчә, ул искиткеч тәрбияле кеше, кешедәге иҗади, конструктив башлангычны гәүдәләндерә алган, табигать һәм тормыш серләренең асылына төшенә һәм үзен аның аерылмас бер кисәге дип караган кеше.

Әйтик, М. Фәйзи аңында Гете лирикасы шигъри азатлык белән тиңләшә:

Тереклек шул: синең кулыңа бирелгән чаткы тәңредән;
Ничек куллансаң, иркең бар, азатсың аллаң өмереңнән.
Аның белән үзеңне, башкаларны ямьлә, нурландыр;
Я, киресенчә, үзең һәм башкаларның һәммәсен яндыр [5].

---

[1] Тукай турында замандашлары. Казан. 1960 ел. 109 бит.

[2] В. Шекспир. Полное собрание сочинений. Мәскәү. 1960 ел. 7 том. 486 бит.

[3] Шунда ук. 519 бит.

[4] Пантеизм — философик тәгълимат. Бу тәгълимат буенча, асыл нигез күренешләрдән аерым, үзбаш яшәми, ә күренешнең эчендә була. Димәк, художникның бурычы — тормышны, аның мең төрле чагылышын күзәтү. Чөнки һәр күренеш — асыл нигезнең үзенчәлеге, кабатланмас бер гәүдәләнеше. Мәсәлән, мәхәббәт гашыйкларга күп нәрсә сөйли торган йөзләрчә вак детальләрдә гәүдәләнә. Әдәби образның көче аның бетмәс-төкәнмәс эстетик кичерешләр тудыра алуы белән бәйле.

[5] «Шура» журналы. 1916 ел. 23 сан. 559 бит.

Ф. Агеевның «Мөсафирның төнге җыры»н тәрҗемә итүе кызыклы, анда ул Гетены дидактик Шәрык традициясе рухында күз алдына китерә:

Төн кочагында тыныч таулар түбәсе йоклыйдыр,
Тын далалар төнге салкынча белән моң селкидер,
Кырдагы юлларны, җил юкка, тузаннар капламый,
Нык оешкан төсле, шылт итми агачлар яфрагы!

Бел, синең тормышта да мәңге давыллар кайнамас,
Ял итәрсең, җанкаем, тыныч килеш, түз син берaз! [1]

Шигырь Лермонтов тәрҗемәсе буенча эшләнгән, ләкин тәрҗемәче Лермонтовны да, Гетены да кабатламый. Әгәр Гете өчен тулы канлы тормыш, Лермонтов өчен «күк белән горур дошманлык» идеал булса, Ф. Агеев өчен исә мәңгелек акыл, халык тормышы идеал. Гете белән Ф. Әмирхан да кызыксына. Ул аның иҗатының эстетик асылын аңларга омтыла. «Мәктәпләребездә әдәбият дәресләре» исемле мәкаләсендә Ф. Әмирхан болай яза: «Кант фәлсәфәи тәнкыйдиянең мөәссисе, мөкәммиле хисап ителсә дә, Гете шул фикерне халыкка кабул иттерүче хисап ителәдер» [2]. Әгәр Ф. Әмирхан Кант белән Гетены бер-берсенә каршы куя икән, бу — барыннан да бигрәк, аның эстетик бәя белән рациональ фикерне чагыштыруы дигән сүз. «Гүзәллекнең специфик сыйфатларына Кантча билгеләмә бирү методы — аналитик, берьяклы, абстракт характерда. Реаль эстетик бәя — катлаулы күренеш. Анда аерылмаслык булып эстетик, этик, социаль һәм танып-белү мотивлары чиратлаша» [3].

Ф. Әмирхан да образларның катлаулыгына, сыйныфларга бәйле булуына басым ясый. Ф. Әмирханның «Картайдым» хикәясендә без Гетеча дөньяга караш, бурыч идеясен закон төсенә әйләндергән Кант этикасын кире кагуны күрәбез. Әгәр тормышның кайчандыр кичергән мизгеле кабатланса, герой бөтенесен, хәтта университетта алган белемен дә бирергә риза. «Хәят» повестеның да буеннан-буена кызыл җеп булып бурыч һәм теләк арасындагы конфликт сузыла. Гете белән Кант арасындагы эстетик һәм рациональ мөнәсәбәтләрне каршы куюдан тыш, Ф. Әмирхан игътибарын Гетеның тормыштагы бөтен идеалистик нәрсәләргә җирәнеп каравына, Гете фикеренең конкретлыгына, художникның бөрәмле һәм үзенчәлекле нәрсәләрне сурәтләргә юнәлтелгән булуына игътибар итә. Ф. Әмирханның «Кадерле минутлар» повестенда шул сыйфатлар күздән кичерелә. Герой тормышындагы һәр аерым момент, һәр аерым очрашу — аның бөтен тормышының кабатланмас эпизодлары, шулардан кадерле истәлекләр җыела: повестьның төп фикере әнә шул. Бер дә юкка гына повестька лейтмотив итеп «Фауст» трагедиясендәге арияңең сүзләре алынмаган. Гете иҗатының синтетик характерда булуын Габдрахман Мостафа [4] дөрес аңлаган. Мостафа өчен Гете — материалист. Халык тормышы өчен яшәгәндә генә, бөтеннең бер кисәге буларак, синең яшәвең аклана — Г. Мостафа Гетеның менә нинди фикерен күтәреп чыга: «Боларның соңгысы (Шиллер — Э. Н.) «син үлем алдында калтырыйсың! Син үлемсезлекне теләсәң икән, бөтеннең бер кисәге булып торырга тырыш! Син күптән беткән, югалган чагында ул бөтен калган булыр!» — ди» [5].

Көнбатыш әдәбияты һәм эстетик фикере белән бәйләнеш мәсьәләсе яңа күтәрелеп кенә килә. Ул күп галимнәрнең бергәләп, кулга-кул тотынып эшләвен сорый.

---

[1] «Ак юл» журналы. 1915 ел. 13 сан. 364 бит.
[2] Ф. Әмирхан. Сайланма әсәрләр. II том. 1958 ел. 337 бит.
[3] В. Асмус. Немецкая эстетика XVIII века. 189 бит.
[4] Ул Х. Ямашев белән бергә укыган һәм икесе дә материалистик философиядән яхшы хәбәрдар кешеләр булганнар.
[5] «Шура» журналы. 1912 ел. 22 сан. 712 бит.

# УЙЛАНЫРГА КИРӘК...

Ренат Харисов — үзенчәлекле шагыйрь.

Башка каләмдәшләре кебек үк, Ренат Харисов та үзенең шигырьләрендә тормыш һәм кеше матурлыгын расларга омтыла, коммунизм төзүче совет кешесенең иң югары, иң пакь идеалларына хезмәт итә. Ләкин ул моны үзенчә эшли, бүтәннәргә охшамаган рәвештә башкара. Нидән гыйбарәт соң бу үзенчәлек? Барыннан да элек шуннан: шагыйрь бер-берләреннән ерак торган, ләкин мәгълүм дәрәҗәдә үзара охшашлыкка, тиңдәшлеккә ия булган төшенчәләргә, күренешләргә таянып шигъри образ тудыра. Әйтик, табигатьтә кайтаваз дигән физик күренеш бар. Ул менә шушы күренештә образлы фикер яралгысы күреп ала. Аның өчен кайтавазда кеше гүя үзенең барлыгын, яшәвен хәбәр итә сыман. Ләкин шушы хәлендә генә бу идея шигырь өчен җитәрлек түгел. Аны үстерергә, көчәйтергә, баетырга кирәк. Ренат Харисов үзенең «Кайтаваз» исемле шигырендә шулай эшли дә. Ул тавыш хасил иткән кайтавазны кеше «кулының тавышы», кеше «сүзенең тавышы» тудырган кайтавазга әйләндерә. Әлбәттә, «кул һәм тавыш» яки «сүз һәм тавыш» — бер-берләреннән ерак торган төшенчәләр. Аларны хәтта янәшә куеп та булмый кебек. Ничек инде «кул»ның тавышы булсын,ди. Ләкин «кайтаваз» образы әлеге төшенчәләрнең янәшә куелуын сәнгатьчә аклый. Шул ук вакытта тавыш хасил иткән кайтавазны, охшашлык, тиңдәшлек нигезендә, кул эшчәнлеге тудырган кайтавазга әйләндерү авторга шигырьне яңа эчтәлек белән баетырга мөмкинлек бирә.

> Кулының тавышы,
> Өйләр, бакча, шәһәр булып,
> Кире яңгырап үзенә кайта...

Хәзер инде кайтаваз кешенең «биредә булуын» хәбәр итү белән генә чикләнми, ул, барыннан да элек, үзеңне, иҗтимагый шәхес буларак, бөек хезмәттә раслау булып яңгырый. Хезмәтең «өйләр, бакча, шәһәр булып, кире яңгырап үзеңә кайта икән, димәк, син — Кеше, син яшисең, син биредә, коммунизм төзү эшендә. Кайтаваз образының эчтәлеге хәзер менә шул. Шагыйрь нәкъ шундый кешене олылый һәм аңар үзенең иң игелекле теләкләрен күндерә:

> Яшә, Кеше,
> Үзең тудырган
> Игелекле Кайтавазда,
> Яңа дуслар табышып,
> Сөекләң белән кавышып!

Ренат Харисов — эзләнүчән шагыйрь. Ул сурәтле фикерләүгә ирешү өчен бер шигырьдә кулланган алымын һичбер үзгәрешсез икенче шигыренә күчерми. Дәлил итеп, «Кар киткәндә» шигырен күрсәтергә мөмкин. Биредә бер-берләреннән ерак торган төшенчәләрне янәшә кую юк. Ләкин теге шигырьдәге кебек үк, сурәтле фикергә «оеткы» хезмәтен үтәүче образ монда да сакланган. Ул шуннан гыйбарәт: кышын кешенең аяк эзе, батып, ак карда кала, язын исә әлеге эз, калкып, җир өстенә чыга. Күз алдына китерик: кара җир, ак эз! Ирексездән игътибарга ташлана торган образ, шулай бит! Автор шигырьдә менә шушы образга актуаль иҗтимагый эчтәлек салган:

> Аклык гомерен озайтмакчы
> Җирдә мин.
> Ни кылсак та, ярылып ятсын
> Аклыкта.
> Бәлки, аклык алып килер
> Пакьлеккә...

Ренат Харисовның сәнгатьчә фикерләү үзенчәлеген билгели торган сыйфатларның тагын берсе шул: аның шигырьләре тышкы тенденциядән, шигырьнең өстендә ята торган, маңгайга төртеп тора торган тенденциядән азат. Биредә тенденция я шигырьнең нигезенә салынган образны иҗтимагый эчтәлек белән баетудан килеп чыга, я бул-

масә, ул тормыштагы күренешне типиклаштыру аша тәгъбир итеlә. Менә «Метаморфоза» исемле шигырь. Югарыда телгә алынган шигырьләрдәге кебек, биредә образлы деталь юк. Култык таягы, сыник кәүсә, балына баткан умарта корты, квартира эзләүче ике яшь...— болар, аерымаерым алганда, һичбер образлылыкны дәгъва итмиләр. Чөнки биредәге һәр сүз үзенең туры мәгънәсендә кулланыла. Ләкин менә автор аларны бергә тезә, ритмга сала:

Күзем күргән
Күземә кердә:
Култык таягы керде,
Сынык кәүсә,
Балына баткан умарта корты,
Квартир эзләүче ике яшь...
Күземә керде.

Нәтиҗәдә әле генә коры атама вазифасын үтәгән төшенчәләр конкрет образга әйләнәләр, безне шактый шыксыз һәм күңелсез күренешләр дөньясына алып китәләр. Аларның киң «адымыннан», бер-берләреннән нык аерымлы булуларыннан тормыш сурәте барлыкка килә, һәм менә ул күренешкә авторның мөнәсәбәте:

Күзгә кергән
Күздә эреде,
һәм күземнән
Ике тамчы
Кочсез
Сыек тоз гына тамды.

Бу мөнәсәбәт укучыларның фикеренә дә билгеле бер юнәлеш бирә. Автор белән бергә, аларда да күренешкә карата тискәре хисләр уяна, уңайсызлану, шыксызлык тойгылары кабына. Шөбһәсез, бу — тенденция. Ләкин маңгайга төртеп тора торганы түгел.

Менә шигырьнең икенче өлеше:

Күзем күргән
Күземә кердә:
Ал әләмнәр,
Бармакларлардагы алтын балдаклар,
Сөю сүзе язып ашалган каләмнәр,
Яңа квартирага ачкыч,
Чәчләрдәге такыя...

Биредә караңгы, шыксыз буяулар юк, киресенчә, детальләрдән якгылык сирпелеп тора, күңел күтәренкелеген тудыра торган байлык, бөтенлек, иминлек үзен сиздерә. Күренешкә карата автор мөнәсәбәте дә икенчә төрле:

Күземә керде дә
Эреде,
һәм күземнән
Нур иуды,

һичшиксез, бу нур укучыны да яктыртып җибәрә. Күңел күтәрелә, тойгылар яңаралар, хисләр кабынып китә. Бу — тенденция. Ләкин типиклаштырылган тормыш сурәтенең үзеннән килеп чыга торган тенденция. Тагын шунсы игътибарга лаек, шигырьдә тормыш үзгәрештә, хәрәкәттә сурәтләнә. һәм бу үзгәрешне укучыга җиткерү өчен, автор естәмә рәвештә «шигърият заводы» ачмый, бары тик композиция чарасыннан файдалана: буяулары, детальләре белән бер-берләреннән ерак торган ике күренешне бер-бер артлы кую — үзе укучыда әлеге фикерне тудыра. Бу — шигырьләрнең эчтәлеген баетуда композиция чарасын белеп куллану күрсәткече. Ләкин Р. Харисов өчен композициянең вазифасы моның белән генә чикләнми. Шигырьнең эстетик камиллеген тәэмин итү — менә автор аны тагын нәрсәгә хезмәт иттерә белә.

Күзләремә кара туры.
Туры гына керсен әле
Күзләремә күзең нуры.

Туры кара күзләремә.
Күзең сүзе таңгал микән
Телең әйткән сүзләреңә...

Күзләремә туры кара...
Сау бул... Киттем... Күзең буйлап
Ят бер егет үтеп бара...

Игътибар итик: шигырь өчьюллыклардан тора. Беренче юл һәр куплетны башлап җибәрә, бу юлдагы өч сүз шигырь дәвамында үзара урын алыштыра һәм һәр очракта тулы рифма белән ныгытыла. Болар барысы бергә шигырьгә пехтәлек, оешканлык, ыспайлык биреп торалар. Шул ук вакытта эстетик камиллек үзмаксат түгел, бәлки эчтәлекне тәэсирле тәгъбир итүгә буйсындырылган. Бер генә деталь: автор куплетның беренче юлындагы өч сүзне төрлечә урнаштыра. Ни өчен? Камиллек өчен генәме? һич юк. Нәкъ менә әлеге сүзләрнең төрлечә урнашуы шигырьдә хәрәкәт, хис агышы, драматик киеренкелек тудыра, эчтәлекне тирәнәйтә. Чыннан да, беренче юл таләпчән интонация белән башланып китә. Биредә төп игътибар үзегендә торган сүз — күзләремә. Икенче куплетта инде аның урынына «туры» килеп урнаша. Сәбәп шул: димәк, кыз егет күзләренә әле һаман туп-туры карамаган икән. Дөрес, бу турыда шигырьдә ләм-мим юк. Шуңа да карамастан, әлеге эчтәлек укучыга барып житә һәм моны бердәнбер чара — сүзләрнең урыны алмашыну эшли. Тагын шунысы

да бәр, «туры» беренче планга күчерелү белән шунда ук интонация үзгәрә. Шигырь хәзер тагын да таләпчәнрәк яңгырый, хис киеренкелеге арта, драматизм көчәя. Соңгы куплетта **«күзләремә»** яңадан беренче урынга күчә, инверсия бетә. Бу инде кызның егет таләбенә буйсынуы турында хәбәр итә. Әлбәттә, шагыйрьнең сурәтле фикерләү үзенчәлеген югарыда әйтелгәннәр белән генә иңләрлек түгел. Шагыйрьнең эзләнүләре төрле юнәлештә бара. Ул, барыннан да элек, интеллектуаль шагыйрь. Аның шигырьләре укучыны уйларга, уйланырга чакыра, эстетик матурлыкларны табарга, үзләштерергә димли. Авторның бу омтылышлары, һичшиксез, теләктәшлек тудыра. Ләкин Ренат Харисов эзләнүләрендә барысы да урынлы, уңышлы дип булмый. Авторның күп кенә шигырьләрен укыгач, ирексездән:— Сез кем өчен, кемгә төбәп язасыз? — дип сорыйсы килә.

Менә «Чигешем, тегешем» исемле шигырь. Биредә күзгә беренче булып бәрелгән нәрсә — ул сурәтле фикер катлаулыгы.

Вакыт — җеп,
Мин — энә...

Күрәсез, болар бер-берләреннән нинди ерак торган төшенчәләр! Ләкин автор ихтыяры белән алар үзара якынайтылганнар, хәтта бер-берләренең синонимына әйләндерелгәннәр. Кайсы категория укучы бу әверелүне кабул итәргә мөмкин? Терлекче, савымчы? Юк. Игенче, тегүче, механизатормы? Юк. Китапханә эшчесе, татар теле укытучысымы? Юк. Хәлбуки, татар әдәбиятын укучылар — әнә шул төр кешеләр сафыннан бит. Ә аларга «Минне — энә», «Вакытны — җеп» итеп күзаллау җиңел эш түгел. Бу очракта шигырьдә алынган төшенчәләр арасында «Кайтаваз»дагы охшашлык, тиңдәшлек юк. Шуңа күрә дә «вакыт — җеп, кеше — энә» синонимы әлеге укучы массаларына аңлашылмый. Инде килеп шигырьнең эчтәлегенә күз салыйк:

Вакыт — җеп,
Мин — энә,
Бер төшәм,
Бер менәм:
Өйләрне, юлларны,
Урамны, урманны —
Барысын мәңгегә
Мин җиргә беркетәм,
Шул минем тегешем,
Чигешем — шул менә.

Бу юлларның мәгънәсен ничек аңларга? «Өйләрне... урманны — барысын да мәңгегә җиргә беркетәм» мәгънәсендәме? Алай икән, ул чагында шигырь язып торасы да юк, чөнки «йортлар... урманнар», шагыйрьдән башка да инде күптән җиргә мәңгегә беркетелгәннәр. Димәк, авторның тел төбендә башка фикер булырга тиеш. Менә син, савымчы, игенче, механизатор, шуны эзләп тап инде. Ничекме? Автор киңәше шулай:

Җентекләп кара син:
Вакыт — җеп,
Син — энә!

Менә «Дәрдмәнд» исемле икенче бер шигырь. «Маңгай җыерчыгы анаң булган...», дип башлана ул. Нинди реаль мәгънә ята соң бу катлаулы метафорада? Бу сорауга җавап табу укучы җилкәсенә авыр йөк булып төшә. Чөнки әлеге метафораның чын мәгънәсе аста, еракта, җиде кат җир астында. Гади укучы аны шуннан казып чыгарырга тиеш. Башка чара юк, шигырьнең идея-эстетик эчтәлеге шул метафорага салынган.

Шундый ук күренешкә укучы авторның «Ат», «Ярсыган ат», «Яткан ат» кебек шигырьләрендә дә тап була. Димәк, сурәтле фикернең аңлашылмаслык дәрәҗәдә катлаулыгы Ренат Харисов иҗатында ялгыз күренеш түгел, ул системага әйләнеп бара. Әлбәттә, иҗади эшчәнлегенең мондый юнәлеш алуы авторның үзенә сизелмәскә дә мөмкин. Чөнки кеше, мәгълүм юнәлештә даими эш итеп, бик нык чарлана, үсә, камилләшә. Алга барган саен аның тагын да тылсымлырак, нечкәрәк, серлерәк итеп фикер йөртәсе килә башлый. Укучыга катлаулы метафорага төренгән фикер барып җитәме? Мондый сорау аның башына да килмәскә мөмкин. Шагыйрьнең үзенә җиңел аңлаешлы нәрсә, ничек итеп укучыга барып җитмәсен, ди. Аннары таянырга дәлил дә бар: шагыйрьнең бурычы укучы артыннан бару түгел, бәлки аны үз артыннан ияртү, үз дәрәҗәсенә күтәрү. Шушы дөрес фикер ялгыш эшчәнлекне аклау хезмәтенә алына, шагыйрь тынычланып, үз юнәлешендә яза бирә, язган саен укучылар массасыннан ераклаша, һәм, ниһаять, үз дөньясына кереп бикләнә. Бу дөньяга инде тар даирәләрдән тыш башка кеше керә алмый. Сурәтле фикернең аңлашылмаслык дәрәҗәдә катлаулылыгы бара-тора котылгысыз рәвештә менә шушы аяныч финалга китерә. Шуңа күрә дә социалистик реализм әдәбияты талант иясен укучылар массасыннан аеруга илтә торган үзенчәлекне кире кага. Чын үзенчәлек — ул халыкка хезмәт итү чарасы, талант иясен сафлар башында баручыга, чакыручыга, чаң сугучыга әйләндерү чара-

лекка аңлаешлы булганда гына ирешергә мөмкин. Чөнки аңлашылмый торган нәрсәгә беркем иярми. Моннан инде практик нәтиҗә чыга: иҗат итү дәвамында укучыны бер генә минутка да истән чыгарырга ярамый.

Югарыда мисалга китерелгән шигырьләрдән күренә ки, Р. Харисов бу таләпне әлегә җитәрлек дәрәҗәдә искә алмый.

Ниһаять, тагын бер мәсьәлә бар. Ренат Харисовның уңышлы шигырьләрендә идея типиклаштырылган тормыш күренешеннән табигый рәвештә килеп чыга. «Метаморфоза», «Болыт үтте», «Куанды ил», «Табып ләззәт», «Көлемсерәп көн башланды», «Аһ, син ничек каты үйлыйсың!» һәм башка шигырьләр әлегә фикергә ачык дәлил булып торалар. Әйтәсе дә юк, бу — дөрес юл. Тик шунсы гына аяныч: шушы юлдан барганда автор кайвакыт читкә тайпыла, ачык фикерле, сөйләп торучы күренешләр урынына, «телсез» сурәтләр ясап куя.

Ук гәүдәмне
Күккә төбәп,
Иңнәремә атты...
Канат дисәм — аска баса
Җәя дисәм — атмый...

Ни әйтергә теләгән автор моның белән? Бармы анданиндидер яңа фикер, яңа эчтәлек?.. «Гитара», «Сыгылдырып күл камышын...» исемлеләре дә — нәкъ менә шундый характердагы парчалар. «Казан утларының быелгы беренче санында басылган тыралар.

Югарыда саналган кимчелекләр Ренат Харисовка хас булган иҗат үзенчәлегенең уңай сыйфатларына һичшиксез шәүлә төшерәләр. Алар шигырьләрне укучы массаларыннан ераклаштыралар, шагыйрьгә үз кабыгына бикләнеп калу куркынычын тудыралар. Аннары, үзең раслаган иҗат алымы халык тормышының бүгенге ихтыяҗларына ни дәрәҗәдә җавап бирә алуы турында да уйланырга кирәк.

Бәлки, бүгенге укучы белән «Вакыт — җеп, мин — энә» дип сөйләшү урынына, шагыйрь үтемлерәк юлны сайларга тиештер. Чөнки «Яфраклар» исемле шигырьдәге кебек «Агач — күккә төбәлгән елга», дип эндәшүгә каршы гади укучылар керфек тә какмаячаклар. Димәк, иҗат үзенчәлеген раслаганда бу турыда да уйларга кирәк. Ләкин «нинди үзенчәлек яхшы» мәсьәләсен хәл итүнең иң дөрес юлы — укучылар белән очрашу, урыннарда иҗат кичәләре оештыру. Киң катлау укучы массалары катнашы белән уздырылган андый кичәләр чын мәгънәсендә талантларны ачу, чарлау, чыныктыру, иҗат үзенчәлекләрен сынау мәктәбе булып торалар. Мәсьәләнең икенче ягы да бар: әдәби кичәләрдә катнашу — ул укучыларның эстетик зәвыкларын үстерүгә хезмәт итәчәк. Димәк, бу турыда да уйларга кирәк.

**ШӘРӘФ ӘХМӘДУЛЛИН.**

# МУСА ҖӘЛИЛ—ТАТАРЧА БАЛАЛАР ЖУРНАЛЛАРЫН ОЕШТЫРУЧЫ

Муса Җәлилнең сүнмәс поэзиясе әдәбият белгечләренең игътибар үзәгендә булып килә. Җәлил иҗаты турында аерым тикшеренүләр, монографияләр, күп санда мәкаләләр басылып чыкты. Әлбәттә, бу тикшеренүләр шагыйрь эшчәнлегенең, аның биографиясенең барлык якларын да яктырттылар, дип әйтеп булмый әле. Шулардан берсе — Муса Җәлилнең балалар журналларын оештырудагы хезмәте. Балалар өчен чыгарылган татар совет журналларын күзәткәннән соң Муса Җәлилнең педагогик эшчәнлеге дигән аерым бер мәсьәләне көн тәртибенә куеп булыр кебек.

Хәзер егерменче елларга экскурс ясыйк. Милли республикалар һәм өлкәләрдәге җаваплы работниклар белән РКП(б) Үзәк Комитеты уздырган киңәшмә резолюциясендә (1923, 9—12 июнь) «Туган телдә яхшы оештырылган вакытлы матбугат булдырырга» дигән бурыч куела.

«Кечкенә иптәшләр» — азчылык милләтләр телендә чыгарылган беренче балалар журналы була. Аның беренче саны 1924 елның мартында Мәскәүдә чыга. М. Җәлил журналның беренче саннарыннан ук анда актив катнашып килә. Комсомолның Бөтенсоюз киңәшмәсендә (1927 елның язы) ул ВЛКСМ ҮКның татар-башкорт секциясе әгъзасы итеп сайлана. 1927 елның 5 августында ВЛКСМ ҮК аны үз карамагына чакыртып ала һәм «Кечкенә иптәшләр» журналына эшкә җибәрә. 1927 елның октябрендә инде ул — журналның җаваплы редакторы. Нәкъ шул саннарыннан башлап журналның тематикасында, материалларның сыйфатларында борылыш сизелә башлый. Яңа редактор журналны гомумилектән конкретлыкка таба алып бара. Бу — журналның педагогик юнәлешенә әһәмият артуда сизелә. Ихтимал, журналның исеме дә аның юнәлешенә, максатына туры килеп бетмәгәндер. Гарәп хәрефеннән латинга күчү чорында М. Җәлил яңа балалар журналы оештыру турында эш кузгата. 1929 елның 13 мартында ВЛКСМ Үзәк Комитеты «Кечкенә иптәшләр» урынына яңа алфавитта икенче бер журнал чыгару турында карар кабул итә. 16 июльдә ул «Октябрь баласы» журналының редакторы итеп раслана. Бу журнал ВЛКСМ Үзәк Комитеты каршындагы татар-башкорт бюросы һәм РСФСР Наркомпросы органы була. Журнал Мәскәүдә 1933 елга кадәр чыгып килә. Журналны үзе күрергә теләгән дәрәҗәдә яхшы сыйфатлы, тирән эчтәлекле итеп чыгару өчен Муса Җәлил шактый зур кыенлыкларны җиңәргә тиеш була. Болар — полиграфик мөмкинлекләрнең гаять чикләнгән булуы (хәреф, кәгазь, клише мәсьәләләре), хәзерлекле редакция хезмәткәрләренең җитмәве... Муса Җәлил мондый мәсьәләләрне хәл итүдә ярдәм сорап ВЛКСМ Үзәк Комитетына, Центриздат идарәсенә һәм редакциясенә кат-кат мөрәҗәгать итә. Яңа журналның әле корреспондентлар челтәре дә булмый. Шул челтәрне тудыру максаты белән М. Җәлил яшь язучыларга, хәбәрчеләргә, пионерларга «каләмнәрен кайрарга» һәм журнал эшендә актив катнашырга чакырып мөрәҗәгать итә. Яңа журналда яңа бүлекләр барлыкка килә. «Музыка сабаклары», «Башны эшләт», «Көлке бүлеге», «Һөнәр-техника» — әнә шундыйлар.

Журналның 1931 елгы 1 санында урнаштырылган белдерүгә караганда, «Октябрь баласы»ның әдәби өстәмәсе дә булган. Бу китапчыкта матур әдәбият әсәрләре урнаш-

ганычка каршы, Казан архивларында һәм китапханәләрендә бу өстәмәнең бер нөсхәсе дә табылганы юк әле.

Журнал барлыгы 41 сан чыга. Бу саннарның һәрберсендә диярлек Муса Җәлилнең үз әсәрләре бар. Балалар дөньясында фамилиясе инде шактый таныш булганлыктан, шагыйрь төрле псевдонимнар кулланып яза. «Шахмай», «М», «Мостафа улы», «Асум», «М. Апуш» һ. б.— аның шул журналдагы псевдонимнары. Ләкин шагыйрь үз материаллары белән генә журналны алга алып бару мөмкин түгеллеген яхшы аңлый. Шуңа күрә ул балалар өчен яңа әсәрләр язуларын сорап күп кенә язучыларга мөрәҗәгать итә. «Менә боларны кем язган дисең! Журнал күптән түгел генә чыга башлады бит, аның янында язучылар активы тупланып өлгермәгән әле,— ди ул композитор Л. Хәмидигә.— Шуңа күрә миңа болай да күп язарга туры килә» [1]. Ләкин озак вакыт та үтми, М. Җәлил яшь хәбәрчеләр челтәрен оештырып эшкә тартуга ирешә. Мәктәп, балалар йорты, пионер отрядларыннан журналга инде биш йөздән артык даими хәбәрче яза башлый. Яшь хәбәрчеләр белән язышуны ул турыдан-туры үзе алып бара.

Журнал битләрендә балалар әдәбиятын үстерү мәсьәләсе үзәк урыннарның берсен алып тора. Шагыйрь балалар өчен Арктика, стратосфера геройлары турында язарга чакыра, мәҗаралы әдәбиятның балаларны тәрбияләүдә роле турында яза. Редакциягә килгән әсәрләр буенча журнал битләрендә фикер алышу, әдәби консультацияләрне турыдан-туры М. Җәлил үзе алып бара. Балалар китабының оформлениесен һәм эчтәлеген яхшырту өчен көрәш — шагыйрьнең бу чор эшчәнлегендә аеруча күзгә ташлана. Бу мәсьәләне ул Татарстан язучыларының I съездына куюны да таләп итә. «Таткнигоиздатның күп кенә китаплары хәреф хаталары, рәсем һәм тыш, кәгазь ягыннан яхшы ук түбән торалар» [2], дип яза ул, борчылып. Журнал педагогикага кагылган күп кенә конкрет мәсьәләләр күтәрә. М. Җәлил татар әдәбияты классиклары Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ш. Камал һ. б. әсәрләреннән зур тираж белән «Мәктәп сериясен» чыгару кирәклеге турында сүз алып бара. Бу елларда балалар әдәбиятын тудыру, элеккеләрен сайлап алып яңадан бастыру мәсьәләләре нигездә «Октябрь баласы» журналы битләрендә алып барыла. Журнал, шулай итеп, балалар арасында зур популярлык казана башлый. Чыга башлаганда аның тиражы өч мең экземпляр итеп билгеләнсә дә, бераздан ул җиде мең биш йөз экземплярга җитә. Тәҗрибәле журналист буларак, ул журналның тиражын арттыру, аны пропагандалауны көчәйтү максаты белән кызыксындыру чаралары уйлап таба. Балалар арасында уннан артык подписчик туплаган кешегә истәлекле бүләкләр бирелә, журналга бушлай подписка рөхсәт ителә һ. б.

Журнал битләрендә туган якның табигатен өйрәнүгә, табигатькә мәхәббәт тәрбияләүгә зур урын бирелә. Кошлар тормышы турында, кош ояларын ясау, авыл хуҗалыгында кошларның файдасы турында язылган мәкаләләр белән беррәттән, журналда М. Җәлилнең әлеге темаларга кагылышлы матур-матур шигырьләре басылып килә.

М. Җәлилнең музыка өлкәсендә шактый мәгълүматлы кеше икәнлеге мәгълүм нәрсә. Аның музыканы пропагандалавы, бигрәк тә балалар өчен музыкаль әсәрләр иҗат итү өлкәсендәге эшчәнлеге «Октябрь баласы» чорына туры килә. Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, журналда 1929 елдан башлап «Музыка сабаклары» дигән бүлек ачыла. Бу бүлекне М. Җәлил белән композитор Л. Хәмиди алып бара. Шул ук вакытта М. Җәлил балалар өчен көйгә салынган җырлар китабын төзү буенча да эшли. Бу процесста ул музыка теориясенең нигезләрен, музыка тарихын өйрәнә. Яшь композитор Җ. Фәйзи белән берлектә алар «Нәни җырчылар» дигән бер китап чыгаралар. Бу китаптагы җырлар татар совет мәктәбе укучылары арасында зур популярлык казана. Әйтергә кирәк, ул иҗат иткән «Карак песи», «Күке», «Сәгать», «Беренче дәрес» һ. б. җырлар бүгенге көндә дә мәктәп программаларына кертеләләр һәм балаларның яраткан җырлары булып исәпләнәләр.

Соңгы елларда гына ТАССР Мәгариф Министрлыгы мәктәп балалары өчен бер серия җырлар язылган грампластинкалар чыгарды. Ләкин моның балаларны эстетик яктан тәрбияләүдә әһәмиятле эш икәнлеген М. Җәлил утызынчы елларда ук күтәреп чыккан иде. Бу турыда шагыйрьнең партия Үзәк Комитетына һәм ТАССР Халык Комис-

---

[1] Муса турында истәлекләр. Казан. 1964 ел. 63 бит.
[2] М. Җәлил. Сайланма әсәрләр. 1956 ел. 3 том. 177 бит.

тарих институтында саклана.

«Октябрь баласы» үзенең битләрендә интернациональ, хәрби-патриотик, атеистик тәрбиягә дә зур урын биргән. Журнал Морзе әлифбасы, топография картасын өйрәнү буенча мәгълүматлар бирә, хәрби уеннарга өйрәтә. Шагыйрьнең бу мәкаләләре ахырдан «Авылда пионер эшләре» дигән аерым китапка тупланып чыгарыла.

«Октябрь баласы» — татар пионерларының чит ил балалары белән хат алышуын башлап җибәргән журнал. Монда Чехословакия, Болгария, Германия кебек илләрдәге мәктәп яшендәге балаларның ул чордагы авыр, фаҗигале тормышы чагылдырыла, аларның хатлары урнаштырыла. «Без пионерларның аңына интернациональ берлек тойгысын сеңдерергә тиешбез,— дип яза М. Җәлил журналда,— алар үзләренең бөтен дөнья интернациональ армиясенең бер кисәге генә булганнарын аңласыннар»[1].

Журнал балалар арасында атеистик тәрбия эшләрен алып баруда да бердәнбер методик үзәккә әверелә. Журналда атеизм почмаклары оештыру, сорау-җавап кичәләрен уздыруның методик программалары бирелә, атеизм буенча әңгәмәләрнең тематикасы тәкъдим ителә. «Аллага ышануның килеп чыгу тарихы», «Диннең сыйнфый асылы», «Дингә каршы көрәшне ничек алып барырга» һ. б. әнә шулардан берсе. Шагыйрь фикеренчә, дингә каршы көрәш шаблон характерда булмаска, дингә ышанучыларны куркытмаска тиеш. Атеистик пропаганда дингә ышанучыларны уйландырырга тиеш, ди ул. Муса Җәлилнең публицистикасы әле аз өйрәнелгән. «Октябрь баласы», «Фән һәм дин» журналларында без аның атеистик темага язылган дистәләрчә мәкаләсен, хикәяләрен, фельетоннарын таба алабыз. Аның «Колхозга өрлык, муллага йодрык», «Уразага каршы көрәшкә», «Исмай белән Мыртый», «Корбанга каршы», «Тәре белән корбан походы», «Изге җимеш» кебек мәкалә, хикәяләре утызынчы елларда сугышчан атеизмга лаеклы өлеш керттеләр.

«Октябрь баласы» гомуми мәҗбүри башлангыч белем бирү турында партиянең XVI съезды карарларын пропагандалауга күп көч куйды. Журналның редакторы булarak, ул бу уңайдан бик күп укытучылар белән аралаша, җыелышларда, конференцияләрдә чыгыш ясый.

Шунысы характерлы, журнал нинди генә тема күтәрмәсен, бу тема М. Җәлилнең шагыйрь буларак та иҗатында чагылыш таба. Мәсәлән, журнал үзенең битләрендә спорт турында күп кенә материал урнаштыра. М. Җәлил үзенең мәкаләләрендә яшь буынның саф, сәламәт булып үсүе өчен тән тәрбиясенең әһәмияте турында яза. Шул ук саннарда аның «Чаңгы эзе», «Чаңгы шуганда» кебек шигырьләре дә басыла. Соңыннан аның шигырьләре уку китапларына кертеләләр. Шулай итеп, М. Җәлил журнал күтәргән мәсьәләләргә публицистикасы белән дә, шигырьләре белән дә актив катнаша. М. Җәлилнең армый-талмый эшләве нәтиҗәсендә, «Октябрь баласы» акрынлап педагогик журналга әйләнә һәм яшь буынны тәрбияләүдә иң актив мәсьәләләрне күтәрә.

Аның «Кечкенә иптәшләр» һәм «Октябрь баласы» журналларындагы бу мәкаләләрен җыеп аерым бастыру Җәлил мирасын өйрәнүчеләребезнең киләчәктәге бурычларыннан берсе булып кала.

Ялкынлы шагыйрьнең калдырган мирасы бәхетле язмышка очрады: чөнки ул үзе гомере буе каләме белән пропагандалаган Ватанга турылыкны, батырлыкны, фидакарьлекне тормышы белән исбат итте. Шагыйрьнең язганы белән тормышы, көрәше арасында без берниндиаерма күрмибез. Аның бу сыйфаты поэзиясендә генә түгел, педагогик темага язылган мәкаләләрендә дә, гомуми публицистикасында да сизелә.

Муса Җәлилнең «Кечкенә иптәшләр» һәм «Октябрь баласы» журналларындагы публицистикасы, әдәби әсәрләре белән танышып чыккач, аның «Бер үгет» исемендәге шигырен шагыйрь гомеренең табигый йомгагы дип кабул итәргә мөмкин.

Эзе калсын керсез намусыңның,
Ни үтсә дә синең кулыңнан.
Көчлелегең белән горурланма,
Көшелегең белән горурлан!

...Син яшәмә җирдә файдасыз бер
Түмгәк булып тигез урында.
Янып калсын гомерең маяк булып,
Үзеңнән соң килгән буынга.

Яшьләргә бу үгетне бирергә Муса Җәлил тулысынча хаклы иде.

ФААТ МОСТАФИН,
Казан дәүләт университеты аспиранты

[1] «Октябрь баласы» журналы. 1931 ел. 2 сан.

Газиз Мөхәммәтшин

# ИКЕ ӘБИ БӘРӘҢГЕ АЛА...

хикәя



Сентябрь азаклары. Кояшлы, җылы көн. Ике әби яулыкларын арттан гына бәйләгәннәр, бишмәтләрен салып көнбагышка элгәннәр, чулпыларын чылтырата-чылтырата, ашыкмый-кабаланмый гына, үз җайлары белән генә бәрәңге алалар.

Әбиләрнең берсе җитмеш биш яшьтә. Икенчесе аннан яшьрәк — җитмеш бердә генә. Алар казыган бәрәңгене сиксән биш яшьлек бабай ындырдан ишек алдына ташып тора. Ул лапас капкаларының икесен дә киереп ачып куйган. Капчыгына өчәр чиләк бәрәңге чүпләп сала да, җилкәсенә күтәреп, сукмак буйлап китә. Шулай әкрен генә әйләнеп, әбиләр белән өй арасында йөри дә йөри. Әбиләр белән сөйләшми. Тегеләре бертуктаусыз «ләчтит сатсалар да», тукта, ни сөйлиләр икән, тыңлап карыйм әле, дими. Бәлки, тыңлар да иде — ишетми. Колагы катыланганга унбиш еллап бар инде.

Ә безнең колаклар, аллага шөкер, ишетә бит әле. Шулай булгач, әйдәгез, бу форсаттан файдаланып, әбиләрнең сүзен тыңлап карыйк...

Яшь әби, эһ-эһ дип, көрәгенә ике-өч тапкыр баса да, бәрәңге төбен актарып чыгара.

— И алла, бигрәк тирәнгә утырткансыз быел. Моңа көч тә җитмәй, беләксез дә калырсың, исәркәем. Бәрәңгесе булса ярар иде тагын. Гүпчим юк бит. Безнең бәрәңге кер бәләге хәтле. Былтыргының яртысы да чыкмас моннан.

Карт әби көнбагыш тамырына көрәге белән бәргәли.

— Чыкма-ай. Менә бит, бигрәк юк бит. Бәрәңгемени бу! Әле аның да яртысы җиргә күмелеп кала.

— Тырмаларсыз инде. Соңга таба. Эш беткәч.

— Миннән булмый. Җизнәң караса карар. Без үзебез җизнәң белән аена бер пот та бәрәңге ашамыйбыз. Малга, кош-кортка ашатып бетерәбез. Көн дә иртән казанга ике бидерә бәрәңге салам да, шуны төеп, көрпә белән болгатам, көрпә булмаганда он салам — шулай итеп ашатабыз.

— Нәмәкәйгә интегәсез шулхәтле? Бер кортка белән бер картка күп кирәкмени? Бик интегеп ятар идем мин булсам! Малайларым, кызларым җибәргәнне тик ашап ятар идем рәхәтләнеп бер дөньясында.

күтәреп көн дә кешедән сөт сорап йөрерсеңмени, исәр. Без гомер буена малсыз тормадык, аллага шөкер. Абзар тутырып сарыгын асрадык. Икешәр сыер сауган чаклар булды. Аның янында тагын танасы, бозавы. Сугыш вакытында да ниндәен нәрәт кайтса, иң башта безгә килеп керделәр, бездән алдылар. Җизнәң Сталинград фундына гына да дүрт сарыкны җитәкләп илтте. Йоннары да алынмаган иде.

— И тутәй, кичә син үрдәк тазартып йөргәндә яңа гәҗит кайтты. Җизнәй укып күрсәтте. Япун белән Кытай ягында әле дә бик каты сугыш бара дигән.

— Әмерикәнме?

— Әмерикән. Шул тагын бик нык сугыша икән. Бер бәләкәй генә Вьетнам дигән халыкны буйсындырам, дип әйтә ди. Сез кайчан да булса бер барыбер минем кул астымда булырсыз, дип әйтә ди, мөртәт.

— Ходай күрсәтмәсен! Бәләкәй халыкка рәт юк бу дөньяда. Алла ярдәм бирсен мескеннәргә! Бу Әмерикәне дә яшь этәч төсле гел сугышырга кыҗырай да тора, кыҗырай да тора. Өендә тыныч кына чәй эчеп утырса ни булган!..

— Беләмени алар чәй тәмен! Ул якларда иртән торсаң — күфи ди бит... Кара әле җизнәйне. Нәмәгә безгә карап торасың, җизнәй? Әзрәк ял итеп ал!

— «Мине сөйләми микән болар», ди инде. Аңларга тырыша. Юк, юк, сине сөйләмибез — сугышны сөйлибез, сугышны. Сугышлар булмасын, тынычлык, иминлек белән яшәргә язсын, дибез. Сиңа әйтәм, син бар кер, чәй эчеп чык. Самавыр суынмагандыр әле, яңа гына гөжләп утыра иде.

— Берүзе эчмәй бит у-ул.

— Ю-ук! Эчерерсең аны! Мин кич ашка китәм. Самавырга күмер салып кайнатып китәм. Эч тә ят, интегеп утырма, йокла, димен. Тәки мине көтеп утыра. Нигә мин берүзем чәй эчеп ятаем, дие. Менә, дивана түгел диең син аны.

— Дивана булыр ул! Күңеле тартмый. Нишләп ялгыз башы чәй эчеп утырсын! Илле тугыз җыл бергә яшәп, бер түшәктә җоклап икегез бер кешегә әйләнеп беткәнсез инде. Ходай тагын гомерегезне бирсен! Ул балаларыгызны әйтәсеңме! Берсеннән-берсе уңган, берсеннән-берсе тәуфыйклы, берсеннән-берсе олы урыннарда эшләйләр. Миннән булмады инде. Утыз яшьтән ятим калып. Укыта алмадым. Үзләре дә ялкау булды, каһәр суккан нәмәкәйләр. Мин укырга китте диеп торыр идем, ул кибән артында тәмәке таргып ятар ие, иптәшләре кайтканда гына шуларга ияреп кайтыр ие, бер нәмәкәй дә булмагандай күзен тондырып, инә-әй, үләм, корсагым ачты, давай, ашарга бир, диеп. Имансыз! Менәтерә, бүгенге көндә бозау көтеп йөри үз башын үзе кадерсез итеп. Укыса, зур урыннарда эшләмәс идемени! Өстәл башында тилефүн челтерәтеп кенә утырыр ие. Үзе кешеләрне кушып...

— Нахак бәләләр тагасың. Бик әйбәт эшләй бит. Тагын ни кирәк? Эчмәй. Катын-кыз димәй, азмай-тузмай.

— И түтекәем, анысына мең шөкер итәм инде. Намаз артларыннан теләем, катын-кызлары аның хәзер катын-кыз төслемени! Заман ахыры житкәндә, ире, катыны хайван сурәтенә кереп бергә йөрер дигән сүзләр дөрескә килдеме — килде!

— Килми ни! Менә минем Акбай киленен ал. Югыйсә, карап торуга акыллы гына төсле бит инде. Укыган кеше дә. Былтыр шуларның Кәме буендагы дачаларына бардым. Анадан тума шыр-шәрә тик йөри. Ике төшенә тар гына ике чүпрәк каплаган. Карап торсаң — әдәм тәгәнәсе менә! Тьфү, тьфү, ташка үлчим. Төшеңә керә күрмәсен. Киленкәем, дидем, ник болай йөрисең әдәм араларында оялмыенча, дидем, әллә

тирә-ягында, дидем. Бар, тизрәк, кеше-кара нәгәләт укыганчы, өстеңә киен, дидем. Әллә миңа кояшка кызынырга да ярамаймы диеп мыгырданып, такта өйләренә кереп китте. Менә, исәр, күрәселәрең булса, күрәсең аны. Картайгач та күрсәтә.

— Шулай булмай, түтекәем. Әйттеңме соң, без яшь чакта бер дә шәрәләнеп кызынып ятмадык, диденме? Өстә чүбек җебеннән үзебез сугып кигән күлмәк-ыштан, аякта тула оек белән чабата булыр иде, кулда йон бияләй-кә, башта — төшереп бәйләгән яулык. Шуның белән көн буена кызу кояшта урак урасың бит әле, инәкәеңнең башыкае, бала имезәсең. Анысы бакырып чүмәлә төбендә ята. Кайда ул кояшта кызынып ятулар! Ә хәзер ирәяләр, түтекәем, авызларына бөтен нәрсәне хөкүмәт каптыргач. Шулай ирәя, шулай бозыла бала-чага.

— Сабан туеннан соң, әбекәем, бабыкай, бик сагындым дигән булып Нәфиганың олы кызы Хәния кайтып киткән булды бит әле. Инде дүрт-биш ел кайтканы юк иде. Менә шул әдәм рисвае итеп китте бит имансыз нәрсә. И илаһым, җизнәнең дә, минем дә нерваларыбызны калдырмады, исәркәем. Төн буена капка төбендәге утыргычка утырып чыгалар. Иртән мин кәҗә саварга торгач кына кереп ята. Күлмәккәе бөтенләй юк диеп әйтерлек — арт йомрыларын да капламаган ристанның. Җизнәң шуны күрде дә кайтып керүенә эт итеп сукте. Алланың каһәре суккан нәрсәкәй, әбиең белән бабаңны картаймыш көннәрендә бөтен авылга рисвай итәргә кайттыңмыни күзеңне-башыңны тондырып, дие, менә эпекәйдер! Самавыр да куя алмыйсың, идән дә юа алмыйсың, бер нәмәкәй дә эшләй алмыйсың бит — иелдеңме шәрәң күренә, болай йөремә минем алдымда, кайтып кит бүген үк, намаз артыннан каргармын, дие.

— Ә үзе нәмәкәй дие шуннан соң җизнәйнең сүзенә каршы?

— Нәмәкәй дисең! Хәзер җегерменче вик, дие дә тора, имансыз.

— Вик дигәне нәмәкәй микән соң аның? Әллә ниткән политик сүз булмасын.

— Белмәем. Сорарбыз әле. Көчкә кайтарып җибәрдек. Инәсеннән хат килде. Картая-картая котырып беткән икән наше дедушке диеп кайтып әләкләгән.

— Аларны әрләп тә, кыйнап та булмый хәзерге вакытта. Суксаң, хәзер бакырып кәнсәгә чабалар. Закун үзе шулай диеп тора.

— Бабалары шикелле житмеш жыл дөнья көтсәләр ни әйтерләр ие микән? Бабай дүрәк түгел, акыллы — без үзебез дүрәкләр, диеп әйтерләр ие, нибуч.

— Карале, түтәй, шушы атнада Әзербәйҗанга да илле яшь тулган дие. Радио әйтте.

— Кайсы ул тагы?

— Теге... бар бит әле тау халыгы. Нифтене дә бик күп чыгарган жир. Минагратлы як. Кафиянең кызы шуннан бер тартма минаграт жибәргән иде бит. Килгәнче череп беткән — утынлыкларына чыгарып түктеләр...

— Ә-ә-ә, аны әйтәсең икән. Дәүләт булып оешуларына илле жыл булган шул. Шул көнгә хөкүмәт бурычларын да үтәп бетерделәр, дие, укытучы әйтә.

— Тилевизер дә сөйләгән бит.

— Нигә аны тиле диделәр икән соң? Хәтәр акыллы сүзләр сөйләй бит ул.

— Син әле нием әйт, пучтыга кереп тиле грам сугыйм дисәң, анысы тиле. Челтерәтәем дисәң — тиле фуны — тагын анысы да тиле.

— Бала-чага куша инде аны, юри, мыскыл итеп. Үзләрен генә акыллыга чутлап йөриләр.

ай ярым торып кайттым бит. Шунда моның мин барган көнне үк ярты миске сөтле ашы калды. Җылытып бирсә үзем дә ашаган булыр идем, әрәм итмәсием. Ә үзем гәзләрен бора белмәдем, курыктым. Эштән кайтты да шул ярты миске ачымаган-питмәгән менә дигән тәмле ашны туәлит дигән бүлмәләренә керде дә, гөпердәтте дә тишеккә салды. Кызым, дидем, минем бу туәлиткә керергә бүтән йөрәгем җитмәй, моннан бүтән тишегенә дә утырасым юк, дидем, аш өстенә утырсаң, корышып катармын, давай миңа билет ал, килгәндәге шикелле тәкси дигән машина чакырт, минут тормаем, хәзер үк кайтып китәм, дидем. Менә бит, диванакай, гәзне борала бит ул. Җылытып бирсә, үзем ашаган булыр идем. Ә Оркыя көлә, аңа көлке. Инәй, кайгырма, ул токмачлар әллә кайчан Кәмегә агып китте инде, дие. Беләсеңме, түтәй?!.

— Белмәй ни! Безнең киленнәр дә шулай. Әй, ташыйлар мәгәзиннән ситке-ситке, сумкы-сумкы нигъмәт. Калбасасын, балыгын, прәннигин, маен-шикәрен, җимешен, төрле-төрле кәнсирләрен. Аша, әнкәй, дигән булалар. Аша диюләренә рәхмәт инде. Яртысын ашап каламмыюкмы, кич кайталар да калганын барын җыеп, каткан инде болар диеп, тыштагы тартмага чыгаралар да түгәләр. Үзләре тагын ситке тотып мәгәзингә чыгып китәләр. Ә ул калган продуктыга нимә булган? Аны миңа ашарга ярамыймыни? Элек ярты сынык әпекәй күрмәенчә ачка интегеп яткан чаклар да була иде дип сөйләсәң, берсе дә ышанмай, көлә генә. Дөньяда шундый тормыш буламыни, әкият бу, әбекәй, диләр.

— Карале, түтәй, әкият дигәннән, безнең рәките айга менеп кесәсенә ком салып алып төшкән, дие. Син ишеттеңме?

— Ишетмәй ни! Кичәдән бирле бөтен радиу, тиле визер шаулап тора.

— Чыннан да, шул нәрсәкәй дөрес микән?

— Ай ул бер нур гына бит. Анда нindәй ком булсын?

— Рәките ничек менеп җитсен, диең. Ничәмә-ничә млиун чакрым бит ул. Иге-чиге юк бит аның. Әбугалисина әфсенен генә өйрәнмәгән булсалар. Һи-һи-һи...

— Рәкитәсе менсә дә, кайда аның лумы балчык ватарга?! Һә-һә-һә!..

— Лум белән ватып түгел — бораулап алган, диләр, түтәй.

— Бораударга айда нинди борау булсын!.. Һә-һә-һә-һә!

— Балчыгын учлап алсын да ди! Кая ул рәкитәнең кесәсе — балчыгын салырга?! Һи-һи-һи-һи!..

Язалар бит, сөйлиләр! Әкият!.. Һә-һә-һә!..

— Томаналар ышана инде аңа. Бала-чагасы гүпчим ышана. Тач шулай булган икән, дие... Һи-һи-һи!..

Яшь әби белән карт әби, җир йөзендә теләсә нәрсәгә ышанып йөрүче беркатлы кешеләрнең булуына гаҗәпләнеп, үзләренең андый кешеләрдән акыллырак, хәйләкәррәк булуларына куанып, бәрәңге алуларыннан туктап рәхәтләнеп кет-кет көләләр. Болар нигә көлә микән, шуны беләсе иде, дигән шикелле кызыксынып, күзләренә карап торган бабайга да, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә, кычкыра-кычкыра, хәлне төшендереп бирәләр.

— Ә-ә-ә, аны сөйлисез икән. Рәкит айга барып кунып, ай туфрагын алып төште шул, төште, — ди бабай. — Анысы дөрес. Булдырып тора хәзерге халык, булдырып тора-а.

Шулай ди дә, капчыгына өч чиләк бәрәңге салып, кайбер урыннарында көнбагыш төпләренә абынгалап, лапаслар ягына юнәлә.

Әбиләр тагын сүзгә керешәләр:

— Сина әйткән идем микән, Айбикәнең түтәсе килеп китте бит әле, — ди карт әби, буразна арасыннан алабута чүпләштереп. — Мәсүфәсе, Карамалы кулдән.

— Юк әле, түтәй, ишетмәгән идем.

— Шул Мәсүфә беркөн безгә килеп утырды. Сарыкларны яңа гына ябып кереп ашка утырган идек. Нәмәкәй эшләп хәҗәйстуасын бер дә карамай ул Айбикә? дие. Бөтен әйберләре ватык та җимерек, дие. Сәгатьләрен җибәрим дигән идем — сәгатьләре йөремәй, тукмагына трахтыр тимерләре тагып бетергәннәр. Тик утырганчы яулыгымның читен бөгеп алыйм әле дисәм — машиналары текмәй, алганнан бирле май чырае күрмәгән, калтыр да колтыр, энәсе кугәреп беткән. Ятып тораем дисәм — караваты кәкшәннәп беткән, пружинасы янбашыма кереп китте, дие. Убырныйлары уң якка кыйшайган, дер-дер селкенеп авып китәргә генә тора, хәзер басып үтерә бу мине диеп куркып, кергән җиремнән кире чыгып йөгердем, дие. Радиуларын сөйләтәем дип борсам — сөйләмәй, эченә үрмәкүч оялап беткән. Сикереп кенә менеп атланаем да урман буйларыннан бер чаптырып урап кайтаем әле дисәм — лилсәпитләренең тыны чыгып беткән, дие. Менә, җүләр, ишетәсе колакларың булгач...

— Э-э-э, Мәсүфәнеке шикелле умарта гәүдә белән сикереп кенә лисәпиткә менеп атланырсың! Җиде пот бит ул...

— Нишләп дөнья күтәргә тырышмай ул Айбикә? — дие.

— Ничек күтсен! Бар тапканын малае талап алып эчеп баргач.

— Шулай шул. Аның бәләкәй кызы, бабыкай, әбекәй, диеп гел бездә ята. Бөтен нәрсәләрен сөйләп бара. Әтәң кая китте, дисәң, Мөслимгә, дие. Нигә китте, дисәң — эчәргә, дие. Әтәң кайттымы, дисәң — кайтты, дие. Нишләй, дисәң — әбекәй белән талаша, дие. Нәмәкәйгә талаша, дисәң — эчәргә акча сорый, дие.

— Эчкән кешедә өмет юк инде. Убырныең түгел — өең авып төшәр. Безнең авылның да чын леснигы эчә-эчә алькожуликка әйләнде бит. Хәзер бульнискә барып беләгенә укул кадатып йөри.

— Нигә эчмәскә, эчәм шул. Урмандагы агачларның һәр ботагы саен бер бутилкә эленеп тора мица, диеп әйтә диеп сөйләгәннәр ие — шулмы?

— Шул үзе. «Хатыным кеше белән йөргән сыман тоела. Шуны үтерәсем килә», диеп әйтә дие тагын. Ходаем, үзең сакла!.. Чамасын белеп эчәргә кирәк, чамасын. Белеп эчсәң — дару, белмәсәң — агу бит ул дөмеккере нәмәкәй.

— Мин аның пивасын үзем дә эчәм. Кунакка барган саен малайлар акча бирә. Мә, инәй, урамда йөргәндә рәхәтләнеп пива эчеп йөре, курыкма, монда синең белән ашка йөргән ахирәтләрең юк, диләр. Иплэп кенә урамга чыгам да берәр бакал пива эчәм дә кайтам. Килен сизми дә кала. Аларның фатиры парк дигән бакча янында гына. Шуның капка төбендә генә гел пива сатып торалар.

— Булса бик эчәр идек тә, монда кайтармайлар шул пиваны...

— Кичә Мәсәянны эт урынына сүгеп кайттым әле.

— Бәрәч, нигә тагын? Бик акыллы малай диләр бит аны.

— Амбар алдына барсам, яңгыр коя. Амбар ишек алдында тау хәтле тары өелеп ята. Өстенә, ичмасам, салам да капламаганнар. Җырганак белән агып ята. Үзе каравыл өенә кергән дә утырган кладавшик башы белән.

— Нәмә диде соң, син әйткәч?

— Бар, бар! Убирәйсә, кайтып кит! Дилаң булмасын монда, дие. Менә имансыз!

— Алланың каһәре сугасы нәстә икән!

— Тәүфыйксыз! Әллә нәмә күреп үләр әле.

— Эпекәйнең кадерен белмәгән кеше — кешемени ул. Ыштыр бит ул!

— Прсидәтелгә әйтәм әле мин аны. Әләкләде дисә дияр. Ник куркып тораем аннан. Прсидәтел капка төбеннән үткән саен машина-

сыннан төшеп: «Нихәл, бабай, нихәл, әби», — диеп кулын биреп исәнләшмәенчә китмәй. Бик нык әйтәм әле мин аны.

— Бәй, шулай булмай, түтәй. Әйт, бик ныклап әйт... Җизнәй эндәшә түгелме? Ә? Нәмәкәй?

— Бүген көндез чәй эчмәйбезмени? — дие. Хәзер кирәбез. Син кереп самавырны гөжләтә тор. Менә бу буразнаны гына чыгыйк инде. Кирә тор, кирә тор, димен. Самавырны гөжләтә тор. Бар, бар!..

— Җизнәй дә картайган инде. Бакчый, җилкәләре төшкән, билләре бөкерәйгән. Алла гомерен бирсен!

— Картаймый инде. Яшең сиксән бишкә житкәч. Үзе шулай булса да би-ик көчле ул, исәркәем. Җәй көне тагын алты олау печән чапты. Ат сорап аны ташыды. Лапас түбәсенә өйде. Тамагына ашый бит ул. Аның менә гомер буена ашказаным авырта диеп җүри дә әйткәне булмады. Ә менә холыгы үзгәрде, анысы бар. Картайган саен кешенең холыгы әшәкеләнә икән, хикмәт.

— Нирвыдан икән ул, түтәй, карт кешенең нирвысы бетә икән.

— Шулайдыр. Нирвысы бөтенләй юк инде аның хәзер. Син килгәнче генә әле мунча ягып кергәниек. И ләүкәдә утыра жизнәң, и чабына, и чабына. Эссе сал да эссе сал, дие. Янып үләсең бит инде, ходаем, төш тизрәк диеп кычкырам. Төшү исендә дә юк. Бер аягыма эссе үтмәй, нишләп микән, син ныклап чабып карале, дие. Чабаем дип карасам — бер аягының оегын бөтенләй салмаган, үтмәй дә үтмәй диеп сәгать буе шул җен оегын чабып утырган. Аннан көч-хәл белән төште хәзер. Төшкәндә аягы шуып китте дә кайнар су салган бидрәгә утырды. Әллә-лә, үлдем, үлдем, баш бетте, диеп кычкыра. Мин бидрәгә кулымны тыгып торган булам, менә бит гүпче кайнар түгел, менә бит, дигән булам. Аны көчкә коендырдым. Киенә башлады бу хәзер. Син ыштанны тар итеп тегәсең, алла бирса, өч метр ситса алам да Нажиягә илтеп, киң итеп тектерәм, диеп жикеренә башлады. Кил әле, кигерт, дие. Кигертәем диеп барсам, аягына күлмәген киеп утыра. Бер җинен ничек кирәк алай тезенә хәтле кигән, икенче җиңен бөтенләй кия алмый, тарта да тарта. Алланың каһәре суккыры, ыштан балагын тар итеп гомер буена интектердең, дие. Аннан чыкты да, нирвысыннандыр инде, бал белән, лимун белән берүзе бер самавыр чәй эчеп бетерде. Мин эчәлмәй дә калдым.

— Нирвыдан, нирвыдан бу, түтәй. Безнең авылның Мөхетдин нишләде дисең кыш көне? Ул да сугыштан нирвым бетеп кайттым дие бит. Печәнгә барган да, печән төягәндә бер киез катасы аягыннан салынган да чыккан. Оегы да киез катасы эчендә калган. Шәрә үкчәсе белән карга тек-тек басып, чанасы артыннан көлә-көлә кайтып килгән була дие мескенкәй. Үзе шуны сизмәй дие. Киез катасы лапасларында печән бушаткан чакта гына килеп чыккан. Менә бит ул, нирвың бетсә! Нәмәкәйләр кыланмай кеше!..

— Патпискегә язылдыгызмы әле. Пучты кердеме?

— Керде. Килен быел бик күп язылды. Әллә унөч, әллә унбиш таңкәлек.

— Безнең жизнәң быел язылмады бугай әле. Әллә онытып йөри микән, кәлиндәр дә кирәк.

— Әнә, су буеннан бер машина килә. Балалар кайтмай микән?

— Кая? Ә-ә-ә... Юк, бу мәгәзингә тавар китерә торган машина бугай. Индийский чәй дә булса ярар ие... Балалар тиле грамнарында әйткәннәр бит, төштән соңгы самолетка утырабыз дигәннәр. Ә ул сәгать унөчтә генә килә. Кичсез кайтып житмәсләр әле.

— Мескеннәр, ниндәен ерак жирләрдән жыл саен бәрәңге алырга кайткан булалар. Әтәйләр, инәйләр интекмәсен дия торганнардыр инде.

— Шулай диләр. Бәрәңге дә утыртмагыз, мал да асрамагыз, диләр. Күпме кирәк булса да, акча җибәреп торырбыз, диләр. Нинди интегүмени ул! Тән таза булганда әле, аллага шөкер, бәрәңге дә утыртмый, печән дә чапмый, утын да кисмәй ничек ятасың дие! Җизнәңнең аның гомер буена утырып торганы юк.

— Син үзең дә шулай инде, түтәй — тынгысыз. Икегез дә бер төрле.

— Тынгысыз булмасаң, дөнья көтеп булмый бит.

— Әле менә бу бәрәңге соң? Балалар җүри шуның өчен бәрәңге алырга кайтабыз диеп тиле грам суккан. Кайтып керсәләр, шаккатып бот чабарлар инде, кайда бәрәңгегез, диярләр.

— Бәй, аларны көтеп тик утырмакмыни! Хәл кадәренчә кыймылдап тораек диеп кенә тотынган иек тә... Бер башлагач әкренләп кими инде ул эш.

— Кимү генә түгел — хәзер бетә бит инде бөтен бакчагыз. Мондә, күп булса, ындыр табагы хәтле җир калды.

— Әйдә, бик ару булды, аллага шөкер... Аларга бәрәңге алдырып ятарга... Рәхәтләнеп ял итеп, туйганчы йоклап китәрләр.

— И-и-и, шәһәр халыгы тәк тә йоклап кына ята инде ул. Иртән торып сыер савасы, көтү чыгарасы юк. Эшләре дә сминәләп кенә.

— Шулай инде. Су да чыгып аласы юк бит аларның. Тоткасын бордисәң — үзе челтерәп ага... Карале тегене... җизнәңне... тагын баскычка чыгып баскан. Мин каршысында утырмасам, тамагыннан үтми инде аның. Әйдә, хәзер чыгабыз инде бу буразнаны, хәзер керербез.

— Шулай итәрбез, түтәй, җизнәйне зарыктырмаек...

Көз. Көн кояшлы, җылы. Яулыкларын арттан гына бәйләгән ике әби, чулпыларын чылтырата-чылтырата, бәрәңге ала. Алар артыннан, суалчан чүпләп, кызыл кикрикле ак тавыклар ияреп йөри. Бакча башындагы күрән читендә оя-оя каз-үрдәкләр ял итеп утыра. Авылның югары очында тук-тук яңа бура бурыйлар. Амбар алдында келтер-келтер бодай җилгәрәләр. Басу түрендә тракторларның җир сөреп йөргәннәре күренә. Һавада, кыйгак-кыйгак каңгылдашып, торрыйк-торрыйк торкылдашып, киек казлар белән торналар очып бара...

Күкләр тыныч!

Җирләр, илләр тыныч!..

Тыныч җирдә, тыныч илдә ике әби бәрәңге ала...

## Моң сөюче

Берәү музыка кибетенә керә.

— Малаема контрабас алмакчы идем.

— Ә улыгыз ничә яшьтә соң?

— Сигез белән бара.

— Андый яшьтәгеләргә контрабас уйнарга ярамый бит әле. Сез аңа әнә теге кечкенә флейтаны алыгыз.

— Аның флейтасы бар иде инде, ләкин ул аның көпшәсен урталай сындырган.

## Сәбәбен ачыклыйлар

Мәктәптә рәсем укытучысы бер баланың рәсемне гел кара буяулар белән генә ясаганын күрә дә, аны, тикшереп карау өчен, психологка җибәрә. Үзе кирәк тапкан барлык анализларын ясагач, белгеч дигәнебез баладан сорый икән:

— Я, дөресен генә әйтеп бир әле, ни өчен рәсемнәрне бары тик кара төсле итеп кенә ясыйсың?

— Чөнки минем кара буявым гына бар.

## Косметик могҗиза

Бер ханым үзенең танышына әйтә:

— Кигчә җыерчыкларны бетерә торган искиткеч крем турында мин бер журналда белдерү укыдым.

— Беләм, җаным, беләм, минем аны сөртә башлавыма инде тиздән ел тула.

— Кара инде, ник шулай алдалап язалар икән?..

## Танышлар сөйләшә

— Ихлас күңелен белән ин дөресен генә әйт әле: миңа ничә яшь бирергә мөмкин?

— Тукта, бер минут... Чамалыйм әле... Минемчә, йөзеңә карап — егермене, фигураңа карап — унсигезне, прическаңа карап әйткәндә — уналтыны биреп була.

— Булмас, син комплимент әйтәсеңдер.

— Бик була! Хәзер шул өч төрле яшьнең бөтенесен бергә кушарга кирәк.

Тәмуг капкасын бер кеше килеп шакыгач, аны дежурный шайтан каршылый.

— Сез биредә калырга киләсезме?

— Юк, мин бер генә минутка керәм, бары тик миңа бурычларын кайтарырга тиешлеләрне генә күрергә телим.

— Алар биредә икәнен сез каян беләсез соң?

— Чөнки биреп торган әҗәтне кайтарыгыз дигән саен, миңа «иди к черту» дип җавап бирәләр иде.

## Кызганыч

Ире бик соң гына һәм бик яхшы кәефләнеп кайтып керә. Хатын дәшми.

— Ник бернәрсә дә сорашмыйсың әле миннән? — ди ир хатынына.

— Сорашырга да теләмим.

— Кызганыч! Ә мин бүген акланыр өчен шундый әйбәт сәбәп уйлап тапкан идем.

## Төшке аш

Эштән бик ачыгып кайткан ир бик ачулы тавыш белән хатынына әйтә:

— Ашың тагын әзер түгел, ә минем эчтә бүреләр улый... Болай булгач, киттем ресторанга.

— Бер биш минут кына көт инде.

— Биш минутта нинди аш өлгертә аласың?

— Юк, өлгертеп тормыйм, менә хәзер бераз киенәм-ясанам да ресторанга бергә китәбез.

## Куркыныч нәрсә

Шоферлар курсында имтихан бара. Имтихан алучы бер укучыдан сорый икән:

— Машинада нинди нәрсә иң куркыныч?

— Кабинада шофер белән янәшә утырып барган ханым яки кыз.

## Штат буенча

Дуамалрак бер начальник үз кул астында эшләүче бер хезмәткәрен акырып-бакырып тирги.

— Тавышыгызны баса төшебрәк кычкыруыгызны үтенер идем мин сездән,— ди икән хезмәткәр.

— Нишләп алай дисең әле син?

— Чөнки мин бит сездә ярты штат кешесе булып кына эшлим һәм ярты хезмәт хакы гына алам.

## Кичке мәҗлес

Дүртенче катта торучы берәү баскычтан төшеп барганда үзенең күршесен — өченче катта нәкъ аның фатиры астында торучы кешене очрата.

— Кичә миндә бәләкәй генә кичке мәҗлес булды... Кавалерия полкында бергә хезмәт иткән дүрт танышымны кунакка чакырган идем. Сезгә тыныч йокларга комачау итмәгәндербез бит?

— Юк, юк, күрше! Ләкин шунысын гына әйтмәссезме: дүртенче катка ничек итеп атлар менгерә алдыгыз сез?

## Арзан бәягә

— Минем кызымның җырга өйрәнүе бик ярап куйды әле.

— Нәрсәсе белән?

— Ике күршем дә, йортларын миңа бик арзан бәягә сатып, бүтән урамга күчтеләр.

## Соңга калмый

Поездга соңгаручы бер дачник станциягә күрше йортның ишек алдыннан үтеп барырга тели: әйләнеч түгел, юл кыскара. Шуның өчен йорт хуҗасыннан рөхсәт сорый:

— Зинһар, шулай узыйм инде, 8 сәгать тә 10 минутта китәсе поездга өлгерәсем бар.

— Узыгыз, уз, рәхим итеп. Анда минем үгезем очраса, сез әле 7 сәгать тә 40 минуттагы поездга да утыра алырсыз.

## Зоомагазинда

— Әнә теге сиам мәчесе күпме тора? — дип сорый бер әби.

— Йөз злотых.

— Үткән атнада бит сез аның бәясен икеләтә ким итеп әйткән идегез!

— Әйе, әйткәнмендер, ләкин бит шуннан соң ул мәче егерме бишәр злотыхка сатыла торган ике тутый кошны тотып ашады.

## ТУКАЙ КӨННӘРЕ

Шушы елның 26 апрелендә бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 85 ел тулу уңае белән республикабыз районнарында һәм шәһәрләрендә шигырь бәйрәмнәре үткәрелде. Инде моннан дистә еллар элек традициягә кергән бу зур бәйрәм быел аеруча тантаналы төс алды.

Бәйрәм язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында башланды. Монда шагыйрьләр үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, Тукайга булган олы ихтирамнарын белдереп, үз иҗатларына Тукай шигъриятенең тәэсире турында сөйләделәр.

*
* *

24 апрельдә бер төркем әдипләр шагыйрь үзенең балалык елларын үткәргән авылда — Кырлайда булдылар. Кунакларны Г. Тукай исемендәге урта мәктәп укучылары һәм укытучылары каршы алды.

Очрашуда өлкән шагыйрьләрдән Тукай премиясе лауреаты Хәсән Туфан катнашты. Шагыйрьләрдән Марс Шабаев, Самат Шакир, Рәшит Гәрәй, Ренат Харисов, Фаил Шәфигуллин, Разил Вәлиев һәм прозаик Газиз Мөхәммәтшин чыгышларын укучылар яратып тыңладылар.

Әдипләр бу көнне Кырлайда әле янарак кына ачылган Г. Тукай музеен карадылар. Фикер дәфтәренә музейда алган тәэсирләр язып калдырдылар.

*
* *

Бу көнне Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасының ике ягына урнаштырылган ике бөек шагыйрь — Пушкин һәм Тукай скульптуралары да чәчәкләр белән бизәлде.

Бәйрәм Кабан күле буенда Тукай һәйкәле янында дәвам итте. Һәйкәл тирәсе чәчәкләргә, гөлләргә күмелде. Мәскәү шагыйрьләре Михаил Львов, Вадим Кузнецов, Василий Шабанов, Уфадан килгән шагыйрь Әнгам Атнабаев Тукайны олылау, хөрмәтләү сүзләре әйттеләр, яңа шигырьләрен укыдылар. Бәйрәм тантанасында татар шагыйрьләреннән Х. Туфан, С. Хәким, М. Садри, З. Нури, Р. Харисов, Г. Рәхим һәм башкалар катнашты. Татар дәүләт академия театры артистлары М. Җәлил, Г. Тукай, Ф. Кәрим шигырьләрен укыдылар.

*
* *

Шул ук көнне кичен 4 нче номерлы балалар китапханәсендә А. М. Горький музее хезмәткәрләре инициативасы белән оештырылган Г. Тукай экспозициясен ачу тантанасы булды. Монда әдипнең замандашы, фикердәше, ТАССРның халык артисты Касыйм Шамил Тукай турында кызыклы истәлекләр сөйләде. Профессор М. Гайнуллин Г. Тукай иҗатына кагылышлы яңа мәсьәләләргә тукталды. Аннары шагыйрә Г. Зәйнашева шигырь кичәсен ачып җибәрде. Кичәдә яшь шагыйрьләр Зөлфәт, Рәшит Әхмәтҗанов, Т. Камалиев, М. Зарецкий, Разил Вәлиев, Ф. Шәфигуллин, Ф. Сафин үзләренең яңа әсәрләре белән катнаштылар. Уфа кунагы, яшь артистка И. Газетдинова Тукай шигырьләрен укыды.

*
* *

Әлмәт шәһәрендә дә Тукай көннәре тантаналы шартларда зур оешканлык белән узды. «Татарстан» кинотеатры каршындагы Г. Тукай бюсты янына шәһәрнең хезмәт ияләре, мәктәп укучылары җыелды.

Бәйрәмне партиянең шәһәр комитеты секретаре С. Хәкимова ачып җибәрде. Тукай иҗаты хакында Татарстан язучылар союзы Әлмәт бүлегенең җаваплы секретаре Р. Фәйзуллин сөйләде. Шагыйрә С. Сөләйманова үзенең яңа әсәрләрен укыды. Артистлар һәм мәктәп укучылары җыелган халыкны Тукай шигырьләре белән таныштырдылар. Кичен клубларда һәм культура сарайларында әдәби кичәләр уздырылды.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Казан шәһәренең 55 нче мәктәп укучылары һәм укытучылары Ташкенттан килгән журналист Исхак Зәбиров белән очраштылар.

Кичә мәктәпнең Абдулла Алиш музей-бүлмәсендә үткәрелде. Исхак Зәбиров Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре турында үзе эзләп тапкан яңа материаллар белән таныштырды, күп фоторәсемнәр, документлар күрсәтте. Аның Муса Җәлил һәм Гайнан Курмаш шигырьләрен укуын да укучылар бик яратып тыңладылар.

*
* *

Шушы елның апрель аенда Казанның беренче тегү фабрикасы китап сөючеләре язучы Н. Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» һәм «Җимерелгән бастион» әсәрләре буенча конференция уздырдылар. Конференциядә катнашкан автор укучыларның сорауларына җаваплар бирде, әсәрләренең язылу тарихын сөйләде.

Язучы Г. Ахунов Казан киез итек фабрикасы эшчеләре белән очрашты. Әдип эшчеләрне үзенең иҗат планнары, язылачак әсәрләре белән таныштырды.

* * *

Казанның 4 нче тегү фабрикасында язучы Р. Мостафин һәм шагыйрь М. Хөсәен эшчеләргә бүгенге татар әдәбияты турында сөйләделәр. Шул ук фабрикада партиянең XXIV съезды тәмамлану уңае белән «Әдәбиятта эшче образы» дигән темага зур сөйләшү үткәрелде. Очрашуда Г. Паушкин, З. Нури, Р. Мостафин, М. Маликова, М. Зарецкий катнашты. Бу очрашу телевидениедән дә күрсәтелде.

* * *

Язучылар Г. Ахунов, А. Расих, Г. Бакир, Р. Мостафин Казанның Киров районында ачылган хезмәт даны музее экспонатлары белән таныштылар. Музей хезмәткәрләре һәм музей карарга килгән халык алдында чыгыш ясадылар.

* * *

Республика китапханәсенең зур уку залында күренекле язучы Гомәр Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» исемле әсәре буенча укучылар конференциясе уздырылды. Кичәдә автор үзе, фольклорчы галим Хәмит Ярми, язучы Газиз Мөхәммәтшин катнашты.

Укучылар Гомәр Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» әсәрендә татар халкының гореф-гадәтләрен, йолаларын әйбәт чагылдыруын, бу әсәрнең татар халкы тормышын өйрәнүчеләр өчен кыйммәтле чыганак, энциклопедия булып тора алырлык кыйммәте барлыгын әйттеләр.

Хәмит ага Ярминең чыгышы Гомәр Бәшировның иҗатын тагын да киңрәк аңларга ярдәм итте. Кичәнең ахырында Гомәр ага Бәширов укучылар сорауларына җаваплар бирде, әсәрнең ничек язылуы турында сөйләде.

* * *

Май аенда Казанның Воровский исемендәге культура сараенда язучылар Н. Дәүли, З. Нури, Г. Паушкин, М. Хөсәен катнашында «Хәрби-патриотик әдәбият» дигән темага зур сөйләшү булды. Әдипләр очрашуга җыелган халыкны патриотик әдәбият өлкәсендә эшләүче язучылар һәм аларның китаплары белән таныштырдылар. Үзләре дә Бөек Ватан сугышы ветераннары буларак, патриотик темага язылган яңа әсәрләре, киләчәккә иҗат планнары турында сөйләделәр.

* * *

Яз башында башкорт әдипләре: Сәләм премиясе лауреаты Равил Бикбаев һәм Шакир Җанбаевлар Казанга килеп әдәбият сөючеләр белән очрашулар үткәрделәр. Кунакларның Казанның культура сарайларында, мәктәпләрдә, Минзәлә районы



## МӘКТӘП МУЗЕЕ

Әле күптән түгел генә Пермь шәһәренең 70 нче урта мәктәбендә Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты, шагыйрь-патриот Муса Җәлил музее ачылды.

Бирелә шагыйрьнең тормышын һәм иҗатын чагылдыручы экспонатлар, уникаль фоторәсемнәр, хатлар, истәлекләр байтак җыелды. Шулар арасында Андре Тиммерманс хаты, Леон Небенцаль истәлекләре аеруча игътибарга лаеклы.

## ГАФУР КОЛӘХМЕТОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Шушы елның май аенда татар пролетар әдәбиятына нигез салучы әдип-революционер Г. Коләхметовның тууына 90 ел тулды. Шул уңай белән СССР Фәннәр академиясенең Казан институтлары конференцзалында фәнни конференция уздырылды. Конференцияне кереш сүз белән профессор М. Мөхәррәмов ачты. «Г. Коләхметов — татар пролетар әдәбиятына нигез салучы» дигән темага докладны өлкән фәнни хезмәткәр Б. Гыйззәт ясады. «Г. Коләхметов һәм татар революцион публицистикасы» дигән темага профессор М. Гайнуллин, революционер язучының социаль-экономик һәм иҗтимагый политик карашлары хакында доцент Ф. Газизуллин чыгыш ясады. Өлкән фәнни хезмәткәр С. Алишев исә үзенең докладында «Г. Коләхметов — тарихчы» дигән теманы яктыртты.

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры бинасында революционер, тарихчы, ялкынлы пропагандист, публицист Г. Коләхметовның юбилеена багышланган тантаналы кичә үткәрелде. Кичәдә филология фәннәре кандидаты Б. Гыйззәт доклад ясады.

Кичәнең тантаналы өлешеннән соң Татарстан сәнгать осталары тарафыннан зур концерт күрсәтелде.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Әлмәттә язучылар союзының тәнкыйть секциясе һәм Әлмәт бүлеге язучыларының берләштерелгән утырышы булды. Бу утырышта Алабуга педагогия институты проректоры вазифаларын башкаручы, тәнкыйтьче Тәлгать Галиуллинның иҗаты тикшерелде. Чыгыш ясаучы С. Хәким, Ю. Әминов, Э. Касыймов, С. Сөләйманова, Р. Фәйзуллин, Г. Афзал, Ә. Маликов, М. Мәһдиев, Ф. Миңнуллин, Р. Төхфәтуллин һәм башкалар тәнкыйть өлкәсендә сизелерлек өлеше барлыгын әйттеләр. Тәнкыйтьчегә күп кенә киңәшләр дә бирелде.

* * *

Әлмәт язучыларыннан Р. Фәйзуллин, Г. Афзал, Ә. Маликов, Р. Төхфәтуллин,

Казан кунакларыннан С. Хәким, М. Мәһдиев, Ф. Миннуллин иптәшләр нефть районнары мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән очраштылар. Йөздән артык укытучы катнашкан бу очрашуда әдипләр үзләренең яңа әсәрләреннән өзекләр укыдылар, әдәби процесска кагылышлы сорауларга җаваплар бирделәр.

* * *

Шагыйрь С. Хәким, филология фәннәре кандидаты, язучы М. Мәһдиев, Г. Афзал, С. Сөләйманова, Р. Фәйзуллин, Ю. Әминов, «Казан утлары» журналының тәнкыйть бүлеге мөдире Ф. Миңнуллин иптәшләр Бөгелмә шәһәрендә булды. Алар шәһәр белән таныштылар, КПСС райкомы җитәкчеләре белән әңгәмәдә катнаштылар. Соңыннан әдәбият сөючеләр белән очрашулар булды.

* * *

Баулы районының Урыссу поселогында киномеханик булып эшләүче З. Хәкимовның әсәрләре буенча индивидуаль семинар үткәрелде. Р. Төхфәтуллин, Р. Фәйзуллиннар катнашында үткән бу тикшерүдә яшь авторның уннан артык хикәясе тикшерелде. Аның «Уелып калган эзләр», «Җирдәге тумгак» исемле хикәяләре матбугатка тәкъдим итәрлек дип табылды.

## ИЛҺАМ ЧЫГАНАГЫ

Татарстан нефтьчеләре, Ватаныбыз нефть промышленносте тарихында беренче тапкыр буларак, 1970 елда елына 100 миллион тонна нефть чыгаруга ирештеләр. 14 майда Татарстан нефтьчеләре тарафыннан миллиардынчы тонна нефть чыгарылды. Бу истәлекле көнгә багышлап Әлмәт шәһәрендә тантаналы җыелыш үткәрелде. Җыелышны Ленин орденлы «Татнефть» берләшмәсе начальнигы, Социалистик Хезмәт Герое, КПССның XXIV съезды делегаты А. В. Вәлиханов ачты. КПССның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Ф. А. Табеев көчле алкышлар астында КПССның Татарстан өлкә комитетының, ТАССР Верховный Советының һәм ТАССР Министрлар Советының нефть крае эшчеләренә, инженер-техникларына, хезмәткәрләренә җибәрелгән котлавын укыды. СССР нефть промышленносте министры В. Д. Шашин, СССР Министрлар Советы председателе урынбасары, СССР Госпланы председателе Н. К. Байбаков чыгышлары зур игътибар белән тыңланды. Җыелышта Татарстан язучылары Г. Бәширов һәм Х. Туфан катнашты. Хәсән Туфан Татарстан язучылары исеменнән чыгыш ясады.

## ДУСЛАРЫБЫЗ СЪЕЗДЛАРЫНДА

Шушы елның апрель, май, июнь айларында берничә союздаш һәм автономияле республикаларда язучылар съездлары үткәрелде.

Мордва язучыларының VIII съездында (Саранск) Татарстан язучылары исеменнән тәбрикләү сүзе белән Хәсән Сарьян чыкты. Соңыннан ул Татар Юкәсе мәктәбе укучылары белән очрашу үткәрде. 1918 елны бу авыл янәтына революционер язучы Гафур Коләхметов күмелгән булган. Х. Сарьян, укучылар белән берлектә, әдипнең каберенә чәчәкләр куйды.

Латвия язучыларының VI съездына (Рига) татар язучысы Г. Минский катнашты. Идел буенда акгвардиячеләргә каршы көрәшеп һәлак булган Ян Юдин кебек легендар латыш геройларына ихтирам йөзеннән, татар язучысы алып килгән Татарстан икмәген латыш дуслар веручә җылы кабул иттеләр.

Төркмән язучылары (Ашхабад) съездына драматург А. Гыйләҗев барды. Ул съездга Татарстан язучыларының котлавын тапшырды, төркмән дусларга истәлекле бүләкләр калдырды.

Белоруссия язучыларының VI съездына (Минск) татар язучысы Н. Дәүли барды. Ул съездга Татарстан китап нәшрияты тарафыннан даими рәвештә чыгарылып килә торган «Дуслык букеты»ның бер матур чәчәген — белорус шагыйрьләре җыентыгын бүләк итте. Съездан соң Н. Дәүли Борисов шәһәренә барды. Бу шәһәрдә сугыш елларында фашистлар концлагере урнашкан булган. Язучының «Яшәү белән үлем арасында» дип исемләнгән әсәрендәге вакыйгалар нәкъ менә шул шәһәрдә, шул концлагерьда бара. Үн меңнән артык әсир күмелгән туганнар каберенә хәзер гигант монумент куелган. Н. Дәүли Татарстан язучылары исеменнән шул туганнар каберенә венок куйды.

Чувашстан АССР язучыларының X съездында РСФСР язучылар союзы җитәкчесе С. Михалков, «Правда» газетасы хәбәрчесе Л. Кудреватых, Башкортстан халык шагыйре М. Кәрим, Ленинградтан шагыйрь һәм тәрҗемәче Л. Хаустов һәм башкалар катнашты. Татар язучыларыннан бу съездга вәкил булып Л. Ихсанова барды. Ул чуваш әдипләрен татар язучылары исеменнән котлады, аларга бүләкләр тапшырды. Съезд көннәрендә кунаклар эшчеләр, колхозчылар, укучылар алдында чыгышлар ясадылар.

## КӨН ТӘРТИБЕНДӘ — ТУГАН ТЕЛ

Казанның Пионерлар сараенда 12—14 майда «Белем бирү эчтәлегенең үзгәрүе уңае белән татар мәктәпләрендә туган телне һәм әдәбиятны, рус телен һәм әдәбиятын укыту методикасының актуаль мәсьәләләре» дигән темага багышланган фәнни-практик конференция эшләде. ТАССР һәм РСФСР Мәгариф министрлыкларының милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институты оештырган бу конференция эшендә биш йөзгә якын кеше катнашты. Конференциягә дүрт союздаш, җиде автономияле республикадан, татар мәктәпләре бул-

гән тагын алты өлкәдән кунаклар килгән иде.

Пленар утырышта СССР педагогия фәннәре академиясе член-корреспонденты, ТАССР Мәгариф министры М. И. Мәхмүтов, РСФСР Мәгариф Министрлыгының милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институты директоры, тарих фәннәре кандидаты Р. Қ. Черников, СССР педагогия фәннәре академиясе милли мәктәпләр институтының сектор мөдире, педагогия фәннәре докторы Н. З. Бакеева, КГПИ ректоры, филология фәннәре докторы М. З. Зәкиев, РСФСР Мәгариф Министрлыгы милли мәктәпләр институтының сектор мөдире, педагогия фәннәре докторы, профессор А. Ф. Бойцова, СССР педагогия фәннәре академиясе, милли мәктәпләр институтының Татарстан филиалы мөдире, педагогия фәннәре кандидаты Г. А. Жданова иптәшләр доклад белән чыктылар.

Конференциядә язучылардан М. Әмир, Г. Әпсәләмов, Ф. Хөсни, Н. Дәүли, З. Нури, профессор И. Нуруллин, Р. Гатауллин, яшь шагыйрь Р. Вәлиев катнаштылар. Алар татар теле һәм әдәбияты укучыларына үзләренең иҗат планнарын сөйләделәр. Соңыннан матур әдәбиятны бергәләп пропагандалауның чаралары буенча конкрет фикер алышулар булды. Шул ук темага фикерләр һәм тәкъдимнәр әйтеп Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе, шагыйрь З. Нури чыкты.

## КЫЗЫКЛЫ СӘЯХӘТ

Май урталарында үзбәк журналисты Ташмәмәт Рузибаев Ташкенттан Казанга җәяүләп килеп җитте. Сәяхәтнең максаты — күп милләтле совет халкының тормышын өйрәнү. Сәяхәтнең маршруты 17 мең километрга исәпләнгән һәм илебезнең барлык союздаш республикалары аша уза. Т. Рузибаев «Совет Үзбәкстаны»нда бергә эшләүче иптәшләре, семьясы белән ел ярым элек саубуллашкан иде. Өенә ул бары тик 1972 елның ахырына гына кайтып житәчәк. Ару-талу белмәс бу сәяхәтче Алма-Атада яшәүче казакъ шагыйре М. Алимбаев һәм Башкортстан әдибе М. Кәримнең өлкән шагыйребез Хәсән Туфанга адресланган китапларын алып килде. Казан җәмәгатьчелеге белән очрашулар вакытында Т. Рузибаев үзе җәяүләп узган җирләр турында сөйләде, сорауларга җаваплар бирде. Республикабыз язучылары һәм журналистлары аңа хәерле юл теләделәр, Татарстан һәм аның кешеләре турында китаплар бүләк иттеләр.

Сәяхәтче берничә көн Казанда кунак булганнан соң Чабаксарга китте. Аннан ул Горький, Ярославль, Мәскәү һәм башка шәһәрләр аша Балтик буе республикаларына юл тотачак.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Татарстан язучылар союзы партия оешмасының ачык партия җыелышында КПССның XXIV съезд йомгаклары һәм язучылар алдында торган бурычлар турында доклад белән КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев чыкты. Доклад буенча фикер алышуларда язучылардан Б. Камалов, Г. Мөхәммәтшин, Ә. Еники, Ф. Хөсни, Н. Дәүли, Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе З. Нури, Татарстан язучылар союзының партия оешмасы секретаре, «Азат хатын» журналы редакторы А. Хәсәнова, С. Радзиевская, Р. Фәйзуллин иптәшләр катнаштылар. Алар үзләренең чыгышларында иҗат сешмалары алдына съезд куйган яңа бурычларга тукталдылар, партия билгеләгән планнарны тормышка ашыруда барлык язучыларның да көчләрен аямыйча эшләячәкләрен белдерделәр.

Җыелыш XXIV съезд карарларын бертавыштан яклады һәм аларны пропагандалауны һәр язучының төп бурычы итеп куйды.

## «ГАБДУЛЛА ТУКАЙ» ТЕПЛОХОДЫН КАРШЫЛАУ

Бер төркем язучылар Казан елга портына татар әдәбияты классигы Г. Тукай исемен йөртүче теплоходны каршыларга бардылар. Теплоход экипажы һәм теплоходтагы пассажирлар белән очрашуны шагыйрь З. Нури ачып җибәрде. Ул теплоход экипажына Тукай һәм башка күренекле татар язучыларының китапларын бүләк итте, экипаж членнарына тугызынчы бишьеллык планнарын уңышлы үтәүләрен теләде. Очрашуда язучылардан С. Сабиров, Ю. Белостоцкий, Ш. Рәкыйпов, Г. Зәйнашева, Р. Гатауллин һәм башкалар катнашты. Н. Дәүли үзенең «Габдулла Тукай» теплоходына багышлап язган шигырьләрен укыды.

«Габдулла Тукай» теплоходының капитаны В. Блохин туганнарча җылы каршылаулары өчен язучыларга рәхмәт белдерде, теплоход экипажының, коммунистик хезмәт экипажы буларак, бөек шагыйрь Г. Тукай исеменә беркайчан да тап төшермәячәген әйтте.

## ӘДӘБИ КОНСУЛЬТАЦИЯ БҮЛЕГЕНДӘ

Автозаводчылар өчен чыгарыла торган күп тиражлы газета каршында оешкан әдәби-иҗат берләшмәсе күп кенә яшь каләмнәрне берләштерә. Соңгы утырышта балта остасы Рафис Хисамиев, измә-бетон заводы эшчесе Сәлимә Шәрипова, механизатор Франц Галин, тәзүче Әлфия Зәйнетдинова һәм башкаларның яңа әсәрләре тикшерелде. ТАССР язучылар союзы консультанты Илдар Юзеев, шагыйрь Шәүкәт Галиев, берләшмә житәкчесе Мәхмүт Газизов, төзелеш газетасының редакторы урынбасары Равил Вәлиев, үзешчән композитор Хәмит Булатов h. б. яшь язучыларның иҗатларын тикшерүдә катнаштылар. Яхшы дип табылган әсәрләр «Идел» альманахына тәкъдим ителде.

* * *

Буа районыннан яшь шагыйрә Динә Камалетдинова консультация бүлегенә чакырылып, индивидуаль семинар үткәрелде. Семинар эшендә шагыйрьләр Әхмәт Юныс, Гөлшат Зәйнашева, Гәрәй Рәхим катнаштылар.

# *Хөрмәтле иптәшләр!*

Шушы елның сентябрь аеннан «Казан утлары» журналына 1972 ел өчен подписка кабул итү башланачак.

Соңгы атналарда редакциягә килгән хат авторларының күбесе киләсе елда «Казан утлары»нда нинди яңа әсәрләр басылачак, дип сорап язалар. Башка еллардагы кебек үк, 1972 елда да журналда татар язучыларының иң яхшы яңа романнары, повестьлары, хикәяләре, поэмалары, шигырьләре, драма әсәрләре, очерклары һәм публицистик мәкаләләре бастырылып барачак. Замандашларыбызның эшен, тормышын, уй-хисләрен чагылдырган әсәрләргә аеруча зур урын бирелә. Редакция әдәби тәнкыйтькә, яңа чыккан китапларга рецензияләргә, әдәбият тарихына, культура тормышына, театрга, музыкабызга кагылышлы материалларга шулай ук киң мәйдан бирүне күздә тота. Язучыларыбызның иҗат портретларын, танылган артистларыбыз, композиторларыбыз, художникларыбыз иҗатын яктырткан материаллар да һәр сан саен диярлек дөнья күреп барачак.

Прозаикларыбыздан Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов, М. Әмир, А. Гыйләҗев, Ә. Еники, Л. Ихсанова, М. Хәбибуллиннар хәзер яңа роман һәм повестьлар язалар һәм әсәрләрен шушы ел ахырында редакциягә тапшырырга вәгъдә итәләр. Шагыйрь Ф. Яруллин да «Җилкәнне җилләр екмач» исемле яңа повесть язды. Аның ул әсәре шулай ук 1972 елда басылырга әзерләнә.

Поэзия әсәрләре дә 1972 елда бик мул булачак. Шагыйрьләребездән Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арсланов, Г. Афзал, З. Нури, Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин, Г. Рәхим, Р. Гатауллин, Зөлфәт һәм башкалар үзләренең яңа әсәрләрен журнал редакциясенә тапшырдылар инде.

Редакциягә килгән хатлардан күренгәнчә, кайбер иптәшләр журналга вакытында язылырга онытып җибәрәләр дә аны ел башыннан ала алмыйлар һәм беренче саннарда басыла башлаган зур күләмле әсәрләрне тулысынча укудан мәхрүм калалар, аннары, ярдәм сорап, редакциягә мөраҗәгать итәләр. Әмма андый хәлдә без аларга ярдәм итә алмыйбыз, чөнки **подписка кабул итү белән редакция түгел**, бәлки «**Союзпечать**» **һәм элемтә бүлекләре шөгыльләнә**.

Менә шундый уңайсыз хәлдә калмас өчен, без сездән, кадерле укучыларыбыз, «Казан утлары»на газета-журналларга подписка кабул итү башланган көннәрдә үк язылып куюыгызны үтенәбез.


«**Казан утлары»на СССРдагы теләсә кайсы элемтә бүлегендә язылырга мөмкин.** Журнал Бөтенсоюз газета-журналлар каталогына **7 3 2 1 0** номерлы индекс белән теркәлгән.

Язылу бәясе: бер елга — 6 сум,
бер саны — 50 тиен.

# ЮЛЛАРЫМ

ӘДИП МАЛИКОВ сүзләре

ӘНВӘР БАКИРОВ музыкасы






Яратам матур яз аен,
Һавада тургай сайравын.
Кырларга чыксам,
шатлыгым арта,—
Илтегез еракка,
юлларым, юлларым.

Яратам яңа көн туганын,
Илемнең агым суларын.
Күңелем кош сыман
очардай була,—
Илтегез еракка,
юлларым, юлларым!

Яратам хисларнең кайнарын,
Дусларның тугры булганын.
Авыр юл җиңел,
чын дустың булса,—
Илтегез еракка,
юлларым, юлларым!

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210